# Казан утлары

6
ИЮНЬ-1973

## *КПСС өлкә комитетында һәм Татарстан АССР Министрлар Советында*

# 1973 ЕЛ ӨЧЕН ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ РЕСПУБЛИКА ПРЕМИЯЛӘРЕН БИРҮ ТУРЫНДА

КПСС өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан АССР Министрлар Советы, Габдулла Тукай исемендәге республика премияләре комитеты тәкъдимен караганнан соң, 1973 ел өчен Габдулла Тукай исемендәге республика премияләрен түбәндәге иптәшләргә бирү турында карар чыгардылар:

ӘДӘБИЯТ ӨЛКӘСЕНДӘ

Язучы **ГАРИФ АХУНҖАН** улы **АХУНОВКА** — «Чикләвек төше» повесте һәм «Хәзинә» романы өчен.

ТЕАТР СӘНГАТЕ ӨЛКӘСЕНДӘ

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе композитор **ӘНВӘР ЗАКИР** улы **БАКИРОВКА**; РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, либретто авторы һәм постановщик **ИГОРЬ ВАЛЕНТИНОВИЧ СМИРНОВКА**; РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе художник **БОРИС ГЕОРГИЕВИЧ КНОБЛОККА**; РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе дирижер **ХӘСБИ ВӘЛИУЛЛА** улы **ФАЗЛУЛЛИНГА**; РСФСРның атказанган артисты балет солисты **РЕВДАР ФӘИЗ** улы **САДЫЙКОВКА** М. Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында куелган «Су анасы» балеты өчен.



Г. А. АХУНОВ



Ә. З. БАКИРОВ



И. В. СМИРНОВ



Б. Г. КНОБЛОК



Х. В. ФАЗЛУЛЛИН



Р. Ф. САДЫЙКОВ

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**6**

ИЮНЬ
1973

## Бу санда

Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Күк күкрәр. Роман . . . . . 3
Ф. ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА. Иртәнге җырлар. Шигырьләр 63
М. ГАЛИЕВ. Ана. Хикәя . . . . . . . . . . 69
Р. ГӘРӘЙ. Алтын тотып түгел... Шигырьләр . . 72
Г. ЗӘЙНАШЕВА. Әкият илендә. Шигырь . . . . 74
Н. ИЗМАЙЛОВА. Билгесезлек. Шигырьләр . . . 75
Л. ШАКИРҖАНОВА. Чигү чигәм. Шигырьләр . . 76
С. СӨЛӘЙМАНОВА. Шаһинә. Хикәя . . . . . 78

ДУСЛАР ҖЫРЫ

Г. РАМАЗАНОВ. Лирик дәфтәрдән. Шигырьләр . 84
М. ГАЛИ. Үземә кайтып барам. Шигырьләр . . . 88
А. ИГЕБАЕВ. Сөенечем дә, көенечем дә. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . 91

ОЧЕРКЛАР

Ф. ВИДРАШКУ. Вахта . . . . . . . . . . . 94
Җ. КӘЛИМУЛЛИН. Япь-яшь кенә булса да . . . 112

СӘНГАТЬ

М. ШИҺАПОВ, Ә. РӘШИТОВ. Тәгәрмәчләрнең таныш җыры . . . . . . . . . . . . . . 118
В. ОСТРОУМОВ. XVIII—XIX гасырларда Казан татар корылмалары архитектурасы . . . . . . . 123

ӘДӘБИЯТ БЕЛЕМЕ

Ф. ХАТИПОВ. Прозабыздагы психологизм турында 129

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Р. ӘХМӘТҖАНОВ. Заман утлары . . . . . . . 137
Ф. МУСИН. Югары сәнгатьлелек өчен . . . . . 149

КПССның
ТАТАРСТАН
өлкә
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. УРМАНЧИЕВ. Җырласаң җыр . . . . . . 159

ИСТӘЛЕКЛӘР, ОЧРАШУЛАР

Г. ИДЕЛЛЕ. Беренче зур сәяхәт . . . . . . . 165

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

В. СКВОРЦОВ. Н. Э. Бауман . . . . . . . . . 180

«ЧАЯН» БҮЛЕГЕ

Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Кычыткан чыпчыгы. Хикәя . 182
И. ТУКТАР. Җөмләләр . . . . . . . . . . . 184
В. БУЛАТОВ. Җөмләләр . . . . . . . . . . . 185

БАЛАЛАРГА УКЫГЫЗ

Х. ХАЛИКОВ. Конструктор мин. Шигырьләр . . 186

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*
Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар. Баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.

Баш редактор: **Гариф Ахунов**

Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәукәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Рәфыйк Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова, К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 7/III-1973 ел. Басарга кул куелды 27/IV-1973 ел. ПФ 07055.
Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 85246 экз.
Заказ Я-131. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советының нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең К. Якуб исемендәге матбугат комбинаты. Казан, Бауман урамы, 19. 1973 ел.

Габдрахман Әпсәләмов

# КҮК КҮКРӘР

РОМАН

## 29



Көннәр, атналар, айлар бер-бер артлы мәңгелеккә чумалар. Кешеләр көндәлек ыгы-зыгы, уй-мәшәкать арасында вакытның үтеп китүен сизмиләр дә. Бер мизгел аңга килеп, ул көннәрне кире кайтарып алырга теләсәләр, булмый, вакыт, агым су кебек, бары тик бер якка — киләчәккә таба ага. Ә киләчәк томан эчендә барлыкка килсә дә, кайдадыр еракта аз-аз гына таң беленә, кешеләр шул беленер-беленмәс яктылыкка карап, ышанычлырак атлыйлар, кара урманнар артында авыр, газаплы юлның ахыры бар кебек, аннары дөнья үзгәрер шикелле. Ул бәхетле чакларга ерак калмаган, хәтта бер кеше гомерендә барып җитәргә мөмкин... Әгәр белсәләр, берәүләр моны могҗиза, икенчеләр тарихның үзгәрешсез юлы диярләр иде. Әмма ул чакта моны кем генә өздереп әйтә алган!

Кинәт бөтен Россияне дер селкетеп коточкыч хәбәр яңгырады: имеш, бер төркем студентлар тагын патша хәзрәтләренең үзенә кул күтәргәннәр. Беренче көннәрдә чынын беркем белмәде, бары тик имеш-мимешләр генә, берсеннән-берсе яман, куркынычлы, дәһшәтле имеш-мимешләр генә айкалды. Күңелләреннән патша хәзрәтләренә мең кат турылыклы булырга ант иткән сәүдәгәрләр, обыватель-мещаннар арасында бу көтелмәгән хәл чын-чыннан аптыраш һәм тетрәү тудырды.

Исмәт бер кадәр арулана башлаган иде, бер көнне ул кибетеннән акны-караны күрмичә кайтып керде дә:

— Әй, кем бар үдә? Анасы, син кайда? Урамда кыямәт, мәхшәр. Чапанны, чалманы давай, мәчеткә барам, пашта хәзрәтләре рухына коръән чыгарга кирәк. Тиз булыгыз, аңгыра башлар! — дип кычкырды.

Раббани, куркып:

— Ни булды, сиңа әйтәм? — диде.

---

Дәвамы. Башы 4, 5 саннарда.

— Миңа чуртым да булмаган, Питердә йолкыш студеннар патша хәзрәтләренә бомба ташлаганнар. Коточкыч шартлау булган, атә, бөтен урамның асты-өскә килгән, атә.

Раббани лап итеп урындыкка утырды, кулы белән күкрәген умырды, авызы ачылды, күзләре маңгаена сикерде. Ул нидер әйтергә тели, ләкин сүзе аңлашылмый иде.

— Нәрсә каттың, чапан, чалма! — дип, кабат кычкырды Исмәт.— Хөҗҗәт хәзрәт мәчеткә кем беренче килеп җитәр дип күзәтеп тора.

Кинәт аның авызы күбекләнде.

— Патша хәзрәтләренең үзенә кул күтәрәләр бит, явыз маңкалар! Юк, аларны укытырга кирәкми, кулларына сәнәк тоттырырга, абзар чистартсыннар, нибуч, аннары кычкырмаслар! Караучы итеп Хөҗҗәт мулланы куярга, ул, палицайлар кебек, мыек борып гомер уткәрмәс. Ә син нәрсә авызыңны ачып утырасың? Әллә кызганасыңмы шуларны?

Раббани ике кулын селекте.

— То-ты, то-ты. Аларны барысын сыпырганнар инде, тиздән дарга күтәрәчәкләр. Патша ике сөйләми ул, аның кулына бер эләксәң... Араларында бер янарал бар дип сүләделәр,— ат азгыны тайга иярә бит,— анысын да хәбес иткәннәр, ди.

— Янарал башы белән патша хәзрәтләренә кул күтәрәме? Аңламагансыңдыр, атасы, бәлки, малаедыр?

— Чортым беләмени, мин яннарында булмаган,— дип кырт кисте Исмәт.

— Малайларга ышаныч юк хәзер. Әнә синең үз малайларың нишләде...

— Минем малайлар ни, син, чүпрәк баш, белеп сүлә! Миңа дисә ул үн тапкыр карак, йөз тапкыр талаучы, разбойник булсын, патша хәзрәтләренә генә тимәсен. Патша ул... патша ул... Аңардан зур, аңардан мөкатдәс зат юк!

Билгеле, студентлар арасында бернинди генерал булмаган, бары тик бер студентның фамилиясе Генералов икән, ә русчаны ярым-йорты төшенүче Исмәт аны «янарал» ясаган.

Тагын шунысы бар: байлар, түрәләр, руханилар патшаны бертавыштан яклап, студентларны «разбойниклар» дип атасалар, аларның тизрәк дарга асылуын көтсәләр, түбән халык аларга яшерен теләктәшлек күрсәтә, аларның эшләре барып чыкмауга әчтән әрни иде.

— Мескеннәрнең ата-аналарына нинди зур хәсрәт тагы,— диде Айтүтә.

— Ата-ана мондый чакта кайгырмый булмас. Минемчә, аларга хәзер бер генә юаныч бар. Алар үзләре улларын шулай батыр итеп тәрбияләгәннәр. Балага ата-ана күңеленнән батырлык күчмәсә, тәгаен ул батыр була алмый торгандыр,— диде Әбелмәних, уйланып кына.

— Мин ул изге җаннарга бер генә күзем белән булса да карар идем. Безнең кебекләрме икән алар?..

Бик моңлы итеп будильник уйный башлады. Мәрхабә белән Вәли, күзгә-күз карашып, әкрен генә елмайдылар. Инде кич якынлашып килә иде. Вәли кепкасына үрелде. Мәрхабә җиңел ак шарфын иңбашына салды. Алар күл буена чыктылар.

Өйдә бераз бөркүрәк иде, күл буенда җиләс икән. Кеше әллә ни күп күренми. Күләгәләр озынайган. Һава җылы, күк йөзендә бер болыт юк, тик кояш баешында буяулар куера төшкән, бераздан анда бик матур алсу шәфәкъ иңәр. Шул шәфәкъка алдан сөенгәндәй күл буендагы яшел яфраклар әкрен генә шыбырдашып куялар. Ниндидер сер һәм моң бар шикелле. Башны-башка куеп, уйга чумып, күл өстенә карап

торасы килә. Күл дә күл түгел кебек, әйтерсең якты юл сузылып киткән, анда сине ала килгән тройка атлар күренер төсле.

Бу лирик манзара яшь йөрәкләр тибешеннән, бер-берсенең тән жылысын тоюдан туа торгандыр. Югыйсә, алар кичке хозурлыкка чумар өчен чыкмадылар. Хәзер алар ике күзләрен дүрт итеп тирә-якны күзәтергә тиеш. Әнә ак киемле, ак эшләпәле бер ханым белән чуар костюмлы бер ир күренде. Хатынның кулында алсу зонтик, ул аны ачкан, гүя кояш нурларыннан саклана. Ләкин хәзер кояш алай кыздырмый.

Алар су янына туктады. Култыклашканнар, әкрен генә нидер сөйләшәләр, ара-тирә хатын көлеп ала. Бу — Ольга Леонардовна, янындагы ир — Сергей Сергеевич иде. Менә алсу зонтик бөтерелә башлады. Хәзер инде аларның йөзләре күренми иде. Озакламый алар бөтенләй күздән югалдылар.

Бер биш минут та үтмәгәндер, икенче яктан кулына нечкә таяк тоткан, башына түгәрәк сай эшләпә кигән, мыек чылгыйларын көязләтеп өскә таба борып куйган яшь ир күренде.

— Әфәнделәрем,— диде ул, кылана төшеп,— монда көймәләр бармы икән?

— Арырак узыгыз,— диде Вәли әкрен генә.

Ун-унбиш минуттан өстенә таушалып беткән ак костюм кигән, кызгылт йөзе шабыр тиргә баткан, сулышы капкан урта яшьләрдәге юан гына ир күренде.

— Гафу үтенәм, яшьләр,— диде ул пофылдап,— кунагымны жуйдым. Сыра эчәргә дип чыккан идек, әллә кая китеп барды. Башында түгәрәк эшләпә, үзе мыеклы.

— Моннан, абый, төрлесе үтә. Әнә ул түгелме? — дип, бөтенләй икенче якка таба күрсәтте Вәли. Анда салам эшләпә шәйләнә иде.

— Әллә шулмы икән? — дип, абый кеше ашыгып шул якка китеп барды.

Сукмак тау астына төшеп күздән югалганчы, Вәли аның артыннан күзәтте, эндәшмәде, аннары Мәрхабәнең колагына иелеп:

— Чыпчапчак,— дип пышылдады.

Кайдадыр куаклар арасында гитара тавышы ишетелә башлады. Бераздан ярым матрос киемендә — буй-буй тельняшкалы егет күренде. Ул, гитарасын чиертә-чиертә, Вәлиләр каршына килде дә:

— Пардон, папиросыгыз юкмы? — диде.

— Бар,— диде Вәли һәм тавышын әкренәйтә төшеп: — тизрәк китсеннәр, кигәвен,— дип өстәде.

Матрос аңлаганлыгын белдереп күз кысты, бераз киткәч, кычкырып жырлап жибәрде:

> Ой да вот и что у города было,
> У города Севастополя...

Бу — куркыныч барын белдергән шартлы сигнал иде. Матросның дәртле яшь тавышы бик еракка яңгырады, белгән кешеләр аңа, һичшиксез, игътибар иткәннәрдер. Мәрхабә белән Вәли исә һаман күлгә карап утырдылар. Алар көттеләр, әмма шпик бу якта кабат күренмәде. Шулай да ул яшерен оешманың бер кешесен таныйп. Әлбәттә, эшләпәне салырга, мыекны кырырга мөмкин. Ләкин шпикның күзе шуннан башканы күрмәгәндер дип уйларга ярамый иде.

Бу кичне Мәрхабә белән Вәли өйләренә кайткач та озак тынычлана алмадылар. Элек алар гамьсезрәк иделәрме, артык тирән уйламыйлар идеме, куркыныч болай ук сизелми иде кебек. Хәзер кемне иң элек югалтасыларын белгәнгәме, катырак борчылалар. Мәрхабәгә Вәлисез тормыш тормыш булып тоелмаса, Вәли, үз чиратында, яшәүне Мәрхабәсез күз алдына китерми иде...

Көз көне Мәрхабә бала тапты. Бу вакытта инде Айтүтә кияүләрендә генә торды. Тик көндезләрен ара-тирә өйләренә барып кайткалады. Болай тыныч торалар. Тик Исмәт турында гына хәвефле хәбәр сөйләделәр: бай өзлеккән. Хатыны күрмәгән чагында өйдән чыгып китеп югала икән. Бер тапкыр кызы Җәннәтнең бусагасына аркылы яткан хәлендә тапканнар, икенче тапкырында кайдандыр күпер астыннан алганнар, миңа тимәгез, мин Әзһарымны көтәм, ул озакламый килергә тиеш. Җәннәтне үтерергә генә китте, аннары Хитровкага барабыз, анда безгә ночлежка бар, дигән.

Балага Әхмәт дип исем куштырдылар. Баланың тууына иң шатланган кеше әтисе Вәли булды бугай. Исемне дә үзе тапты. Беркадәр вакытка гүя Мәрхабәне дә онытты, аның өчен хәзер шул бишектәге бала гына бар иде кебек. Эшкә киткәндә үбә, эштән кайткач, улымның хәлләре ничек? дип, иң элек аның бишеге янына уза. Айтүтә үзалдына көлемсери. Киявенең бала җанлы булуы аңа бик ошый. Ул тәҗрибә буенча белә: мондый ирләр гаилә өчен үләләр, аңа хыянәт итмиләр. Шул ук вакытта ата-баба йоласын да онытмады: пир [1] алмаштырмасын дип, бала бишегенә тимер кисәге куйды. Тимер янына пир килми ди.

## 30

Март матрата диләр дә, быел яз тиз генә килергә уйламый бугай, тышта шундый салкын, очып барган чыпчыклар һавада туңа. Кояш, январьдагы кебек, колаклы алка эчендә күтәрелә, яктысы бик саран, белмәссең, әллә томан, әллә сыкы шунда. Урамнар буп-буш, кешеләр йөгерә-атлый узалар, бик тиз каядыр кереп посалар.

— Ахырзаман килүе шушыдыр... Зәмһәрир суыклары шуңадыр. Инсанда бәрәкәт бетте, алла яраткан патша тәгъзим хәзрәтләренә тәмуг зобанилары оялмыйча кул күтәрә. Каян яхшылык көтәсең...

Хөҗҗәт мулла мәчет михрабыннан шундыйрак сүзләр сөйли, ди, патшага кул күтәргән шайтан кавеме студентларга коточкыч бәддогалар яудыра, ди. Әйтәләр, алла рәхиме белән патшаның исән-сау калуына шатланып, Хөҗҗәт мәчет михрабында бала кебек үкереп елаган, ди.

Исмәт бай тәмам өзлекте, ахрысы, хәзер чалма-чапан дауламый, ә патша хәзрәтләре янына барам, ди, аңа кул күтәргән тәмуг кисәүләрен барысын хәбес итмәгәннәр, галауныйлары һаман иректә йөри, ди, Исмәт аларны белә, янәсе, патшадан тоттыра икән.

Шул көннәрдә хатыны күрмәгәндә Исмәт тагын өеннән чыгып югалган. Аны эзләп-эзләп тә таба алмаганнар. Соңыннан кемнәрдер сөйләгән, Исмәтне Хитровка ночлежкаларында күргәннәр. Ул шәрә сәке өстенә бөтен буена баскан да үрле-кырлы сикереп кычкыра икән.

— Тоттым, эләктердем! Патшаны үтерергә баручыларны тоттым! Килегез, җәмәгать, тизрәк! Ә, качмакчы буласызмы? Юк, Исмәт кулыннан ычкынмассыз! Ә-ә, качтылар. Әнә тәрәзәдән сикермәкчеләр. Юлларын кисегез, юлларын!..

Исмәт сәкедән сикергән дә идән уртасында, лап итеп егылып, җан биргән. Соңыннан җеназасын укыганда Хөҗҗәт мулла әйткән ди:

— Исмәт изге кеше булгандыр, патша хәзрәтләре өчен шәһит китте,— дигән.

Бу араларда каты суыклар булып торганга, Мәрхабә яшь бала белән әниләренә бара алмады. Бүген, көн бераз сындыра төшкәнгә, әнисе Айтүтә үзе хәл белә килде.

---

[1] Пир — пәри.

— Һи, сагындырган оныгым нинди зур үскән,— диде Айтүтә, Әхмәтне кулына алып. Онысы аны килгән саен шатландыра, шундый тере, кулларын һич тотмый, инде көлә башлаган. Күзләре чем-кара, үзләре чәчрәп торалар.

Мәрхабә хәзер эшләми, көне буе баласы янында. Мичкә ягу берни түгел, менә кое ераграк. Ләкин бала елак булмаганга, Мәрхабә анысына да өлгерә.

— Онысым үз нәселебезгә охшый, Карышканнарда елаклар булмаган,— диде Айтүтә, онысын алсу яңагыннан үбеп.

Табын хәзерләнгәч, Мәрхабә әнисен өстәл янына утыртты, баланы үз кулына алып:

— Әни, бик озак килә алмадың, хәлегезне белә алмадык. Соң, барыгыз исән-саулармы? — дип сорады.

— Без аллага шөкер, кызым. Менә Исмәт бай... тончыкты. Үлгән кеше турында начар әйтергә ярамаса да, бүтәнчә телем бармый. Кибетләрен яптылар, атларын саттылар. Әтиең ат өчен бик ямансулый, бик ияләшкән идем шул хәйванга, ди. Әйләнә дә ат абзарына чыга, әйләнә дә ат абзарына чыга.

— Алай булгач, абзый белән Әбелфәрит тә эшсез калдылар,— диде Мәрхабә, артык борчылмыйча.

— Шулай шул. Раббани безнең белән сүләшми бит. Кеше аркылы әйттергән: Әбелмәнихләр үзләренә квартир тапсыннар, мин өемне сатам, дигән. Әбелхарислар, вакытлыча кодагыйларга күчәбез, диләр. Без әтиең белән кая барырбыздыр, белмим. Дворниклыкка урын булмасмы дип, көн саен караштырып йөри, бәхетсезгә җил каршы. Җомга көнгә бер җиргә чакырганнар үзен. Квартирасы бар барын, ягылмаган, ди. Кыш уртасында ягылмаган үгә ничек барып керәсең.

Бала, уянып, елый башлады.

— Тамагың ачтымы, улым? — диде Мәрхабә, Әхмәтне кулына алып.— И әни, монда ташу. Бир коры искеләр.

Баланы коры чүпрәкләргә төреп имезгәндә Мәрхабә аңа сөеп карап торды. Аның бөтен кыяфәте үзгәрде, матурланды, йомшарды. Күрәсең, бала имезүче анадан күркәм зат юк дигән сүз дөрес икән. Бөтен яшәеш дәвамы аңарда бит! Вәли, күзен алмыйча, Мәрхабәгә карап торды. Мыек баса башлаган нык иреннәре үзләреннән-үзләре җәелде. Кеше үз хатынына икенче тапкыр гашыйк булмый торгандыр инде, әмма бу минутта Вәли кинәт гашыйк булган егеткә охшый иде. Ул түзмәде, урыныннан торып хатыны янына килде, аның белән бергә балага карап тора башлады, аннары тамагын кырып алды. Бала имеп туйды, әтисенә карап елмайды. Аның алсу иренендә күгелҗем сөт тамчысы иде. Бала елмаюы! Нинди саф, бөтенләй ихлас күңелле икән сабый!

— Нәрсәгә таң калдың? — диде Мәрхабә иренә һәм Әхмәтнең иренен сөртеп алды.— Мә әле улыңны. Тик кара, иплебрәк тот, бу кытыршы тимер кисәге түгел сиңа.

— Ярый, Мәхүп, әйтәсеңне әйт,— дип елмайды Вәли һәм шунда ук улы белән сөйләшә башлады: — Я, Әхмәт батыр, хәлләр ничек? Көләсеңме? Көл, көл, малай. Хәзер синең көләр чагың. Ә аннары... аннары ни буласын юрамыйк. Әнә әбиеңне, әниеңне Карышкан кызлары дигәннәр. Син үскәч Карышкан егете булырсыңмы? Бу дөньяда карышырга кирәк. Ләкин мәңге карышып кына эш чыкмас, шулаймы? Шулай, Әхмәт дус! Әниең, минем куллар тимер бөгәргә генә ярый, ди. Бәлкем, тагын берәр нәрсәгә ярардыр. Эшченең сөялле кулы күтәрелә, ул бөтен богауларны зир-зәбәр китерер. Һичшиксез, шулай булыр, Әхмәт дус, шикләнмә!

— Син балага нәрсәләр сүлисең? — диде Мәрхабә иренә.

— Ә-ә? — диде Вәли гаҗәпләнеп.

Мәрхабә көлеп җибәрде.

Завод гудогы үкерә башлаганда Вәли йоклый иде әле. Күзен ачкач, иң элек тәрәзәгә карады. Пыялалар зәңгәрләнә башлаган. Вәли, Мәрхабәне уятмаска тырышып, караватыннан сак кына төшеп кухняга чыкты. Каенанасы торган иде инде.

— Бүген Әхмәт борчылды,— диде Вәли,— Мәрхабәне уятмыйк.

— Ишетеп тордым,— диде Айтүтә.— Ярый, йокласын. Бала асраганда шулай була инде ул. Син, кияү, юын, комганга җылы су салдым. Чәем хәзер кайный.

Вәли юынган арада Айтүтә табынны өлгертте. Гадәттә, иртән Вәли олы якта ашый-эчә иде. Кичә зур мичне якканга, бүген кухняда да җылы, шуңа күрә тамагын монда гына туйдырды.

Вәли эшкә китәргә дип кыска пальтосын кигәч, Айтүтә:

— Я, ярый, кияү, аепләп калма, бүген кайтам инде,— диде.

— Тагын берәр көн кунар идең, әни.

— Рәхмәт, кияү. Картымның борчулы чагы. Кайтыйм инде.

Кичә Айтүтә киявенә үзләренең хәлләрен, бүлмә эзләүләрен сөйләгән иде. Вәли кичә дә әйтте, бүген тагын кабатлады:

— Әнкәй, чын күңелемнән әйтәм, квартир тапканчы үзебезгә күчеп торыгыз, кечкенә булса да сыярбыз.

— Киң күңелегез өчен рәхмәт, кияү. Башта үзебезгә эзләп карыйк, бәлки, ходай бирер. Яшьләр үз бүлмәгездә үзегез рәхәтләнеп торыгыз. Суыклар үтмичә, Мәхүпне урамга чыгара күрмә, кияү. Баланы суыктан саклагыз.

— Ярый, әнкәй, ярый.

Кияве эшкә чыгып киткәч, Айтүтә табынны җыйды, аннары олы якка кереп әзрәк черем итәргә ятты. Бала да, Мәрхабә дә йоклыйлар иде әле. Айтүтә, аларны борчымас өчен, бик сак кыланды һәм, урынга яткач, ничектер бик тиз онытылып китте. Күрәсең, төнге тынычсызлык ана да тәэсир иткән. Шулай инде, яшь балалы өйдә кояшы, болыты, кар-бураннары еш була.

...Мәрхабә төш күрә иде. Яңа квартирга күчкәч, аларда ике тапкыр яшь кенә бер хатын кунып чыкты. Билгеле, ул үзе генә кагылган булса, аны кундыру түгел, ишектән дә кертмәсләр иде. Аның белән Ольга Леонардовна бар иде. Ул, Даша сездә бер кич кунып чыкса, комачауламасмы? диде.

Даша беренче килгәндә җәй көне иде әле. Җинел генә киенгән, сары калын толымын артка төйгән, башында киң кырлы эшләпә. Мәрхабәгә ул бик оялчан булып күренде, сүз әйткән саен яшь кызлар кебек кызара. Сөйләшүе бик әкрен, тавышы ишетелер-ишетелмәс кенә чыга иде. Икенче тапкыр килгәндә инде көз иде. Бу юлы аның өстендәге пальтосы, эшләпәсе иске, үзе шактый олыгайган кебек, йөзендәге алсулыкның эзе дә калмаган иде. Аның килүен берәү дә алдан хәбәр итмәде. Ул бик туңган иде.

— Мөмкин булса, мин әзрәк ятып җылыныр идем,— диде, күгәргән иреннәрен чак кыймылдатып.

— Башта кайнар чәй эчмисезме? — диде Мәрхабә.

— Рәхмәт. Бу тәрәзәгез бакчага чыгамы?

— Әйе каршындагы бакчага. Тик без икенче катта бит.

— Беләм...

— Борчылмагыз,— диде Вәли һәм Дашага кухняны күрсәтте. Монда, мич артында, икенче ишек бар иде. Ул запас баскычка алып чыга.

Янадан бүлмәгә кергәч, Даша галанка артына Мәрхабә түшәп биргән урынга бөгәрләнеп ятты, бераздан бөтенләй тынды. Мәрхабә аның шиблетларын алып карады. Бер сынарының олтаны купкан, эче лач су. Ул шунда ук кухняда нидер эшләп утырган иренә:

— Моның белән кая бара инде көзге пычракта,— диде.
Вәли шиблетны кулына алып башын селекте. Күренеп тора: Даша монда кереп яшеренер алдыннан йөгергән, сөрлегеп олтанын каерган. Мәрхабәнең авырлы чагы булганга, Вәли аны борчымас өчен, уйларын аңа әйтмәде, мич артыннан тимер табанны алып, олтанны кага башлады. Мастеровой кешенең бөтен кирәк-ярагы бар иде.
Шиблетны төзәткәч, хатынына бирде.
— Булды, Мәхүп. Урынына куй. Чәең әзерме?
— Әзер. Уятыргамы?
— Кирәкми. Без монда гына эчик.
Мәрхабә эчке бүлмәгә кереп китте, Вәли нәрсәгәдер сагаеп тынлап тора башлады. Ишегалдында эт бар, хәзер өрми, димәк, тирә-як тынычь. Вәли, иңбашына пиджагын салып, баскычка чыкты, аннары — ишегалдына. Тышта вак яңгыр сибәли, караңгы, тәрәзәләрдән төшкән тонык ут яктысында яңгыр сулары ялтырый. Гадәттә, бистә урамнары шау-шулы була, бүген әйтерсең барысы үлгән.
Ул төнне алар рәтле йокламадылар. Иртән Вәли эшкә киткәндә Даша:
— Шулай килеп чыкты... Әгәр килеп алмасалар, ихтимал, мин бүген дә сездә кунар идем. Каршы килмәссезме? — диде.
— Күпме кирәк, шул хәтле торыгыз. Әгәр ул-бу кирәк булса, Мәрига әйтегез. Мин кич кенә кайтам.
Көндез бер вакытта Мәрхабә, Дашаның үтенүе буенча, икмәк кибетенә чыгып керде. Аннан ул борчыла төшеп кайтты: тәрәзә төбендә яран гөле юк иде. Димәк, куркыныч кайдадыр якында. Мәрхабә шул турыда Дашага сөйләде. Берничә тапкыр Дашаның күзләренә карады.
— Мин аңлыйм,— диде Даша әкрен генә,— сез аңа булырга... Бәлки, миңа китү хәерлерәктер?
Мәрхабә әкрен генә башын селекте. Күз карашы катыланды, кырысланды. Аңарда берникди икеләнү, уңайсызлану юк иде.
— Уйлама да. Син минем кунагым. Хәзер чәй куям.
Даша ерак өннәргә колак салгандай тынып калды, үзе Мәрхабәне күзәтте. Бая урамнан кергәндә аның йөзендә курку бар иде кебек. Бу аңлашыла да. Йөгерә-йөгерә, димәк, эзенә басып килгән кешеләрдән кача-кача шиблет олтаны купкан төнге кунакны өйдә тоту бик хәтәр нәрсә. Дашага Викторны һәм аның хатыны Мәрины ышанычлы кешеләр дигәннәр иде. Көтелмәгәндә килеп кергәч тә аны бик җылы кабул иттеләр. Инде тизрәк урын алмаштырырга кирәк, бигрәк тә Мәри йөкле икән, борчылу аңа һич ярамый. Ләкин нишләргә? Әгәр кичә Даша аларга кереп яшеренмәгән булса, аны һичшиксез тотып алачаклар иде. Әгәр сүз Дашаның үзе турында гына барса, Даша бу адымны ясамаган булыр иде, полициягә эләгү нәрсә икәнен белсә дә, башкаларны куркыныч астына куймас иде. Ләкин аның янында шундый кәгазьләр бар иде, аларны саклап калу өчен теләсә нинди адымны атларга ярый, диделәр. Әмма тумаган баланы куркыныч астына кую... Даша хатынкыз кеше, аңа тойгысының дөньяда бар нәрсәдән өстен икәнен ул белә. Боларны кичә уйламаган иде. Инде нишләргә? Ул тиз генә шиблетларына үрелде.
— Кирәкми, Даша бәгърем. Хискә бирелмә. Безнең эштә аның харап итүе генә мөмкин,— диде Мәрхабә кисәтеп.
Даша кызарды һәм уңайсызлыктан котылу сылтавы итеп булса кирәк:
— Шиблетымны төзәткәнсез икән... Ничек рәхмәт әйтергә инде сезгә? — диде.
— Анысы зур эш түгел. Менә бу якка утырыгыз. Без, татарлар, чәй эчмәсәк, эчкә җылы төшми, дибез.
Кич белән Вәли эштән кайткач, Дашага:

— Абыйлар синең өчен бик борчылганнар икән. Берничә көн беркая чыкмаска куштылар. Аннары килеп алырлар,— диде.

Даша, аңлаганлыгын белдереп, баш иде. «Абыйларның» хәбәрдар булулары аны бик шатландырды, ул ярыйсы тынычланды.

Өч-дүрт көн үткәч кенә, кич караңгы төшкәч, Артем агай Дашаны алып китте...

Бүген шулар нәкъ өндәгечә Мәрхабәнең төшенә керде.

— И әни, мин тәмам изрәгәнмен,— диде Мәрхабә, күзен ачып.— Вәли киттеме?

— Сон кояшка кара, вакыт күпме булды инде.

Чәйләр эчкәч, Айтутә кайтып китте. Мәрхабә баласы белән булышты. Кичен, эштән кайткач, Вәлинең түгәрәк утырышына барасы бар иде.

— Син инде минем өчен дә тыңла, Вәли,— диде Мәрхабә, аны озатып.— Кайткач сөйләрсең. Югыйсә, тәмам каралып бетәм.

— Борчылма, Мәхүп. Безнең йөрисе көннәр алда әле.

Ялгыз калгач, Мәрхабә баланың чүпрәкләрен юды, аннары Әхмәт белән бик озак уйнап утырды. Соңыннан кисәктән генә борчыла башлады һәм, сәгатькә карый-карый, Вәлинең тизрәк кайтуын көтте. Унбер булды, унике — Вәли кайтмады. Мәрхабәнең кайнар чәйнеге суынды. Әхмәт тыныч кына йокласа да, Мәрхабәнең күңеле борчулы иде. Торабара аны коточкыч курку биләп алды. Түгәрәккә катнашучы барлык иптәшләре белән бергә Вәлине частька озатканнардыр кебек тоелды. Бу чын хакыйкатьтән ерак түгел иде.

## ИКЕНЧЕ КИСӘК

# Беренче тау

### I

Таулы-чокырлы җирләргә урнашкан башка шәһәрләрдә булгандырмы-юктырмы, әмма Казанда Беренче, Икенче, Өченче тау дигән урыннар бар, андагы урамнарны да шул таулар исеме белән атаганнар. 1887 елның августында Беренче тауга чорның булачак бөек кешесе — Владимир Ильич Ульянов аяк баскан. Бирегә ул, Россиянең төрле почмакларыннан агылган меңнәрчә яшьләр кебек, Казандагы император университетының студенты булу теләге белән хыялланып килгән...

Карышкан кызлары дастанының да шунда яңа сәхифәсе башланган.

Исмәт бай вафат булгач, аның җәмәгате Раббани иренең елы тулганын көтмичә, бу вакытта инде сәүдәсен Мәскәүгә җәелдереп җибәргән Шома Зәһугына өен сатты да үзе кызы Җәннәтләргә күчеп китте. Шома Зәһугы Әбелмәних белән Айтутәнe дә үзләрендә ялчы итеп калдырасы килгәнлеген кеше аркылы әйттергән. Теләсәләр, дигән, Әбелхарис белән Әбелфәритләренә дә эш табарбыз.

Моны ишеткәч, Айтутә:

— Сезнең, балалар, үз акылыгыз үзегезгә җиткән, ихтыярыгыз, без, әтиегез белән, картаймыш көнебездә Шомаларга бил бөгә алмыйбыз,—

дип кырт кисте.— Ризыгыбыз калган булса, кайда булса, ничек булса көн күрербез, инде беткән икән, ходай тәләнекен берни эшләп булмый. Шомалар тыштан гына шома, эчтән аларның кимлекләрен ходай күрсәтмәсен. Без бер авыл кешеләре идек, хәйләләрен барысын беләбез.

— Мин дә, балалар, бер-ике сүз әйтим,— диде Әбелмәних сабыр гына.— Моңарчы мин үземне онытып, гел семьям турында гына уйлап килдем, аны гына җил-давылдан сакладым. Үз ихтыярыма, үз холкыма каршы барган чакларым була иде. Әйтмәгәч, зарланмагач, дуламагач, бәлки, сез атагызга бик яхшы булгандыр, ул Исмәт байга күнеккән, шуңа бик канәгать дип уйлагансыздыр,— диде Әбелмәних, бар хәсрәтен ачып.— Хәзер инде сез зурлар, үз көнегезне үзегез күрә аласыз. Мин бер хатамны ике тапкыр кабатларга теләмим, балалар. Исмәттән котылып, Шомалар элмәгенә башымны тыгасым юк. Әниегез белән сүләшкән идек, нафакабыз[1] булса, көч житәрлек эш табарбыз, аның каравы, җаныбыз тыныч булыр, вөҗдан газабы кичермәбез. Ирегенне саткач, бик авыр, оланнар... Сез инде безгә үпкәләмәгез, калган гомерне иркле булып уздырасыбыз килә. Мин сездән бәхил, сез дә бездән бәхил булыгыз.

Әтисе белән әнисенең эчке кичерешләрен барыннан элек Әбелфәрит аңлады. Ул әсәрләнеп:

— Солдаттан гына котылыем, әти-әнине һич ташламам! — диде.

Әбелхарис тирәнрәк уйлый иде. Сүз әти-әнисе турында гына бармый, бүген Мәрхабә белән аның күкрәк баласы да туганнарының ярдәменә мохтаҗ. Вәлине Себергә олактырдылар, хаты-хәбәре юк, тормышны белгән кешеләр ул тиз генә әйләнеп кайта алмас дип әйтәләр.

Киңәшә торгач, шундый фикергә килделәр: хәзергә Айтүтә белән Әбелмәних Мәрхабә янына, Әбелхарислар кайнаталарына күчәләр. Әбелфәриткә яңа байлары кибеттә урын тәкъдим итәләр.

Мәрхабә, нәни баласын әнисе кулына калдырып, яңадан шифаханәгә эшкә керде. Анда инде элекке танышлар, дуслар калмаган диярлек, кайсыларын чыгарганнар, кайсылары үзләре киткән. Мәрхабә үзенә дә кырын карый башлауларын сизде. Ул белә иде: оешмага провокатор сырышкан булган, ул байтак кешене саткан, больницадан да ике кешене алганнар. Ни өчен Мәрхабәгә тимәгәннәрдер — хәзергә билгесез. Ихтимал, провокатор аны белмәгәндер, ул завод һәм эшчеләр белән турыдан-туры бәйләнмәгән иде бит. Бәлки, башка бер сәбәп булгандыр. Иң авыры шунда иде: киңәшергә кеше калмаган. Сергей Сергеевич белән Ольга Леонардовнаның тавышы-тыны ишетелми; Артемның хатыны: «Дөрес булса, алар чит илгә китеп өлгергәннәр, монда аларны бик каты эзлиләр», дигән иде. Артемның үзен, Вәлине олактырган кебек, каядыр Себергә озатканнар. Алексей Петровичны да сөргәннәр икән.

Дүрт-биш айдан Вәлидән кош теле хәтле генә хат килде. Аны ике елга сөргенгә сөргәннәр, Мәскәүдә торудан гомергә мәхрүм иткәннәр. Ул Мәрхабәгә нык булырга, Әхмәтне яхшылап карарга кушкан. Хат русча язылган, арада кайбер татар сүзләре бар иде. Алары тикмәгә түгелдер, өстәмә мәгънәләре булырга тиештер. Мәрхабә, күзләрен яшь томалаганга, башта берни аңламады. Тик өченчеме, дүртенчеме тапкыр укыгач кына кайбер нәрсәләрне төшенде. Кыргаяк... Еракkарак күчәргә...

Мәрхабә Вәлинең кисәтүләре житди икәнен аңлады. Ул әнисенә шуларны бәйнә-бәйнә сөйләде. Вәли безгә моннан китәргә куша, диде.

— Белмим инде, кызым, ни әйтергә дә,— диде Айтүтә, бишек тирбәтә-тирбәтә.— Еракkарак күченә башласаң, иң элек акча кирәк.

[1] Өлешебез.

Безнең ниебез бар? Әбелхарисның үз семьясы, Әбелфәритне солдатка алсалар... Аннары яшьләрне бик кысмыйсы иде, аларның үз киләчәкләре.

— Мин үзем эшләрмен, әни,— диде Мәрхабә.

— И кызым, хатыннар бу дөньяда ни эшли ала? Аларга кем юл бирә? Закирҗан кияүгә киңәш сорап хат язсак ничек булыр? Бөтенләй ыру-кардәшең булмаган шәһәргә барып төшү бик кыен бит. Без аларны кысынкыламас идек...

Закирҗаннар бу вакытта Петербургтан Казанга күчеп тора башлаганнар иде. Петербург университетында көнчыгыш бүлеге бетерелгәнгәме, башка бер сәбәптәнме, Казанга күчүне артыграк күргәннәр. Закирҗан белемле, укымышлы кеше, кыен чакта ярдәме тимәсме. Иң мөһиме, Айтүтә моңа басым ясамаса да, төп нияте шул иде: анда Хәерниса! Башкалар әле теләсә ничек уйлаулары мөмкин, Хәерниса эти-әнисе белән сеңелесен ташламас. Карышкан кызлары андый эшне эшләмиләр.

Язылган хатларга җавап көткән арада, Әбелмәних берничә тапкыр Гыйльметдиннең ит кибетенә барып кайтты. Иске гадәт буенча ул анда баш-аяк сатып ала торган иде. Мәрхабә рус суйган итне дә ашый, картларга татар суйганы булсын, янәсе, татар суйган ит тәмлерәк.

Әбелмәних итчегә үзләренең авыр хәлләрен сөйләп бирде, киңәш сорады.

— Казанга бару ниятегез булса, мин мәслихәт күрәм, Әбелмәних абзый. Күптән түгел минем энекәш Казаннан килгән иде. Аның белән киңәшеп карармын. Ул Закирҗанны ишетә белә,— диде Гыйльметдин.

— Сөйләшә күр инде, Илметдин брат. Кеше кешегә таянмыйча кая бара ала... Кайчан кереп белешим икән?

Өйгә кайткач, Әбелмәних шуларны хатынына сөйләде. Айтүтә картының уйларын бик мәгъкуль күрде, тик Закирҗаннардан хат килмичә, Илметдиннең сүзенә карап кына, мондый озын юлга чыгу ярап бетмәстер, атасы, диде. Закирҗаннарга барысын ачыктан-ачык язганнар иде. Бәлки, Закирҗан шундый балдызының үзе белән бер шәһәрдә торуын теләмәс.

Мәрхабә тәүлек буе эшли иде. Айтүтә, ире кайтып керүгә, Әхмәтне имезергә алып китте. Шунда этисе алып кайткан хәбәрләрне кызына сөйләп өлгерде.

Мәсьәлә шул хәтле җитди һәм катлаулы иде ки, бер сөйләшү белән генә эш бетмәде. Якшәмбе көнне кич Әбелхарис белән Габидә килделәр, бераздан Әбелфәрит тә килеп җитте. Тагын мәсьәләне уртага салдылар.

— Без Әбелхарис белән киңәштек,— диде Габидә, чак кына кызарып,— әниләрне дә, ахирәтне дә әллә кая читкә җибәрәсебез килми. Кечкенә генә бүлмәләр тапсак, барыбыз бергә сыяр идек.

— Солдатка каралу гына бар, югыйсә...— диде Әбелфәрит, башын кашып.

Мәрхабәне бер нәрсә шатландырды: эти-әнисе, абыйсы-энесеннән башка Габидә дә аны читкә какмый, хәтта Брамат килеп китте, бераз акча калдырды. Мәрхабә белән Айтүтә никадәр алмаска теләсәләр дә, Брамат тыңламады.

— Син, Мәрхабә, аз булганга, бәлки... Нишлим, булса күбрәген дә... Минем үземә җитә, мин ач торырга күнеккән. Вәли душа кеше иде, авыр чакта мин аның хатыны белән баласына булышмасам, ул ни була аннары. Губчем бер нәрсә булмый.

Брамат киткәч, Айтүтә башын селкеп утырды. Ходайның яхшы кешеләре дөньяда аз түгел икән. Рәхмәт үзләренә, авызларыннан өзеп бирергә торалар.

Бер атна үтмәгәндер, Мәрхабәне сорап, ыржык[1] хәтле бер карт урыс килде. Мәрхабә бу кешене танымый иде, шуңа күрә аның сорауларына сакланып җавап бирде. Ниһаять, теге кеше Алексей Петровичның исемен телгә алгач кына Мәрхабә беркадәр ачыла төште, шулай да бөтенләй чишелмәде. Ахырда теге карт авыр көрсенеп:

— Күрәм, сез миңа ышанмыйсыз, нишлим. Сезгә, Маша, моннан китәргә кирәк, никадәр тиз булса, шул кадәр яхшырак,— диде.— Сезнең кайда булса кардәшләрегез бармы? Икенче шәһәрдә?

— Юк,— диде Мәрхабә.— Әтием белән әнием янымда.

— Аның кардәшләре?

— Юк.

— Минә бәла... Мин Сергей Сергеевич белән Ольга Леонардовнаның кушканнарын үтидер идем.

— Мин аларны белмим шул.

Язның иң ямьле вакыты — апрель житкән иде. Ләкин яз яме Мәрхабәнең күзенә күренмәде. Җан борчулы булгач шулай икән. Башына берсеннән-берсе хәтәррәк җавапсыз уйлар килде. Дөрес, күнеле бу карт урыстан курку тоймады. Әмма ул әйтеп калдырган сүзләр... Китәргә... Ашыгыч китәргә... Кая китәргә? Закиржаннар нигәдер җавап бирми.

Көндез Айтүтә баланы имезергә китерде. Карты Гыйльметдингә барган булган. Гыйльметдиннең энесе абыйсы аркылы әйттергән: Казанга бару фикерләре булса, ярдәм итәрмен, дигән. Тагын бер чакырган, юл хәлләрен сөйләрмен, юл мәшәкатьле, Мәскәүдән Казанга чуен юл юк, дигән.

Ниһаять, Закиржаннан хат килде. Айтүтә конвертны калтырана-калтырана ачты. Әбелмәних өстәл читенә утырды. Ул хатының ашыктырмады. Айтүтә иҗекләп кенә укыды.

Закиржан белән Хәерниса — хат аларның икесе кулы белән язылган иде — әти-әниләре белән Мәрхабәне үз яннарына чакырганнар, теләсәгез аерым бүлмә табарбыз, борчылмагыз, дигәннәр.

— Рәхмәт инде үзләренә,— диде Айтүтә, күз яшен сөртеп алып.— Үз балаларың — үз балаларың инде. Ничек, атасы, Мәрхабәне барып шатландырыйммы?

— Шатландырсаң яхшы булыр иде дә, күп йөрүеңне больницында яратып бетермәсләр. Иртәнгә кадәр сабыр итик,— диде Әбелмәних.

Бу кичне Айтүтәнең бармавы яхшы булды, чөнки каты авырулар күп иде, Мәрхабә бер генә минутка да алар яныннан китә алмады. Инде сәгать унберләр тулганда икенче бүлектән бер авыру ир адәм керде.

— Исәнмесез, Мәри,— диде ул,— сез мине таныйсызмы?

Мәрхабә баш иде. Бу кеше, Мәрхабә кебек, элемтә бурычларын үти иде.

— Син карт урыстан шикләнмә. Ул кушканны үти. Үзең беләсең, яңгын көчле булды... Исән калганнарны барлау, туплау... мәшәкатьле эш. Кайберләренә ашыгыч булышырга кирәк... Аңлыйсыңдыр...

Мәрхабә төшенгәнлеген белдереп башын иде.

— Сиңа бераз ярдәм итәрләр, тартынма, ал. Тиз генә күрешмәсәк, сау бул... Карт сине якшәмбе көн... бакчада күрер. Өч белән дүрт арасында...

... Казан аларның килүенә игътибар итмәде. Бу зур шәһәргә көн саен йөзләрчә кешеләр килә, шул хәтле үк китеп торалар. Казанның даны ерак-еракларга таралганга, Мәрхабә һәм картлар тирә-якларына

[1] Ыржык — колгасар, озын буйлы.

утә кызыксынып карадылар. Билгеле, алар Казанның Европа белән Азия арасында барлыкка килүен, бу хәл аның архитектурасына, көнкүрешенә, сәүдәсенә үзенчәлекле эз салуын белмиләр, алар бары тик тышкы күренешләргә генә игътибар итәләр иде. Монда мәчетләр күп икән, чиркәүләре дә җитәрлек. Кешеләрнең киемнәре төрле-төрле, татарлар аерылып тора. Татар хатын-кызлары урамда бөтенләй диярлек күренми.

Кич. Кояш батып бара, күктә кызыл шәфәкъ. Аның шәүләсе урамнарга, тыкрыкларга йоккан. Бу алмашынучан яктылыкта кешеләр ничектер гайре табигыйрәк күренә, ә манара башларыннан ишетелгән кичке азан тавышлары каяндыр теге дөньядан килә кебек.

Әгәр дә шушы минутта Әбелмәнихларга Казан Урта Идел белән Кама буеның үзенә күрә пайтәхете була, Казан губернасы гына түгел, Вятка, Сембер, Оренбург, Уфа, Пермь һәм Самар губерналары да экономик яктан аңа карый, шуның өстенә, Казанның Мәскәүгә һәм ел саен гаҗәеп зур ярминкәсе булып торган Мәкәрҗәгә чагыштырмача якын булуы, су юлы өстендә бик уңай утыруы турында сөйләсәләр, күбесе башларына сыймас иде. Әмма урамнарның чамасыз пычрак икәнен, көннәр коры торуга карамастан, күл-күл сулар җәелеп ятуын үзләре дә күрәләр иде, җитмәсә, кичке шәфәкъ кызыллыгы аларга әллә нинди тылсымлы көч биргән иде.

Олаучы агай ара-тирә чыбыркысын шартлата, аты койрыгын гына селкетеп куя. Әбелмәних — ат тоткан кеше, белә: атны чыбыркы белән кума, солы белән ку. Ләкин бу агайның солысы юк бугай. Тәгәрмәчләре майланмаган, бөтен урамга илерәләр.

— Шыгырдамагыз, ләгънәт,— диде олаучы, аклангандай булып,— килеп җитәбез инде. Син, агай-эне,— ул Әбелмәнихка мөрәҗәгать итте,— бераз өсти төш инде. Балалар туйганчы ипи күрми. Көн саен алып кайтам дип вәгъдә итәм, көн саен коры кул белән. Кешеләр Казанга Мәккәгә килгән кебек киләләр, монда ширбәт дәрьялары ага дип уйлыйлар, ә монда сасы Болак суы гына... Син, агай-эне, кайдан киләсең?

— Мәскәүдән.

— Үзеннәнме? Анда тормышлар шәптер, ичмасам!

— Шәп,— диде Әбелмәних, ачы көлемсерәп,— кубышкалары булганнарга.

— Ни әйттең? Кубы... кубы...

— Аңламыйсыңмы? Ә алтынны аңлыйсыңмы?

— Төштә дә күргән юк. Алтын мишәрдә булса булыр.

— Мишәрләрнең дә төрлесе бар, иккүзем. Хуҗаның янчыгы калын иде, без аның атын карап тордык, бездә ат таңкәләре дә юк иде.

Айтүтә икенче нәрсә белән мәшгуль иде: әллә каян гына борынга бик саф та, бик сасы да ис килеп тора. Ул атаклы Кабан күленең шушы ике-өч катлы йортлар артында гына җәелеп ятуын, даны әллә кайларга таралган берадәрән[1] Крестовниковларның сабын һәм шәм заводларының моннан ерак түгеллеген, ямьсез исләр нәкъ менә шуннан килүен белми иде.

— Тып-ру,— диде олаучы.— Шушы йорт булырга тиеш.

Бераздан Хәерниса белән Закирҗан йөгереп чыктылар. Исәнлек-саулык сорашулар, күрешүләр китте. Атны ишегалдына керттеләр. Биредә яшел чирәм, түрдәрәк кечкенә бакча иде.

Төеннәрне күтәреп, икенче катка менеп киттеләр. Әбелмәних портманетын ачып, олаучыга килешкән акчасын, аннары өстәү бирде.

— Балаларыңа калач ал.

— Рәхмәт, агай-эне. Бирмәсәң дә ярый, мин бит сине...

[1] Берадәрән — бертуган.

— Балаларның хакы аерым. Теләк теләсеннәр.

Олаучы атын капкага таба борганда Хәерниса белән Закиржан чыгып агайны чәй эчәргә чакырдылар. Хуҗалар чын ихластан дәшкәч, агай кыстатмады. Тик кухнядан ары узмады, мин тузанга баткан кеше, миңа шунда да ярый, диде. Аңа бәлешләр, пәрәмәчләр куйдылар, Хәерниса чәй ясады.

— Минем мондый әгъләә нигъмәтләрне күргәнем дә юк,— диде агай, исе китеп.

Мишәрдәге гадәт буенча, Хәерниса калган кисәкләрен олаучының балаларына төреп бирде.

Закиржан белән Әбелмәних олы якка уздылар. Шактый иркен бүлмә, савыт-саба шкафы, гөлләр, стеналарда шамаиллар, ак ашъяулык ябылган бер зур өстәл, тәрәзә каршында кечкенә өстәл, анда китаплар, кара савыты, кауры каләм. Почмактагы ишектән хатыннар тавышы ишетелә.

— Юлда мәшәкатьләнмәдегезме, эткәй? — диде Закиржан.

— Юл азабы — гүр газабы дигәннәр дә, килеп җиткәч, зарланып булмый, кияү. Шәһәри Казанны да күрдек.

— Казанны иртәнге якта карарбыз инде,— диде Закиржан.

Әбелмәних сөйләшә-сөйләшә киявен күзәтте. Ул Закиржанны бик аз белә иде. Әйтеп булмый, килеп төшкәч, караңгы чырай күрсәтмәде кебек, шулай да күңеле төбендә нәрсә бар? Петербургтан кайткач, Айтүтә киявенең кешелеген бик мактаган иде дә, ул чакта башка иде шул, хәзер бөтенләй башка...

## 2

Беренче тау урамында Мәрхабә карадан киенгән, буе-сыны матур, сөйкемле йөзенә тирән кайгы билгесе яткан бер хатынны очрата башлады. Ул каршы яктагы ике катлы агач йорттан чыга, капка төбендәге хатыннар белән баш иеп кенә исәнләшә, алар янына туктап яки утырып «тәләкә» кыздырмый, ягъни юк-бар сүз сөйләшми, үзенең күзгә күренми торган бинһая хәсрәт йөген күтәреп, ашыкмый гына урам буйлап каядыр китеп бара. Элек ул Беренче тауда юк иде,— Мәрхабәләр монда июнь аеннан бирле,— күрәсең, балалары белән яңарак каяндыр күчеп килгән. Ул үзенең тышкы кыяфәте белән дә, үз-үзен тотышы, мөгамәләсе белән дә башка рус хатыннарыннан шактый аерыла, эреләнми, масаймый, башкалар кебек үзеннән түбәннәрне басып китәргә, мескен татар карчыкларын, өлкән яшьтәге татар хатын-кызларын юкка санарга, мәхлуккә тиңләргә җыенмый, киресенчә, аларга юл бирә, кайсы берсе белән хәтта исәнләшә. Күбрәк ул ялгыз йөри, кайчакта янында буй җиткән кызы яки гимназистлар киемендәге улы була. Тагын ике баласы — улы белән кызы бар, тик алар яшьрәкләр, әниләре янында сирәк күренәләр, күбрәк няньялары белән йөриләр. Зур улы болай әнисенә охшамаса да, күз тиреләре туры килә. Кешегә ягымлы, игътибарлы. Татарчаны бераз төшенә бугай, һәрхәлдә, урамнан узып барган кешеләр татарча ни дә булса сораса, туктап төшендерә.

Мәрхабәләргә Беренче тау кешеләре үз була башлаганнар иде. Закиржан белән Хәерниса: «Бездә генә торып торыгыз, кысынкыламыйсыз, комачауламыйсыз», дип, әллә ничә әйтеп карасалар да, Айтүтә белән Әбелмәних абзый һәм Мәрхабә аларны артык бимазаларга теләмәделәр.

— Закиржан кияү,— диде өч-дүрт атна үткәч Айтүтә,— синең дә, Хәерниса кызыма да мең-мең рәхмәт, авыр чагыбызда бездән йөз җыермадыгыз, үз итеп каршы алдыгыз, җылы урын бирдегез. Без

монда кунакка килмәгән, үзебезгә оя табарга булышсагыз, рәхмәт әгер идек.

— Анысында эш тормас, тик бездә торсагыз ни була?

— Үпкәләмәгез, кияү,— диде Әбелмәних та, сүзгә кушылып,— яхшылыкның кадерен белергә кирәк. Әле кулда көч бар, кешегә салынып ятмыек.

— Шулай, шулай, кияү,— дип өстәде Айтүтә.— Казаныгыз бик ошады, оныкларым Кабан күлен карарга да илттеләр... Шәмнәрегез дә бик якты яна,— шәм шәһәре икән Казан, шулай да, караңгырак булса да, үз ояң кирәк.

Закирҗан белән Гыйльметдиннең энесе бик булыштылар. Торак турында гына сүз барса, әллә ни кыен булмас иде. Монда бит Әбелмәнихка да, Мәрхабәгә дә эш кирәк. Әбелмәних — карт кеше, дворниктан башкага ярамый, Мәрхабәгә шифаханә якын булсын, чөнки аның бүтән һөнәре юк.

Бу көннәрдә Әбелмәнихның күңеле шактый төшенке иде. Ул, кияве белән Гыйльметдинның энесе ярдәменә генә салынып ятмыйча, үзе дә эш эзләп караштыргалады. Кая ул кулай эш табу!

Бер көнне ул шулай көнозын Казан урамнарында йөреп, тузанга батып, арып-талып кайтты да, ике кулын тез башларына куеп:

— Эх, атай, йөрмәсәң генә белмисең икән,— диде һәм бик озак башын чайкап торды.— Казанның үз Хитровкалары тулып ята лабаса! Печән базарыннан уздым, Мокрыйда булдым, Марусовкасын бактым. Һи-и! Аләмәт! Белмим, бу Казанда үз нафакабыз бардырмы?.. Кияүләр ярдәм итмәсә, анасы...

Ниһаять, күп эзли торгач, Беренче тауда ике бәләкәй генә бүлмә һәм Әбелмәних абзыйга урын табылды. Шифаханәләр дә, мондагыча әйтсәк, сырхауханәләр дә якын икән.

— Илметдиннең братына рәхмәт, кияү дә чын кеше икән,— диде Әбелмәних, кызы эшкә йөри башлагач,— ә мин шикләнгән булдым. Кеше чикләвек төше кебек шул, ачып карамыйча белеп булмый.

Күңеле яраткан эш Мәрхабәне тынычландырды, аңа кеше төсе керә башлады, икенче яктан, ул күзгә күренмичә һаман сыза бара иде. Өйгә кайтып кергәч, ишекне ачу белән үк:

— Әнкәй бәгърем, Вәлидән хат юкмы? — дип сорый иде. Булмагач, күңелсезләнә, башын ия иде.

Мәрхабә энисенә Әхмәтне күбрәк урамда тотарга куша иде. Җәй көннәрендә моның ни мәшәкате бар, Айтүтә, өй эшләрен бераз рәтләгәч, капка төбенә кулагага чыгып утыра. Әхмәт инде йөри башлаган. Күрәсең, Казан һавасы аңа килешә: яңаклары кып-кызыл, күпереп тора, үзе көннән-көн матурая бара. Бик кызык итеп әннә-әттәләрен сөйли. Карчык кешегә бу кош сайравы инде.

Кайчакта Айтүтә янына тирә-юнь карчыклары чыгып утыра. Аларда инде бөтен урамның хәбәре. Айтүтәгә татарча сөйләсәләр дә, русча сөйләсәләр дә барыбер, һәммәсен төшенә. Татар карчыклары хәтта кызыгып куялар:

— Син, Айтүтә, русның үзен сатасың икән! — диләр.

Бүген урам әле буп-буш, карчыклар чыгып утырырга өлгермәгән, Әхмәт яшел чирәм арасында кымшана, Айтүтә урамны күзәтә. Аратирә байлар ишегалдыннан яхшы файтуннарга җигелгән атлар чыгып, урам буйлап чабып китәләр; кибетләрдән, базардан кайтучы асраулар күренә, кайсысы коедан чиләк белән су ала. Еракта, кара төтеннәрен айкап, Крестовниковлар заводының ике биек морҗасы күренә. Әйтерсең алар Казан өстенә ашкан. Күптән түгел ул завод шартлаган да булган икән, тагын төзәткәннәр диме. Булыр да, төтеннәре әнә нинди, чаршаумыни!..

Каршы яктагы ике катлы өйдә торучы матур хатын соңгы вакытта нигәдер күренми башлаган иде, бүген Айтүтә янынннан тагын исәнләшеп үтте.

Айтүтә аның кемлеген белми иде. Шуңа күрә кулына таяк тотып янына чыгып утырган рус карчыгыннан:

— Күрше, бу матур хатын кем була? — дип сорады.— Безнең шикелле прастуй булмавы күренеп тора, үзе татар хатынына да баш ия. Күпләре бит безнең ишеләрне күрми дә, янәсе, капка төбендә багана башы. Чын, валлаhи.

— Һәй, Айтүти, алла күпләргә байлык бирсә, акыл бирми. Ә бу хатын — изге, аның артыннан күзең талганчы карап калырга ярый. Ул күтәргән кайгыны без күтәрә алмас идек, сыгылып төшәр идек... Менә шул хатынның өлкән улын, башка биш студент белән бергә, Питердә дарга асканнар, өлкән кызын сөргенгә озатканнар. Казаннан ерак түгел Кокушкино авылына. Анда шул матур хатынның әтисенең үз утары булган, ди. Әтисе күптән үлгән, хатынның сөекле ире дә дөнья куйган. Кайгы бер каныкса каныга ул, Айтүти.

Карчык бу сүзләрне әкрен генә, як-ягына карана-карана әйтте. Айтүтә бу хәбәрдән хәйран-вәйран калды. Кайчандыр ул, әле Мәскәүдә чакта, патшага кул күтәрергә батырчылык иткән шул балаларның газиз аналарын бер генә күз белән булса да күрсәң иде, дип уйлаган иде, алар гади кешеләр кебек түгелдер, дип исәплэгән иде, чөнки гади кеше итеп аларны башыңа китереп кара! Баксаң, шул ана Айтүтәләр белән бер урамда тора, житмәсә, Айтүтә белән исәнләшә дә!!

Бу хәл Айтүтәне тетрәтте. Ул ни әйтергә белмәде. Аналар күңеленнән күңелгә юл бармы әллә, алар сөйләшми дә бер-берсенең йөрәген аңлыйлармы? Ул хатын Айтүтәнең йөрәгендә төзәлмәс кайгы барын сизгәнме? Дөрес, Айтүтәнең кайгысын бу матур хатынның кайгысы белән бер ничек чагыштырып булмый, шулай да чын кайгының нәрсә икәнен ул белә. Ходаның төрле бәндәләре бар икән, үз кайгына күмелеп, башны бөгәргә ярамый, янында кайгылары синекеннән мең мәртәбә зуррак хәсрәт ияләре булуы мөмкин. Айтүтә, билгеле, изге көрәш турында берни белми, аны аңламый, ул бары тик начарлыкка карышучы Карышкан кызы гына. Хәзер ул үзен шул матур һәм хәсрәтле хатын белән рухи кардәшләнгән кебек хис итте.

Кич белән эштән кайткач, Мәрхабә беренче караудан ук әнисенең сәерлеген сизде һәм: «Ни булды?» — дип сорады.

— Һай, бетмәде шул,— диде Айтүтә ачуланмыйча гына.— Әтиең булды әтиең сорап аптыратты, инде син... Эштән кайткан кешене ни әлек ашатыем, аннары сүләрмен. Менә чүлмәк бәлеше [1] пешердем. Бик тәмле.

Тамагын туйдыргач, Мәрхабә әнисенә карап:

— Я, әни, сүлә, сүлисең килгәнне күреп торам ич,— диде.

— Минем шул инде, шатлыгым, кайгым бөтен кешегә күренә,— диде Айтүтә һәм матур хатын турында ишеткәннәрен кызына сөйләп бирде.

— Әйтәм ул хатынның йөзендә хәсрәт билгесе ярылып ята,— диде Мәрхабә, әнисен тыңлагач.

— Кешенең йөзе — җанының көзгесе...

— Фамилияләрен белмәдеңме, әни?

— Күрше әйтте дә... Ульяннныкы диде ме.

— Александр Ульяновның әнисе шушымыни?! — Мәрхабә Александр Ульяновның судта үзен иң батыр тотуын, яклаучы алмавын, судьяларның йөзләренә карап үзе сөйләвен ишеткән иде.

---

[1] Чүлмәк бәлеше — төпсез бәлеш.

Айтүтә кызына карап алды: Мәрхабәнең йөзендә сагыш, карашы ачык тәрәзәдә, әмма тышта ни барын күрә идеме ул?

Алар Мәскәүдән чыгып киткәч ике атна да үтмәгән, Мәрхабәне полициядән сорап килгән булганнар. Шул хәбәрне алгач, Мәрхабә бик борчылган иде, күкрәгенә бөтенләй сөт килми башлады, баланы аерырга туры килде. Әле дә ярый, Әхмәт артык бимазаламады.

Мәрхабә аны кулына алып, еш кына күзләренә карый иде.

— Рәнҗемисеңме әниеңә, алтыным? Сөтем юк шул.— Ул баланы алсу яңакларыннан кат-кат үпте.— Рәнҗемә, җаным. Чү, улым, нигә әниеңне яңакларыннан умырасың? Кара, син нинди усал! Бак, бак, тиле, йодрыклап орыша!

— Карышкан кызлары нәселенең каны уйный торгандыр,— диде ишектән килеп кергән Айтүтә.— Ашыйсың киләме, улым?

Баланы ашаттылар, аннары Мәрхабә улын урамга алып чыкты.

Капка төбендә Әхмәт энисе итәгеннән җиргә төште. Күк күгәрченнәр җим чүпләп йөри иде. Әхмәт аларны тотарга итеп куа башлады. Күгәрченнәр очалар да, ерак китмичә, тагын җиргә төшәләр.

Урамның аръягында тирән чокыр. Аннан карт агачларның ябалдашлары гына күренә. Мәрхабә, уйга калып, аларга карап тора башлады.

Бераздан янына әтисе Әбелмәних килеп утырды һәм уйга чумган кызын борчымас өчен Әхмәткә дәште:

— Һи, улым, күгәрченнәр тоттырмыймы? Тоттырмас шул, аларның үз канатлары бар. Канатлары! Ә безнең синең белән юк. Кешегә дә, улым, канат бик кирәк... Әтиең алып кайтса гына...

Мәрхабә, авызын учы белән каплап, иснәп утыра иде, әтисенең тел төбен аңламады. Әбелмәних канат турында Әхмәткә түгел, Мәрхабәгә әйтә иде. Ләкин кызының артык йончуын күреп:

— Кызым, кереп әзрәк сузылмыйсыңмы? — диде.— Оныгымны үзем карармын. Ул хәзер зур, мичем памушник.

— Әзрәк утырыйм, әти. Монда һава яхшы, бездә, шифаханәдә, бик авыр.

Мәрхабә каршыдагы ике катлы агач йортка карады. Тәрәзәләрендә ак пәрдәләр, бер кеше күренми, гүя анда һичкем тормый.

— Күршеләр әллә китканнәр инде, әти,— диде Мәрхабә, урам аръягына ымлап.

— Матур хатынны әтәсеңме? Иртән Куку авылына китте, кызы янына. Аңа Казанга килергә рөхсәт юк икән. Әниләре барып хәлен белә.

«Өлкән малаен асканнар, өлкән кызын сөргенгә озатканнар...» — дип уйлады Мәрхабә. Нинди коточкыч авыр хәсрәт күтәреп йөри бу хатын, үзе сыгылмый, еламый. Йөрәге таш булганга түгел, анда җәһәннәм газабыдыр, ләкин ул аны кешеләргә күрсәтми, чөнки кешеләр болай да кайгылы, кайгы өстенә кайгы өстәсәң, ни була аннары.

Әбелмәних кибеттән кайтканда, Айтүтә кече якта савыт-сабалары белән кайнаша иде.

— Анасы, инде якты күздә Хәернисаларга барып кайтсам ничек булыр? — диде Әбелмәних әкрен генә.

— Бара алсаң, карт, бик яхшы. Шул хәтле сагындым оныкларымны, аягүрә төштә күреп йөрим. Бүген Әбелхарисымның улы да исемә төште. Мәскәүгә әйт дигәндә генә бара алмыйсың, мондагылар, ичмасам, якын.

Әбелмәних абзый алъяпкычын чиште дә тау астына төште. Георгиевский урамын үтеп Кабан ярына чыкты. Аннары Крестовниковлар заводына таба юл алды.

Күлгә арты белән утырган тыкрыкларның берсендә Закиржаннарның өе. Ишегалдында кибәргә кер элгәннәр. Әллә Хәерниса керләре, әллә аскы катта торучыларныкы. Ишегалдында оекбаш бәйләп утыручы күрше карчыктан башка бер кеше күренми.
— Исән-сау гына торасыңмы, әби?
— Аллага шөкер, Әбелмәних. Кызың килденмени?
Балалар бабаларын тәрәзәдән күргәннәр, йөгереп ишегалдына чыктылар, иң алдан Гөләндәм, арттан Хәлил титаклый. Әбелмәних балаларны иелеп кулына алды.
— Их, парин, алмаларга ничек җитәм хәзер, кул буш түгел. Әбиегез кып-кызыл алмалар җибәргән иде.
Балалар шунда ук җиргә төштеләр. Бигрәк тә Хәлил алма ярата, аның күзләре зур булып ачылган, түбәтәе артка шуган.
— Алмалары да алма, прямо алтын! — диде бабасы, кесәсеннән алма чыгара-чыгара.— Һәй, монда тагын бар. Монысын Әхмәт җибәрде.
— Әхмәт минем кебек чаба беләме, бабакаем? — диде Хәлил, алма ашый-ашый.
— Әхмәт хәзер, улым, бай рисаклары кебек чаба. Тик кайчак киреләнә.
— Менә Хәлил дә кайчак киреләнә,— диде Гөләндәм, зур булып.— Кечкенәләр киреләнә. Хуҗа Насретдин ишәге кебек.
— И, болар бабалары янында инде,— диде Хәерниса, ишектән чыга-чыга.— Саумы, әти. Әни белән Мәрхабә исәннәрме, Әхмәт авырмыймы?
— Барысы аллага шөкер, кызым. Сәлам әттеләр.
— Рәхмәт, сәламәт булсыннар. Әйдә, өйгә кер, әти.
Бүген этнография җәмгыятенең утырышы булганга, Закирҗан тоткарланган. Озакламый кайтыр. Хәерниса шуларны сөйли-сөйли табын әзерли башлады, әнисе турында сорашты.
— Әниең оныкларын бик сагынган, мине шул былбылларымны китер дип җибәрде. Мәрхабәбез дә бик ямансулый...
— И әти, Вәлидән хат бар. Безнең атка булгач, ачтык.
— Исән-саумы?
— Үзем таза, сезне сагынам дигән. Казанга күчүегезгә әйтеп бетергесез шатланган.
— Алайса, ярый. Мәрхабәне дә, әниегезне дә шатландырам болай булгач. Әниегез, бар да бар дип, колак итемне ашады. Җаны сизгән икән...
Ишегалдында балаларның шат тавышлары ишетелде. Әтиләре кайткан, балалар муенына асылынганнар. Закирҗанның өстендә тездән чак кына түбән җиңел җилән, башында кара түбәтәй. Мыек җибәргән. Кара мыек аңа бик килешә, әллә ничек мәһабәтлек өстәгән шикелле. Ул кайнатасы белән бик җылы күреште, гадәт буенча хәлә-хвәл сорашты, Вәлинең саулык хәбәренә без дә бик шатландык, диде.
— Мәрхабә тагын да шатланыр инде,— диде Әбелмәних.— Бая гына шулай урамда, капка төбендә, утырып торабыз. Әхмәт күгәрченнәр куа, әнисе каршы яктагы йортка нәүмизләнеп карап тора. Ни уйлавы мина, ата кешегә, билгеле бит. Анда малаен патша астырган матур хатын яши. Мин еракта гына урап, Әхмәткә әйткән булып, канат турында сүли башладым, этиең алып кайтмасмы, дидем. Мәрхабә тел төбемне әллә аңлады, әллә юк, эштән бик арып кайткан иде...
— Ул хатын турында, әткәй, еш сөйлисезме? — дип сорады Закирҗан.
— Сүләмичә, кияү. Без бер урам кешеләре бит. Бигрәк тә хатыннар. Бер көннәрне әниегез дә ишетеп кайткан...
Закирҗан, торып, ишекле-түрле йөренеп алды, аннары тагын кайнатасы каршына килеп утырды.

— Син, эткәй, минем сүземне, зинһар, авырга алма, акыл өйрәтә дип тә уйлама. Минемчә, ул йортны яшерен шымчылар дүрт күз белән күзәтә торганнардыр. Аңсыздан ул бичараларга зыян итеп куймагыз, дим.

— Аңлашыла, кияү,— диде Әбелмәних сүзсез торганнан соң.

— Син миңа ачуланма, эткәй.

— Юк, мин үпкәләмим, кияү.

— Нигә соң тавышың үзгәрде?

— Кызганыч бит.

— Кызганыч кешеләр дөньяда күп, эткәй. Бу заманда кеше үзенең чын уйларын, чын хисләрен ачыктан-ачык күрсәтмәскә тиештер. Ирексездән суфи булырга... Төшенәсеңме?

— Төшенмичә...

Хәерниса кухняда самавар кайната иде. Ул олы якка кергәч, сүз инде бүтәнгә күчте.

Чәйләр эчкәннән соң, Әбелмәних абзый урыныннан торды.

— Ярый, бик рәхмәт, миңа кузгалырга вакыт. Оныкларымны җибәрәсезме әбиләренә? Бик сагынган үзләрен, теленнән салмый.

— Мәшәкатьләр бит, эткәй,— диде Хәерниса.

— Һай, кызым, юкны сүләмә. Балалар үгә бәхет кенә китерә.

— Барсыннармы? — диде Хәерниса иренә.

— Әлбәттә,— диде Закирҗан.— Мин Тимергали абзыйга кереп чыгыйм, аты белән илтеп куймасмы балаларны. Ә җомга көн үзебез барып алыр идек.

Балалар шатлыкларыннан, яшь бәрәннәр шикелле, сикерешә башладылар. Озакламый Закирҗан кайтып керде. Тимергали хәзер атын җигә, диде.

— Мин үзем дилбегәне тотам! — дип кычкырды Хәлил.

### 3

Володя апасы Анна тора торган бер катлы агач флигельдән чыкты да, бакча түренә үтмичә, Үшнә суы буена төште. Монда тегермән буасы булганга, елга мул сулы булып күренә. Володя әрәмәле яр башыннан елгага уйчан гына карап торды. Бернечә ай гына элек гимназияне тәмамлаган, бераз арыган һәм талчыккан Володя табигать кочагында — Кокушкино авылы табигатенең матур бер җирендә иде — колын кебек чабарга, уйнарга, бер нәрсә турында уйламаска тиеш иде кебек. Ул бит Үшнә буен, шуннан ук башланып киткән каенлыкны, кечкенә Кокушкиноны, бу вакытта инде чалара башлаган кырларны, урман кырыенда утлап йөргән көтүне бик сагынган, хәтта төшендә күрә торган иде. Володяны авыл халкы хыялый егет дип, төрле мәзәкләр чыгаручы дип атый иде. Ә быел ул уйнамый, шаямый, күзләрендә тирән сагыш һәм моң, иңнәрен хәсрәт йөге баскан. Шуңа күрә ул сөекле апасы һәм әнисе янында озак утыра алмады,— хатын-кызларның үз сүзләре бар,— Маняша белән Дима чыр-чу килеп уйнаган бакчага юнәлмәде, куләгәле сирень куаклары янына бармады,— күптәнме соң анда кулына кигап тоткан Саша уйланып йөренә иде, әле дә ул агачлар арасына гына кереп киткән төсле, хәлбуки... ул инде монда гомергә кайтмас. Нәрсәдер Володяның бугазын буып алды сыман, суларга һава калмады кебек. Чү, иңнәренә пиджагын салган, башын игән Саша су төбеннән бара түгелме? Менә ул аргы якка чыкты. Кокушкиноган күтәрелде...

Володя башын селкеп алды, хыялый күренеш юкка чыкты. Ул инде чын Кокушкинога карый: салам түбәле фәкыйрь өйләр, аннан-моннан корыштырган каралтылар, киң тармаклы агачлар, ак чәчле, киндер

кулмәкле, ялан аяклы берничә малай. Авыл уртасыннан үткән юлдан кемдер арбалы атта килә, янынннан көчек йөгерә...

Володя Үшнә буеннан китте, ап-ак каенлыкка барып чыкты, ак атлас кебек каен кәүсәләренә кулы белән кагыла-кагыла, әчкәрәк узды. Көн бик җылы, кояшлы; үлән арасында төклетуралар, аяк астыннан гына төрле кошчыклар пыр итеп очып китәләр һәм һавада эрегән кебек юк булалар. Шунда ук нәрсәдер күгәрчен кебек гөрләп җибәрде. Володя, туктап, тирә-ягына каранды, яфраклар арасында бернәрсә күренмәде, ә гөрләү шундый ачык ишетелде, әйтерсең колак төбендә генә иде. Володя куш каен кәүсәсенә сөялде, башын иде, озын чәче каерылып төште. Тагын йөзенә күләгә ятты. Ул, үзе дә сизмәстән, кулындагы үлән сабагын тешләре белән өзгәли башлады, өстендә кыек якалы, путa белән буган ак күлмәк, кара чалбар, аягында шиблет. Бер кулын чалбар кесәсенә тыккан.

Кинәт кайдадыр татарча җырлап җибәрделәр, Көе, сүзләре бик таныш:

Сары, сары, сап-сары
Сары чәчәк саплары.

Кем җырлый, кайда? Тукта, бу Баһави ич, көтүче малай! Элегрәк елларда җәйге каникул вакытында Володялар Кокушкинога килгәндә Баһави аларга гел шул җырны җырлый торган иде. Көтүче төшлеккә туктаган, сыерларының кайберсе яртылаш суга кергән, кайсылары яр буенда куаклар арасында ята. Баһави үзе ясаган чыбыктан курай тарта, я әлеге шул җырын җырлый. Володя ул чакта татарча күбрәк төшенә иде,— малай чакта бөтен нәрсәне бик тиз отасың бит, аннары Сембердә дә татарлар шактый, аларның көй-моңнары Володяның колагына ят түгел. Идел яры буенда, пристань тирәләрендә Володя әтиләре, бабалары янында басып торган, ялан аяклы, түбәтәйле татар малайларын күпме күрде тагы. Бирегә, Кокушкино янында, ярты чакрымда Апакай дигән татар авылы бар. Баһави әнә шул авылныкы.

Володя чынлабрак тыңлый башлады, җыр ишетелмәде, күрәсең, бая да ул күңелдә генә булгандыр. Баһави да юк инде, ул балалык истәлеге генә, хәзер көтүне башка бер кеше көтә. Бер көнне Володя көтү янына махсус барып Баһавины сорашты, бу көтүче аны белми иде.

— Кемгә булса ялчы булып ялланганды́р,— диде ул,— адәм баласы аю түгел, ул бармагын имеп тора алмый.

Володя кайчан җиргә утыргандыр — белми. Хәзер инде аның уйлары Кокушкинодан, Баһавилардан да еракта. Володя гимназияне туган шәһәре Сембердә тәмамлады, алтын медаль алды. Сембер каласы — дворяннар йорты, дворяннар оясы, аларның особнякклары анда шактый. Шәһәрнең уртасында атаклы Карамзин һәйкәле,— аны бирегә Кара Морза диләр. Идел буенда киләчәк буыннарга тере булып калган «Обломов»ның авторы Гончаров йорты. Рус телен, рус әдәбиятын үлеп яраткан Володя бу изге урыннарда еш була торган иде. Гимназияне тәмамлагач, якын танышлары аңа әдәбият буенча, я математика буенча белем алырга киңәш иттеләр, чөнки математикага ул бик сәләтле, әдәбиятны бик ярата. Ә ул, барлык танышларын шаккаттырып, юридик факультетны сайлады. Моның сәбәпләрен сорагач, Володя күпне күргән өлкәннәргә җавап бирде:

— Хәзер заманы шундый... Хәзер барыннан да бигрәк хокук фәнен һәм политик экономияне өйрәнергә кирәк. Башка вакыт булса, мин я математиканы, я әдәбиятны сайлар идем.

Өлкәннәр бу җавапны аңлап бетермәделәр, яшьләргә мода белән мавыгу хас нәрсә дип уйладылар. Володя мавыга идеме соң?

Володяның бөтен тәрбиясе революцион традицияләр рухында булды, 60 нчы, 70 нче һәм 80 нче еллар үзләренең бөтен ашкынулары һәм фаҗигалары белән алар өеннән чыкмады, яңгыр суы кебек Володяның бөтен тамырларына үтеп сеңде. Шуның өстенә, Ульяновлар гаиләсендә Володяның аң үсешен аерата тизләткән һәм аны бик яшьли җитлектергән авыр вакыйгалар бер-бер артлы булып кына торды: сөекле әтисе Илья Николаевич кинәт вафат булды, ул фаҗига басылырга өлгермәде, абыйсы Сашаны һәм апасы Аннаны кулга алдылар. Аннары абыйсын патшаны үтерергә әзерләнүдә гаепләп, башкалар белән бергә, Шлиссельбург крепостенда дарга астылар, апасы Аннаны сөргенгә озаттылар.

Әмма, чамасыз авыр булса да, тормыш дәвам итә иде. Алга бик зур мәсьәлә — Володяның укуын төгәлләү мәсьәләсе килеп басты. Башка урынга рөхсәт булмаганга, Володя Казан университетын сайлады, Мария Александровна улының теләгенә каршы килмәде, тиз арада өй әйберләрен сатып, бөтен балалары белән Казанга бара торган пароходка утырды. Әкрен генә Сембер каласы артка кала башлады, онытылмас Илья Николаевичның кабере дә яшел агачларга күмелә инде. Мария Александровнаның керфекләренә яшь эленгән, Ольга, Маняша һәм Дима әниләренә карап еларга торалар, Володяның кашлары кысылган, күзен әнисеннән алмый. Ул күңеленнән аңа соклана. Өйдәге сатылган әйберләрне кешеләр алып чыгып киткәндә дә, кайберәүләр юри кызганган булып кыланганда да, ул калтырамады, менә хәзер чит күзләрдән еракта да үзен никадәр нык тота. Аңа җиңел түгел, ләкин ул бирешми, сыгылып төшми. Аның матур йөзендә кыюлык, горурлык һәм язмышка буйсынмау. Тик Идел җиле генә аның киң эшләпәсенең кырыйларын һәм чәч бөртекләрен җилфердәтә.

Казанда Володя гаризасын университетка бирде, ләкин укырга алуларына бик ышанып бетмәде. Дөрес, аның алтын медале бар, характеристикасы яхшы, монда аның әтисе Илья Николаевичны беләләр, ул шул ук университетны тәмамлаган, аннары мәгърифәт өлкәсендә бик зур хезмәтләр күрсәткән, монда аның коллегалары байтак, шулай да Володя — патшага кул күтәрергә җыенган җинаятьченең бертуган энесе. Володя инде сизеп алды: әтисенең бик яхшы танышлары, белешләре дә хәзер аның балаларын, хәсрәтле әниләрен күрмәмешкә салыналар, я ясалма төчелек күрсәткән булалар. Бу читкә борылып үтүдән дә авыррак тәэсир итә, аларга бик каты итеп бер әйтәсе иде, ләкин Мария Александровнаның түземлелеге болардан мең мәртәбә өстен.

Тормыш шартлары шулай ук уйландыра. Гаиләнең бөтен килере — Илья Николаевич өчен ала торган пенсия. Мария Александровнага шактый авырга туры килә, ләкин ул балаларын сынык күңелле итәргә теләми. Бала чакта берәр җирең чатнаса, шаукымы гомергә бетми бит...

Вакыт байтак үткән, кояш кичкә авышкан, күләгәләр озынайган, эсселек басыла төшкән. Кайдадыр балта тавышы ишетелде. Володя урыныннан торды, шул тавышка таба китте һәм бераздан Апакай кырыена килеп чыкты. Балта тавышы тынды.

Авыл читендә тәбәнәк кенә, фәкыйрь генә бер өй, тәрәзәләре — карындык, казык башларында чүлмәкләр. Ишегалдының ихатасы-фәләне юк, анда ат-сыер түгел, кәҗә бармы икән. Өч-дүрт тавык, бер кызыл әтәч эре генә йөренә. Каен төбендә ак күлмәкле, ялпак түбәтәйле, яңа туган ай шикелле түгәрәк чал сакаллы карт, түмәр өстенә утырып, чабата үрә. Янында бик җитди кыяфәтле алты-җиде яшьлек өч бала, икесе — ир, берсе — кыз. Кыз бала озын чәчле, озын күлмәкле. Бер читтә әрекмән яфрагы белән каплап куелган чүлмәк, анда чишмә суы булса кирәк.

Володя бу картны элекке еллардан ук белә иде. Бу — Ильяс бабай. Володя аның белән исәнләште.

— Ә, знакум, Илья малае бит әле? — диде карт, кулын каш өстенә күтәреп.— Менә монда түмәргә утыр, гостем будешь.

Володя рәхмәт әйтеп, түмәргә утырды. Карт русча аз-маз маташтыргалый, дөресрәге, русчаны, татарчаны вата-сындыра, шулай русча сөйлим дип белә. Картның сөйләве бик сәер яңгыраса да, аның күләргә асла исәбе юк, ул бик житди иде. Володяны бабай бәләкәй чагыннан бирле белә, алар Кокушкинога ел саен диярлек киләләр, әнисе кыз чагын монда үткәргән, Кокушкинода гына түгел, Апакайда да аны ягымлы, әдәпле булганы өчен ярата торган булганнар.

— Батюшка помер дисең? Ай-яй жалкы. Яхшы кеше иде, жаныңа кирә иде. Минеке белән күпне говорил! Санап бетерә алмассың. Минеке нәрсә белә, шаляй-валяй, вот лапти үрә, ә Илья большой человек был... Менә оныкларым тиздән зур була, уракка бара, ялан аяк белән камылда йөрү, ай-яй! Карош будет лапти,— ул Володяга сыңары инде үрелгән чабатаны алып күрсәтте.— Моның белән плясать будешь, верны? — Ильяс бабай кеткелдәп көлде.— Әгәр сиңа шундый кәвеш кирәк булса, үземә әйтерсең, момент үреп бирермен. Раз и готово.

— Рәхмәт, бабай, кирәк булса әйтермен.

— Лапти карош, можно девка ходит, шыгыр-шыгыр, любой посмотри. Девка скажет: знам, Ильяс бабай рука. Карош чабата, прямо кәвеш. Ты знай кәвеш? Мулла надевай, бай надевай, кожаны такой, кароший такой. У нас кожа нет, чөнки аты-сыеры юк аның. Понимаешь? Бедный человек давно-давно жил трудно. Вот тянешь сюда, ай, не хватат, тянешь туда, опять коротка. Шуннан башын кашый, что делать, не поймешь. Мулла пойдешь — не знай, староста пойдешь, тоже не знай, а хто знай, чорт не знай. Староста менә мондый медаль күкрәгенә тага, бер пот булыр, ә башка пустой, вон как горшук-чүлмәк. Живай как хочешь, умирай как хочешь. Теге дөньяда, мулла әйтә, рай будет, карошо будет, прямо кесәл кушай, денег не спрашивай. Тик аннан берәү дә не шагай, мулла не знай правильно гаварит, не знай мало-мало врет. Муллалар алар хәйләкәр халык. Ә син, улым, нигә молчал? Яшь кешегә авызга су кабып тору ярамый. Смеят надо. Пусть враг плачет, нам туды-сюды смеять надо. Вот моя имя Ильяс, твой папа Илья. Значит, по нашему адаш, по вашему как — забыл. Только сапсим близко. Безнең халык калякал, йөрәктән-йөрәккә жепләр сузыла, ә карашо. Все понимай, русский, татарин, чуваш, чирмеш, еще хто. Менә сабыйлар гына аңламый. Өлкәннәр мыекка чорный. Чөнки без барыбыз нужа бабай шулпасын эчәбез. Дөресме? Как не правильно! Менә брала белый, не правильно гаварн нельзя. Чәй эчәсеңме, знакум? Старушка мамент кайната. Чәй урынына кипкән кишер яки кипкән малина. Ай, тәмле. Теләмисеңме? Как хочь. Ату старушка кликнем.

— Рәхмәт, бабай, рәхмәт.

— Менә жәй үтәр, кыш килер. Печька греть — старушка дело. Яшь егет ни эшләргә уйлый?

— Мин университетка укырга керергә уйлыйм, бабай.

— Тагын укыргамы? Ай-яй, много знай.

— Хәзер, бабай, күп белергә, күп өйрәнергә кирәк. Белмичә берни эшләп булмый.

— Әйе, белмәгәннәр башкаларны өйрәтә алмый. Рас. Тулькы син күп укыган бит. Адрес яза беләсең, писарь булсаң да ярый. Ә түрә булырга чәпчим белем кирәкми, башка да кирәкми, командуй направо, налево, горло надо, кричать надо, кулак надо. Пузо будет гора, усы тоже, начальство серчай, усы дергай, как исправник!

Картлар күп сөйлиләр, кайчак мәгънәсез сөйлиләр, әмма аларның сүзләрендә, килде-китteләр арасында, мәгънәлесе була, хакыйкать ярылып ята.

Володя урыныннан торды һәм авылга карады. Авылда, билгеле, нык, таза ихаталы йортлар да бар, мулласы-мәзине, байлары, старостасы авылның үзәгенә утырган, әнә кукраеп торган мәчет манарасы аларның хакимлеген күрсәтә. Озакламый кояш баер, манарадан кичке азан яңгырар, аннары көтү кайтыр, бала-чага авыл буйлап йөгерешеп сарыкларын, кәҗәләрен, сыерларын өйгә куар.

— Бабай,— диде Володя, урамга карый-карый,— мин Баһави турында сорамакчы идем. Белмисезме?

— Баһави... Әйтәм күз нурыңны түгеп урамга карыйсың. Белмим шул, хәзер кайдадыр ул. Ятим ул, сирота. Ә әпәй барыбер кирәк. Не знай ялчы булып ялланган, не знай көтүче. Ләкин Апакайда күренми. Болай ут малай, югалмас.

Володя Ильяс бабай белән ике куллап, татарча саубулашты, аннары бабасының утарына таба атлады. Апакайдан кичке азан тавышы ишетелә башлады. Володяга ул тоташ иңрәү булып тоела, башы да, ахыры да юк кебек. Володяның күргәне бар: мәчеткә карт-коры гына йөри, ахрысы, татарның барысы күңелендә, тышкы яктан ул дин кануннарын әллә ни сакламый. Володяның сораганы юк: Ильяс бабай мәчеткә йөриме, юкмы? Йөрми торгандыр, чабата үрүне артыграк күрә торгандыр.

Азан тавышы тынгач, Володя Ольга белән Маняшаның чыр-чуын ишетте. Анна да көлә. Туганнары белән бергә булгач, ул да кайгыхәсрәтен оныткан. Җанлы тормыштан, дусларыннан аерылып тору бу яшь кызга авырдыр. Хәзер — җәй көне, һәр төштә күңел юана, кардәшләре, туганнары, бигрәк тә сөекле энесенең бирeдә булуы бәхет, ә көз-кыш көннәрендә монда җан әсәре калмый диярлек, этләр өрә дә, ач бүреләр улый. Апакайда, Кокушкинода, керосин булмагач, халык иртә ята, төннәрен утардагы ялгыз тәрәзәдә генә ут җемелди.

Володя Үшнә ярына борылды. Су өсте шома, анда алы-кызыллы шәфәкъ чагылган, ярны куаклар каплаган, монда су кап-кара һәм бик тирән сыман. Вак балыклар уйный, су өстендә бер-берсе эченнән чыккан түгәрәкләр җәелә, ул да булмый, бакалар тилереп сайрап җибәрә. Елга буенда рәхәт салкынча, каяндыр җылы сөт исе килә, кайдадыр коры тизәк якканнар, әчкелтем төтене борынны яра...

### 4

Володя уянганда әле кояш чыкмаган иде. Берничә минуттан күзләре тагын йомылды. Әллә төнге уйланулары дәвам итә, әллә төш күрә иде. Идел ярларында сыек ак томан, ат кебек җигелеп бурлаклар көймә тарталар, йөрәкне парә-парә китерә торган моңлы җырлары ишетелә. Шулай җырлый-җырлый, дөресрәге, иңри-иңри, ак томанга кереп китәләр алар. Инде бурлаклар күренми, ак томан гына җәелә бара һәм ерактан килгән җыр авазы яр буе уфтангандай булып ишетелә. Мөгаен, бик күп еллар үтәрдер, ат кебек җигелгән бурлаклар чал тарихта гына калыр, ә җырлары һаман яңгырап торыр. Сыек ак томаннар ул җырны әллә кайлардан китерер, уйга калган сыман торган карт наратлар, карт имәннәр, аны исләренә төшереп, җилле кара төннәрдә, сөякләре сызлагандай, гөҗләрләр. Кеше тавышы гына, табигать музыкасыннан башка, бу сагышны, бу моңны, бу авыр хәсрәтне биреп бетерә алмастыр шикелле.

Ул да булмый, Хәсрәт елгасы дип аталган Идел ярында иненә иске чикмән салган, йөзен сакал-мыек баскан, чабаталы бер егет күренә, имеш. Ул әрнеп җырлыймы, сөйлиме шунда:

> Выдь на Волгу: чей стон раздается
> Над великою русской рекой?
> Этот стон у нас песней зовется —
> То бурлаки идут бечевой!..

Тагын бурлаклар, тагын җир-күк бергә инри, бергә сыкрый. Юк, моңа түзәргә мөмкин түгел, бу кешенең бөек исеменнән көлү, аны ин кабахәт рәвештә мәсхәрә итү, изү, таптау. Көчле бер ярсу белән Идел дулкыны ярга бәрелә, аннары мең-миллион тамчылар булып җилгә чәчри. Инде икенче, көчлерәк, дәһшәтлерәк дулкын ярга якынлашып килә, аның артыннан өченчесе, дүртенчесе... Ташкын ярны ашый!

Шул ярсулы дулкыннарга карап, яр буеннан Саша белән Володя бара, имеш. Саша ялан баш, коңгырт чәчен җил тузгыта, каеш белән буган ак күлмәген җил күпертә. Володя гимназист киеменнән, башында фуражка, аркасында китапларын салган букча. Ул каты җилгә иелми, тик күзләре генә кысыла төшкән. Алар киң Идел өстендә нәрсәдер күрәләр кебек. Давыл кошымы әллә анда?

Володя абыйсын бик ярата, эченнән аның белән чиксез горурлана, аңа соклана. Саша бөтен яктан аңа үрнәк. Әйе, ул акыллы, хисләре тирән, елмаюы якты, тик күзләрендә Володя әле аңлап җиткерми торган тирән сагыш һәм тәвәккәллек бар. Ниндидер пакьлек, затлылык, тугрылык сизелеп тора. Аңардан һич тә аерыласы, аның янынан һич тә китәсе килми, аның канат астына сыенып иден кебек.

Төштә, хыялда мизгелләр бик тиз алмашына. Саша янында ниндидер кыз бар. Алар Идел ярында түгел, җанга якын тыныч Үшнә суы буенда. Кем икән бу кыз? И-и, ничек танымый тора соң аны Володя: бу аның туганнан туган апасы Анюта Веретенникова ич. Саша аны хөрмәт итә, якын күрә, алар һәр вакыт икәү нәрсә турындадыр сөйләшәләр. Анюта, тулы исеме белән әйтсәк, Анна Ивановна, күз докторы. Ул күбесенчә, фәкыйрьләрне дәвалый, аларга һәр вакыт бушлай ярдәм итә. Бигрәк тә аны татарлар ярата. Ул аларны дәвалап кына калмый, хәреф танырга да өйрәтә. Ул татарча бик иркен сөйләшә, укый-яза. Үзе искиткеч кешелекле, сөйкемле.

Володяның алар янына йөгереп барасы килә, ләкин аны нәрсәдер тотып тора кебек. Ул куаклар арасына яшеренә. Сашалар каенлыкка кереп китәләр, Володяны күрмиләр, имеш. Володя инде чәчәк аткан сирень куагына карый, чәчәкләрнең нәфислегенә соклана, хуш исләрен иснн. Ул да булмый, агачлар арасыннан, оныгын нәртеп, түбәтәйле Ильяс бабай килеп чыга. Өйгә керергә кыймый, бакчада Володяны көтә, имеш.

— Вот карошний знакум,— ди ул Володя белән исәнләшкәч,— дочка мало-мало авырды, значит заболел. Күзе авырта, прямо беда. Синең апаң күз докторы, карамасмы шул сабыйны? Мин йомырка бирер идем, акчабыз юк. Булса, кызганмас идек. Дочка бик жалкы, прямо, эх, сердце рвется, дитя ведь. Сукырайса, кая бара...

— Хәзер мин Анюта апаны чакырып киләм. Шунда көтеп торыгыз.

Володя йөгереп китә. Менә каен урманы. Саша да, Анюта да юк. Кая киттеләр икән? Володя тагын йөгерә, туктап, кулын авызына куеп кычкыра, тагын йөгерә. Ул инде басуда. Монда тургайлар сайрый, зәңгәр күктә алар бер югары күтәрелә, бер түбән төшә. Әнә болыт чыккан, нинди куркыныч кара болыт ургылып-ургылып килә. Сашалар аны күрми торганнардыр, Володя аларга хәбәр итәргә тиеш, каты җил исә, дөнья карангылана бара...

Володя инде Үшнә буенда, болыт юк, җил басылган. Су кырыена кемнәрдер учак яккан. Сыек кына зәңгәрсу төтен күтәрелә. Учак янында беркем юк. Кая киттеләр болар? дип Володя тирә-ягына карана. Әрәмәлектән Анюта берүзе килеп чыга, йөзе сагышлы. Саша, Саша кайда? И, ул биек тау башына менгән, шуннан түбәнгә карап тора. Володя кычкыра-кычкыра аны чакыра, Саша нигәдер төшми.

— Син аны борчыма, Володя. Ул таудан безгә карасын... Синең йомышың бармы? — ди Анюта.

Володя аңа Ильяс бабай оныгы белән килгәнлеген әйтә. Оныгының күзе авырта икән.

— Әнә анда, бакчада, көтеп утыралар.

Анюта белән Володя инде бабай янына баралар.

— Исәнмесез, бабай! — ди Анюта татарча.

— Аллага шөкер, кызым,— ди Ильяс бабай түбәнчелек белән,— сине борчыдык бит әле. Минә кызчыгымның күзе авырта. Казан ерак, анда бара алмыйбыз, менә сиңа килдек. Гаеп итмә инде. Менә шул йомыркаларны ал, аз булса да күп итеп ал. Башка әйберем юк.

— Оныгыңны карыйм, бабай, кулымнан килсә, ярдәм дә итәргә тырышырмын, йомыркаларыңны алмыйм, карчыгыңа кайтарып бир.

Кызык, Володя барысын аңлый, имеш, нәкъ русча сөйләшәләр кебек. Анюта өч ай эчендә татарча сөйләргә, укырга һәм язарга өйрәнгән. Татар теле әллә ни авыр түгел, ди.

Анюта кызчыкны, кулыннан тотып, өйгә алып кереп китә. Ильяс бабай белән Володя баскычта калалар, бусагага утыралар. Ильяс карт башын салындырган.

— Менә йомыркаларны алмады доктор, азсынды, ахрысы,— ди Ильяс бабай, башын хәсрәтле генә селкеп.— Нишләргә инде? Акчам юк, каян алырга да аптыраган. Бала кызганыч. Күршеләрдә трахум көчле, аларда булгач, безгә дә килеп эләгә. Нишлисең, барыбызның тормышы бер чама. Инде ничек кенә бәхилләтим икән бу докторны?

— Борчылма, бабай, ул фәкыйрьләргә миһербанлы.

— Шулаен шулай, улым, бушка кем эшләсен... Андый хәл булмый бу дөньяда. Становой пристав соңгы тиреңне туный, актык җиз самавырыңны тартып ала, ә татар самаварсыз тора алмый. Муллага барсаң, сәдакасыз сакалын сыпырмый.

— Становой приставлар, муллалар башка алар,— ди Володя.— Алар кеше таламыйча яши алмый, Анюта кеше талауны хәрәмгә саный. Төшенәсеңме, иң зур хәрәмгә.

— Төшенәм дә... төшенмим дә... Соң бу доктор нинди кеше? Кеше түгелдер алайса, фәрештәдер,— ди Ильяс бабай һәм тагын башын кашый.

— Юк, фәрештә түгел, бабай, кеше ул.

Бабай әллә нинди хикмәтле сүзләр сөйләүче бу үсмергә озак карап тора. Аның карашы аптыраулы, ул ни дип әйтергә дә белми...

Володя кинәт күзләрен ачты һәм боларның барысы да төш кенә икәнен аңлады. Әмма бу төшнең чынбарлыктагы нигезләре бар: Ильяс бабай трахум белән авырган кызчыгын Анна Ивановнага күрсәтергә алып килгән иде, аның татарча белүе шулай ук хак. Саша белән Анютаның дуслыгы да хак иде. Тик хәзер Саша үзе... төштә күрергә генә калды. Әмма кайгыга бирелергә ярамый. Володяның күптән инде: без башка юлдан барырбыз, дип әйткәне бар. «Башка юл...» Күренәме ул? Күренми әле. Вакыт-вакыт теге-бу яклары гына ялтырап куя.

Кинәт аның күз алдына ап-ачык булып кызыл шарф килде. Аны яшьләр байрак итеп күтәргәннәр һәм шул шарф колонна алдыннан җилфердәп бара, яшьләрне үз артыннан ияртә. Бу инде хыял да, төш тә түгел, бу — булган хәл. Володяга моны иптәшләре сөйләде: былтыр

ноябрь аенда университетта студентларның бик зур демонстрациясе була, анда студентлар беренче тапкыр, байрак итеп, кызыл шарф күтәрәләр...

Володяның тизрәк университет залларына кайтасы килә. Анда давыл башланырга тора, ул Володяны да шунда чакыра — егет юлы данлы күрәштә, ди.

Володя урыныннан торды, киенде, өйдәгеләрне уятмас өчен, аяк очларына баса-баса, бакчага чыкты да кичтән укый башлаган китабын ачты. Башта күләгәдә йөри-йөри укыды, аннары урындыкка утырды. Әйе, гаделсезлек бик күп асыл ирләрне борчыган, алар аның эскәнҗәләреннән котылу юлын эзләгәннәр, утларга кергәннәр, эшафотларга менгәннәр. Соңгы минутта Саша нәрсә уйлагандыр, еракта томан эчендә ни күргәндер? Мөгаен, народниклар юлының дөрес көрәш юлы түгеллеген төсмерләгәндер. Ләкин батыр, намуслы кеше буларак ул иптәшләреннән аерылырга теләмәгән, иптәшләрең каршында намуссыз булып күренгәнче, дар элмәге мең мәртәбә артык...

Бераздан Володя янына апасы Анна Ильинична килеп утырды.

— Володя, син нигәдер начар йокладың. Бик күп уйланасыңмы әллә?

— Әйе. Төшемдә Сашаны, Анютаны күрдем.

— Кирәкми, Володя,— диде Анна әкрен генә.

Кояш минут саен югарырак күтәрелә бара, бүген бик кыздырыр, ахрысы, җил бөтенләй юк, һавада тожым җепләре оча. Кояш нурларында алар көмеш баулар шикелле җем-җем итә.

— Кайчак әллә нәрсә эшлисе. йолдыз кебек атыласы килә... Тик җирдәге тавышларны гына ишетмисе иде,— диде Анна, каядыр Үшнә буена караган килеш.

— Юк, Анна, җирдән аерылган хыялны, йолдызлар арасында очуны мин өнәмим. Көрәшче хыялы җир белән бәйләнгән булырга тиеш.

— Син, Володя, тиздән университетка керерсең. Анда — белем чишмәсе, әни әйтә, андагы белемне син бүтән бер җирдә дә ала алмыйсың, ди.

Володяның әнисенә хөрмәте чиксез зур, аның сүзен тотмауны ул түбәнлек саный иде. Анна Ильинична моны бик яхшы белгәнгә, сүзне юри әнисенә күчерде.

— Мин нигәдер борчыла башладым инде,— диде Володя уйчан гына.— Гариза биргәнемә күпме вакыт булды, әле бер хәбәр юк. Минем Сашаның энесе булганым өчен генә дә куркалар бугай. Үзәк университетларга миңа юл ябык икәнен әнигә бик ачык төшендергәннәр. Күрәсең, Казан университетының да ишекләрен ябарга уйлыйлардыр.

Володя белми иде: Казан университетының ректоры Кремлев әфәнде бу вакытта аның гаризасына «характеристика килгәнче кичектереп торырга» дип резолюция салган иде. Алмаска хаклары юк, Ульянов гимназияне алтын медальгә тәмамлаган, ләкин университет җитәкчеләре һәр очракта җаваплылыкны үз өсләреннән төшерергә телиләр иде.

— Әйе, алар «дәүләт җинаятьчесенең энесеннән» ераграк булырга тырышачаклар,— диде Анна Ильинична.— Ләкин күңелем сизә, алар сине университетка алмый булдыра алмаслар...

— Тыныч кына укырга ирек бирерләрме?

— Бу, Володя, күп нәрсәләргә бәйләнгән. Әнә Ольга безне чакыра килә. Әйдә,— дип, Анна беренче булып аякка басты.

Володя апасын хөрмәт итә һәм ярата иде. Аның Саша белән бергә эшләве, бергә хөкем ителүе апасының дәрәҗәсен энесе каршында берм-бер күтәрә, Анна белән сөйләшеп утыру, кайчакта җиңелчә бәхәсләшеп алулар җанга гаҗәп күп азык бирә иде. Аннаның холкы әйбәт, ул һәр вакыт тотнаклы, чамасыз авыр минутларда да дәрәҗәсен саклый белә. Дөрес, Володя аның бу матур сыйфатының инде какшый

башлавын да күрә. Төрмәдә утыру, Саша фаҗигасе, үзенең каты хөкемгә дучар булуы, сөргендәге ялгызлык эзсез үтмәгәннәр. Аннары, яшь аермасы да үзен сиздерә. Володя күбрәк сеңелесе Ольганы ярата. Ольга шул хәтле саф күңелле кыз, тормышны искиткеч ярата, сихри музыканы үлеп сөя. Күченү котылгысыз булгач, Сембердә алар бик күп нәрсәләрен саттылар, әмма рояльне — борынгы зур рояльне Казанга алып килделәр. Әнисе яки Ольга уйнап җибәргәндә Володя җаны-тәне белән бирелеп тыңлый. Ул музыка җанлы, нечкә хисле егет. Сембердә чакта алар бөтен гаиләләре белән, бик зур бәйрәмгә барган шикелле, музыка кичәләренә йөриләр иде. Казанда театр дөньясы булса да, аларның әле театрга барганнары юк. Казан театры бик атаклы, монда мәшһүр артист, артисткалар җырлый. Урнашып, башкүз алгач, театрга һичшиксез йөрерләр.

Җәй көне Кокушкино бик ямьле, аннан аерылып китү, Аннаны ялгызын сөргендә калдыру бик авыр, ләкин, нишлисең, кайтырга кирәк. Тормыш дәвам итә, аның бетмәс-төкәнмәс яңа мәшәкатьләре калка тора, искеләре тиз генә онытылмаса да, кичәге көн кебек, артка чигә, теләсәң-теләмәсәң дә моның белән исәпләшергә мәҗбүрсең.

Елашып, саубуллашып, тиздән шатлыклы көннәр киләсенә өмет баглап, кайтырга чыктылар. Кырлар, кырлар. Уракка төшкәннәр инде. Урылмаган җирләрдә арышлар куян куа. Киң кырда, иксез-чиксез басу юлында арышларга карап баручы күңелне әллә нишләтә, сагышларны тарата, үзенне диңгез уртасыннан юл ярып баручы итеп сизәсең. Монда ирек тойгысы көчле. Рухың азат, урман буйлап үткәндә кошлар шуңа мәдхия җырлый кебек.

Вакыт-вакыт атларны туктаталар. Балалар, юлдан ерак китмичә, чәчәк җыярга керешә. Ольга чәчәк җыярга бик ярата, чәчәкләрнең әллә нинди матурларын таба. Маняша апасына охшарга тырыша. Дима кош оялары эзли.

— Кошчыкларга тимә,— ди Ольга, җитди кисәтеп.— Кошчыкларга карата гадел булырга кирәк, чөнки алар үзләре бер начарлык та эшләмиләр.

Тагын әкрен генә кузгалалар. Арттагы атта баручы Ильяс бабай үз алдына борын эченнән генә татарча җырлый. Сүзләре аңлашылмый, моңы йөрәккә сылана, әллә нинди тылсымлы әкият сөйли кебек. Халыкның гасырлар буе сакланып килгән раушан хыялы да, өмете дә, киләчәккә ышанычы да бар кебек анда.

Алдагы атта балалар белән Мария Александровна утырган, арттагы атта — Володя белән Ольга. Ольга ничектер үз эченә йомылган кебек, ул Анна турында уйлана бугай. Бер үзенә аңа кыен, күрше авылларга барырга рөхсәт юк — ул полициянең ачык күзәтүе астында тора. Хатларын, әлбәттә, барысын укыйлар. Шуңа күрә бик язасы килгәндә дә яза алмый, ә аның дуслары белән уйларын, серләрен бүлешәсе килә торгандыр, барысын да күңелгә бикләп саклавы бик авыр бит.

Володя кулын иягенә куйган килеш басуларга карап бара. Еракта авыллар күренә. Казан тирәсендә, егерме биш-утыз чакрымда, татар авыллары юк. Дөресрәге, кайчандыр булган, соңыннан татарларны аннан куганнар, кайбер авылларның рус теленә яраклаштырылган иске татар исемнәре генә сакланган. Патша хөкүмәте, үзенең мәгълүм колонизаторлык политикасына нигезләнеп, анда русларны китереп утырткан, татар рухын бетерергә тырышкан, ләкин моны хәтта миссионерлар да җуя алмаганнар.

Үзе дә азатлык яратучы рус халкы, башкаларга азатлык бирмичә, үзенең бөек тарихи миссиясен үти алмас, дип уйлый Володя. Аның уйлары еракларга китә дә тагын шул ноктага әйләнеп кайта. Әле күп нәрсә ачык түгел, болар бары тик фрагментлар гына.

Еракта, рәшә эчендә, инде Казан күренә. Кояшта чиркәү манаралары ялтырый, салмак жил белән чан тавышлары ишетелә. Ильяс бабай иреннәрен чупылдатып атын әйди. Ат болай да кызурак атларга тырыша, кигәвеннәр бик күп, алар хайваннарга тынгылык бирми, канга батырып бетергәннәр, атлар туктаусыз койрыкларын селки, башларын чайкый, пошкыралар.

— Володя, беләсеңме, мин әллә төш күрдем, әллә онытылып киттем,— диде Ольга, алга карый-карый.— Моннан якында гына Себер тракты уза бит. Шул олы юл буйлап декабристларны, азатлык сөюче башка революционерларны каторгага куганнар. Бу изге юл, без туктап аңа баш иярга тиешбез!

— Әйе! — диде Володя.— Рәхмәт сиңа, Оля, искә төшердең.

Менә Кокушкино юлы Себер трактына килеп кушылган җирдә алар арбадан сикереп төштеләр һәм абыйлы-сеңелле буш юлга карап башларын иделәр. Колакларында богау тавышлары чыңлады. Ике яшь җан бөек хәсрәт йөген тартып барган, залимнарга буйсынмаган тоткыннарны өндәге кебек ачык күрделәр. Аларга күңелләрен күтәрә торган итеп нәрсәдер кычкырасылары, без сезне мәңге онытмабыз, дип әйтәселәре килде.

Товарищ, верь: взойдет она,
Звезда пленительного счастья...—

дип яттан әкрен генә шигырь укыды Ольга.

5

1887 елның 13 августында Владимир Ульяновны университетка кабул иттеләр, ә 25 августта инде укулар башланды. Беренче лекцияләргә Володя гаять зур күңел күтәренкелеге белән йөрде, университет коридорларыннан үтү, аудиторияләргә керү, китапханәләренең ишекләрен ачу — болар бар да ниндидер эчке мәгънә белән тулы, күңелдә әллә нинди якты хисләр уята, укытучыларга, мәһабәт профессорларга караганда, бигрәк тә лекцияләрен тыңлаганда үзенне гаҗәп бәхетле сизәсең. Монда бар да яңа, серле, хыялны уйната. Володя инде студент! Алмаслар дип хәтсез күп борчылулары да онытылган инде!

Профессор Загоскинның «Рус хокукы тарихы» һәм «Хокук энциклопедиясе», профессор Дормидонтовның «Рим хокукы тарихына» дигән лекцияләр курсы башта ук Володяның күңелен биләп алды. Тора-бара, күнегә, иялэшә төшкәч, хисләр беркадәр басылгач, бу ике галимнең шәхес буларак кына түгел, дөньяга карашлары ягыннан да ике төрле булуы күренә башлады. Загоскин заманның күренекле җәмәгать эшлеклесе, студентларның «кумиры», бик күп гыйльми хезмәтләр авторы һәм «Волжский Вестник» газетасының мөхәррире. Экстраординарный профессор Дормидонтов исә юридик фәннәрнең рәсми вәкиле, Загоскин шикелле либераль түгел, коры, салкын бер кеше.

Володя студент иптәшләрен дә беренче көннәрдән үк җентекләп күзәтә башлады. Аларның күбесе — разночинец балалары. Бигрәк тә алар ике факультетта — медицина һәм юридик факультетларда күп икән. Рухларында бунтарьлык көчле. Бу нәрсә тәнәфес вакытындагы үзара сөйләшүләрендә үк сизелеп торды. Билгеле, патшага кул күтәрергә җөрьәт иткән Саша Ульяновның энесенә күпләр ачыктан-ачык сокланып карый, кырын караучылар да юк түгел иде. Бу Володя өчен көтелмәгән хәл булмаса да, аны җыйнаграк булырга мәҗбүр итә иде.

Бер караганда Володя үзенең иң бәхетле көннәрен кичерә иде кебек. Ул үзенең беренче теләгенә иреште, университетка керде. Хәзер аның алдында уку бурычы гына тора. Университетта укуга чиксез

житди караган кешегә моннан да зур бурыч булуы мөмкинме? Берничә көн генә элек ул «бернинди түгәрәкләргә катнашмам» дип кулыннан язу да бирде.

Володяның университет тормышына хөрмәте бик зур иде. Университетларга кертелгән яңа устав аның демократик хокукларын бик нык киссә дә, аның күптәннән килә торган барлык яхшы традицияләрен бетермәгәндер дип уйлый иде ул. Бик кыска вакыт эчендә моның нәкъ киресен күрә башлагач, Володя, табигый, уйга калды. Ул озак баш ватты, ләкин бу уйларын ачыктан-ачык иптәшләренә әйтә алмады. Студентлар арасында уй бердәмлеге юк иде. Бердәмлек яшерен түгәрәкләрдә генә булуы мөмкин. Һәм Володя, вакытны әрәм итмичә, шул түгәрәкләр белән бәйләнешне эзли башлады.

Көннәр үтте.

Бүген университеттан кайтканда Володя Лядской бакчасында утырып торды. Көз инде үзенең сары сулышын яфракларга өреп өлгергән. Һава да ямансу бер сагышка өртелгән кебек. Кошлар җылы якларга китәләр, зәңгәр күктән аларның саубуллашу җыры ишетелә.

Володя да нәрсә беләндер саубуллаша һәм нәрсәгәдер хәзерләнә иде кебек. Ул яңа адымының җитди һәм куркыныч буласын белә, ләкин аны атламыйча булдыра алмый иде. Бәлки шуңа, озын, мәшәкатьле юл алдыннан тын алыр өчен, бакчада утырадыр да ул.

Тагын берничә сәгатьтән Володя якташ студентларның «иң куркынычлысы һәм зарарлысы» дип саналган Сембер-Самар землячествосының утырышына катнашырга әзерләнә, Сембер егетләре Володяга азмы-күпме таныш, ә Самарныкылар?

Володя урыныннан торды, тагын бер тапкыр кичке кояш яктырткан алтын-сары агач башларына, салкын зәңгәр күктәге китеп барган торналарга карап алды. «Хәерле юл сезгә!» диде егет эченнән.

Володялар күптән түгел генә яңа квартирга күчкәннәр иде. Хәзер алар бер башы Беренче тауга барып чыга, икенче башы менә шушы бакча кырыннан үтә торган Яңа Комиссариат урамында торалар. Бер катлы кечкенә генә агач йорт, бәләкәй генә ишегалды, җыйнак кына бакчасы бар.

Ольга, Маняша һәм Диманың тавышлары ишетелми, берәр яры чыгып киткәннәр, ахрысы, энисе — өйдә.

— Володя, кайттыңмы? — диде ул, улын каршы алып.

— Кайттым, эни.

— Ашыйсың киләме?

— Бик.

Мария Александровна улына кайнар шулпа, икмәк, ит һәм җимеш суы китереп бирде. Үзе дә өстәл янына утырды. Бу кыска вакыт эчендә Володя никадәр ябыкты, уйчанланды.

— Володя, укуларың ничек бара? — дип сорады Мария Александровна сабыр гына.

— Бара, эни.

— Баштарак син дәртлерәк йөри идең түгелме?

— Хәзер дә дәртем сүнмәгән... Рәхмәт, эни, ашың бик тәмле.

— Аш булсын.

Володя чын уйларын энисе белән дә бүлешә алмады. Ул бит анын өчен никадәр тырышты. Нигә аны борчырга?

— Эни, газета бармы?

— «Волжский Вестник» килде.

Володя газетаны караштыра башлады. Ул инде игътибар итеп өлгергән иде: «Волжский Вестник» еш кына уйга һәм җанга азык бирә торган төпле мәкаләләр, ара-тирә хикәяләр, фельетоннар баскалый. Аларның әдәби кыйммәтләре әллә ни югары булмасалар да — хәзер Казанда зур язучылар юк диярлек — әдәби формаларда бүгенге

заманның иң кыю фикерләрен үткәреп була. Бу — газетаның мөхәррире профессор Николай Павлович Загоскинның «сукырлыгы» дигән иде бер рәсми тәнкыйтьче. Кайчагында «реакционерлар да» укучыларның игътибарын кирәкле нәрсәгә юнәлтә беләләр. Володя газетаны караштырган саен шуны истә тота торган иде.

Володя урыныннан торды, сәгатькә карады, аннары энисенә иптәшләре янына барасы барлыгын әйтте, сон кайтса, борчылмавын үтенде. Үзе чак кына кызарды. Ул бик җитди иде, балалык иллюзияләре артта калды инде.

Алдан билгеләнгән урынга алар иптәше белән икесе бер үк вакытта диярлек килеп җиттеләр, аннары очраклы күрешкән дуслар сыман бергә киттеләр. Шәһәр урамында парлап-парлап яки төркем-төркем йөргән студентлар азмыни? Беришеләре тегеләй бара, беришеләре болай килә, үзара көлешә-көлешә сөйләшәләр. Яшьләргә дөнья рәхәт, таныш кызлары килеп чыкса, нәзакәтлек белән баш ияләр, аннары шул нәфис кызлар турында аларны фәрештә итеп күккә чөеп сөйлиләр. Алар чамасыз шат та, Байроннар, Лермонтовлар кебек сагышлылар да. Володялар тыштан алардан бер яклары белән дә аерылмый, тик чатка борылганда гына тиз-тиз як-якларына карап алалар: артларыннан берәр шымчы-фәлән иярмәгәнме?

Алар шәһәр читендәге бушлыкка караган бер йортның подвалына юнәлделәр. Подвалның тәрәзәләрендә ут-мазар күренми, гомумән бу йортта торучылар бармы-юкмы — анысы да билгесез, һәрхәлдә, аларга бер җан иясе очрамады. Ишек төбендә беркадәр каранып һәм тынлап торгач, эчкә керделәр. Беренче бүлмәдә «тычкан күзе» генә яна, бер кеше юк. Икенче бүлмә шактый иркен, якты, анда студент яшьләр тулган иде. Керүчеләрнең аяк тавышлары ишетелгәч, ишек төбендәге бер студент аларга каршы күтәрелде. Алар пароль әйтергә тиеш иде бугай. Володяның иптәше чыннан да шыпырт кына нәрсәдер әйтте, әмма әлеге студент Володяга карый бирде.

— Үзебезнеке,— диде аңа Володяның иптәше.

Кемдер, Сембер егете булса кирәк, Володяны танып алды, янындагы буш урындыкны күрсәтте. Володя, аның кулын кысып, янәшә утырды һәм бирелеп тынлый башлады. Лампа янында сакал-мыеклы, күзлекле бер егет Плехановның «Наши разногласия» дигән брошюрасын кычкырып укый иде. Ул укып бетергәч, бәхәс купты. Белинский, Добролюбов, Чернышевский, Писарев әсәрләреннән озын-озын өзекләр китерә башладылар. Тынлаучыларның берише шунда ук сөйләүчегә ду килеп кул чапса, икенчеләре, сикереп торып, каршы сөйләп киттеләр. Володяны шунысы шатландырды: монда кешеләр үзләренең фикерләрен ачыктан-ачык әйтәләр, курыкмыйлар, як-якларына каранмыйлар, теге нәрсә әйтер дип көтмиләр иде. Яшьлек пыскып янмый шул!

Беренче дулкынлану минутлары үткәч, Володя өчен ике котып ачыграк күренә башлады. Берәүләр ду килеп народникларны яклый, аларның сүнә башлаган ялкынын дөрләтеп җибәрергә маташа, икенчеләр, яшьлеккә генә хас бер дәрт һәм тәвәккәллек белән Маркс, Энгельс тәгълиматын алга сөрәләр, аларның идеяләрендә чын яңалык күрәләр, яшьләрне шул идеяләр байрагы астына чакыралар.

Кемдер түземсезләнеп:

— Володя, сөйлә! — дип кычкырды.

Володя эндәшмәде.

— Саша Ульяновның энесе бирелә утыра...— дип пышылдаштылар.

Шуннан соң да Володя эндәшмәде. Ник? Яшьлеге белән шүрләп калдымы, әллә фикерләре өлгереп җитмәгән идеме?

Өйгә кайтып, йокларга яткач та, карангы түшәмгә карап, Володя шул турыда озак уйланды. Сөйләү өчен генә сөйләргәме? Сашаның исеме белән үзенә авторитет казаныргамы? Юк! Сашаның якты образы күңелдә мәңге сакланыр, ләкин... ләкин Володя Саша юлыннан бармас. Куркыныч булгангамы? Бу юл яңа булмагангамы? Вак хисләр!..

Бер көнне Володя түзмәде, әнисенә үзенең түгәрәккә йөри башлавын, башкача булдыра алмавын әйтте. Түгәрәктән алып кайткан китабын күрсәтте. Мария Александровна кулдан күчереп язылган бу китапка озак карап торды. Мондый китапларның матбагада басылмавын, халык арасында таратылмавын ул аңлый иде. Ана йөрәге икенче улының да язмышы өлкән улыныкына охшау ихтималын сизде, ләкин сөекле улын күз яше белән ялварып бу һәлакәтле юлдан кире чигермәде, тик иреннәре генә калтырап китте һәм ул:

— Володя, сөеклем Володя! — дип пышылдады.

Володя бу минутта ана йөрәгенең никадәр тирән борчылуын да, улына бу юлда бары тик бәхет кенә теләвен дә бик яхшы тойды. Әнисе аңа мең тапкыр кадерлерәк булып китте, аңа нииндидер бик зур изгелек эшлисе килде. Әмма аңлы рәвештә көрәш юлына басудан да изгерәк адым бармы? Дөрес, ул гомерен бер сөекле әнисенә генә багышлый алмас, киресенчә, аңа бетмәс-төкәнмәс борчылулар гына китерер, әмма бу җир шарындагы барлык аналарның бәхете өчен кирәк. Гафу ит, сөекле әнием!

Мондый газаплы әзләнүләр, уйланулар тиз генә үтеп китмәде, алар университеттагы лекцияләр барышында да, өйдә китап укыганда да, яшерен түгәрәкнең ишеген ачканда да, искә төшеп, җанны айкап алалар иде. Бер нәрсәдән курыкмый торган таш кешеләр юк, әмма аңлы көрәшчеләр бөек максат бәрабәренә ул куркуны басалар, еракка карак яшерә беләләр. Аларның батырлыгы шунда. Югыйсә, карап торырга алар бер дә пәһлеван түгел.

Володя бик тырышып лекцияләргә әзерләнде, конспектлар язды, экономик мәсьәләләр буенча китаплар, мәкаләләр укыды, дәреслекләргә күз салды. Аның тормышы хәзер ике ерганактан ага иде: университет һәм яшерен түгәрәк. Башка бер кешенең тормышында бу ике башлангыч тора-бара каршылыкларга очрар, берсе үзеннән-үзе төшеп калыр иде. Володя Ульяновның тормышында гаҗәп дәрәҗәдә эчке бердәмлек булганга, ул үзенә кирәк сабакны университетта да, түгәрәктә дә ала иде, тик вакыт бик аз, ә аңа белергә кирәк нәрсәләр исә ифрат күп, ифрат катлаулы, һәр туар көн аларны тагын да катлауландыра. Тимер түземлелек, ныклык һәм максатка юнәлгәнлек булмаса, бер нәрсәгә ирешә алмассың.

Якшәмбе көннәрдә Володя Казан урамнарына чыккалый иде, Идел ярына, Яна бистәгә бара, татар тормышына якыннанрак күз сала.

Володя һәм аның иптәшләре Крестовниковлар заводында һәм Алафузов фабрикаларында булгалыйлар иде. Анда җирле халык та байтак. Хуҗаларга бу файдалы, чөнки татар эшчеләренә, рус эшчеләренә караганда, шактый кимрәк түлиләр, нужа аларны шул кадәр изгән, алар көн үткәрсәләр, шуңа шатланалар, башкасын уйламыйлар да. Аларның укымышлары юк дәрәҗәсендә аз, бигрәк тә русча начар беләләр. Үзләренчә нидер укыган, язган булалар, мөгаен, корьән сүрәләредер.

Татарлар күп тора торган бистәләрнең бүтәннәрен Бишбалта һәм Ягодная дип атыйлар. Бишбалта русча бик сәер яңгыраганга, руслар аны күбрәк Адмиралтейство дип йөртәләр. Кайчандыр Петр I монда кораблар төзегән, хәзер бу җирләр Алафузов фабрикалары, казна заводы — Пороховой белән дан тота. Монда татар эшчеләре революцион хәрәкәткә дә катнашалар икән.

— Монысы бик тә яхшы, бик тә яхшы,— диде бер көнне Володя иптәшен тынлагач.— Капитализм төрле милләт эшчеләренә үзе үк сабак бирә, кемнәр аларның кан дошманнары, кемнәр жан дуслары икәнен күрсәтә. Әйе, әйе. Бер яктан, капитализм азчылык милләт эшчеләрен рус эшчеләренә каршы куя, русларга вак-төяк өстенлекләр биреп, менә сезнең чын дошманнарыгыз кемнәр, дип әйтә, икенче яктан, объектив үсеш законы бу сафсаталарның нәкъ киресен раслый, төрле милләт эшчеләрен бер-берсенә якынайта.

Бистәләр тормышы Казанның югары як тормышыннан үзенең фәкыйрьлеге, караңгылыгы, пычраклыгы белән аерылып тора. Монда, Идел һәм Казанка елгалары якын булуга карамастан, сулар өчен һава җитми, әллә нинди сасы ис борынны яра, өйрәнмәгән кешене хәтта укшыта да. Өйрәнгәннәргә берни түгел, ахрысы, тәбәнәк өйләре, бараклар каршындагы бәләкәй бакчаларда, изүләрен чишеп, чәй эчеп утыралар. Тула оеклы, түбәтәйле, ак түгәрәк сакаллы картлар гаҗәп дәрәҗәдә Апакайдагы Ильяс бабайны хәтерләтәләр.

Бишбалтадан кайтышлый яман атлы Мокрыйдан уздылар. Бу җирләр җәмгыятьнең ташландык базы, монда хәерчеләр, сукбайлар, монда ночлежкалар. Төннәрен монда иң түбән, иң хокуксыз, иң фәкыйрь катлау җыела, аларның кеше дип әйтерлекләре дә юк, тик мескенләнеп сөйләшүләре генә кайсы милләттән икәнлекләрен күрсәтә... Хәер биргән кешегә кайсы битен сыпыра, кайсы чукына һәм тегеләре дә, болары да нәрсәдер мыгырданалар. Әллә дога укыйлар, әллә сүгенәләр.

Мондый сәяхәтләрдән соң Володя, тормыштагы гаделсезлекләрне күз алдына китереп, тирән уйга чума иде.



## 6

Мәрхабә әкренләп Казанның шифаханәсенә ияләшә, күнегә башлады. Кайчак аңа монда Мәскәүнекеннән аермасы һич юк кебек тә тоела иде. Менә операция бүлмәсеннән Алексей Петрович килеп чыгар төсле. Монда да врачлар — әйбәт кешеләр, бигрәк тә карт хирург — һәйбәт, авыруларга бик игътибарлы, сестраларга таләпчән, гадел. Башта ул Мәрхабәне операция сестрасы итеп алырга һич теләмәде. Мөгаен, татар кызы нәрсә белә ул, операция бияләй ямау түгел, дип уйлагандыр. Соңыннан, Мәрхабәнең эшен күзәткәләгәч, хирургия сестрасы буларак белеме дә, тәҗрибәсе дә барлыгын күргәч, фикере үзгәрде. Ул гомумән татарларга каршы түгел, фәкать эшкә сәләтле булуын гына кайгырта иде. Моны Мәрхабә, хирург аны кабинетына чакыртып күзгә-күз сөйләшкәч, аеруча төшенде. Вадим Прохорович иң элек: «Кайда, кемнәр белән эшләдегез?» — дип сораштырды. Алексей Петрович Белоглазовның фамилиясен ишеткәне юк иде, ахрысы, шулай да, Мәрхабәгә калса, карт хирургның ихтирамы уянды шикелле, кырыс күз карашы йомшара төште.

— Миңа сезне татар кызы диделәр,— диде Вадим Прохорович, Мәрхабәгә туры карап,— русча ару сөйләшәсез. Бу гаҗәбрәк. Сезнең әти-әниләрегез кемнәр? — Ул эченнән аларның югары катлаудан булуын беркетеп куйган иде. Мәрхабәнең җавабы аны аптырашта калдырды.

— Һем... Ә русча кайда өйрәндегез?

Мәрхабә сөйләп биргәч, Вадим Прохорович:

— Сез мишәр кызымы әллә? — дип сорады.

— Әйе,— диде Мәрхабә, чак кына кызарып. Кара, моны татарлар гына түгел, руслар да белә икән. Әллә бер-бер гаебе бармы?

— Аңлашыла,— диде Вадим Прохорович.— Бездә элек тә татар хатын-кызлары булгалады. Алар санитаркалар, я кара эшчеләр иде. Бер врач та бар иде, ләкин ул... морза кызы иде.

Мәрхабә, операция сестрасы буларак, шактый нык холыклы, кыен минутларда аптырамый, каннан курыкмый, җирәнми иде. Дөрес, хирург аны мактамады, ләкин эшеннән канәгать иде булса кирәк, бер тапкыр да әрләмәде.

Мәрхабәнең авыруларга мөнәсәбәте башта ук әйбәт булды, ул аларга җикеренмәде, таләпчән һәм ягымлы булды. Хирургия бүлегендәге авырулар башкарак бит. Ихтимал, ярдәмгә күбрәк мохтаҗ булулары аларны шулай итә торгандыр. Пычак астына бик батыр кешеләр дә куркып яталар. Күбесенең чире соңгы чигенә җитә язган була, шуның белән алар үз хәлләрен үзләре бермә-бер авырайталар. Татарлар исә шифаханәгә гомумән кермәскә тырышалар, имче карчыклар табалар, әллә кемнәрдән өшкертәләр, әллә кайлардагы суфиларга, хәлләрәкләре ишаннарга, әүлия аталарга баралар. Мәрхабәнең ничәнче ай инде шифаханәдә бер татар күргәне юк иде.

Шуңа күрә күрше палатадагы студент:

— Минем күршемдә бер татар егете ята. Сүз кушам — җавап бирми, күрәсең, русча төшенми,— дигәч, Мәрхабә шунда ук авыру татар егете янына китте. Почмакта бөтенләй үсмер малай сыман бер кеше кулларын баш астына салган килеш ята. Йөзе уйчан, сагышлы, күзләрендә курку да, рәнҗү дә бар шикелле.

Мәрхабә аның баш очына килеп утырды һәм татарча:

— Абый, хәлегез ничек? — дип сорады. Егет, шифаханәдә татарча сүз ишетүенә гаҗәпләндеме, берни җавап бирмәде, бары тик күзләрен зур ачып Мәрхабәгә текәлеп карап торды.— Абый, сез борчылмагыз, терелерсез. Безнең докторлар яхшы.

— Син безнеңчә сөйлисең, каян беләсең? — диде егет ахырда.

— Мин татар кызы.

— Юк-к,— дип сузды авыру,— татар кызлары шифаханәләрдә булмый.

— Сезнең бер-бер йомышыгыз юкмы?

— Китегез моннан,— диде авыру әкрен генә, күзләрен йомды, нәрсәдер укына башлады.— Әлхәмделиллаһи...

Мәрхабә урыныннан торды да ишеккә юнәлде. Аның хәтере калмады, ул авыруларның психологиясен беркадәр белә иде. Әллә бу матур хатын аның авыруының серен белүдән шүрләдеме? Алексей Петрович әйтә торган иде: «Безгә авыруларның төрлесен күрергә туры килә, бар шундый авырулар, алар турында врач кабинетыннан башка бүтән бер җирдә дә авыз ачарга ярамый. Кешенең авыруы турында башкалар алдында лыгырдау — гайбәттән дә әшәкерәк. Медицина кешесе моны белергә тиеш».

Икенче көнне авыру студент — аның исеме Борис Рогачевский иде — Мәрхабәне тагын күрде. Ул төнне сызланып чыккан иде, күрәсең, чырае тәмам качкан иде.

— Гафу итәсез, сестра,— диде ул гасаби тавыш белән,— минем күршем һаман нәрсәдер сөйләнә, нәрсәдер әйтә, һич төшенә алмыйм. Тәрҗемәче эзләдем — таба алмадым. Шайтан белсен нәрсә бу? Цивилизацияле калада яшибез, имеш!

— Яхшы, Рогачевский әфәнде,— диде Мәрхабә тыныч кына,— хәзер безнең операция сәгатьләре башлана. Бушагач, керермен.

— Миңа, зинһар, әфәнде дип эндәшмәгез, җенем сөйми рәсмилекне. Яхшы кешеләр арасында мин — Боря, Борис.

Мәрхабә берни әйтмәде, операция бүлмәсенә ашыкты. Аннан ул төш вакытында гына чыкты, шактый арган иде. Шулай да авыру татар егете янына китте.

— Абый, сез нәрсәдер әйтергә телисез диделәр? Ни йомыш?
— Син тагын килденме? — диде егет һәм күзләрен йомып укына башлады, йөзе агарды. — Син адәми затмы?
— Әллә җен кызына охшаганмы? — дип, ихтыярсыз көлемсерәде Мәрхабә.
Егет тагын, бу юлы кычкыра төшеп, сүрә укыды.
— Корьән укыгач, җен югалырга тиеш, мин — югалмыйм ич.
Егет кычкырып укуында булды. Шул чакта палатага гасабиланып студент килеп керде.
— Казанда татарча тәрҗемәче эзлә, имеш...
— Эзләмәгез. Ул миннән сез әдәми затмы дип сорый.
— Нәрсә? Сез әллә аның белебардасына төшенәсезме?
— Мин татарча беләм.
— О, монысы бик яхшы. Димәк, сез ана әдәми зат булып күренмисез? — Студент көлеп җибәрде. — Ә мин бер-бер ярдәм кирәктер дип торам.
Мәрхабә аның сүзләрен егеткә тәрҗемә итте.
— Юк, кәфернең сүзе яхшы булса да, әһле мөселманга түгел, — диде татар егете һәм читкә борылды.
— Ул саташа бугай, — диде студент. — Әллә мәдрәсә шәкертеме?
— Белмим, әфәндем...
— Тагын бер тапкыр әйтәм: мин әфәнде түгел, ә Боря, Борис.
Мәрхабә кызарды.
— Гафу итәсез... Алла кушса...
— Нәрсә?! Белегез: мин — динсез. Христиан динен дә, ислам динен дә танымыйм, чөнки дин — опиум. Бер җирдә шуны ачыктан-ачык әйткән идем, минә кулымны сындырганчы кыйнадылар. Икенче шундый дәһри сүзләр лыгырдасаң, башыңны култык астына кыстырып җибәрербез, диделәр. Мин курыкмыйм, Җир барыбер әйләнә!
— Сез әллә нәрсәләр сөйлисез, мин аңламыйм, — диде Мәрхабә һәм тиз генә китеп барды.
Ике көннән татар егетенә операция булды. Ул шул кадәр курыккан иде, Мәрхабәне дә танымады. Соңыннан, үз палатасында, аңга килгәч тә беркадәр вакыт әйле-шәйле булып ятты.
— Беләм, син җен кызы, мине хак динемнән яздырмакчы буласың...
Бер атнадан егет тәмам кеше төсенә керде, Мәрхабә белән дә ипле генә сөйләште. Күрәсең, зиһенен алган куркуы кими башлаган иде.
— Сеңелем, — диде ул Мәрхабәгә, — мин сине кыерсыткан булсам, гафу ит. Минем әнием бар... Ул бик карт та түгел. Үзе бөтенләй диярлек күрми. Казанда татарча белә торган бер күз докторы бар икән, үзе хатын-кыз икән. Әнкәй әйтәдер иде: күренсәм, шул докторга гына күренәм. Мин ул докторны табармын дип вәгъдә бирдем. Белмисеңме — шул доктор кайда тора?
Мәрхабә белми иде, әмма эзләргә кирәк булмады. Шул ук көнне Мәрхабә бу турыда теге студентка әйткән иде, Рогачевский кычкырып җибәрде:
— О, мин ул докторны беләм! — диде. — Ул моннан ерак тормый. Профессорский тыкрыгында гына. Анна Ивановна Веретенникова. Татарлар аны чыннан да бик яраталар. Ул татарча белә. Кайдадыр татарлар арасында эшләгән. Ничек онытканмын.
Кич эштән кайтышлый, Мәрхабә Профессорский тыкрыгына кагылды. Биек яр башындагы ике катлы агач йортның беренче кат ишегендәге звонокны шалтыратты. Анна Ивановна аны кабул итү бүлмәсенә алып керде. Мәрхабә ана үзенең кайда эшләвен һәм үтенечен сөйләде. Веретенникова игътибар белән тыңлап торды да аннары әйтте:
— Бик яхшы, егет терелеп чыккач, әнисе белән бергәләп миңа килсеннәр. Мин көн саен дүрттән алтыга кадәр кабул итәм. Тик шуны-

сын җае белән төшендерегез: миннән могҗиза көтмәсеннәр, мин сихерче түгел, гади врач.
— Халык, Анна Ивановна, врачка я бөтенләй ышана, я бер дә ышанмый. Ышануы, артык булса да, яхшы. Безнең врачыбыз шулай әйтә,— диде Мәрхабә.
Анна Ивановна елмайды да: «Врачыгыз кем?» — дип сорады. Мәрхабә әйтеп бирде.
— Шулаймы? Вадим Прохорович белән бәхәсләшмим.
— Сезне, Анна Ивановна, татарча белә диделәр. Татар карчыгына врач ана телендә сөйләшсә, гаҗәп бит.
— Ә сез татарча беләсезме?
— Мин үзем татар хатыны.
— Монысы яхшы. Җирле халыктан врачлар да хәзерли алсак, медицина эше бик алга китәр иде.
— Хушыгыз, Анна Ивановна.
— Хушыгыз, үз җайлары белән килсеннәр.
Профессорский тыкрыгыннан Беренче тау ерак түгел. Тик башта тау астына төшәргә, аннары икенче тауга күтәрелергә кирәк. Мәрхабә Собачий урамы буйлап китте дә Аркылы Горшечныйга борылды. Салкын җил исә, агачларның берән-сәрән соңгы яфраклары да коела. Инде бер кар явып эрегән иде, тагын салкынайткан, көз шундый инде ул. Агачлар каралган, күк йөзе соры, юеш мамык кебек. Кояш ялтырап елмаерга өлгерми, көн тагын сүрәнләнеп китә. Иртә көздәге исәпсез-хисапсыз бизәкләр юк инде хәзер, җир тизрәк ак юрганын ябынырга җыена. Һавада тагын кар бөртекләре оча.
Собачийдан тауга менә-менә Мәрхабәнең яңаклары кызарып чыкты. Беренче тау урамына борылгач, бераз тын алды.
Мәрхабә өйгә кайтып керсә, аларда кунаклар бар икән — Хәерниса белән Закирҗан утыра иде. Закирҗанның итәгендә — Әхмәт. Торып исәнләштеләр. Әхмәт шунда ук әнисе кулына күчте.
Закирҗан белән Хәернисаның йөзләре шат иде. Мәрхабә моңа бик тиз игътибар итте.
— Әллә сөенечегез бармы, җизни? — диде ул, үзе дә көлемсерәп.— Йөзләрегез әмән айның ундүртенче кичәсе.
— Алай дисәң, әнә әткәй белән әнкәй дә елмаялар,— диде Закирҗан, мыек астыннан көлемсерәп.
— Әти белән әни сез килгәнгә кинәнгәннәрдер инде.
— Бак, анай, киявем белән кызыма сөенмәсәм, кемгә сөеним,— диде Айтүтә.— Син дә кичә генә игәченне сагынып сөйләдең ич.
— Ярый, Закирҗан, интектермә балдызыңны,— диде Хәерниса һәм Әхмәтне кулына чакырды.— Кил, улым, әниең хат укысын.
— Биетәсе иде балдызны, булмады,— Мәрхабәнең йөзе агарынуын күреп, Закирҗан тиз генә өстәде: — Син, балдыз, курыкма. Вәли исән-сау. Хат безнең атка язылган...
Мәрхабә хатны эләктерде дә икенче бүлмәгә чыгып китте. Ул ин элек үзенә дип аталган хатны укыды. Бүлмә эченә кояш тулгандай булды, колак төбендә Вәлинең тавышы яңгырады: «... Менә бер ел үтеп тә китте. Инде кайту айларын саный башладым... Барыгызны да сагындым... Улым зур булгандыр инде...»
Кинәт Мәрхабәне бик зур шатлык биләп алды, нәрсәдер бугазыннан кысты: «Исән-сау булсак, киләсе елның май-июнь айларында кавышмабызмы икән, дип өмет итәм. Элек торган җиремә җибәрмиләр, анысын кистереп әйттеләр, туган ягыма сорадым, анысына каршы килмәделәр шикелле. Ни булса да хәерлегә булсын...»
Мәрхабә олы якка чыкканда күзләрендә яшь бөртекләре җемелди иде.
— Я, күңелең булдымы, балдыз? — диде Закирҗан.

— Рәхмәт, жизни.
— Безгә ни өчен рәхмәт?
— Шатлык китергән өчен.
— Әгәр безнең ихтыярда булса, без, Хәерниса белән, көн саен шундый шатлык китереп торыр идек,— диде Закиржан һәм бераз уйлап торгач, болай дип өстәде: — Сиңа гына түгел, бөтен халыкка. Шатлык бергә-бергә булса күзгә күренә. Шулайдыр бит, әни?
— Әлбиттә, шулай, кияү,— диде Айтүтә.— Барәм бит халык белән генә күңелле. Я, ярый, утырышыгыз, чәйләрегез тала төшкән[1] иде, кайнарлаттым. Мәхүп, жизнәң белән игәчеңә каршы утыр, сагынышып беткәнсездер, ара якын булса да, күрешергә сирәк туры килә.
— Әбелфәриттән хат-хәбәр юкмы? — дип сорады Хәерниса.
Әбелфәритне солдатка алганнар һәм каядыр Варшау ягына озатканнар. Әбелфәрит, солдат итеп алсалар да, билгә каеш салдырмам, дип җырлый иде җырлавын, алгач салалар икән.
— Безгә юк шул, кызым. Мәскәүгә бер хаты килгән булган,— диде Айтүтә, күз төпләрен сөртеп.— Варшауда дисеңме әле, атасы? Анысы инде Алтыавылдан да ераграктыр?
— Варшау, анасы, Влиндордан, Алтыавылдан гына түгел, Мәскәүдән дә ары, Казаннан да.
Мәрхабә күз докторы Анна Ивановна Веретенникова янына барганлыгын әйтте һәм жизнәсеннән аны белүен-белмәвен сорады. Татарлар чыннан да аны яратамы?
— Татарлар аның өчен мөккибән китә инде,— диде Закиржан.— Син аңа ничек барып эләктең?
Мәрхабә сөйләп бирде.
Иртән Мәрхабә, ак халатын киеп, шәкерт абыйсын шатландырырга ашыкты. Палатага керсә, ни күзе белән күрсен, авыруның караваты буш. Мәрхабә туктап калды. Шунда аның янына студент килде.
— Кая ул? — диде Мәрхабә, буш караватка ымлап.
— Кайтмас җиргә китте. Төнлә сәгать икеләрдә, өчләрдә...— Рогачевскийның йөзе үзгәрде.— Мин бүген бер минут йоклый алмадым. Нәрсә бу? Кем аларны шундый наданлыкта, түбәнлектә, кыргыйлыкта тота? Кем моның өчен җавап бирә?
Мәрхабә, студентның сүзләрен тыңламыйча:
— Ә мин аны шатландырыйм дип килгән идем... Мин күз докторында булдым,— диде.
— Безнең тормышта шатлык һәр вакыт соңга калып килә. Уйласаң, без коточкыч тормышта яшибез. Моңа ничек түзәргә? Без кешеме, юкмы?!

## 7

Рогачевский терелеп чыгып китте. Киткән чакта ул әллә нәрсәләр сөйләп бетерде. «Бигрәк гасаби, ни сөйләгәнен дә белми. Ничек гомер сөрер»,— дип уйлады Мәрхабә һәм Вәлине исенә төшерде. Ул да бит гаделсезлекне яратмый, әмма ул — башка, өзгәләнми, аһ ормый. Аһ ору — аптырау билгесе. Вәли, Мәрхабәгә калса, нәрсәдер белә, шуңа күрә көлемсерәп йөри шикелле. Бу — гамьсезлек түгел, бу — йомыклык та түгел, бу ... Вәлинең укымышы юк, ул гади бер эшче, ләкин аңарда өзелми торган бер тамыр бар кебек, ул башкалар күрмәгәнне күрә кебек. Мәрхабә шундый кешенең якын дусты булуга эченнән горурланып куйды.
Татар егете үлгәннән соң байтак көннәр үткәч, Мәрхабә аның энисен эзләп табарга булды. Ул егеткә биргән вәгъдәсен онытмаган иде.

[1] Тала төшү — суына төшү.

Әгәр карчык каршы килмәсә, ул аны күз докторына алып барыр. Айтүтә дә кызының бу фикерен бик хуплады.

— Вакытың булса бар, кызым, бар,— диде ул чын күңелдән.— Кара, үз ягыбыз түгелме? Кайчагында үз ягыңның бер сүзен ишетергә зар буласың.

Әлеге татар егетенең әнисе кайдадыр зәңгәр мәчет янында тора икән. Мәрхәбә көч-хәл белән эзләп тапты. Яртылаш җиргә сеңгән бер катлы иске агач йорт. Күптән кар яуган булса да, ишегалдына җәелгән сары су әле катып бетмәгән. Мәрхәбә керер ишек таба алмыйча аптырап бетте. Яз-көз монда ничек йөриләр икән?

Ярым сукыр әби, кызыл бөрчекле яулыгын ябынып, берүзе өендә кыштыр-кыштыр килеп нидер эшләп йөри иде. Өй эче ярым караңгы, почмакларда нәрсә барлыгы да рәтләп күренми. Коточкыч фәкыйрь. Әбинең аягында иске ката, өстендә сәләмә кием. Идән әллә җир, әллә такталары шулай кырылып беткән.

Мәрхәбә ничек сүз башларга белмәде. Карчыкның йөрәгенә авыр булыр дип үзенең шифаханәдә эшләвен әйтмәде. Янәсе, карчыкның хәсрәтен күршеләрдән ишеткән. Аның таныш күз докторы бар, әгәр әби теләсә, аны шул докторга алып барырга дип килгән.

— И кызым, миңамы соң кеше яллап докторларга бару,— диде карчык хәсрәтле тавыш белән.

— Нинди кеше яллау ул, әби. Синең бер тиенең кирәкми. Мин бары тик кызганып кына килдем.

— Минем хәлне ходаем үзе яхшырак белә, кызганырга кирәкми, юкка мәшәкатьләнмә, кызым. Аның бит докторына, даруына түлисе була. Мин каян алып бирәм? Хәер сорашып, тамакка да җиткереп булмый. Менә мичкә ягарга утыным беткән, салкында туңып утырам. Докторлар, моның җылаучысы юк дип, газиз улымны суйган кебек, бугазларлар да ташларлар. Без бу дөньяда килмешәк. Тәкъдиремдә ничек язылган, шулай булыр, каршы килмим раббем әмеренә. Барма шул кафер йортына дип, улыма ничә әйттем, тыңламады, барды, яшисе килде, һаман яхшыны өмет итте. Бичарамны әҗәле тарткандыр... Үзең бик каты сөйләшәсең, Казанныкы түгелме әллә?

Мәрхәбә уңайсызланды, ни әйтергә белмәде. Шифаханәдә ул көннән-көн буе русча сөйләшә, өйдә үзләренчә, урамдагы татар хатын-кызлары белән күпме генә очраша? Шул сукыр әби сизәрлек булгач, каты сөйләшә торгандыр. Үзе сизми дә.

— Чистай ягыннан мин,— дигән булды, үзе уттай кызарды.

Шул чакта өйгә бер бөкре теләнчеме, дәрвишме килеп керде. Ул исәнләшмәде, сәлам бирмәде, әби дә аңа күтәрелеп карамады. Үзе туңган, өстендәге киеме чат сәләмә, башына, колакларына кара тастымал урап, мескен бүрек кигән, аягына чүпрәк чолгаган. Аны бер хәерче карчык дияр идең, кәҗә сакалы бар.

Мәрхәбә курка калды, күзләрен зур итеп ачып, керүчегә карап торды.

— Курыкма, кызым, мин угры да, юлбасар да түгел, алла бәндәсе. Кунар җирем булмагач, әби янына керәм,— диде карт хәлсез тавыш белән һәм каршы яктагы артсыз урындыкка утырып, башын кыйшайтты.

Бу өйгә кайчак эштән сөрелгән бичара асраулар елап кергәлиләр, аларның йөзләре шешенгән, күзләре кызарган була. Бу кыз еламый. Ник килгән соң? Шул турыда белешкәч, карт кулын гына селекте.

— Кысыр хәсрәт белән йөрисең икән, кызым. Әбигә доктор кирәкмени, ул ходайның соңгы әмерен көтә. Без, кызым, мәхлук, безнең бар хокукыбызны тартып алганнар, үзебезне, җаныбыз чыкмас борын ук, салкын баз төбенә ташлаганнар. Мин бер картны иртәп йөртә идем, үлде бичара. Җирләргә кәфенлеге, җеназасын күтәреп зиратка илтер-

гә кеше булмады. Ә ул яшьрәк чагында безнең авылдагы күн заводында иң яхшы рабочий-оста иде. Авыргач, бай заводыннан куып чыгарды, мине дә сөрде, егәрең юк синең, диде, ана аю кебек таза ирләр кирәк. Нишлисең, киттек Казанга... җәяүләп. Ә монда безне көтеп торганнар, ди. Казанның үз хәерчеләре йөзәрләп тә меңәрләп. Эш эзләп, каңгырып йөрүчеләрне әйтмисең дә... Бер урынга йөзләп керергә торалар, теләсә нинди эшкә риза. Эт тормышында гомер иттек, кызым, хәзер менә,— карт хәлсез кулларын тезләренә салды,— кыл өзәрлек егәрем юк. «Бирсәгезче бер тиен» дип, мәчет каршында торам. Белмисең син, кызым, ничек авыр кул сузып хәер сораулары... Ир-ат булсаң, йөрәгемдә күмерләнгән сорауларымны бирер идем дә, хатын-кыз булгач, ни әйтим, үзегез дә усак яфрагы кебек калтырап торасыз.

Операция булган көннәрдә Мәрхабә һәр вакыт шифаханәдә куна иде. Бүген төн тыныч үтте. Көндез, кайтырга җыена башлагач, Мәрхабәне чакырып алдылар. Көтү бүлмәсендә, аны күреп, студент Рогачевский урыныннан кузгалды.

— Исәнмесез, Мәри Михайловна.

— Тагын килеп җиттегезмени, сугыш чукмары? — дип елмайды Мәрхабә.— Соңладыгыз бит, врачлар кайтып киттеләр инде.

— Миңа алар кирәкми, Мәри Михайловна,— диде Рогачевский, тагын Мәрхабәнең тулы исемен кабатлап. Биредә аңа бу исем белән бер кем дә дәшми иде. Мәрхабәнең йөзенә гаҗәпләнү билгеләре чыкты.

— Гаҗәпләнмәгез,— диде студент җитди итеп.— Сезне бер Мәскәү танышыгыз күрергә тели, диделәр. Аның белән бергә сезгә таныш кешç булыр.— Ул күрешүнең урынын һәм вакытын әйтте.

«Нинди Мәскәү танышым? — дип уйлады Мәрхабә өенә кайтканда.— Берәр провокация була күрмәгәе. Анда мине эзләп полиция килгән булган бит. Аннары бу студентны ул бөтенләй белми. Нигә мәскәүләр бәйләнеш өчен мондый шикле юлны сайладылар икән? Берәр көтелмәгән хәл килеп чыккан булса гына...»

Өенә кайткач, Мәрхабә киемен алыштырды, әнисенә: Бер дустым килергә тиеш, әзерләнебрәк тор? — дип чыгып китте. Беренче таудан аска төшеп, Георгиевский буйлап бераз барды да Вознесенский урамына борылды. Ул, кайда да булса студент күренмәсме дип, каранып барды. Күренмәде. Ә Рогачевский аңа «Мәри Михайловна» дип мөрәҗәгать итүләрен каян белгән? Мәрхабә тагын шикләнә башлады.

Урам буп-буш диярлек. Тик аргы баштан болай таба бер аксак хатын белән бер татар кешесе килә. Татарны Мәрхабә бераздан таныды: бу Гыйльметдиннең энесе иде. Итче кебек кызыл йөзле, аны буташтырырга мөмкин түгел. Карчык кем булыр — һич таный алмады. Мондый аксак әбине Мәрхабәнең күргәне дә, очратканы да юк.

Вознесенскийда бүтән кеше күренмәгәч, Мәрхабә аларга таба атлады. Очрашкач, туктадылар.

— Әбине таныйсыңмы? — диде Гыйльметдиннең энесе.

Мәрхабә юк дип башын болгады.

— Яхшылап кара.

Карчык яңагын ача төште. Мәрхабә шаккатты. Бу Ольга Леонардовна иде. Аягы чыннан да аксый башлаганмы әллә?

Мәрхабә карчыкны култыклап алды.

— Әбине бер кич кунак итсәң иде,— диде Гыйльметдиннең энесе, янәшә атлый-атлый.

— Рәхәтләнеп,— диде Мәрхабә. Шуннан Гыйльметдиннең энесе үз юлына борылды, Мәрхабәләр Беренче тауга күтәрелделәр.

— Эни, бу без,— диде Мәрхабә эчтән кем бар дигән тавышка.— Хәзер керәбез.

Алар караңгы өйалдында озаграк торгач, Айтүтә кабат эндәште:

— Әллә күрмисезме, ут чыгарыйммы?

— Юк, юк, кирәкми, әни. Безнең сүзебез бар иде.

Ниһаять, алар саран гына яктыртылган өй эченә керделәр. Мәрхабә янында урта яшьләрдәге, күрер күзгә чибәр генә бер хатын басып тора иде. Ул аксак та түгел, бөкрәймәгән дә. Әгәр берничә минут элек бу хатынны Айтүтә күрсә, шактый куркыр һәм шикләнер иде. Болай ул бер шик уятмады.

— Исәнмесез, апа? — диде ул русча.

— Саумы, саумы, кызым,— диде Айтүтә дә русча. Аның елгырлыгы, ачык чырайлылыгы кебек үк, йөзенә чыккан иде.

— Әнкәй, әткәй кайда? — дип сорады Мәрхабә.

— Лаукага киткән иде, хәзер кайтып житәр.

Бер минуттан Әхмәт, уенчыкларын ташлап, кунакның итәгенә үк менеп утырды. Күрәсең, аны хатынның ялтыр төймәләре кызыктырды, бала шул төймәләр белән уйный башлады. Кырысрак сыман күренгән хатын бала янында бөтенләй эреде, ул аны иркәли, алма кебек кызыл битләреннән үбә башлады. Әхмәткә әйтерсең әллә ни булды, ул рәхәтләнеп көлә, кулларын чәбәкли башлады.

— Безнең Әхмәтебез ябдаш [1] бала да, начар кеше кулына бармый. Син, кызым, яхшы кеше икән,— диде табын әзерләп йөргән Айтүтә кунакка.— Үзеңнең балаларың бармы?

— Юк, апа, андый бәхеткә ирешә алганым юк,— диде Ольга Леонардовна, кызара төшеп.

— Хатын-кызны бала матурлата. Ирең яхшы кешеме?

— Начар дип әйтә алмыйм,— дип көлемсерәде кунак.

— Үзен хөрмәт иткән хатын ирен яманламас. Ирен яманлаган хатынның үзенең рәте шул гына. Я, ярый, чәйдән рәхим ит. Өшегәнсеңдер.

— Рәхмәт, апа.

Әхмәт әнисе кулына күчте, аннары әбисе итәгендә бераз уйнагач, янадан кунакка үрелде.

— Анай, кара,— диде Айтүтә, кулларын чабып,— бу кунагыбызны чыннан да үз итте, ахры. Сүзен дә төшенәме икән, бахыр?

Ольга Леонардовна елмаеп куйды. Мәрхабә аңа астыртын гына карап алды. Ул тыштан бик тыныч сыман, баладан башка бер гаме юк шикелле, ә эчтән бик киеренке: бүген ул уйламаган-көтмәгән жирдә төн үткәрә. Аңа билгеләнгән урынга барырга ярамый, аны көн-төн күзәтәләр, диделәр. Менә шуннан соң инде Ольга Леонардовна Мәрхабәне исенә төшерде. Иртәгә ул тагын башка бер жирдә кунар. Уйласаң, шулай: профессиональ революционерның сузылып ятарга жылы почмагы да булмый, ул һаман киеренкелектә, борчуда, минут саен куркыныч көтә. Аның Сергей Сергеевич белән тыныч кына чәй эчкәне булдымы икән? Ул бит Мәрхабәләргә кергәнче дә бүлмәнең тәрәзәләре кай якка ачыласын, ишегалдында ниләр барын һәммәсен белеште. Кирәк була калса, ул ике уйлап тормыйча шуннан файдаланачак, күз ачып йомганчы, билгесез караңгылыкка чумачак. Моңа гади бер нәрсә, көндәлек хәл дип карар өчен нинди йөрәк, нинди тәвәккәллек кирәк? Мәрхабә аның Казанга нинди йомыш белән килгәнен белми, ләкин бушка килмәгәнен төшенә. Сораштырырга ярамый, Мәрхабә аңа бары тик кулыннан килгәнчә ярдәм итәргә тиеш. Ихтимал, бу караңгы төндә полиция, бөтен Казанны айкап, «дәүләт жинаятьчесен» эзли

[1] Ябдаш — үз итә торган.

торгандыр. Ә ул итәгенә бала утыртып чәй эчә. Ризыгын бик сакланып кына каба, күрәсең, рәтләп ашаганы да юк.

Айтүтә, хатынның борчылуын сизеп:

— Син әзрәк, былбылым, Мәрхабә белән сөйләшеп утыр, мин хәзер кайнар аш өлгертәм,— диде.

— Әни,— диде Мәрхабә тиз генә,— кунагым бүген бездә куна. Ул Ягодный ягында тора. Мондый караңгыда анда ничек барасың.

— Бер кич түгел, икене, өчне кунсын. Үзенә уңайсыз булмаса, безгә һич комачауламый. Әнә картым да кайта.

Мәрхабә белән Ольга Леонардовна тиз генә икенче бүлмәгә чыктылар. Айтүтә аларның күзгә-күз карашып алуларын сизми калды.

Өс киемен салып, агара башлаган башына түбәтәй каплап, Әбелмәних абзый бүлмәгә керде. Шунда ук Мәрхабә аңа каршы чыкты.

— Әти, кайттыңмы? Әллә кар ява инде?

— Белмәссең, ярма сибәли әмән.

— Әти мин кунак алып кайткан идем.

— Бик яхшы булган.

— Таныштырыйммы?

— Килгән кунак белән танышу кирәктер.

Мәрхабә үз ягына кереп, Ольга Леонардовнаны ияртеп чыкты.

— Исәнме, бабай?

— Без, кызым, карт тирәк кебек, әкрен генә шыгырдыйбыз. Сез, яшьләр, бирешмәгез, утырыгыз.

— Эшләр ничек, бик кыен түгелме, бабай? Урамнар тынычмы, борчу юкмы?

— Урамнар тыныч, борчу юк. Исерекләр дә, болай йөзе каралар да күренми. Без читтәрәк бит.

— Елга аръягында әллә нәрсәләр сөйлиләр.

— Анда булыр, анда рабочийлар...

## 8

Айтүтә ишетеп торды: караңгы төндә алар бик озак пышылдаштылар. Нәрсә турында? Бер генә минутка булса да куркыныч янавын оныттылармы? Ольга Леонардовна үзен төнката эзләүләрен, полиция эзенә баса язганын белә, Мәрхабә, ихтимал, сизенә генә торгандыр. «Кирәк була калса, бер атна, артык та тор», дип пышылдады ул. Ольга Леонардовна бу яхшы кешеләрне кирәгеннән артык куркыныч астына куярга теләмәде, чөнки ул моның нәрсә икәнен бик яхшы белә иде. Аннары профессиональ революционер, куркыныч реаль булганда, үзе дә бер эзгә ике тапкыр басмый, бу — аларның язылмаган законы. Вәли турында пышылдашканда, Вәлине яңадан Мәскәүгә җибәрмәячәкләрен белгәч, Мәрхабәгә: «Кайгырмагыз, көрәш өчен кайда да урын бар»,— диде. Шул ук вакытта, хатын-кыз буларак, Мәрхабәнең ирен никадәр сагынып көтүен бик яхшы сизде. Алар, өйләнешкәч, бер ел бергә тордылармы икән? Моны бит әйтүе генә ансат, чынлыкта моны кабат кичерергә теләмәссең. Монда килгәндә Ольга Леонардовна бер нәрсәне анык белми иде: аерылышуны Мәрхабә ничек кичергән, Вәли ни хәлдә, аның рухы сынмаганмы? Каты сынауны бар кеше дә үтә алмый. Мондый чакта иң элек гаиләдәге бердәмлек чатный. Аннары хәзер революцион хәрәкәткә азчылык милләтләр кушыла башлады. Эшләр уңышлы барганда алар, билгеле, калтырамыйлар, ә эшләр кирегә китсә? «Бичараның башын бер ашадыгыз, икенче тапкыр эзегез булмасын!» — дип әйтүләре ихтимал бит.

Мондый үзгәрешне Ольга Леонардовна Мәрхабәдә аз гына да сизмәде һәм җиңел сулап куйды. Әти-әниләре дә салкын карамады.

— Миңа, Ольга Леонардовна, эшкә барырга вакыт. Чын күңелдән әйтәм, әгәр вакытыгыз сыйдырса, тагын бездә куныгыз,— дип пышылдады Мәрхәбә иртән.

— Рәхмәт, Мәри. Апа мине Суконныйга озатып куйса, шул җитә,— Ольга Леонардовна урамдагыниндидер тавышка колак салып торды да: — Урам хәлен белеп кер әле,— диде.

Мәрхәбә чиләкләр алып суга чыкты. Урам буш, тын, бер шикле кеше юк. Шактый салкынайткан, бераз җиле дә бар, яңак очларыннан чеметеп ала. Әтисе Әбелманих урам себерә — эш яраткан кешегә эш бетми бит.

Мәрхәбә су кертеп, урамның тыныч икәнлеген әйтте. Аннары әнисенә таба борылып:

— Әни, син кунакны Суконный чатына кадәр озатып куярсың инде,— диде.

— Ярый, ярый, борчылмасын. Тагын бер кич кунса да ярар иде, бик ошады үзебезгә.

— Вакыты юк, әни. Суконныйда бер танышын күрәсе бар. Аннары якты куздә Ягодныйга кайтасы...

Мәрхәбә белән Ольга Леонардовна үбешеп аерылдылар. Мәрхәбә шифаханәгә үзенең көндәлек эшенә китте. Шифаханәдә бар да тыныч, операция ясалган авырулар тын гына яталар. Мәрхәбә һәрберсенең караваты янына туктый-туктый хәлләрен сорашты. Тик берсе:

— Нигәдер тамак бик кибә, сестра,— дип зарланды.— Әзрәк су эчәргә ярыймы?

Мәрхәбә аңа берничә кашык су эчерде.

Сәгать уникеләрдә Вадим Прохорович килде. Өстендә — ак халат, башында — ак бүрек. Йөзе һәр вакыттагыча кырыс, торышында салкынлык. Мәрхәбә белә иде: бу тышкы кабык, асылда Вадим Прохорович киң күңелле, шәфкатьле кеше.

— Менә нәрсә, күгәрченем,— диде ул каршылык көтми торган кырыс, салкын тавыш белән бер авыруга,— мин сиңа үзең булышсаң гына ярдәм итә алам. Тереләргә теләмәгән кешене терелтеп булмый. Төн — йоклар өчен бирелгән, әллә нәрсәләр уйлау нигә?

Икенче авыру янына утыргач, Вадим Прохорович иң элек тәрәзә төбенә карады.

— Бу складны моннан алырга,— диде сестрага.— Күзем күрмәсен. Бу хәтле ашарга сәламәт кешегә дә ярамый. Исегездә тотыгыз, күгәрченем,— диде хирург авыруга,— әгәр ярылганчы ашыйсыз икән, мин сезнең врачыгыз түгел. Акланып маташмагыз, мин тыңламыйм.

Караватында сузылып яткан карт янында Вадим Прохорович озаграк туктап торды, ярасын җентекләп карады, борчымыймы? дип сорашты.

— Сез шикләнгән булдыгыз, ышанмадыгыз. Тагын бер атнадан карчыгыгыз янына кайтырсыз. Шул.

— Рәхмәт, Прохорович, рәхмәт, батюшка!

— Мин чиркәү хезмәтчесе түгел, батюшка буласым килми. Әгәр мине рәнҗетәсегез килмәсә, мине алай зурламагыз.

— Ачуланмагыз, Прохорович, шулай әйтелә инде ул.

— Юк, рус теле бай тел, һәркемгә үзенә лаек хөрмәтләү сүзләре бар...

Вадим Прохорович яңа авыру янына күчте.

Обходтан соң нянялар юан авыруның тәрәзә төбендәге «складын» алып чыгып киттеләр, карчыгыңа бирербез, диделәр.

— Бирерсез, көт сездән, живодерлар! — дип сукранды юан авыру.— Сездә күп ятсаң, вобла кебек эчең-эчкә ябышыр.

Кайтканда Мәрхәбә яхшы ук борчыла башлаган иде инде. Ул адымнарын кызулатуын да сизмәде.

— Әни, кунакны озаттыңмы? Исән-иминме? — дип сорады ул ишектән керү белән.

— Бик яхшы озаттым, рәхмәт әйтеп калды. Өенә кадәр озата барыйм дигән идем, моннан үзем дә табам диде.— Айтүтә кызына яшертен генә карап алды һәм аның йөзендә тынычлану күреп: — Бик сәер булды бу кунагың, кызым,— диде.— Чак тавыш булса, хәзер колагы үрә тора. Урамга чыккач та як-ягына каранып алды. Әмән шикләнә...

— Юк, әни, сиңа шулай тоелган гынадыр.

— Өйалдында нindидер төенчеге бар иде. Онытa язган иде, әйткәч борылып алды.

Шуннан соң бер ун көн вакыт үтте. Мәрхабә болай бернәрсә сиздермәсә дә, эчтән бик киеренке йөрде. Бер көнне полициянең кемнедер бик нығытып эзләвен ишеткәч, куркуы йөзенә үк чыкты. Андый чакта еш булганча, хатыннар әллә никадәр имеш-мимешләр өстәделәр. Имеш, әлеге кеше яшь кенә бер поп, рясасы астында җәһәннәм машинасы йөртә икән.

— Ходаем, поплар да акылларыннан язганнармы,— диде бер хатын.— Нинди заманалар китте.

Коега суга чыккан Мәрхабә сүзгә катнашмады. Ольга Леонардовнаның поп киеме киюе бик мөмкин, тик бу кадәр озак вакыт Казанда торырмы? Шулай да имеш-мимешләр басылганчы Мәрхабә эчтән бик газапланды. Гыйльметдиннең әнесен табарга була, ләкин ул бер-бер нәрсә беләме икән? Белсә дә, әйтмәс. Студент Ольга Леонардовнаны күрмәгән дә.

Көннәр үтү белән бу имеш-мимешләр басыла башлады, дөресрәге — бүтәннәре калкып чыкты. Фәлән урамда көпә-көндез бер байны суйганнар, шәһәрнең бер атаклы чиновнигы кызыл фонарьлы йортка йөри, имеш, хатыны сизеп алып, трарам күтәргән, базарда ит сатучы ике кассапчы беләк буе пычаклар белән сугышканнар, имеш,— лыгырдаучыларга моннан да кызыклырак сүз бармы соң!

Соңгы көннәрдә гел кар яуды. Салкыннар кими төшсә дә, дворникларга эш күбәйде. Мәрхабә гадәтенчә шифаханәгә эшкә йөрде. Кешеләргә күпмедер ярдәм күрсәтә алу аңа эчке канәгатьлек бирә иде. Дөрес, эштә кыен, үтә кыен чаклар була, күңел дә кайта, нишлисең, шифаханә юлларына гөл сибелмәгән, кан, яшь, сызланулардан ерак булсаң, бик яхшы, ләкин кешеләр авырый, кемнәрдер аларга ярдәм итәргә тиеш, һәркем үз кайгысын гына кайгыртса, җәмгыять яши дә алмас иде.

Бер көнне Мәрхабә эштән кайтышлый урамда Анна Ивановна Веретенникованы очратты. Ул картайган һәм ябыккан сыман күренде. Борчылып хәлен сорады.

— Ә... бу сезмени? — диде Анна Ивановна туктап.— Авырыйм шул нигәдер... Ә теге сез әйткән хатынны китермәделәр бит.

Мәрхабә егетнең кинәт үлгәнлеген, карчыкның докторга күренергә теләмәгәнлеген сөйләде.

— Сез аңарда булдыгызмыни? — дип сорады Анна Ивановна.

— Булдым, Анна Ивановна. Улымны суйдылар, мине дә харап итәрләр, ди.

Анна Ивановна тирән итеп көрсенде.

— Их, бу караңгылык, наданлык. Адәм баласының шундый хәлдә булуы кызганыч...— Анна Ивановна йөткерә башлады һәм муфтасыннан кульяулыгын алып иреннәрен каплады.— Гафу итегез...

Инде соңыннан Мәрхабә уйлап куйды: Анна Ивановна аңа үпкәләмәдеме икән? Караңгылыкны яктылыктан артык күргән карчык Мәрхабәнең милләттәше бит.

Мәрхабәнең ачынуы, күрәсең, шул кадәр көчле булган, кайткач әнисенә сөйләми түзмәде.

— И, кызым, дөнья кешене шулай тиле итә инде ул,— диде Айтута, башын селкеп,— бер заман акны, караны күрми башлый. Без авылда торган чакта мескен авыруларны әллә кайдан чомбрактан[1] Исмәт атасы Аблай хаҗига өшкертергә алып киләләр иде. Искил халкы аңа йөрмәде, чөнки алар хаҗиның әшәкелеген беләләр иде, ә чит авыллардан киләләр. Үзең уйлап кара: элекке ат карагы, кеше үтерүче хаҗиның өшкерүе нинди файда итсен? Алла тәлә, әстәгъфирулла, ачык авыз түгелдер инде, кемнең уенда ни барын белә торгандыр. Үзе өшкерә, үзе бу кемсә сәдакага нәрсә бирер икән, дип хафалана торган Аблай хаҗины күрә торгандыр лабаса. Урысы булса тагы, Саручи монастырена святой су алырга титаклый. Чишмәдән чөмереп алалар да шул святой су була, имеш. Бер-ике яки унлап кеше барса, болар акылдан язган, дияр идең, югыйсә, кулларына таяк тотып, аркаларына биштәрле капчык асып, ап-ак сакаллы, ялан башлы картлар, бөкрәйгән карчыклар безнең авыл аркылы йөзәрләп-йөзәрләп узып китәләр иде.

## 9

...Баласы авырган чакта кизү торган сестралар өчен хәзер Мәрхабә үзе эшли иде. Менә әле дә ял итмәде, шифаханәгә китте. Аннан төнге унбер тулып уникенчедә генә кайтырга чыкты. Көндез ул турырак юлдан йөри иде, хәзер әйләнеп булса да зуррак урамнарны сайлады. Ләкин зур урамнарда да караңгы, җитмәсә, буран бурый башлаган.

Урам фонаре яктысыннан узганда коймада бер ак нәрсә күзенә чалынды. Якынрак килеп караса, йөрәге сикереп куйды: прокламация! Караңгыда язуын тулаем укырга мөмкин түгел, тик аерым сүзләре генә күренә. Аларны эре хәрефләрдән җыйганнар булса кирәк: «... *тиран... кровавый деспот...*»

Мондый прокламацияләр Казанда, билгеле, элек тә булгандыр, тик Мәрхабә генә аларга ничектер юлыкмады. Мәскәүдән соң Казан бу яктан, гомумән, өнсез кебек тоелган иде аңа. Дөрес, яшерен типографияләр, шундый эшкә катнашучы ниндидер георгиевский кавалерлар турында халык арасында төрле имеш-мимешләр байтак таралган иде. Имеш-мимеш булгангамы, Мәрхабә аларга әллә ни игътибар итмәгән иде. Баксаң, алар бөтенләй буш түгел, кемнәрдер ут ягалар икән!

Аркылы Горшечный чатында Мәрхабәгә бер төркем студент очрады. Берсе таныш сыман тоелды. Әгәр ялгышмаса, бу күптән түгел генә алар урамында торган матур хатынның улы иде. Билгеле, очраклы рәвештә коймада күргән прокламацияне бу студентлар белән бәйләргә нигез юк иде. Ләкин Мәрхабә ихтыярсыз уйлап куйды: «Әллә монысы да абыйсы юлыннан барамы?»

Кайчакта кешенең кинәт туган уйлары да чынбарлыкка бик якын була. Студентлар бүген чыннан да Самар-Сембер якташлыгының чираттагы яшерен утырышыннан кайталар иде. Күрәсең, бәхәсләре анда, утырышта гына бетмәгән, урамда да дәвам иттерәләр, гүя урамның йөз колагы барлыгын онытканнар, яшь йөрәкләре һаман ярсый.

---

[1] Чомбрактан — бик еректан.

Володя да шактый эсэрлэнгэн иде, өйгә кайткач та тиз генә тынычлана алмады. Ул Самар-Сембер якташлыгының житәкчесе студент Полянский белән танышты. Полянскийның ныклыгы, көрәшкә бирелгәнлеге турында элек тә аның белән бер квартирда торучы иптәшләре Володяга күп сөйләгәннәр иде, хәзер ул моны үзе дә күрде. Сергей Полянский бүген дә җыелышның уртасында булды, Володя аңа соклынып утырды.

Студентларның нәфрәтләре ташуга сәбәпләр кирәгеннән артык күп иде. Яңа реакцион устав нигезендә университетның моңарчы яшәп килгән автономиялелеге тәмам бетерелде, студентларның ирекле оешмалары һәм җыелышлары законга сыймый дип тыелды, «кухарька балалары», төрле сылтаулар белән, университеттан куыла торды, китапханәләр ябылды, якташлык оешмалары туздырылды. Университетка кертелгән инспекторлык хокуклары бермә-бер киңәйтелде. Инспекторлар чынлыкта студентлар арасында полиция һәм жандармерия функцияләрен үти иде...

Әле кайчан гына Володя боларны бар дип тә белми иде, ә хәзер менә төн йокларга бирмичә күңелен борчый. Тормыш, тормыш! Аның һәр почмагында гаделсезлек тулып ята.

Икенче көнне иртәнге сәгатьләр университетта лекцияләрдә үтте. Профессор Дормидонтовның дәресләрен Володя әле игътибар белән тыңлап утырды, аларда рәсмилек ярылып ятса да, фактик материал бай иде, ә профессор протоиерей Миловидовның дин тәгълиматы турындагы лекциясе Володяның күңелен генә кайтарды.

Университеттан кайтышлый Володя казанлыларга бик яхшы таныш булган Деренковның икмәк кибетенә сугылды. Бирегә укучы яшьләр әеруча күп йөри, бу аларның үзенә күрә бер очрашу урыны, клубы иде. Монда алар соңгы яңалыклар белән уртаклашалар, бәхәсләр дә шунда ук кызып ала, серләшәләр дә. Деренковның китапханәсе дә бар. Анда бүтән җирдә табып булмый торган китаплар байтак. Салтыков-Щедрин, Грибоедов, Гоголь, Некрасов, Белинский, Добролюбов, Глеб Успенский, Тургенев, Чернышевский, Писарев һәм башкаларның тыелган китаплары дисеңме — барысы бар. Володя Ульянов бу китаплардан еш файдаланды.

Ләкин бүген Володя Ульянов кибеткә китаплар өчен килмәгән иде.

5 нче ноябрьда университет чиркәвендә ел саен үткәрелә торган рәсми тантаналы акт булырга тиеш. Студентлар аңа байкот ясарга булдылар. Байкот яңа уставка ачыктан-ачык каршы чыгу төсендә үтәргә, ягъни иң үзәккә — самодержавиенең рәсми политикасына каршы юнәлдерелергә тиеш иде.

Нәкъ менә шул турыда сөйләшү өчен Володя Деренков кибетенә килде. Кирәкле кешеләрне бик тиз күрде. Ул кемгә нәрсә әйтәсен барысын алдан уйлаган иде.

— Педельләр безнең эшләрне гади тәртипсезлекләргә кайтарып калдырырга, шуның белән аның әһәмиятен төшерергә тырышырлар,— дип пышылдады Володя.— Ләкин гади тәртипсезлекләр безне мавыктырмый, без малайлар түгел, без — көрәшчеләр, ә көрәш зур максатлар куя.

Студентларны байкотка чакырып махсус өндәмә яздылар. Володя аның авторларыннан берсе иде. Хәзер ул шул өндәмәләрне дә иптәшләренә таратты.

5 ноябрь килеп җитте. Тантаналы акт билгеләнгән сәгатьтә университет чиркәве ярым буш иде. Студентларның күбесе килмәгән иде. Бу ни бу? Моның очраклы хәл булуы мөмкин түгел. Университет житәкчеләренең йөрәгенә ут капты.

Без капчыкта ятмый, икенче көнне үк мәгълүм булды: студентлар чиркәүгә киләсе урында танца кичәсенә җыелганнар. Бу инде полициягә дә билгеле икән. Ачуыннан кара көйгән инспектор Потапов бу башбаштаклыкны оештыручы биш студентны һич кичегүсез университеттан куарга дип исемлек кертте. Университет ректоры Кремлев исемлекне кулына алды һәм: «Ярый миндә калып торсын»,— диде. Потапов алдында ул эчендә нәрсә кайнавын белдерергә теләмәде. Инспектор чыгып киткәч, әдәп-инсафны онытып, сүгенеп куйды. Ләкин аның сүгенүе Потаповка карата түгел, бәлки акылсыз студентларга төбәлгән иде.

Бераздан ректор янына профессор Преображенский килеп керде. Аның йөзе кызарган, үзе әсәрләнгән иде.

— Ни булды, Христофор Яковлевич? — дип каршы алды аны Кремлев. Ул инде яңадан рәсми битлек астына кереп өлгергән иде.

— Ни булганын сез беләсез, Николай Александрович,— диде Преображенский, Кремлевның дәү өстәле алдына басып.— Ахыр килеп анысы артык мөһим дә түгел. Без инспектор Потапов әфәнде белән чәкәшеп алдык.

— Сез бу хәлгә җиңел карыйсыз, Христофор Яковлевич.

— Мин үз фикеремдә калам. Университет — мәдәният учагы, полиция часте түгел!..

Кремлев әфәнде аякка басты.

— Гафу итәсез, Христофор Яковлевич... Рәсми урында рәсми кешеләрне хурларга... Мондый акылсызлыкны бары тик...

— Аңлашыла... Моңарчы сезгә хөрмәтем зур иде. Хәзер...

— Мин сезнең каршыда түбән төштеммени? — Кремлевның йөзе агарынып китте.

— Үзегез моны яхшырак сизәсез, Николай Александрович,— диде Преображенский нык итеп.— Башкаларның әйтүенә сез мохтаҗ түгел. Карагыз, сезнең юл куюыгыз аркасында безнең кадерле фән учагыбыз нинди аяныч хәлгә төште. Хәзер ул алдынгы мәдәният йорты түгел, казарма, монда тынчу баткаклык! — Преображенский кызганнанкыза барды.— Кайчандыр бу стеналарда җанлы фикер булган. Рус фәне әһелләре Лобачевский, Зимин, Бутлеров, Щапов лекцияләр укыган, ә хәзер... Некрасовка, Добролюбовка, Герценга, Чернышевскийга, Лев Толстойга урын калмады. Рус мәдәниятенең, рус әдәбиятының аталарына университетта дәрәҗә юк! Мин сездән сорыйм: бу нәрсә?

— Мин мондый тәшвишле сорауларга...

— Җавап бирмисез? Алай булгач, мин... мондый университетта кала алмыйм. Менә минем гаризам...

— Сез студентларга бик начар үрнәк күрсәтәсез, Христофор Яковлевич. Сез шул турыда уйладыгызмы? Ат азгыны тайга иярә, диләр. Сез...

— Сездән катырак сүзләр ишетсәм дә гаҗәпләнмәс идем. Хушыгыз!

Тантаналы актка катнашмаска өндәгән студентларны университеттан чыгару кәгазенә Кремлев кул куймаган иде әле. Хәзер ректор кәгазьне тартып алды да каләмен карага манды. Актык минутта тагын икеләнеп калды...

Бу көннәрдә Володя өйгә тирән уйга чумып кайта башлады. Ул дәһшәтле вакыйгаларның үскәннән-үсә баруын сизә, алардан курыкмый, кыен минутта иптәшләрен ташлап китәргә уйламый иде. Ул ни генә булса да үз тиресен саклап калу кебек вак җанлылык рухында тәрбияләнмәгән. Бу зур сынауга ул бик җитди карый иде. Уйларын

энисе белән булеште, иң яхшы профессорларның университет тәртипләренә протест йөзеннән аннан китүләрен әйтте.

— Чын кешеләр, әни, намусларына каршы барып, намусларын сатып үзләренә иминлек яуларга омтылмыйлар, чөнки кабахәтлек, нинди генә тәти кәгазьләргә төрелмәсен, барыбер кабахәтлек булып кала,— диде ул ярсынып. Әнисе аны күкрәгенә кысты. Ул аңлый иде. Ихтимал, бу көннәрдә аның улына булган мәхәббәте бермә-бер арткандыр,— без әле ана мәхәббәтенең бөтен тирәнлеген, олылыгын, пакьлеген белеп житкермибез. Ихтимал, моны әйтеп бирер өчен даһи шагыйрь кирәктер, ә ул әле тумагандыр...

Тантаналы актны өзү белән студентлар, билгеле, жиңүгә ирешмәделәр, киресенчә, жиңелделәр генә, ләкин бу жиңелүдә никадәр сабак бар иде! Акыллы башлар ниләр генә сөйләмәсеннәр, нинди генә каһәрләр белән куркытмасыннар, карагыз, әлек биш кенә студентны чыгарырга булганнар иде, хәзер ике өлеш артык чыгардылар, дип эчләреннән ничек кенә шатланмасыннар, эш аларның пышылдауларындамыни! Әгәр студентлар байкотны яхшырак оештырсалар, бердәмлекләре ныграк булса, нәтижәсе дә үтемлерәк булыр иде. Болай да ул эзсез үтмәде, күпләрне уйландыргандыр, тетрәткәндер.

Шул көннәрдә Володя Ульяновны нык уйланырга мәжбүр иткән тагын бер вакыйга булып алды. Студент Милоновның сатлык жан икәне беленде. Ул студентлар арасындагы оешмаларның бөтен карарларын инспектор Потаповка житкереп торган икән. Бу хәл ачылгач, студентларның нәфрәтенә чик булмады. Алар Милоновка суд ясарга карар чыгардылар. Аерым студентлар аны хәтта кыйнап ташларга булганнар, төнлә Милоновның өенә барганнар, тик ул аларга ишек ачмаган...

Ноябрь ахырларында Милоновка суд булды һәм хөкем карары гектографта басылып студентлар арасында таратылды. Анда Милоновның бөтен әшәкелекләре саналган иде: ул студентларның барлык серләрен инспектор Потаповка житкереп торган, студентларның тантаналы актка бармаска дигән карары булуга карамастан, Милонов тантаналы актка барган. Студентлар оешмасыннан ялганлап акча алган. Шәхси тормышында бик күп бозыклыклары фаш булган... Шулар нигезендә студентлар суды хөкем карары чыгарган: Милоновны бернинди студентлар оешмасына кертмәскә, Милонов белән исәнләшү — һәр студент өчен түбәнлек санала, диелгән.

Юридик факультет студентлары Милоновны артык үзләренең иптәшләре итеп санамыйлар. Аның белән аралашуны студентлар үзләре өчен куркыныч итеп күрәләр, чөнки Милонов янаудан туктамый.

Володя кайтып кергәндә Оля рояльдә уйный иде. Володя һәр вакыт аның уйнаганын тыңларга ярата, сеңелесенең музыкага һәвәслегенә соклана иде. Бүген дә, терсәгенә таянып, аның уйнаганын озак тыңлап утырды.

— Володя, син бүген нигәдер бик уйчан,— диде Оля, уйнап туктагач.— Борчылгансың да шикелле.

— Юк, Оля, борчылуын борчылмадым, ләкин ачуым килде,— диде Володя һәм Милоновка ясалган суд турында сөйләде.

— Студентлар арасында шундый кабахәт кешеләр бармыни? — диде Оля, кулын йомарлап.

— Студентлар, Оля, жәмгыятьтән аерым түгел, жәмгыятьнең яхшы сыйфатлары да, бозык яклары да студентлар тормышында көзгедәге кебек чагыла. Ләкин бозыклыклардан нәфрәтләнү генә аз. Бозыклык намуслы кешеләрне һәр вакыт нәфрәтләндереп килгән. Тик аңа карап

бозыклык бетмәгән... Хәтерлисеңме киләчәк турында без ничек хыялланa идек? — дип сорады кинәт Володя.
— Әйе! Матур, бәхетле, шат, якты дөнья безнең идеал иде.
— Ләкин ул идеалга ничек ирешергә? Дөньяда хыялланучылар аз булмаган, алар начар хыялланмаганнар. Хәзер хыялдан эшкә күчү, хыялны чынбарлыкка әверелдерү төп мәсьәлә. Мине Саша юлына чакыручылар күп булды. Мин ул юлдан бармаячагымны әйткәч, миңа өтек җан итеп карадылар.
— Шуңа синең хәтерең калдымы, Володя? — дип сорады Оля.
— Мондый сүзләрне ишетү җиңел түгел, Оля. Шулай да хәзер мин юл күрсәтә торган йолдызны таптым дип әйтә алам. Син ул белеме?
— Юк, Володя.
— Менә ул! — дип, Володя кесәсеннән чыгарып өстәлгә «Коммунистлар партиясе манифесты»н куйды.— Син моны укы, Оля. Укы! Монда барысы да ачык әйтелгән, ачык күрсәтелгән. Европада шәүлә йөри!
— Бу китап Саша абыйда бар иде бит.
— Әйе, бар иде... Бар иде... Ихтимал, ул нәкъ менә шуннан соң үз юлының дөреслегендә шикләнә башлагандыр!.. Оля, уйна әле берәр нәрсә! — диде Володя, кинәт урыныннан торып, аннары яңгырый башлаган моңлы музыка тавышы астында арлы-бирле йөренергә тотынды.

## 10

4 декабрь җыенын тизләткән вакыйгалар бер-бер артлы булып торды. Университетта тантаналы актны өзү шау-шуы әле тынарга да өлгермәгән иде, бөтен илне дер селкеткән яңа бер вакыйга булып алды. 1887 елның 22 ноябрендә патша палачлары Мәскәү студентларын канга батырганнар. Бу хәбәр бик тиз арада ерак шәһәрләргә хәтле таралды һәм моның яшьләр арасында бик зур җәнҗал кутәрүе ачык иде. Җитәкче әфәнделәр куркуга төштеләр. 27 ноябрьда Казан Үзәктән катгый шифровка алды: «Тәртипсезлекләр була калса, бик каты тотарга» диелгән иде анда. Икенче көнне губернатор өстәленә яңа телеграмма килеп төште. Анда Мәскәү студентларының Казанга барып чыгу ихтималы әйтелгән, күзәтеп торырга, килә калсалар, шунда ук аларны шәһәрдән сөрергә әмер бирелгән иде. Җандармерия ашыгыч чаралар күрә башлады, әмма ул соңга калды. Губернатор телеграмма алу белән бер үк сәгатьтә диярлек Казан студентларының берсенә Мәскәү университетында укучы дустыннан хат килеп төште. Хатта Мәскәүдәге канлы вакыйгалар турында тәфсилләп язылган иде. Казан студенты өлгер егет булып чыкты, тиз арада хатның эчтәлеге белән иптәшләрен таныштырды. Яшьләр дәррәү кабынып бер карарга килделәр: Казанда да реакцион университет уставына, хөкүмәтнең Мәскәүдәге канлы эшләренә бердәм каршы чыгарга, ачулы протест белдерергә булдылар, барлык студентларны шуңа чакырдылар. Хаттан озын-озын күчермәләр алып, студентлар арасында күпләп тараттылар, гектографта басылган листовкалар да шул максатны үтәде. Студентлар дөньясы яңа бер көч белән кайнарга тотынды. Моны белгәч, студентлар инспекторы — ата педель Потапов шартларга житеште, чак күтәрелеп бәрелмәде, агарынып киткән калын иреннәре тагын нинди акылсызлык дип пышылдады. Ул кабинетына бикләнде, тын да алмыйча вак педельләргә — ярдәмчеләренә һәм инспекция хезмәткәрләренә циркуляр язарга кереште: университет студентлары арасында ниләр булып торуын нык күзәтегез, уяу булыгыз, җитди нәрсәләр турында шунда ук миңа җиткерегез, бүтәннәре турында шул ук көнне лекцияләр беткәч хәбәр ителсен, диде ул катгый итеп. Инспек-

ция хезмәткәрләре студентларны университеттан тыш та күзәтү астына алсын, күргән, ишеткән нәрсәләре турында, имеш-мимешләргә кадәр, барысын инспектор әфәндегә шунда ук житкерсен. Аеруча чишенү, тәмәке тарту бүлмәләрен, 4, 7, 10, 12 нче аудиторияләрне, анатомия бинасын, химия лабораториясен, физиология һәм физика кабинетларын, ягъни студентлар күпләп жыела торган барлык урыннарны нык күзәтергә боерды инспектор Потапов әфәнде.

Потаповка үч иткән кебек, нәкъ шушы көннәрдә студентларның яшерен жыелышлары ешаеп китте. Беренче декабрьда университет һәм ветеринария институты якташлыгы депутатларының Нижне-Федоровский урамында яшерен киңәшмәсе ачылды. Бу киңәшмәгә Сембер-Самар якташлыгының һәм Мотовилов-Богораз-Скворцов түгәрәгенең вәкиле буларак, Володя Ульянов та катнашты. Ул бер читтә утырды, куен дәфтәренә нияләрдер сызгалады, үзе һәр чыгыш ясаучыны игътибар белән тыңлады. Түшәмдә яшел абажурлы лампа яна, өстәлдә чынаякларда чәй, стеналарда төрле рәсемнәр. Тик аларга караучы гына юк, яшьләр барысы ораторның сүзләренә йотылган иде. Оратор Казанга Мәскәү университеты вәкиле килгәнлеген, исемен мәгълүм сәбәпләр аркасында жыелышка белдерә алмавын әйтте. Володя бер кулы чүпрәк белән уралган ябык саргылт йөзле бер студентка игътибар итте.

— Әфәнделәр,— диде вәкил әкрен генә,— Мәскәү студентлары золымга каршы үзләренең нәфрәтле тавышларын күтәрделәр. Аларның каннары акты, ике иптәшне үтерделәр, ике йөз студентны кулга алдылар. Университетны яптылар...

Казан студентлары Мәскәү вакыйгаларын ишеткәннәр, аннан килгән хатны гектографта укыганнар иде. Әмма жанлы вәкилнең сүзен тыңлау аларга тагын да көчлерәк тәэсир итте. Вәкилнең хәлсез, авыру тавышы, яралы кулы йөрәккә гүя кайнар ут сала иде. Берничә минут Казан студентлары, ни әйтергә белмәгәндәй, ачудан буылып тордылар. Аннары гүя буа ерылып китте, барысы кычкырып нәфрәтләнә башладылар.

— Бүген Мәскәү студентларын канга батырганнар, иртәгә башкаларны...

— Моңа түзәргә ярамый!

— Казан студентлары Мәскәү студентларын яклый!

— Без бертуганнар!

— Бетсен самодержавие! Бетсен золым!

Председательлек итүче ярсыган студентларны көч-хәл белән тынычландырды, тавышлану, ярсу бер нәрсә бирми, конкрет чаралар күрергә кирәк, тыныч кына утырыгыз, әфәнделәр, диде.

Мәскәү вәкиле тынып калган студентларга Моховая урамында һәм Тверской бульварда булган студентлар демонстрациясе турында тәфсилләп сөйләде, иң вәхши рәвештә үткәрелгән золым, полиция баш-баштаклыгы Мәскәү яшьләре арасында бик зур ачу тудырганлыгын әйтте.

Тагын тавыш купты. Хәзер инде студентларның бердәм түгеллеге дә күренә башлады: берсе «Бетсен самодержавие!» дип кычкыра, икенчесе бары тик үз хокукларын якларга өнди. Студентлар — фикер йөртүче Россиянең нуры, ул таркалмаска, үз бердәмлеге турында кайгыртырга тиеш, диләр.

Володяның кашлары жыерылды. Студентларның күпчелеге демагогия баткаклыгына кереп батар микәнни? дип уйлады ул борчылып.

— Миңа рөхсәт итегез әле,— диде Володя председательгә һәм тиз генә урыныннан торды.— Ректор алдына без тар мәгънәдәге академик яки корпорация таләпләрен генә куя алмыйбыз. Без жәмгыятьнең Россиядәге гомум сәяси хәлгә, аерым алганда, студентларның хөкүмәт алдына куя торган таләпләренә игътибар итүен телибез. Без реакция-

нең җәелгәннән-җәелә баруына каты нәфрәт белдерәбез, университет уставын тамырдан демократизацияләүне сорыйбыз. Икенчедән, полициянең студентларга карата башбаштаклыгы бетерелсен...

Купчелек Володяның тәкъдимнәрен дәррәү күтәреп алды һәм үзеннән өсти башлады. Бер тәкъдим икенчесен, икенчесе өченчесен тудырды. Тәкъдимнәр шул хәтле күп булып китте, алар инде студентлар тормышының гаять киң мәсьәләләренә кагыла башлады.

Киңәшмә прокламация һәм петиция текстларын җентекләп караганнан, өстәмәләр керткәннән соң, ачыклыйсы урыннарын ачыклап, аларны нигез документлар рәвешендә кабул итте.

Киңәшмәдән чыкканда Володяның күңеле инде күтәренке иде. Делегатларның күбесе демагогиягә бирелмәде. Бу үзенә күрә бер җиңү иде. Дөрес, бәхәсләр артык көчле булмады. Ихтимал, моңа гомуми күтәрелеш тәэсир иткәндер, ихтимал, барысы киләчәккә калгандыр, ни генә булмасын, бүген алар дөрес юлны саклап калдылар. Володя кулларын уып:

— Елның иң караңгы ае димәссең, нәкъ май төне төсле, шундый якты! — диде урам буйлап янәшә барган иптәшенә. Үзе, башын күтәреп, каядыр еракка караган килеш атлады. Күз-яз көннәрендә кошлар иксез-чиксез күк юлларыннан очып барганда нәрсә шәйләсә, Володя да бу минутта шул кошлар төсле иде. Тик аның юлы кошларныкыннан еракарак сузыла һәм анда очрый торган кыяларны, киртәләрне, куе томаннарны, давылларны, баткак-сазлыкларны, диңгезләрне үтәр өчен аның күзләре үткенрәк күрергә тиеш. Аннары ул берүзе түгел, ялгыз-ярым максатка ирешеп булмавын ул аңлаган инде. Казан студентлары кабул иткән листовкаларның беренче сүзе «Иптәшләр!» дип башлана иде. Соңыннан бу ялкынлы сүз революцион листовкаларда, прокламацияләрдә, мөрәҗәгатьләрдә, үзара эндәшүләрдә даими булып китәр, төп ышаныч, төп көч, меңнәрне, миллионнарны бергә туплаучы куәт булып әверелер, җиңүгә өндәр, ә бүген бу сүз листовкаларда беренче тапкыр яңгырады.

«Иптәшләр!

. . . . . .

Казан студентлары!

Без университетның тапталган хокукларын яклап бердәм рәвештә аякка басмабызмы, бөтен киңлегенә җәелгән реакция алдында үзебезнең протестыбызны белдермәбезме? Без Казан студентларына ышанабыз һәм без аларны университетта ачыктан-ачык протест ясарга чакырабыз!»

Бу листовка студентлар массасына барып житкәч, алар арасында күрелмәгән дәрт, энтузиазм тудырасына Володя тирәнтен ышана иде. Инспектор Потапов нишләр икән? Мөгаен, аны укыгач, күзләре маңгаена сикереп менәр. Шул кирәк аңарга! Билгеле, моның өчен студентларны, һәрхәлдә, аларның җитәкчеләрен һәм актив катнашучыларны, гафу итмәсләр, күбесен фән йортыннан куарга тырышырлар. Әлбәттә, педельләр ачык күрәштән уттан курыккан кебек куркачаклар, студентлар чуалышын гади тәртипсезлекләр итеп күрсәтергә, юньсезләр башбаштаклыгы дип атарга тырышачаклар. Ләкин яшь йөрәкләр тик ятмас, протестлары бөтен Россиягә яңгырасын, сәяси төс алсын өчен бөтенесен эшләрләр, бүген үк инде күп шәһәрләргә, шул җөмләдән Мәскәүгә дә, хатлар китәчәк, «Рус патшасына ода» шигырен дә конвертларга салырлар.

Бу озын шигырьнең шигъри яктан кимчелекләре бардыр, әмма эчтәлеге ни тора! Володя аны бер генә тапкыр укымады инде:

Царя же ты, Романов дом,
Указан божиим перстом,
Царя и славься много лет

И кровью смой крамолы след!
Стреляй и вешай нигилистов,
Социалистов, атеистов,
А тех, кто может дерзость сметь,
Свое сужденье иметь,

Гнои по тюрьмам и темницам,
По градам, весям и столицам!..
Томи в цепях, в Сибирь ссылай,
Терзай бесжалостно, пытай!..

О царь! Врагам твоим кара:
Всем — петля, пуля — всем... Урра!!!

Бүгенге киңәшмәдә кабул ителгән мөһим документларның тагын берсе «Казан студентларының петициясе» дип атала иде. Монда да шул ук бер фикер — бөтен Россия тормышының түзеп булмаслык авырлыгы һәм аерым алганда студентлар тормышының чиксез катылыгы әйтелә. Аннары инде студентларның таләпләре санала. Беренче караштa бу таләпләр университет җитәкчеләренә генә кагыла төсле. Чынлыкта исә алар бөтен уку-укыту системасын тамырдан үзгәртүне таләп итә. Икенче төрле әйткәндә, студентларның таләпләре патша хөкүмәтенең бу өлкәдә алып барган рәсми сәясәтенә каршы юнәлгән. Әлбәттә, патша хөкүмәте моны ишетергә дә теләмәячәк, җәнҗаллы студентларга каршы бөтен полицияне, хәтта гаскәрне аякка бастырачак.

Урамнар караңгы. Володя инде иптәшләреннән аерылган. «Өйдә нишлиләр икән?» — дип уйлады ул. Әнисе йокламыйдыр. Кремлев әфәнде аны университетка чакырткан булган. «Киңәш иткән», Илья Николаевичның якты истәлеген сакларга өндәгән, Сашаның фаҗигасен телгә алган... Володя әнисенә тирәнтен ышана, ул улының юлына киртә булмас, шулай да вакытыннан элек аны борчымыйсы иде. Тагын нибары берничә көн, аннары инде эшлисе эш... эшләнгән була, чигенергә урын калмый...

Володяның уйлары тагын студент иптәшләренә кайтты. Бер утырышта ул аларга А. Бахның «Ачлык Патша» дигән брошюрасы турында реферат укыды. Бу чорда Бах марксист булмый әле, әмма Маркcның «Капитал»ы турында шундый итеп сөйли — царизмны гына фаш итеп калмый, бәлки бөтен капитализмның череклеген күрсәтә, эшче сыйныфның хәле чамадан тыш авыр икәнлеген тасвирлый.

— Син оратор икән! — диде бер иптәше Володяга соңыннан.

— Эш миндә түгел, менә бу брошюраны эшчеләр арасында да таратасы иде. Крестовниковлар заводы эшчеләренә вәгъдә итеп тә куйган идем...

— Алай булгач эш нидә соң? Минем гектограф бар. 15 декабрьларга кирәк кадәр данә басам да бирәм.

— Менә шәп булыр иде! — дип кычкырып җибәрде Володя. Ә бүген срокны озак куйганлыгын уйлап алды. Вакыйгалар көтелмәгәнчә куерып бара, болай булгач, ул брошюраны таратып та өлгерә алмавы мөмкин. Әмма хәзер срокны үзгәртергә мөмкин түгел инде. Вакыт калмаган.

Ульянов Казан эшчеләре белән бәйләнешне урнаштыра гына башлаган иде. Крестовниковлар заводын юкка гына сайлап алмады. Крестовниковлар заводы Казанда иң зур заводларның берсе, анда мең ярымлап кеше эшли, күпчелеге руслар, татарлар да бар, ләкин аларны иң авыр, иң кара һәм пычрак эшкә генә алалар. Әйтүләренә караганда, Крестовниковлар—иң әшәке великодержавный шовинистлар, татарны гомумән кыралмыйлар. Рус эшчеләренә аз-мaз өстенлек биреп, татар эшчеләрен аларга каршы куялар, шуның белән эшче сыйныфның бердәмлеген какшатырга тырышалар. Ә милли мәсьәләне

дәрес хәл итмәгәндә, революцион эшчеләр хәрәкәтен оештыру да мөмкин түгел...

Ихтимал, Володя монда Зайцевлардан файдаланырга уйлагандыр. Бу атаклы химиклар бер үк вакытта университет белән дә, Крестовниковлар заводы белән дә якын бәйләнгәннәр иде.

Карасу-зәңгәр күктә йолдыз атылды. Володя, башын күтәреп, аның сызылып калган нечкә эзенә бераз карап, Лядской бакчасы аркылы Яна Комиссариат урамына атлады. Әгәр синен дә гомерен тормыш күгендә шундый нечкә эз сызса? Бөтенләй эзсез булуга караганда әйбәтрәк, әлбәттә, зур бәхетләр берьюлы килми, кешелек аңа әкренләп якынлаша. Әкренләп булса да, тик яту түгел. Бабайлар тикмәгә генә әйтеп калдырмаган: йөргән таш шомара, яткан таш мүкләнә, диганнәр. Яшьтән мүкләнү куркыныч, мүкләнгән кеше — тормышта үзен югалткан кеше. Ә атылып киткән йолдыз сүнгәнче яктырып торачак!

Володя инде капка төбенә җиткән иде. Тәрәзәдә ут күренә. Димәк, әнисе йокламый, ул улын көтә әле. Эх, тагын берничә көн генә... Аннары ни? Ни булса, шулмы? Юк, алай түгел, чын көрәшче алга карарга, инанырга тиеш, әгәр инанмаса, күзен йомып давылга каршы ташланса, аннан ни көтәргә? Кирәксез корбаннар болай да күп бирелде. Народниклар... Сашалар... Алар батырлар, чиксез тәвәккәл егетләр иде, барган сукмакларыннан читкә борылмадылар, үлемнең күзенә туры карадылар, әмма аларның юлы хата юл иде, ул юл кешелекне җиңүгә китермәде һәм китермәячәк. Көрәш өчен башка юл кирәк, бөтенләй башка. Менә шул башка юлдан Володя бара да кебек. Ул инде аерым геройларга таянмый, ул эшче сыйныфка таянырга уйлый...

— Володя, син бүген бик озакладың — диде Мария Александровна, улына каршы чыгып.

— Әйе, әни. Бүген безнең түгәрәкнең бик мөһим утырышы булды.

— Ул түгәрәк утырышлары... дәресләреңә зыян китермиме соң?

— Дәресләр... Университетта хәзер безгә дәрес бирмиләр шул. Университетны... полиция оясына әверелдереп бетерделәр.

— Шулай да университеттан башка кайда белем ала аласың, Володя?

— Аңлыйм, әнкәй.

— Соң шулай булгач?

— Мин иптәшләрне сата алмыйм, әнкәй.

Мария Александровна тирән итеп көрсенеп куйды.

— Нәрсә әйтим сиңа, Володя... Белем алмыйча... Яшәргә кирәк бит. Безнең бүтән килеребез, мал-мөлкәтебез юк.— Мария Александровна тагын көрсенде.

Бүген Володя бик озак йокыга китә алмады. Уйлары тагын яшерен җыелышка кайтты, күз алдына ябык йөзле Мәскәү егете килде. Әйе, мәскәүлеләр беренче сүзне ярып салып әйткәннәр, ә Казан студентлары әйтерләрме? Әйтерләр, әйтми калырга һич ярамый. Казан студентлары арасында кыю, батыр кешеләр аз түгел... һәм Володяның күз алдыннан инде якын дус булып әверелгән иптәшләре берәм-берәм үтеп китәләр. Володя күңеленнән аларга исемнәре белән дәшә, күзләренә карарга тырыша. Билгеле, ул үзе беренче курс студенты гына, иптәшләре аны якыннан белеп бетермиләрдер. Ләкин ул патшага каршы кул күтәрергә җыенган Сашаның туганы. Бу хәл үзе генә дә бик күп мәгънә аңлата иде...

Хәзер төннәр бик озын, таң тиз генә беленми. Таң гомумән атмас шикелле. Ләкин вакыты җиткәч, таң ата, аны һичнәрсә тоткарлый алмый. Шул таң яктысына какшамас ышаныч булган кебек, көрәштә дә шулай нык ышаныч кирәк.

Володя ничек йоклап киткәнен үзе дә сизмәде, күзен генә йомды кебек, күр, инде яп-якты булган, университетка барыр вакыт якынлашкан. Володя җылы урыныннан сикереп торып, битен-башын юды, аннары тиз генә ашап алды.

— Әнием, мин киттем.

— Ярый, Володя.

Урамда Володя салкын һаваны күкрәк тутырып сулады. Борчулы уйлары бетмәсә дә, ышануы ничектер артты кебек, адымнары кызуланды.

Университетта Володя Ульянов яңа хәбәр ишетте. Бүген төнлә полиция искәртмәстен килеп кайбер студентларның квартирларын тентегән. Бу хәбәр Володяны шактый борчуга төшерде. Әгәр полиция башланмас борын ук житәкчеләрне кулга алган булса...

Бер кадәр вакыттан соң шунысы мәгълүм булды: полиция студентларның житәкчеләреннән берсе — Сергей Полянский квартирын да тентегән, тик Полянский өендә кунмаган.

— Молодец! — дип уйлады Володя эченнән.

Өченче декабрь көне Потаповка гомумән тыныч кебек тоелды. Бу турыда ул ректорга да хәбәр итәргә ашыкты. Тәртипсезлекләр башланырга нигез юк шикелле, диде. Ләкин шул ук көнне Потапов, ул-бу була калса дипме, үзенә шикле тоелган егерме жиде студентка яшерен исемлек төзеде.

Бу карт төлке ялгышмый иде, аны бары тик давыл алдыннан була торган тынлык кына бутады. Әлбәттә, Потаповны үтә сизгер һәм акыллы инспектор дип әйтеп булмый иде. Аңардан сизгерлек таләп ителсә дә, акыллы булуы... мәҗбүри түгел. Мөмкин булса, патша хөкүмәте акылны кайбер профессорлардан да тартып алыр иде. Нихәтле сәер һәм гаҗәп булмасын, самодержавие студентларны акылсыз профессорлар укытуына каршы килмәс, томана студентлар тәрбияләгән өчен аларга шелтә түгел, рәхмәт әйтер, бүләкләр бирер иде.

Полиция, жандармерия, губернатор, уку-укыту округы попечительләре арасында туктаусыз телеграммалар йөреп торды, ниһаять, Халык мәгариф министры Казан уку-укыту округына: «Яхшы фикер иялерен коткарып калу өчен, юньсез адәмнәрне кызганмагыз», дип, ачыктанчык күрсәтмә бирде.

## 11

1887 елның дүртенче декабре. Сыкылы салкын иртә. Кояш сыкы томаны эченнән бер күренә, бер югала. Агачлар шау чачәктә кебек. Урамнардан узып киткән чаналарның табаннары астында кар шыгырдый.

Ул көнне Володя Ульянов университетка гадәттәгедән ашыгыбрак барды. Ак колонналар янынннан эчкә керде, тиз генә чишенде һәм, тәмәке тартмаса да, тәмәке тартучылар бүлмәсенә ашыкты. Аңа иптәшләрен күрергә, иртәнге яңалыкларны белергә кирәк иде.

Шунда әллә кайдан атылып чыгып, аның каршына студент Борис Рогачевский килеп басты. Рогачевский үзенең гасабилыгы, тиз әсәрләнүе, кабынуы һәм этәч кебек сугышырга әзер торуы белән дан алган иде. Аның фаҗигасе, больницада ятып чыгуы аңа шөһрәт китермәде. Иптәшләре аңардан бер кадәр сакланалар, житди эшләр турында аның белән киңәшмиләр, бүген булачак җыен турында да аңа алдан берни әйтмәгәннәр иде. Ләкин ул барысын каяндыр ишеткән һәм университетка иртә таңнан килеп житкән иде.

— Володя,— диде ул пышылдап кына,— әле яңа гына Фефельнең Потапов кабинетыннан чыгып килгәнен күрдем. Ул егеткә минем

тамчы да ышанычым юк. Миңа калса, безнең булачак җыен турында ул Потаповка барысын да җиткергән. Йөзе чөгендер кебек кызыл иде. Володя, әллә караңгы почмакка кертеп, тәүбәгә китерергәме? Мин моны күз ачып йомганчы эшли алам,— дип, Рогачевский йомарланган кулларын күрсәтте: — Кычытып тора.

Фефель — бу фамилияне студентлар һәр вакыт бозып йөртәләр иде — Милонов кебек, иң сөйкемсез студентларның берсе. Аның Потаповка тәлинкә тотуы билгеле. Бик ихтимал, Рогачевскийның сизенүе дөрестер. Володя бер минутка уйга калды, аннары нык итеп әйтте:

— Боря, без сугыш чукмарлары түгел. Әтәчләнмә!

— Юк, ул Фефель җүнсез адәм, аңардан теләсә нинди явызлыкны көтәргә мөмкин.

— Боря, чыгырыңнан чыкма. Мөмкин булса, син ул Фефельгә күз-колак бул, иптәшләр аның алдында телләрен тыйсыннар,— дип, Володя үз юлына китеп барды.

Фефельнең доносы инспектор Потаповны бик каты борчуга салды. Ул Фефельгә аяк тибеп кычкырды, син моны әлек үк белгәнсең, безгә әйтмәгәнсең, моның өчен муеныңны борырбыз, дип янады. Ләкин вакыт бик тар иде, ашыгыч чаралар күрергә кирәк иде...

Потапов шунда ук губернатор, полиция һәм гаскәр гарнизоны белән бәйләнешкә керде. Әгәр эш Потаповтан гына торса, ул университетка алдан ук полицейскийларны, жандармнарны һич икеләнмичә кертер, берни белән санашмас иде. Университет ректоры Кремлев әфәнде икеләнә, фән йортына полиция керту әдәпкә сыймый, яманатыбыз бөтен Россиягә таралыр, ди. Билгеле, ректор үзенең дәрәҗәсе төшүдән дә курка торгандыр. Артык йомшак холыклы, либераль ул, дип уйлады Потапов. Үзе ул патша хәзрәтләренә турылыклы булырга ант иткән кеше, патша өчен утка-суга керергә әзер. Студентлар аны юкка гына патшаның кара күләгәсе дип атамыйлар. Моны шымчылары Потаповның үзенә дә җиткергәннәр иде. Ул моңа артык ачуланмады, димәк, «мерзавецлар» Потаповның кемлеген беләләр. Ул ыбыр-чыбыр алдында үзенең чын йөзен яшереп тормый, ул Кремлев әфәнде түгел, теләсә ничек кычкыра, хәтта һич икеләнмичә университетны ябар һәм соңыннан анда беркемне дә кертмәс өчен ишеге төбенә сакчы эт булып басар иде. Хәер, Потапов күзләрен йомып ятмады. Аңа хәбәр иттеләр инде, жандармнар, полиция һәм гаскәр күрше йортларның ишегалларында тупланган, кирәк була калса, минуты белән килеп җитәчәкләр. Аларга приказ гына булсын, алар нишләргә кирәген беләләр. Кремлев әфәнде кебек, йомшаклык күрсәтеп икеләнеп тормаслар, бөтерерләр дә салырлар, дип уйлады Потапов.

Сәгать унберләрдә вестибюльдә, чишенү һәм тәмәке тарту бүлмәләрендә төркем-төркем студентлар җыела башлады, алар ашыгыч рәвештә үзара нәрсәдер пышылдашып алалар, нәрсәгәдер әзерләнәләр. Университет студентлары арасында башка уку йортларыннан сөрелгән егетләр дә күренгәли. Алар инде яңа уставның бөтен ачысын үзләрендә татып өлгергән, маңгайларына гүя: мин «кухарка баласы» дигән рәхимсез мөһер басылган. Бүген алар аеруча әсәрләнгән, аларга кабынып китәр өчен кечкенә генә очкын да җитә.

Володя Ульянов һәм җыенның башка җитәкчеләре, алдан сөйләшү буенча, башка уку йортларына вәкилләр җибәрделәр. Хәзер, бергәләп хәрәкәт итәр өчен, аларның университетка килгәнен көтәләр. Көтү минутлары бик акрын уза. Һәркемнең башында бер сорау утлы кадак кебек бөтерелә: килерләрме, юкмы? Студентлар бердәмлеге ныкмы, юкмы?

Беренче булып Духовная академиягә җибәрелгән вәкил кайтты. Ул, чиксез нәфрәтләнеп:

— Булачак поплар, миссионерлар крамолага катнашырга теләмиләр! — диде.

— Теләмиләр икән, теләмәсеннәр, алардан башка да алдынгы студентлар аптырап калмас,— диде Володя.— Кыен минутларда кешеләрнең йөзләре ныграк ачыла.

Ул түземсезлек белән ветеринария институты студентларын көтте. Анда Скворцов, Мотовилов, Воскресенский... Алар, Володя кебек, «иң зарарлы» түгәрәккә керәләр. Володя ышана, хәлиткеч минутта алар ярты юлда туктап калмас, давылга таба ыргылырлар. Чыннан да, хәбәр алу белән үк алар дәррәү кубып, институт директоры янына кергәннәр, аңа үзләренең петицияләрен биргәннәр, аны укуын, петициядә куелган таләпләрне кабул итүен сораганнар. Институт директоры кискен рәвештә баш тарткач, ачулары ташыган студентлар, житмешсиксән кеше, университетка юнәлгән...

... Университетта жыен башлануын белдергән сигнал яңгырады. Коридорларда, аудиторияләрдә: «Жыенга, иптәшләр, жыенга!» дигән тавыш ишетелде, барлык ишекләр ачылды.

— Жыенга, иптәшләр, жыенга! Актовый залга!

Иң беренче сафларда чиксез әсәрләнгән Володя Ульянов, Сергей Полянский. Алар түбән катлардан күтәрелеп киләләр, студентларның яраткан жырлары «Гаудемаус» яңгырый, жыр тынуга, кемдер яңгыравыклы тавыш белән:

— Туганнар, хак эш өчен, иптәшлек эше өчен бердәм атлагыз! — дип кычкырып жибәрде.

Актлар залының биек ак ишекләре бикле иде. Ярсулы студентлар икенче якка ташланды. Анда да шул ук хәл.

— Нәрсә карап торасың, жимерегез ишекләрне! — дип кычкырдылар арттан.

— Тимер ишекләрне үзебез ватмасак, кем безгә аларны ачар! Ур-ра, иптәшләр! — дип кычкырды килеп житкән Рогачевский һәм бөтен көче белән ишекне дөбердәтә башлады. Больницадан чыкканнан соң мул итеп үстергән сакал-мыегы һәм озын чәче тузгып китте.

Ниһаять, ишек каерылып ачылды, студентлар залга ыргылдылар. Дулкынланган тавышлар яңгырады. Ә вестибюльдә, коридорларда, баскычларда әле һаман студентлар жыры яңгырый, ул көчәйгәннәнкөчәя бара иде.

— Без «Алма матерның» йөрәгендә, туганнар!

Залга яңадан-яңа студентлар төркеме керә иде. Алар, дәресләрен ташлап, аудиторияләрдән, клиника һәм шифаханәләрдән бирегә ашыгалар, соңга калмадыкмы дигән сыман, тизрәк вакыйганың уртасына керергә омтылалар иде.

Ишектә Потапов күренде. Ул кара көеп, студентларга берничә минут карап торды да, берьюлы барысының котын алырга теләп булса кирәк, бик яман акырып жибәрде:

— Мерзавецлар, бу нинди башбаштаклык? Миңа закон тарафыннан бирелгән власть исеме белән хәзер үк таралырга боерам!

Потапов, кулларын артына куеп, ишек төбендә тораташ кебек кузгалмыйча басып тора иде. Моннан аны беркем дә читкә тибәрә алмас кебек, тибәрергә, этәргә маташсалар, үзләре челпәрәмә киләләр. Әһә, әнә чигенә башладылар. Потаповның авыр карашын күреп күпләренең аркалары чемердәгәндер. Әй, кем анда чигенүчеләрне туктата? Берермен мин сиңа, дуңгыз малай! Потаповның күзләре тәмам зәһәрләнде. Мерзавецлар,— бу аның яраткан сүзе иде,— чигенүчеләрне туктаттылар, әнә кулга-кул тотынышып, инспекторның үзенә каршы киләләр иде.

— Таралырга боерам, жүнсезләр! — дип кабат кычкырды Потапов

ачу белән. Аның калын тавышы карлыга төшкән иде.— Әллә полицияне чакырып, көч кулланганны көтәсезме? Ялындырып тормам!

Потаповка таба сүзсез генә атлаучы студентлар артыннан кемдер:

— Нәрсә карап торасыз, авызына кундыр, кара каны белән битсен! — дип кычкырды. Бу Рогачевский иде. Ул күз ачып йомганчы алга чыгып Потаповның яңагына чалт итеп сугып та җибәрде. Бу кадәр кыюлыктан шаккатып калган инспектор бер адым артка чигенде. Ул авыз ачканчы арттан тагын кемнеңдер:

— Изегез измәсен! — дигән ачулы тавышы яңгырады. Баш өстенә күтәрелгән урындыклар күренде. Арттагылар алга ыргылды.

— Тыныч булыгыз, әфәнделәр! — дип кычкырды Полянский. Студентлар тагын да катырак шаулаша башлагач, Володя Ульянов:

— Без сугышырга җыелмадык, әфәнделәр,— диде.— Без бирегә үзебезнең гадел таләпләребезне әйтергә, протест белдерергә килдек! — диде.

Володяның үз-үзенә ышанган нык тавышы һәм кыю күз карашы ярсыган студентларны айнытып җибәргәндәй булды.

Потапов куркынычның үз башыннан шаулап үтүен тойды булса кирәк, тын алып, тагын кычкырынырга, сүгенергә тотынды, ләкин аның янауларына игътибар итүче булмады. Ул ачудан буылып калды, аннары каядыр китеп югалды.

Бу вакытта университет каршында йөзләгән халык, күбесенчә студентлар җыелган иде. Тышта кояшлы салкын көн, күктән энҗе бөртекләре кебек җемелдәп сыкы коела иде.

Кемдер тәрәзәне ачып җибәрде:

— Ур-ра! Безнеке алдыра!

— Туганнар, хак эш өчен, иптәшлек эше өчен нык торыйк!

— Шайтаныма олаксын инспекция! Туганнар, хыянәт итмәгез!

Ярсыган тавышлар, берсен-берсе уздырып, көчлерәк яңгырадылар. Барысы да кызган, әсәрләнгән иде, Актлар залы гөрләп торды.

Байтак вакыттан соң гомуми ярсу бераз басыла төште, кайбер студентлар, эш бетте дип, таралыша башладылар. Кемдер, кулларын җәеп:

— Кая китәсез, бетмәде әле. Залга, залга, әфәнделәр! — дип кычкырды һәм студентлар тагы залга тулдылар.

Ул арада, полиция божрасын өзеп, ветеринария институты студентлары Актлар залына бәреп керде. Университет студентлары шатлыкларыннан кул чаба башлады, күтәренке тавышлар яңгырады, килүчеләрне кочаклап каршы алдылар.

— Туганнар!

— Иптәшләр!

— Без бергә, бергә!!! Бергә булгач, давыллар куркыныч түгел!

Җыенның президиумын сайладылар, чыгышлар башланды. Володя да сөйләде. Ул, кайберәүләр кебек, хискә бирелеп кычкырмады, очкакланмады, ә эчке бер ышаныч, тирән нәфрәт белән фикерен әйтте. Күренеп тора: бу хакта ул алдан тирәнтен уйланган, студентлар өчен генә мөһим булган академик мәсьәләләрне күтәрми, бәлки патша хөкүмәтенең изүе, патша судының гаделсезлеге, хәзерге түзеп тора алмаслык режимга каршы илдәге барлык университет студентларының протест ясарга тиешлеген әйтә.

Володядан соң тагын байтак студентлар сөйләде, алар Ульяновның әйткәннәрен куәтләделәр. «Ректорны — залга!» дип кычкырдылар. Бу тавыш шундый көчле иде,— ректор кабинетына да ишетелде. Бераздан Кремлев әфәнде, берничә профессор белән, Актлар залына килеп керде, туктамыйча кафедрага күтәрелде. Бәйдән ычкынган студентларга шелтәле карап алды, үзенең хаклы икәненә нык ышанган хәлдә:

— Әфәнделәр, сезнең бу җыелышыгыз законга каршы килә,— диде.— Әгәр үз ихтыярыгыз белән таралмасагыз, мин сезне полиция һәм гаскәр хөкеменә тапшырырга мәҗбүр булачакмын. Уйлагыз!

— Гафу итәсез, ректор әфәнде,— диде бер студент һәм университетның соңгы уставын юкка чыгаруны таләп итеп сөйләп китте. Шунда ук Кремлевка җыелышның төп документы — петицияне тоттырдылар, аны укуын, инстанция буенча югары җибәрүен сорадылар.

Кремлев кәгазьгә күз салып беренче абзацны укыды да:

— Сез акылдан язгансыз,— диде,— мин сездән бер нәрсә алмыйм, вәгъдә дә бирмим. Рус җәмгыяте исеменнән сөйләргә... Ачык көрәшкә чыгарга... Бу — тилелек! Тагын бер тапкыр әйтәм: таралыгыз! Университетның Актлар залы башбаштаклык урыны түгел.

Бер генә минутка тынып калган зал тагын гөрли башлады. Әллә ничә җирдә ораторлар берьюлы сөйләргә тотынды, алар петициядә әйтелгән таләпләрнең һичшиксез кабул ителергә тиешлегенә басым ясадылар. Күренеп тора, җыелышның нинди дер эчке бер пружинасы бар, ул җыелышка тезгеннән ычкынып китәргә ирек бирми, шул ук вакытта үз сүзен катгый әйтә. Кремлев әфәнде моны бик ачык сизде, шул нәрсә аның ихтыяр көчен алды. Ул Актлар залын ташлап чыгып китәргә үзендә көч тапмады, иңнәренә бинһая йөк салынган кеше кебек, бөкрәеп өстәл артына утырды. Бер караганда, ул студентларын кызгана кебек, икенче караганда, аңарда чиксез ачу кайный, шул ук вакытта йөзенә икеләнү дә чыга: университетка полиция һәм гаскәр кертсәң, коллегалары аңа нинди күз белән карарлар? Профессор Преображенский гына түгел, башка укытучылар да студентлар ягына күчмәсме? Һай, алла, Преображенский тагын сөйли башлады түгелме? Ул бүгеннән университет профессоры түгел икәнен, аның үтенечен канәгатьләндергәннәрен әйтте, ул барыбер мондый университетта профессор булып кала алмас иде...

Студентлар аңа дәррәү кул чаптылар. Бу хәл ректор әфәндене тагын да түбәнрәк иелергә мәҗбүр итте. Ул байтак профессорларның студентларга эчтән теләктәшлек итүләрен белә иде. Әгәр алар да, Преображенский кебек, ачыктан-ачык... Кремлев әфәнде эссе залда үлем салкынлыгы сизде. Аңа вакыт туктаган кебек тоелды. Күпме вакыт үтте, бер сәгатьме, икеме, артыгракмы? Ниһаять, аның янына бер инспектор килде, иелеп, муенын сузып, ректорның колагына нәрсәдер пышылдый башлады.

— Әфәнделәр,— диде Кремлев, ниһаять, аякка басып,— уку-укыту попечителе миңа рәсми әмер биргән: Актлар залын полиция ярдәме белән чистартырга, кирәк була калса, гаскәр чакыртырга...

Студентлар шаулаша башладылар.

— Иптәшләр, безне корал көче белән буйсындырырга уйлыйлар,— диде Володя,— ләкин икенең берсе: я университетка полиция керми, я без студентлар түгел.

— Дөрес, ректор әфәнде җавап бирсен!

— Бер минут көтәбез!

— Мин сезгә үз сүземне әйттем инде, әфәнделәр: залны бушатыгыз,— диде Кремлев.— Бер генә нәрсә өсти алам: университеттан чыккан чакта полиция сезгә тимәячәк.

Җыелыш үзенең максатына ирешкән иде, әйтәселәрен ачык иттереп әйттеләр, инде сәгать дүрт, артык сузганда кан коелуы гына мөмкин.

Полянский белән Ульянов колакка-колак пышылдашып алдылар, аннары Полянский залга мөрәҗәгать итеп:

— Әфәнделәр, ректор да, профессорлар да безгә вәгъдә бирмиләр, безнең башка чарабыз юк, без университетны калдырырга мәҗбүрбез,— диде.

Ул кесәсен капшый башлады. Ул арада Володя ректор алдына

үзенең университетка керү билетын ташлады һәм ишеккә таба юнәлде. Аның артыннан башка студентлар да, керү билетларын Кремлев әфәнде алдына куеп, ишеккә борылдылар. Алар башларын иеп түгел, киресенчә, югары тотып, урамга атладылар. Карап торучылар, студентлар, полицейскийлар кара болыт кебек иде. Володя аларга күз сирпеп алды да үз юлына атлады. Беренче ачык бәрелештә җиңеп чыккан яшь көрәшче нәрсә уйлады? Киләчәктә төп бәрелешләр урамнарда, мәйданнарда булачагынмы? Анда инде тарихны үзгәртүче төп көч студентлар булмас, бәлки завод-фабрикаларда эшләүче меңнәр, миллионнар булыр. Алар бердәмрәк булып алга барыр. Билгеле, интеллигенция дә, студентлар да читтә торып калмас. Кешеләр өчен башка гадел юл юк...

Яңадан аның күз алдына Актлар залы, император университетының төп баганасы булып, йөзе кыйшайган, үзе кара көйгән инспектор Потапов килеп басты. Бүген аннан да зуррак хурлыкка очраган кеше булмады, бөтен халык алдында аның яңагына суктылар.

Кремлев әфәндене Володя бу кадәр ихтыярсыз кеше дип уйламый иде. Бүген ул да чын җиңелү ачысын татыды. Ә профессор Преображенский нинди бөркет булып чыкты, көрәштә чигенмәде, иң изге уйларына каршы бармады. Башка профессорлар Преображенский кебек ачыктан-ачык протест белдерергә җөрьәт итмәделәр. Студентларның төп массасы исә бердәм иде. Ихтимал, аларның яшьлекләре, ташып торган дәртләре, коллективлык көче роль уйнагандыр. Ялгыздан-ялгыз калгач, ихтимал, аларның да кайберләре калтырап төшәр, андый хәлләр дә була...

Володя бик дулкынланган иде, җыенга хәзер генә эзлекле йомгак ясый алмады. Ул әле бу турыда кайта-кайта уйлар; ихтимал, хәзер бөтенләй искә килмәгән нәрсәләр исенә төшәр. Һәрхәлдә, бүген ул зур чыныгу алды. Монысы бәхәссез.

Салкын көчәйгән, йолдызлар чекерәешкәннәр. Лядской бакчасыннан үткәндә Володя урындыкка утырмый түзмәде. Агачларны сыкы сарган, җил бөтенләй юк, йолдызлар белән бизәлгән күк карасу-зәңгәр. Күр — нинди матурлык! Әлек Володя мондый гүзәллекне күрмәдеме, әллә бүген генә күзләре ачылдымы! Әгәр кеше табигатьнең матурлыгын күрә алмаса, ул нинди фәкыйрь, кызганыч булыр иде. Әллә гүзәллек кешегә тора торгач кына ачыламы икән? Ихтимал, ул кешенең рухи халәтенә туры килеп, кинәттән генә бер бизәкләре белән балкып китә торгандыр.

Володя урыныннан торды, бакчаны аркылы үтеп, Яңа Комиссариат урамына аяк басты. Менә Володялар тора торган йорт. Хәзер инде иң зур вакыйга узды, хәзер ни булганын әнисе белән сеңелесе Оляга сөйләп бирергә ярый. Аннары... Володя университет ректоры исеменә гариза язарга утырыр. Шундый гариза — көрәшнең логик нәтиҗәсе. Университетка керү билетын Кремлев әфәнде алдына ташлаганда ук шундый гаризаның кирәк булачагы аңа ачык иде. Юл буенча шул гаризаның аерым сүзләре аның башында айкалды. Бакчада утырып, кышкы хозурлыкка сокланганда да күңелендә шул булды...

Володя сүзсез генә чишенеп әниләре янына керде. Мария Александровна да, Оля да университеттагы буталышлар турында ишеткәннәр. Бүген бөтен Казан шул турыда гына сөйли иде.

— Володя, син кайттыңмы? — диде Мария Александровна әчке бер шатлык белән. Ул инде улын күрермен дип уйламаган иде.

— Кайттым, әни, ләкин озаккамы,— диде Володя турысын әйтеп һәм, әнисенең кулыннан тотып, университетта ниләр булганын сөйли башлады. Әнисе тирән хәвефкә төшеп, Ольга ачыктан-ачык теләктәшлек күрсәтеп һәм сокланып тыңладылар. Володя сөйләгән саен Мария Александровнаның борчылуы артканнан-арта барды. Володя универси-

тетка керү билетын ректор алдында калдырып чыгып киткәнен әйткәч, аңа барысын аңлады. Володя бүгеннән студент түгел инде, аның өчен университет ишекләре ябык. Аңа бернәрсәне дә гафу итмәячәкләр.

Мария Александровна улын ачуланмады, бары тик улының башын күкрәгенә куеп кысты, ә агарынган иреннәре ишетелер-ишетелмәс итеп:

— Володя, Володя!..— дип пышылдады.

— Кичер син мине, әнием. Мин башкача булдыра алмадым.

Аннары Володя ректор исеменә гариза язарга утырды.

*«Университет тормышының хәзерге шартларында Университетта белем алуны дәвам иттерергә мөмкин түгеллеген аңлап, Сез Галиҗәнаптән мине Казан император Университеты студентлары исемлегеннән сызарга күрсәтмә бирүегезне түбәнчелек белән үтенәм.*

*Юридик факультетның I нче семестр студенты Владимир Ульянов.»*

Володя сәгатькә карады. Унике тулып беренче киткән иде инде. Шуннан: «Казан, 1887 елның 5 декабре» дип язып куйды.

Күп тә үтмәде, ишек дөбердәтә башладылар.

## 12

Үзен кулга алуларын Володя Ульянов көтә иде — Потапов тырышкан,— приставның төнлә килүе гаҗәп булмады. Менә әнисе кызганыч. Саша өчен йөрәк әрнүләре басылып өлгермәде, инде икенче улын алып китәләр. Аңа бик авыр, мөмкин булса, Володя аның бөтен кайгысын үзенә алыр иде. Аның белән саубуллашып, бүреген кулына тотып баскычтан төшкәндә, ул әнисенең йөрәк тибешен ишеткәндәй булды. Карт пристав аның кичерешләрен аңламады, бу малай мондый бәлагә очраклы гына килеп эләккәндер дип уйлап:

— Нәрсә бунт күтәрәсез, егет, алдыгызда стена тора бит,— диде.

— Стенасын стена да — тик черек ул, бармак белән төртсәң дә авып китәргә тора,— диде Володя тыныч кына.

Карт пристав, кылычына тотынып, артка чигенде һәм, ни әйтергә белмичә:

— Саграк, егет! — дип мыгырданды.

Чана тирәсендә дә — полицейскийлар, пүнәтәйләр, күчер карт ат башыннан тоткан. Ул Володяның приставка биргән җавабын яхшылап ишетмәде, мәгънәсен аңламады. Ул яшь егеткә чын кызгану хисе белән карады, әти-әнисенә тагын никадәр кайгы, дип уйлады эченнән. Эх, балалар, балалар, белмиләр шул ата-ана йөрәген!

Володя артлы чанага утырды, ике ягына ике кылычлы сикереп менде. Бабай картларча ашыкмый гына атын борды.

— Я, нәрсә каттың?! — дип кычкырды пристав аңа ачулы тавыш белән.— Җәһәтрәк кыймылда!

Олаучы чыбыркысын шартлатты. Төрмәгә тиз барып җитәр — тик аннан тиз чыгарырсызмы, дип уйлады бабай. Салкын урамда тимер табаннар чыжылдап калды. Карасу күктән, бу нинди хәл дигән сыман, йолдызлар чекерәешә. Бакчадагы агачлар баягы кебек ак түгел, карала төшкәннәр иде.

Володя як-ягындагы полицейскийларга карап алды. Тегеләр бу карашны үзләренчә юрап, кача күрмәгәе дип, кылычларына тотындылар.

Володяның башында күңелсез уйлар иде. Мөгаен, бу төндә күпләрне кулга алганнардыр. Университет студентларыннан ышанычлы кешеләр калмас, якташлык түгәрәкләрен туздырырлар. Исмәсәм, Скворцов, Богораз, Мотовилов исән калсыннар иде, алар нык иптәш-

ләр, эшне туктатмаслар, төрмә белән бәйләнешкә кирәкләр. Белеп булмый ул таш капчыкта күпме тотасыларын...

Володяны Кремль янындагы пересыльный төрмәгә илтеп, бер кешелек камерага яптылар. Аның үз киемнәрен салдырып, арестант халаты бирделәр. Володя кулы белән шәрә сәкегә тотынды һәм күз алдына Саша килде. Ул да актык көннәрен шундый шакшы, шыксыз һәм караңгы камерада уткәргәндер. Нихәл итәсең, Володя үзе теләп шундый язмышны сайлап алды. Күпләр, язмыштан узмыш юк, ул ходай тәкъдире белән алдан билгеләнгән, диләр. Соң шулаймы икән бу? Әгәр теләсә, Володя бу язмыштан узар иде, әмма ул теләмәде, башын күтәреп, яшь йөрәкнең бөтен ярсуын тоеп, аңа каршы атлады. Ул киләчәктә дә тартышырга әзер. Үзе өчен түгел, халык өчен, меңнәр, миллионнар өчен. Халыкның йөрәк җылысын тойсаң, салкын камерада куркытмый, алда, караңгы пәрдә артыннан яктылык шәүләсе шәйләнә.

Икенче көнне студентларның барысын тулай камерага күчерделәр. Моны башларына да китермәгән яшьләр, шаулашып, кочаклаша башладылар. Аларга рухи күтәренкелек, дәрт кайтты, алар инде үзләрен чак кына герой итеп саный башладылар. Соң шулай булмыйча, халык өчен газап чигәләр ләбаса! Башка ни эшләргә белмәгәнгә, алар иң элек бу хурлык тамгаларыннан — арестант киемнәреннән арынырга булдылар, үз киемнәрен таләп иттеләр. Кайберәүләр шул кадәр шауладьі, гүя бөтен эш шул пычрак халатларда гына иде кебек. Ниһаять, таләпләре губернатор хөкеменә киткәнлеген белгәч, алар үзләрен җиңүчеләр кебек хис иттеләр. Бер тәүлек ашамауга карамастан, күңелләре сүрелмәде, әле революцион җырлар җырладылар, әле үзләренең яраткан студент җырларын башладылар, шаярдылар, төрле мәзәкләр сөйләделәр, шигырь белән дә, проза белән дә иреккә өндәмәләр яздылар. Тик Володя гына бу шау-шуга катнашмады, эндәшми утырды, гүя үз эченә бикләнгән, гомуми күтәренкелектә аның эше юк иде. Кайчакта иптәшләре кулындагы өндәмәләрне алып укыды, аерым җөмләләрне, аерым сүзләрне төзәтеп куйды.

Володя җыенга кадәр үк житди иде, күп уйлады, күп укыды, ә җыен һәм төрмә аны тагын да рухи үстереп җибәрде, ул бер төн эчендә олыгаеп китте. Кайчан башланды соң бу үзгәреш? Пристав стена турында әйткән һәм Володя аңа җавап биргән минуттанмы?

Студентлар — уйлап табуга һәвәс егетләр. Кайсыныңдыр башына кызыклы бер фикер килде. Ул иптәшләреннән: «Азат ителгәч, ягъни Казаннан сөрелгәч, кем нәрсә эшләргә җыена?» — дип сорады. Бу сорау күпләр өчен көтелмәгәнрәк булды, ахры. Шунлыктан алар икеләнеп, буталып җавап бирделәр. Берсе, ничек кенә булса да, укуымны дәвам иттерәм, диде, икенчесе, язучы булам, матурлык өчен көрәшәм, диде, башкалары башка хыялларын әйттеләр.

Анкетаны Володяга бирделәр.

— Я, Ульянов, синең башта нинди уйлар? Иреккә чыккач нишләмәкче буласың?

Володя, алдагы уйларыннан аерылгандай, елмаеп куйды.

— Нәрсә әйтим мин сезгә? Минем алда бер генә юл — революцион көрәш юлы тора,— диде.

Володя көрәшнең бөтен авырлыгын, житдилеген аңлап, яхшы уйлап, үз-үзенә ышанып җавап бирде. Бер минутлык уңыш казану, иптәшләреннән дәррәү кул чаптыру — аның максаты түгел иде.

Студентлар тынып калды. Алар анда иректәге хәлләрне уйладылар бугай. Әгәр алар бу вакытта Воскресенский урамында йөзләрчә студентларның җыелуын, төрмәдә утыручыларга чын күңелдән теләктәшлек күрсәтүләрен белсәләр, рухлары күтәрелә төшәр иде. Төрмә

теналары калын, тәрәзәләре тимерле, ишекләре йозаклы. Тыштагы вазлар монда ишетелми шул.

Кичкә таба кулга алынган студентларның кайберләрен ирекка ыгара башладылар. Тагын бер нәрсә ачыкланды: аларның берсен дә Казанда калдырмыйлар икән, кайсын кая, күбесен туган якларына заталар, имеш. Университет ябылган!

Тышта каты салкыннар, ә студентларның күбесенен киярләренә җылы киемнәре юк. Нишләрләр, туңып үлмәсләрме?

Володя үзен тиз генә азат итәрләр дип көтмәде. Аның абыйсы гына өкүмәт җинаятьчесе түгел, бер туган апасы да полициянен ачык күзә-үе астында сөргендә ята. Андый кешеләрнен энеләренә нинди мәрхә-әт булсын. Дөрес, әнисе ана кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә ырышыр, тик юл куярлармы?

Исемлектә Володяның фамилиясе турысына өч тәре, ягъни «иң кур-ыныч» дип билге куйганнар иде. Володя моны белми, белсә, ихтимал, ычынып көлемсерәр иде. Төнлә ул бөтенләй диярлек йокламады, гел йланды. Университеттагы җыенга Сембер якташлыгына кергән сту-ентлар актив катнашты. Бу хәлгә Володя бик горурланды. Һичберсе өчен кызарырга туры килмәде. Ә университетта Пензадан, Уфадан Троицкидан, Краснодардан, Доннан һәм башка шәһәрләрдән дә сту-ентлар бар. Милләтләре дә төрле-төрле: руслар, украиннар, белорус-лар, яһүдләр, немецлар, поляк балалары, литвалылар, башкортлар, Бәрән-сәрән татарлар. «Димәк,— дип уйлады Володя,— самодержавие-ге бер халык та яратмый, барысы аның асылын таныйлар. Бу кечкенә нәрсә түгел!»

Володя ниндиләр эчке бәйләнешләр аркасында — ихтимал, төрмә-дәге гомуми караңгылыктандыр — Казандагы студентлар тормышына караган бер мәкаләдә Мәгариф министрлыгын, ягъни агарту министр-лыгын, «караңгылату министрлыгы» дип атауларын исенә төшереп көлемсерәп куйды. Бу сүз уйнату гына түгел, бәлки хәзерге Мәгариф министрлыгына бик дөрес бирелгән бәя иде. Алдынгы студентларның бүген караңгы төрмәдә ятулары очраклы хәлмени?

Кемдер йокы аралаш мыгырдана, карыша, тартыша, кемдер елый, илерә, гафу үтенә иде.

Володя башын күтәреп тавышларын тыңлады. Нәрсә бу, төштә булса да полиция этләреннән гафу үтенүме? Төрмә инде ул егетнең котын алып өлгергән! Бу хәчтерүш шушы шартларда болай илерсә, чын сынау башлангач, нишләр? Өндә бит йөз, мең мәртәбә кыенрак булачак.

Володя бу студентның фамилиясен белми иде. Бәлки, ул иң ямаң кычкыручыларның берсе булгандыр. Сынауга кадәр кайберәүләр йодрыкларын йомарлап дулыйлар, сынау килгәч, шыр җибәрәләр... Шунда Володя инспектор Потаповның яңагына суккан Боря Рогачев-скийны исенә төшерде. Нигә ул төрмәдә күренми? Качып өлгергәнме әллә?

7 нче декабрь көнен хәзергә әле төрмәдә яткан студентлар көгү белән үткәрделәр. Бүген аларның һәммәсен төрмәдән чыгарып бетерә-селәрен әйттеләр. Казанда калдырмауларын да яшермәделәр. Димәк, элекке студентлар тормышында яңа дәвер башлана. Кичә генә мона ышанып бетмәүчеләр бар иде. Чынбарлык бигрәк рәхимсез икән. Ничек яшәрләр? Мал-мөлкәтле ата-аналары булганнар кайгырмый, ә бер тиенсез студентлар? Алар бит күбрәк!

Володяга да әйттеләр: аны сөргенгә Казаннан кырык чакрымдагы Кокушкино авылына җибәрәчәкләр икән.

Иң соңгыларының берсе итеп Володяны дәштеләр. Ул, хәтеренә сеңдерергә теләгәндәй, тагын бер тапкыр камера эчен күздән кичерде дә ишеккә юнәлде.

Төрмә ишегалдында аны энисе көтә иде. Володя энисе янына йөгереп барып, аны кочаклап алды, аннары Маняшаны салкын битеннән үпте.

Воскресенский урамы халык белән тулган иде. Володя күзләрен зур ачып аларга карады: хатын-кызлар кулъяулык болгый, нәрсәдер кычкыралар, китүчеләргә күчтәнәч, жылы кием, тәмәке-папирос бирәләр. Беренче гимназия шәкертләре,— Ольга шул гимназиядә укый иде,— барлык саклык акчаларын, хәтта кул сәгатьләрен дә китергәннәр. Әгәр Володя Николай Федосеевның китүчеләргә ярдәм итү өчен үзенең бөтен шәхси китапханәсен сатканлыгын белсә, нәрсә дип уйлар иде икән! Болай да Володя халыкның студентларны бу кадәр яклавын көтмәгән иде. Күңеле күтәрелеп китте.

Һавада төрле төстәге кәгазьләр оча башлады. Бу студентларның төрмәдән язган саубуллашу хаты иде. Иректә калган иптәшләр аны гектографта басып өлгергәннәр!

«Сау бул, Казан!.. Сау бул, университет!.. Әле күптәнме соң безнең күңелләрдә университетка һәм аның тормышына зур мәхәббәт иде, шул мәхәббәт белән без университетка килеп кердек, монда, фән йортында, газап чиккән туган илнең бәхете өчен көрәшүчеләр булып тормышка атларлык белем табарбыз дип уйлаган идек!.. Без ул белемне бөтен жан көчебез белән эзләдек, эмма... тапмадык!..

Без протест белдерергә мәжбүр булдык һәм безнең бу протест актив төс — жыен төсен алды. Шуның өчен безне университеттан чыгардылар һәм Казаннан куалар!!!

Без үз эшебезнең хаклыгына тирән ышаныч белән Казаннан китәбез. Безне яратучыларның кулларын кысабыз!!!»

Акчарлаклар кебек очкан бу листовкаларны озатучылар һавада тотып алалар, беренче юлларына тиз генә күз салалар: «Сау бул, Казан!.. Сау бул, университет!..» Тулысы белән соңыннан укырлар, хәзер жиң очларына, муфталарына, кесәләренә яшерәләр. Аннары тагын Воскресенский буйлап үтүче студентларга кул болгыйлар. Студентлар, чаналарга басып, уңга да, сулга да баш иyәләр.

Көймәле чаналарның берсендә Володя Ульянов бара. Янында энисе белән сеңелесе Маняша. Мария Александровнаның йөзе агарган булса да — тыныч, Маняшаның күзләрендә борчылу һәм курку галәмәтләре. Кайчак ул, башын сузып, артка карап ала: тимер чанада, бер адым калмыйча, полиция чиновнигы килә, вакыт-вакыт Маняшага ул гүя бармак яный. Маняша шунда ук башын яшерә.

Һавада кар бөртекләре очкалый. Төнлә буран кузгалыр, ахры. Кояш инде күренми, кырлар түрендә жәяүле буран себерә. Шәһәр артта калды. Маняша тагын башын сузып караган иде, полицейскийны күрмәде. Ул арестантны шәһәрне чыкканчы гына озата килгән, ахрысы. Аның югалуына Маняша чын күңеленнән шатланды. Үзе Володяга карап алып:

— Ул карга батты! — дип пышылдады.

Кузла башында толыплы олаучы утыра иде. Ул, туңган иреннәрен чупылдатып, атын әйди, үзе, жил сызгыруы кебек, гел бер төрле тавыш белән жыр суза. Сүзләре аңлашылмый, дөресрәге — сүзләре юк та шикелле, ул гүя үз алдына шыңшый гына. Дугадагы жиз кыңгыравы шул тойгыны тагын да көчәйтә төшә иде...

*Ахыры бар*

## Флера Гыйззәтуллина

# ИРТӘНГЕ ҖЫРЛАР

●

Иртәнге як — күңелләр саф чаклар,
Яңгыр явып узган юллардан.
Сөйгән чагым,
сөелә белгән чагым,
Ерак йөргән чагым моң-зардан.

Кайгылардан китеп торган чагым,
Шигырь көйли минем йөрәгем.
Тел очымда шигырь,
баш очымда,
Шигырь булып күренә тирә-юнь.

Бөтенләйгә онытып торган чагым
Мәшәкатен фани дөньяның.
Суларым һәм чиләкләрем белән
Җырларыма кереп югалдым.

Җырлый-җырлый чәчләремне үрдем,
Туйлар килгән якка йөгердем.
Кабат минем егерме яшь чагым,
Туй күлмәге кигән егермем.

Кыңгыраулар чыңы!..
Ярсулардан
Чак-чак тыеп торам атларны!..
Шигыремә салып бүләк итәм,
Дуслар, сезгә шушы чакларны.

●

Сөйгәнем, өметсез өзелмә,
Юралган көннәргә кайтмадым.
Юлларым — киң ялан — югалмам!
Юлларда язылган җырымда
Мин сине «Идел» дип атадым.

Сөйгәнем, өметсез өзелмә,
Иделдә бүген дә дулкыннар.
Дулкыннар шау-шуы моңымда.
Йөрәккә ут кирәк булганга
Мин сине «учак» дип атадым,—
Үрелеп ал мине җылыңа.

Сүрелмә, өметсез өзелмә,
Буйларың җитмәслек түгел лә!
Мин сине «таулар» дип атадым,
Сүз саен тауларга менгәнгә,—
Җиңелмәс көч-куәт биргәнгә
Таулардай мәхәббәт сакладым.

Галәмдә киңлеклр җитәрлек,
Тиңләшер яктылык эзләсәң!
Мин сине «йолдыз» дип атармын,
Сөюдән өметеңне өзмәсәң.

●

Ялгыз туалар кешеләр
Миллионнар үскән җиргә,
Миллионнар берәм-берәмләп
Дөньядан күчкән җиргә.

Күрәшле, күз яшьле җиремдә
Яз исе,
чәчәк исе.
Яр таба,
сөя,
назлана,
Бәрәкәт тулы иленд
Бәхетен таба кеше.

Бәхеткә куллар сузыла
Берсеннән-берсе узып...
Алда тау-ташлар ятса да,
Ышаныч кумәк булганда
Юл ярулары кызык.

●

Бу тормышта кеше булу өчен
Җитми икән һөнәр,
аң гына.
Кеше изге эшен,
вәгъдәләрен үтәп,
Максатына җитеп таныла.

●

Офыклар ялкын,
офыклар яна,
Иделне мана таңнар алсуы.

Таңнарда Идел ярлардан аша,
Идел шау-шуы — җаным ярсуы.

Офыклар ялкын, офыклар яна.

Иделдә ага таңнар,
ялкыннар.
Идел юллары — бәхет юллары...
Калышма, җырым, Идел артыннан!

●

Җилфер-җилфер гөлчәчәкләр җиле,
Гөлчәчәкләр өздем унҗиде...
Унҗидедә сөйдем,
унҗиде кат көйдем,
Көюем белән бәхетле идем.

Ак күлмәгем салып,
зәңгәрлесен кидем,
Зәңгәр диеп белеп яшьлекне.
Хәзер мин тормышның
барлык төсен күреп
Таный алуым белән бәхетле.

●

Шыбыр-шыбыр килә таш түбәләр,
Таш өстендә бии тамчылар.
Төнге яңгыр таш юлларны юа,
Куаналар микән ташчылар.

Урамнарның изрәп йоклар чагы,
Машиналар тынган бу мизгел.
Күңеле сүлпәннәргә «таш» димәгез,
Бу заманда ташлар, һай, сизгер.

Ташлар юыла, иске эзләр юыла,
Пакь юлларга башлап кем чыгар?
Йокләр авырлыктан җиксенмәгез,
Таш чыдаса, газиз баш чыдар.

Шыбыр-шыбыр ява,
яңгыр ява...
Ярлар тула, ташлар яктыра.
Уй-теләкләр хәерхаһ була да
Тулып чайпалырдай чак була.

●

Алтын тау — ялган вәгъдә,
Беләм онытыласын.
Алтын тауларына да син
Бирешмә, газиз башым.

Алтын ул — салкын хыял,
Җан аулый алтын-көмеш.
Үз көнемә үзем хуҗа
Бер көмешем юк килеш.

●

Каен, каен!
Каерылган саен
Туктап калам шушы урында.
Кинәт чыңлап җыр өзелгән иде,
Тальян тынгач әткәй кулында.

Сайрауларын кошлар оныттылар,
Сулар акмый торды түбәнгә.
Күкләр күкрәр,
җирләр тетрәр булса,
Алдан сизенә икән бу бәндә.

Сугыштан соң ничә еллар узды,
Күңел курка, һаман сискәнә.
Шушы турда без хушлашкан идек,
Әткәй яу кырына киткәндә.

Кырык бернең корым-сөремнәрен
Әле дә саклый каен тузлары.
Яфракларда шаулый тальян моңы,
Хәтеремдә юллар тузаны.

●

Сине сагынып сагышланган чакта
Мин һәр вакыт тулган айга карыйм.
Соңлап юлга чыксам,
юл адашсам,
Күктә янган йолдызларны барлыйм.

Әгәр күкне болыт каплап алса,
Кайталмасам,
өметеңне өзмә!
Мин китәрмен бураннарга каршы,
Артта калган дусларымны эзләп.

●

Кеше чагыштыра иң вак әйберләрне
Энә күзе белән.
Мин — тегүче, энә күзе аша
Бар дөньяны күрәм.

●

Җилдә җилләп керләр кибә...
Сусап иреннәрем кибә.
Су юллары,
су буйлары
Яшел җәймә, ефәк keләм...

Яшел чирәм су юлыннан
Күңелле барулары.
Кое тирән, кое тирән...
Иҗат коелары тирән,
Кыен су алулары.

## Сөю көче

«Яратылган»,— дип сөйлибез бу дөньяны.
Кем тапкан да
кем яраткан башлап аны?
Мәхәббәтне башлап җиргә кем иңдергән?
Дәлилләнгән, куәтләнгән ул ни белән?

Янар кояшка тиңлибез без сөюне.
Һәм шул сөю мәңгелеккә багышлана.
Ләкин кайчак шул мәңгелек алдында да
Юл куела төзәтелмәс ялгышларга:

Кайберәүләр күкне зәңгәр балкыш диләр.
Ә тауларны күккә менәр баскыч диләр.
Һәм үзләре беркайчан да шул тауларга
Менмиләр дә,
менгәннәрне күрмиләр дә...

Мәхәббәттә әзер таулар, баскычлар юк,
Рухы белән таулардан да бөек кеше.
Сөю-сөелү күңелләрнең яшьлеге ул,
Биеклекнең, чиксезлекнең тиңдәшчесе.

...Җирдән алып кояшкача күпме сере,
Ничә катлы офыклары бар дөньяның!
Кешеләрнең баш очында кояш янса,—
Иң алдагы ал таңнарда хыяллары!

Хыялларның, ачышларның дәвамнары
Гомерләрнең мәңге кабатланышында.
Һәр мәхәббәт — бер планета,
бер ачыш ул,
Көчең җитсә яула аны,
яшә шунда.

## Мин Әсәйдән

Тау өстендә таулар.
Тауга карыйм:
Офыкларда — таулар дәвамы.
Таулар түбәсенә илткән сукмакларның
Ил язмышын сөйләп бирердәй
Үз җырлары, бар бит аларның.

Авыл — сукмакларның
Исме яши
Тоташтырып чорлар арасын:
Урманайлар,
Аю, Азнакайлар...
Авыл саный-саный, таулар буйлап,
Барасы да әле барасы...

Мин Әсәйдән үзем.
Тирә-юнем —
Таллы Бүләк,
Балтач,
Яланат...
Мин Әсәйдән үзем.
Әсәй сүзен
Ураллардан урап,
Идел буйлап
Алып килгән безгә Салават.
Мин Әсәйдән!
Әсәй юлында бар
«Емельян» дип йөрткән миләшлек!
Емельяннар, Салаватлар түккән
Кан төсләре миләшләргә күчкән,
Тәлгәш-тәлгәш монда Әсәйләрнең
Хаклык өчен түккән күз яше.

...Аю таулар. Биек Чатыр таулар...
Дөм караңгы тирән куышларда
Җан аямый кемнәр куышкан?—
Легендалар, җырлар туып калган
Гарасатлы хәтәр сугыштан.
Чатыр тау каршында кемнәрнеңдер
Баш сөяге,
балталары калган,
Тау-ташларда — ядрә эзләре!..
Балтачларга,
Аю,
Әсәйләргә
Ирек яулап йөргән Азаматлар —
Җирдә ярылып калган эзләре.
Тау өстендә таулар.
Тауга карыйм:
Офыкларда — таулар дәвамы.
Таулар түбәсенә илткән
Сукмакларның
Ил язмышын сөйләп бирердәй
Үз җырлары бар бит аларның.

## Марсель Галиев

# АНА

*Хикәя*



Сау гынамы, Сания апа!

Ак чалбардан, ак күлмәктән балкып торган егеткә ана күзләрен кыса төшеп карады.

— И-и-и, шөкер генә, улым. Күптән безнең капканың келәсен күтәргәнең юк иде. Әйдә, уз... Бераз ябыккансың димме, улым? Әниеңнең саулыгы ничек соң, сихәтләнәме?

— Һаман шулай, бер көе...

Бер мәлгә икесе дә тын калдылар. Ана егетнең аркасыннан сөйгәндәй итте һәм тынлыкны бозарга теләмәгәндәй сак кына дәшеп куйды:

— Әйдә, улым, өйгә узыйк.

— Юк, Сания апа, озакка дип кермәдем.

Ана: «Хәзер чәй өлгертәм, ризыктан авыз иттермичә җибәрәмме соң!» — дип сөйләнә-сөйләнә өенә кереп китте. Егет чирәмле ишегалдын күздән кичерде. Таныш, бигрәк таныш. Ул — келәм кебек яшел чирәм эченнән сузылып киткән сукмаклар дисеңме, ул тартылган бауга эленгән ак керләр дисеңме (Синара җитез-җитез атлап, аяк очына гына басып үреләүреләуреләә, шул керләрне элеп йөрер иде)— барысы да таныш, күңелгә якын, хәтергә сеңеп калган.

Бакча ягында, нәфис канатлары белән бал исе җилпеп, умарта кортлары очына. Әйтерсең күренмәс куллар яшеллек арасыннан алтын шарлар чөеп уйный.

Өйалды ишеге ябылырга да өлгермәде, ана әйләнеп тә чыкты. Кулында ак конверт. Кызының кичә генә хаты, карточкасы килгән икән.

— Бик борчылган кебек, балакаем. Сагынам, ди шул, сагынам, ди. Укуы да авырдыр инде. Сиңа ничегрәк яза соң?

— ?..

Рәсемдә Кремль дивары янында елмаеп торучы кыз. Ул очып барганда тукталып калган кебек. Егет үзенә дә ишетелмәслек итеп пышылдап куйды: «Синара»... Шул чак аның күңеленнән әйтергә кыймый торган сүзләре берьюлы ташып чыкты.

— Сания апа, мин бит өйләнергә булдым.

— Ничек, улым? Капылт кына. Синараның укуын бетерәсе бар ич. Ул тегендә, син монда дигәндәй.

Егетнең тамагы кипте. Ул кыюсыз хәрәкәт ясап куйды.

— Килүем, бәлки, урынсыздыр да. Килми калсам да, яхшы түгел сыман. Мин бит сезгә шул кадәр күнеккән идем. Әллә ни уйламасын, бүтәннәрдән ишетмәсен дип үзем килдем. Башкага өйләнергә булдым мин, Сания апа.

Ана, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, егеткә карады. Ул күз алдында кечерәеп калгандай булды. «Ничек? Бозылышканнары да сизелми иде. Ул-бу булса Синарам әйтми-киңәшми калмас иде...»

— Мин күп уйладым инде бу турыда. Отыры олыгаела. Ә Синара һаман шулай, җилбәзәк. Укуны бетергәч, еракка китәм, ди. Минем белән китсәң генә мин синеке, ди. Мин аны гаепләмим. Ул шәһәр дөньясына күнеккәндер. Ә миңа монда калу кирәк... Кичер мине, Сания апа.

Ана офыкка төбәлде. Әмма ул берни дә күрми иде. Рәнҗүле карашка дөнья таркау, эчтәлексез. Ул күңеленнән өзелеп-өзелеп тәкърарлады. «Үз улым кебек күрәдер идем бит. Иялән беткән идем үзеңә. Үз улым кебек... бөтенесе дә гади, аңлаешлы иде бит. Кичләрен клубка алырга дип килеп керер иде. Шау-гөр килеп чыгып китәрләр иде. Ә мин, үземчә, озак йөрмәгез дип, шелтәләп калган була идем. Нинди кыз назландырырга яратмый, уйнап кына әйткәндер. Ничә ел бергә булып та...»

Егет кузгала башлауга ана исенә килде.

— Туктале, улым. Күптәнге бер нәзерем бар ие. Сез танышкан елны туй... туегызны ачармын дип юкә балыннан шәраб куйган идем. Әйткән нәзерем тотмасын, я бәхетең ким булыр, балам. Кемнең дә булса кадерлесенә насыйп булгансыңдыр бит. Хәзер, хәзер, сабыр ит.

Ана баз авызын ачты. Тонган караңгылык. Ул капшана-капшана төшә башлады. Менә беренче баскыч. Аңа еллар аръягыннан кызының тавышы ишетелгәндәй булды.

— Әни,чибәр ул егет. Менә күрерсең әле, әни. Үзе акыллы...

Икенче баскыч...

— Әни, ул әллә ниләр белә. Шундый маҗаралы итеп сөйли. Янында бөтенләй дөньяңны онытасың...

Өченче баскыч...

Аягы таеп китте. Юеш, ахры...

— Әни, ул үпкәле дә икән. Шаяртканымны белгәч, яңадан ачылып китә, сабый кебек. Күтәреп ала да мине әллә кая кадәр илтә. Тагын тынып кала да: безнең яшьлек тә шаяру гына булып калмас микән, ди...

Дүртенче баскыч арасы бераз киңрәк. Менә күнегелгән араны аяк эзләп тапты да.

— Әни, кайбер чакта мин аны сине ратканнан да артыграк яратам дисәм, үпкәләмәссеңме?

Ана ихтыярсыздан пышылдап куйды. «Болар икесе ике ярату түгелме соң, балам...»

Бишенче баскыч муртайган. Уртасы сынып җиргә тиеп үк тора. Менә ул сыкрап куйды.

— Әни, ул хәзер әллә ничек. Гел мине тыңлый. Шәһәр турында сөйлә әле, ди. Үзе кырыс. Бер ноктага төбәлә дә уйга чума. Дәшәм, дәшәм,— ишетми. Үпкәләсәм, яңадан иркәли башлый. Әйбәт син, ди. Ә күзләре салкын, көзге төн кебек...

Аяклары җиргә тиде. «Биш ел элек күмгән идем... Кызым шетте микән? Ах, балалар, балалар. Ана теләгәнчә түгел шул... Іушында булырга тиеш...»

Калтыранган бармаклар туфракны аралый башлады. «Юкә балы де... Колмак та салган идем... Биш ел элек... Һай, ул чаклар. Бааңа сөю-сәгадәт килгәндә ана да кызы яшендә буладыр ул... Клуба чыгып киткәннәрен койма ярыгыннан карап кала торган ием. ергә булырлар сыман ие... Ах, балалар, балалар...»

Баздан чыгуга ул көн йөзенә карый алмый торды. Күзләрен чса — ишегалды буш, тын.

— Улым, кайда син?

Ана үз тавышыннан үзе сискәнеп китте. Гүя баздан бүтән берәү әшә иде.

— Улым...

Тавышы гүя иреннәрендә бозланды. Аның баскычка күзе төште. Җанаты каерылган ак күгәрчен тыпырчына. Юк... конверт икән. Җыерчыклы куллар конвертны ачты. Эчендә фотокарточка. Кызыыкы. Очкынлы күзләр. Шат йөз. Ә чәчләре, чәч түгел — туктап, еп калган җил.

— Кызым...

Әйтерсең ана дәшүгә кыз рәсемнән чыгар да яшьлегенә йөгеәр. Шашып! Куанычлы көннәрен табар да шул көн кояшлары белән киредән кайтыр. Көлеп! Сөенеп! Тып итеп рәсемгә тамган яшь нәрдәкләнде, елмаюлы күзләрне каплады. Бала мәхәббәте ана өчен дә сөю-сәгадәттер. Бу минутта ул нәрсәнеңдер өзелүен тойды. Тарыккан җанына киңлек эзләгәндәй капканы ачты. Баганага сөялде. Ананың уңган күзләре кайнарландылар. Дөнья тоташ зәңгәрлеккә манчылды. Урам гүя дәрья. Дәрья уртасында чайкалган ак җилкән торган саен кечерәя барды һәм тәмам эреп күздән югалды.

## Рәшит Гәрәй

### Алтын тотып түгел...

Мәхәббәтне сатып алмагандай,
Бәхетне дә сатып алмыйлар.
Игенчеләр аның җирдә шытып,
Җирдә үскәнлеген аңлыйлар.

Туа тумыштан ук уҗым исе,
Башак исе тансык аларга.
Күнеккәннәр алар һәр бөртекне
Алтыннан да кыйммәт санарга.

Иң кадерле ризык итеп көн дә
Кара икмәк куела табынга.
Алтын тотып түгел, икмәк тотып
Ант итәләр кирәк чагында.

### Шул йөкләрне сөйрәп

Чаллы болай артык ерак түгел
Минем туып-үскән авылдан.
Тик шулай да, юлым аның аша
Узар булса, котым алынган.

Әй, ул чакта кая машиналар!
Туйдыгызмы диген атына.
Кем уйлаган ул чак менә бүген
Төзеләчәк «КамАЗ» хакында.

«Уфалла»га җигелеп йөк ташулар
Искә төшә әле һаман да.
Шул йөкләрне сөйрәп ашыкканбыз
«КамАЗ»ларын бирер заманга.

## Башка чыгучылар ашыктыра

Киң җилкәле ирләр киң урамда
Бура күтәрәләр язларын.
Бу шигыремне алар күтәрәчәк
Бүрәнәгә утырып язамын.

Сагыз исе аңкый тирә-якка
Гәрәбәдәй сары нараттан.
Авыл, авыл, сиңа ямь өстәгән
Биек бураларны яратам.

Башка чыгучылар ашыктыра,
Син аларга тел-теш тигезмә.
Көтелмәгән яңа бәхет иңсен
Алар кора торган нигезгә.

## Яшиләр кешелек күңелендә

Бер йорттан бертуган биш егет
Киткәннәр изге яу кырына.
Авылда бер үк сүз сөйләнә
Аларның һәркайсы турында:

— Батыр ул күп бирер үзеннән,
Үзенә аз сорар тормыштан.
Кешегә хас шундый тыйнаклык
Киләдер, ахры, тумыштан.

Бишесе биш җирдә ауганнар,
Тик алар бер җирдә бүген дә.
Бер җирдә яшиләр барсы да,
Яшиләр кешеләр күңелендә.

## Яшьлегемнең ярсу атлары

Үзем бикләп кергән арт капканы
Кемнәр инде чыгып ачканнар.
Яшьлегемнең җитез чаптарлары
Тезгеннәрен өзеп качканнар.

Ындыр артындагы үзәннәрдә
Ярылып ята тояк эзләре.
Кайда икән хәзер, кайда икән,
Кайда икән алар үзләре?

Тайлар алар кире кайталар, дип,
Нигә, күңелем, мине алдадың?
... Яшьлегемнең җитез чаптарлары
Җилфердәтеп узды елларын.

## Гөлшат Зәйнашева

# Әкият илендә

Синең белән бергә үткән гомерем
Әллә төштә, әллә өнемдә.
Саубуллашып җирчә яшәү белән,
Яшәдек без әкият илендә.
Әкият иле шундый гүзәл иде,
Гөлләр иде тирә-ягыбыз.
Оныттык без дөнья кайгыларын,
Әйтерсең лә сабый чагыбыз.
Сабыйларча чәчәк җыеп йөрдек,
Сокланып һәр гөлгә, үләнгә.
Таң аттырдык урман, аланнарда,
Хуҗа булып барлык гөлләргә.
Сайрар кошлар безнең дуслар иде,
Бар табигать туган йорт иде.
Нинди дуслык булган безнең дуслык —
Ике йөрәк бердәм ут иде.
Миндә, беләм, һич тә булмагандыр
Әкияттәге кебек матурлык.
Тик мин хәйран калдым синдә күреп
Әкияттәге кебек батырлык.
Әкият күге алсу зәңгәр иде,
Күтәрелдек икәү биеккә.
Ахыры матур беткән әкияттәй,
Бетсен иде безнең әкият тә.
Ахыры матур беткән әкияттән
Күчсәк иде без җир иленә.
Чын бәхет бит кешегә җирдә яшәп,
Җирчә яшәп кенә бирелә.

## Нурия Измайлова

### Билгесезлек

Киләсе көн булган өчен
　　　　яшим бүген,
«Ачылыр,— дим,— могжизалы
　　　　яшел бөрем».
Таң ата да юлга ята
　　　　серле томан.
Киләчәккә карап тагын
　　　　юлга чыгам.
Язлар якын, язлар җитә
　　　　йомшак җилле...
Ә алдымда ачылмаган
　　　　тылсым — бөре.
Ә алдымда серле томан —
　　　　билгесезлек.
Һәм мин җирдән мәңге, мәңге
　　　　китмәм кебек.

### Тылсымлы җиләк

Хисләр чәчәк аткан болын
Ачыла, җилләр иссә.
Хыялым болыннарында
Тылсымлы җиләк пешә.
Көнгә ничә табам аны
Иксез-чиксез аланнан.
Бәхет көтеп бөгелгән ул,
Мәхәббәттән алланган.
Яратудай татлы микән?
Югалтудай ачымы?
Ничә еллар! — белә алмыйм.
Күңел әйтә: «Өз шуны!»
Кулым сузам... Җилләр көлә:
— Берәү китте сихерләп.
Өзәргә бәхет җиләген
Сихерче үзе кирәк.

●

Тиеп кенә китте кош канаты,
Чык калмады гөлдә бер бөртек.
Мәрҗән итеп тезгән хисләремне
Бер саксыз сүз куйды юк итеп.

## Лена Шакирҗанова

### Чигү чигәм

Киергедә минем хисләр...
Нечкә күңел — нечкә инә.
Җепләр сайлыйм,
Җепләр саплыйм.

Чигү чигәм...
Ак ефәккә бизәк иңә...
Төсләр эзлим, төсләр сайлыйм.
Күктән миңа
Нурлы дуга
Төрле-төрле
Җепләр суза:
Нинди кирәк,
Менә кызыл, менә яшел,
Сары, ал, ди...
Теләгәнең сайлап ал син,
Ошаганын
Сорап ал, ди.

Кулларымда нәзек инә,
Ак ефәккә бизәк иңә...
Газап чигәм, рәхәт чигәм,
Күңелләргә чәчәк чигәм...

### Ул чакта

Алда нинди олы бәхет булган,
Кем уйлаган аны ул чакта,
Яңакларны куеп яңакларга,
Сөйләшербез диеп шул хакта.

Алда нинди шатлык торган безнең,
Хыялландык микән ул чакта,
Утырырбыз диеп чыбык ташлап
Икәү бергә яккан учакка...

Алда олы бер юл көткән икән,
Атласак та төрле сукмактан.
Йөрәкләр дә бергә типкән икән,
Тоймаганбыз гына ул чакта.

Безне алга бер моң дәшкән икән,
Килде микән башка шул чакта,
Кушылырбыз диеп, бер җыр булып,
Икебез ике ташкын булсак та.

## Нинди көчләр

Әле кайтып төшәм сагынып сиңа,
Әле китеп барам яныңнан.
Язын сулар тулып ташкан сымак,
Ерагаеп көзен ярыннан...

Әле еракларда тыңлыйм сине,
Әле яннарымда җырлыйсың.
Бер ерактан, бер якыннан мине
Сагышларга нигә чорныйсың?..

Әле аерым юлдан атлыйбыз без,
Әле бер сукмактан, янәшә.
Барабыз без шулай тып-тын гына,
Тик йөрәкләр генә сөйләшә.

Аерылып таңда офыгыннан,
Кич кавышкан кояш шикелле,
Китәмен дә кабат кайтам сиңа,
Нинди көчләр мине сихерли?..

## Ялгыш кына

Ялгышып бер күзләреңә күзем салдым,
Төнсез калдык шуннан бирле, көнсез калдык...

Иңнәреңә ялгыш кына башым салдым,
Ниләр эшлик, башсыз калдык, ашсыз калдык...

Ялгыш кына колагыңа бер сүз салдым,
Икебез дә телсез калдык, өнсез калдык...

## Бишек элдек

Бишек элдек бүлмәгә,
Бии-бии тирбәлә,
Күрше-күлән, дус-ишләр
Килде бәби күрмәгә...

Калмады бер килмәгән,
Кояш элдек бүлмәгә...
Тәрәзәдән ай керген,
Шул кояшны күрмәгә...

## Саҗидә Сөләйманова

# ШАҺИНӘ

*Хикәя*



Мин аларның икесенә берьюлы гашыйк булдым,— бер төн эчендә. Җәйге төндә таң алдыннан күз алдымда чәчкә сыман бер матурлык ачылды.

Поезд кузгалыр алдыннан гына вагонга «ябырылган» шау-шулы төркемнән өч кеше мин урнашкан купега килеп керде. Икесе хатын-кыз, берсе ир-ат. Чирәм җирләргә, төзелешләргә эшкә баручы студентлар дисәм, комфортлы урын сайламаслар иде. Аннары үзләре гәүдәгә җинел булсалар да, төскә студент ишедән олырак күренәләр. Ничек кенә булмасын, күршеләрем тиктормас, тынгысыз халыкка охшый.

Керүчеләр беренче чиратта миңа русчалап сәлам бирделәр, аннары үзара татарча сөйләшә башладылар:

— Чур, сәндерә минеке!

— Алай итмик, Ләйлә, без икәү түбәнгә урнашыйк, анда Рөстәм ятсын,— диде күк күлмәкле, зәңгәр күзле кыз. Юлаучыларга утыз-утыз биш яшьләр тирәсе булыр. Гәүдәләре сылу, җыйнак, күнелләре көр, берсенең кара чәче яшьләрчә кыска, икенчесенең озын гына сары чәче нечкә кара резинка белән җилкә турысыннан кыстырып куелган. Өченчесе — керпе чәчле, кечкенә генә мыеклы ир, бу ике хатын-кызга ничек ярарга дигәндәй, нәүмизләнебрәк торды да «кичке обход ясыйм әле» дип чыгып китте. Ишектә мәһабәт буй-сынлы икенче бер ир күренде. Ул, бөтен дөньяны кочарга теләгәндәй итеп, ике кулы белән ишекнең ике ягына таянды. Торышы-килбәте белән бераз Маяковскийны хәтерләтә иде.

Беребез кара чәчле, беребез сары...

Яшь хатыннарның әле берсенә, әле икенчесенә карады, Такташ юлларын дәвам иттерде:

Сары чәчлесе ул мин идем,—

дип, чем-кара чәчле башын күкрәгенә төшерде. Аннары рөхсәт сорап күк күлмәкле кыз утырган сәкенең бер читеннән урын алды. Шигырь сөйләүче кызмача булгангамы, ханымнар берни дәшмәделәр. Чандырычаясы күк күлмәклегә тарак бирде:

— Чәченне кешечә тарап куй әле, сөймим шул ат койрыгынны.— Күк күлмәкленең ефәктәй чәче иңбашларына таралып төште.

Сары чәчкәй, зәңгәр чәчкәм...

Алтынсу ефәкне сыйпарга сузылган кул ханымның кырыс карашыннан һавада асылынып калды, хәлсез генә, кире кайтып, үз хуҗасының алкаланып маңгаена төшкән чәчен каплады. Тагын шигырь юллары. Үкенечле, сагышлы бер юл:

Шаһинәм минем, Шаһинәм...

Рөстәмнәре берничә стакан белән озын гына шешә алып керде. Гадәттәге юл мәҗлесе башланды. Йоклаган булып ятаргамы, чыгып китәргәме? Әһә, миңа теләктәш табылды. Ләйләбез:

— Мин йоклыйм, иптәшләр, узган төн дә черем итмәгән. Үзегезне үзегез карагыз,— дип купеның яртысы өчен хәл итте.

— Тсс, тынлык...

Керпе чәч шәраблы шешәсен өстәлдә калдырып чыгып китте. Зәңгәр күзле ханым йокларга яткан юлдашы янына күчеп утырды. Кәефле ир, ике кулын чәчләренә батырган килеш хәрәкәтсез калды. Бимазалар дип курыккан идем, борчылуым нигезсез икән.

Рөстәм дигәннәре бер-ике тапкыр ишектә күренде дә бөтенләй юкка чыкты, башка юлдашлары янында урын тапты, күрәсең.

Тып-тын. Ара-тирә яңгыраган паровоз гудоклары синең юлда икәнеңне онытырмый, тәгәрмәчләр тавышы юлаучы кешенең халәтен билгеле бер ритмга сала. Шул ритм иркенә бирелеп барасың да барасың. Теләсәң черем ит, теләсәң фикер йөрт. Хәрәкәтләрне чикләсә дә, уйларны чикли алмый бу ритм. Үткәннәргә, яшел уҗымлы басуларга җәяү кайтып төш, корыч акчарлак канатына утырып, киләчәккә оч. Минем уйлар исә бу кысан купе эченнән чыкмады: фикерем дәшми-тынмый бер-берсенә каршы утырган ике кеше тирәсендә әйләнде. Бер эш буенча оешкан төркем кешеләре булудан гайре аларны тагын нидер бәйли сыман. Икәүдән-икәү тып-тын утыру өчен күренмәс нәфис җепләр белән бәйләнгән булу кирәк. Дөрес, зәңгәр күзләр кырыс карый; ул күзләрдә кояш нуры чагылган линзадагы сыман мең төрле чаткы күреп калдым мин бая. Иптәшләре дә үзләрен аулакта калдырдылар. Исемнәрен ишеттемме мин аларның, юкмы — үзем өчен берсен шагыйрь, икенчесен Шаһинә дип атадым.

Шаһинәм минем, Шаһинәм...

Есенин юллары болай гына кабатланмыйдыр, алар кемгәдер төбәлгән, төбәлмеше — әлеге җитен чәч булырга тиеш.

Бер-ике тукталыш арасын дәшми баргач, әлеге «Шаһинә»не телгә алып, «шагыйрь» стаканнарга шәраб салды. Берсен юлдашына бирде. Гадәттә салмыш кешеләрнең күзләрендә мәгънәсез бер бушлык була. «Шагыйрь»нең карашында тирән моңсулык. Төнге лампа яктысында кара керфекләрдән гүя коңгырт-соры нур сирпелә. Чигә чәчләренең чал бөртекләре җемелди. Стаканның яртысыннан узган кызгылт эчемлекне ир кеше бер күтәрүдә эчеп куйды. Каршыдагы стакан эчелмәгән килеш кире өстәлгә утырды. Тагын тынлык. Гудок сызгыртуы да тәгәрмәчләр тыкылдавы.

— Нигә эчәсең?

— Син һаман каты бәгырьле...

— Йомшаклар янында рәхәткә тиештеңме соң?

Кайгыртучанлык белән әйтелгән кебек булса да, Шаһинәнең сүзләрендә беркадәр мыскыллау, беркадәр рәнҗү сизелде. Сорау җавапсыз калды. Ханым миңа күренми, шулай да аның кул эше белән шөгыльләнүен чамалаган идем, дөрес икән.

— Нәрсә бәйлисең?

— Кышка җылы оек. Бездә кыш салкын була бит.

— Сине шундый эшләр белән шөгыльләнә дип һич күз алдына китерми идем.
— Ә ничек китерә идең?
— Сине бит мәктәптә «Белинский» дип йөртәләр иде. Ә хәзер син әкияттәге шикелле кесәл ярлы сөт елгалары хакында хыялланасың. Үзең генә хыялланып калмыйсың, бүтәннәрне дә ышандырырга тырышасың. Синеңчә, тормышның нигезен йомырка белән генә ныгытып була!
— Нигә, борынгы таш пулатларны салганда измәгә йомырка сыткаңнар ич!.. — Юлдашының ярсып китүен Шаһинә уен-көлке белән йомшартмакчы булды, ахрысы.
— Тирәннәнрәк каерырга кирәк, иптәш журналистка!— «Шагыйрь» ялгызы утырган сәкегә сыя алмыйча мең төрле рәвешкә керә: маңгаена төшкән чәчен әледән-әле артка ташлый, кулларын болгый, йодрыгы белән тезенә сугып ала.— Сиңа төсмени ул тирес белән мактану, савымчыларның телевизор каравына соклану?
Шаһинә сабыйны юаткандай итеп кенә сүз ката:
— Син дә бит газета битләрендәге ялкынлы сүзең белән генә гарәп илләрендә социализм төзи алмыйсың. Ләкин һәрберебез бер хакыйкатькә таянып эш итә: ук үтә алмаган җиргә сүз үтә.
Юлаучылар журналистлар икән. Мәскәүдә киңәшмәдә булганнар, күрәсең, кайтып баралар. Мәһабәт гәүдәлесе, аңлавымча, тышкы эшләр комментаторы. Әлеге киңәшмәгә катнашмаса да, Мәскәүдә чагы булып, каләмдәшләре, якташлары янына килүе мөмкин. «Шагыйрь»не чит илдәге кайбер күңелсезлекләр ярсыткан, шул ярсуын бүтән нәрсәгә юнәлтә кебек. Уклар күбрәк Шаһинә ягына оча.
— Баллы теллегә әйләнеп киттек. Онытмыйк, дәва микъдарында гына агу да файдалы.
Ханым укны тотып алып кире җибәрә:
— Минемчә, тәнкыйтьләргә остардык. Бер эшләүчегә йөз тәнкыйтьче туры киләчәк, әгәр андыйга киң юл ачсаң. Мактау сүзенә без болай да юмарт түгел, бигрәк тә үзебезне туендыручыларга карата.
— Ә син өстәгерәкләрне көйдер, иптәш журналистка, һич югы, үзеңнең галим агрономыңны!..
Ниндидер агрономга каныкты шагыйрь. Шаһинәне битәрләве дә шуның аркасында, әлбәттә. Ягымлы сөйләшсә дә, баллы телле булырга охшамаган ханым. Дөреслекне ярып әйтергә ярата шикелле. Менә тагын «шагыйрь»нең теленә төер булган әлеге агроном:
— Шулай да, ничек яшисең син ул җир корытучы белән? Күп еллык үләннән кукурузга, кукуруздан сенажга...
— Минем өчен аның беркемдә дә булмаган өстенлеге бар.
— ?..
— Ул минем баламның атасы!..
«Шагыйрь»нең башы түбән иелеп төште.
Тагын тынлык. Гудок тавышы, тәгәрмәчләр барысы бер омтылыш белән алга тәгәри. Купе ишеген бер-ике тапкыр ачып карадылар.
— Мине исеңә төшерәсеңме?..
Ике арадагы стена аркылы ишетелгәндәй булды шагыйрьнең бу өне. Беравык җавап ишетелмәде. Аннары, чишмә тавышыдай, җайга гына сүзләр агыла башлады.
— Исеңдәме, син минем портретны ясаган идең? Башымда синең ак кубанкаң. Авыз колакка җиткән.
«Шагыйрь»нең карашы берьюлы яктырып китте, чишмә агышы аны да ияртте.
— Әйе шул, синең толымнарыңны таратасым килгән иде, сурәтеңне шулай ясамакчы идем.
— Мин сүттермәдем... Бик еш алып карыйм мин ул рәсемне. Анда миннән бәхетле кеше юк.

Шаһинә, туктап калудан курыккандай, бер хатирәдән икенчесенә үчте:

— Нииндидер бер жыелышта гел сызгалап утырдын. Соңыннан янына ыелып, ясаган рәсемеңне карый башладык. Әле дә күз алдымда: диңз, кояш баеп бара. Дингез өстендә нурлар балкый. Кара да ак белән алган рәсемдә ничек күренде икән ул нурлар? Сул якта кыя өстендә ркет. Башын бер якка салган, моңаеп калган кебек. Уң якта пальма ачы. Музыкант Азалия синең янда бик бөтерелде ул кичне. «О, дингез— инем хыялым!» дигән була, фәлән-фәсмәтән, ди. Рәсемне син аңа бүләк гәргә тиеш, янәсе. Кайтканда артымнан куып житеп, кәгазь рулонны иңа суздың. Өйгә кайткач карасам, рәсемдә өстәмәләр бар: пальмада иләшкә охшаган тәлгәшләр... Астына мондый жыр язылган:

Сандугачлар иялэшкән
Су эчәргә миләштән.
Кайгыларым бетәр иде
Сине күреп сөйләшсәм.

Әле дә бар ул рәсем. Хатларыңны, шигырьләреңне ертып ташладым. миләшле пальма калды. Сиңа охшатам мин аны. Беләсеңме, язмышыңы алдан сизү дигән нәрсә бар. Кайдадыр дингез аръягында йөрисең әзер, ә жимешең, төшең үзебезнең якныкы бит. Бераз ачы. Дәва микъарындагы агу шул микән әллә?— Житди әйберне сак кына уен-көлке белән өртеп бирү сәләте бар икән Шаһинәнең.

Ханымның туктаусыз сөйләнүен «шагыйрь» сүзсез генә тыңлый.

— Рәсем белән, поэзия белән бик мавыга идең, ташлагансыңдыр инде?

— Минем мавыгулар күп булды,— ди «шагыйрь». Үзе житдиләнеп, юшынып китә. Үзен өлкән куеп, Шаһинәнең яңакларыннан сөеп ила, чәчләреннән сыйпый. Аннары купе эчендә арлы-бирле йөренә башлый. Һәр хәрәкәтеннән көч бөркелеп тора. Йөренә дә тагын үз урынына килеп утыра, вагоннан чыгып кая барсын?

— Мин сиңа шул Азалия белән хыянәт иттем бит...

Шаһинә ишетелер-ишетелмәс «аһ» итеп куйды. Менә нинди хәбәр әйтергә жыенган икән «шагыйрь»!

— Нииндидер сәбәп табып, өенә чакырды, сыйлады... Белдең микән бу хәлне, юк микән, ләкин син мине үтәдән-үтә күрәсең кебек иде, күзенә туры карый алмадым. Сиңа якын килергә үземне хаксыз санадым.

Озак тынлыктан соң стаканга сулкылдап шәраб акты.

— Кичә үлгән булсам, бүген белмәс идем...—ди Шаһинә телгә килеп. Тавышының калтыравын басарга тырышканлыгы сизелә.— Белмәвем яхшы булган, югыйсә, син нәфрәт утында янып бетә идең. Безнең аралар нидән өзелгәнлеген мин аңлый алмый аптырадым. Сизеңү генә бар иде миндә. Синдә рухи ярлылану димме...

Көмеш чишмә агымы югалды. Шаһинәнең тавышы карлыгып калгандай булды. Бераз тынлыктан соң ул өзелгән сүзне ялгарга уйлады:

— Ләкин без бит еллар үткәч тагын очраштык, бер генә тапкыр да түгел... Минем күңелдә синең урынны һичкем алмаган иде.

Юк, сүзне генә түгел, кайчандыр өзелгән житдирәк нәрсәне ялгарга азапланy иде бу.

— Син шундый шигъри күңелле нәфис кыз... Ә тормыш ыбыр-чыбырлы... Күп чытырман ерырга туры килде миңа. Алып керәсем килмәде сине ул чытырманга.

Әйе, зур омтылышлар белән яшәп, үз юлларын әле табып өлгермәгән кешеләр язмышларын хатын-кызга бәйләп куюдан тыелалар. Хыяллары тормышка ашмаса, яраткан кешенең өмете акланмавын күреп яшәү — үзе бер жәза.

Бераз тынлыктан соң ул, минем юрауны жөпләгәндәй, өстәп куйды:

— Сине илаһи килеш саклансын дигәнмендер...

— Аллалар янында гына фәрештәләр була ди бит. Шулай диген бер акыл иясе.— Шаһинә үзен кулга алган, тавышы ныгыган иде.

— Мин алла була алмадым шул...

Икесе дә шәрабтан авыз иттеләр.

— Аңламыйм, ничек сине чит илгә җибәрәләр? Эчкече диген даның чыккан.— Шаһинә бу сүзләрне, нинди җавап ишетермен дигәндәй, сагаеп әйтте.

— Кем әйтә?

— Авылдашлар сөйли. Сине иминлек пәйгамбәре итеп күрәселәре килә бит аларның. Сугышка каршы язылган мәкаләләреңне укыйлар.

— Мин бит читтә бер грамм да капмыйм. Айлар, еллар буе. Кайткач инде сагынудан, сөенечтән...

— Салмыш кайтып керсәң, әниең дә бик сөенер инде, алайса, сагынуы шул икән дип...

И бу хатын-кыз политиканы оста үткәрә дә инде. Бездә, укытучыларда, моны «тәрбия моменты» диләр. Сизеп торам: шагыйрь өчен бу «момент» нәтиҗәсез үтмәс, изге урынга гөнаһларын бушатырга килгән кешенеке сыман, гәүдәсе җыйнакланып, бөрешебрәк калды. Тынлык озакка китте, тагын да сузылса, купега сыймас иде шикелле. «Шагыйрь» аны кырт өзәргә карар итте:

— Шигырь сөйләргә ярата идең син, үзең дә язгалый идең. Сөйлә әле берәр нәрсә.

Аз гына паузадан соң Шаһинәнең күңел түреннән ябырылып килгән тавышы яңгырады:

Илчеләргә дә бит үлем килә,
Һәлакәткә очрый яучылар...
Синең өчен мин көрәшәм әле,
Диңгез-таулар аша яу чыгам.

Минсез узган юлларыңнан барып,
Елларыңнан йолкып аерам!
Безнең затка карап хәйран калсын
Синең галиҗәнаб даирәң.

Минсез үткән көннәреңне куып,
Төнчәреңә йозак салдыртам.
Ах, ник таңнар ата миннән узып?
Сине юлга дәшә һәр иртән?

Эчкән суың, очкан күкләреңнән,
Кочкан җилләреңнән көнләшәм!
Янәшәңдә йөрмәм шәүләң булып,
Сирәк килә торган бәйрәм булып,
Гел көттереп яшим, теләсәң...

Кем шигыре бу? Миңа билгесез шагыйрьнекеме, әллә сөйләүченен үзенекеме? Үз көченә нинди ышаныч! Шул ук вакытта шигъри юллар багышланган шәхесне олылау. Башкача булса, аның өчен көрәшергә дә кирәкмәс иде.

Әле генә яңгыраган шигъри юллар ирексездән минем күңелдә кабатлана. Бер көчәеп, бер тынып искән җилгә охшаш бу шигырь. Менә ул агач яфракларын өзеп алырга теләгәндәй давыллана, ярсына. Аннары үзе тузгыткан яфракларны тын гына иркәли, сыйпый.

Мин шигърият тәэсиренә бирелеп барган арада юлдашларымның берсе төнге лампаны сүндерде. Күптән яктырган икән. Поездның барышы әкренәйде, аста ыгы-зыгы, җыену башланды. Шагыйрь коридорга чыкты. Шаһинәнең юлдашы, урын-җирен җыеп, (кичә аңа Ләйлә дип дәшкәннәр иде) юынырга юнәлде. Шагыйрь тагын керде, сәкедәге юл сумкасына карап куйды.

— Китәсеңме?..— диде ул аянычлы да, өметле дә бер тавыш белән. Шаһинә катгый бер омтылыш белән юлдашының каршысына басты, ике кулын аның яңакларына тидерде, үрелеп маңгаеннан, керфекләреннән үпте. «Шагыйрь» һушы киткәндәй кулларын салындырып тик торды. Әгәр ул үзенең кадерле кешесен күкрәгенә кысса, бу гомергә шулай калыр иде, аерылышып китә алмаслар иде сыман. Ләкин алар икесе дә бу хәлиткеч минутка әзер түгелләр иде.

— Озата чыкма!..

«Шагыйрь» исен җыярга өлгергәнче Шаһинә тиз генә сумкасын алды да юк булды. Ишектә Ләйлә күренде, чөйдән плащын алды, саубуллашып, чемоданына үрелде. Кинәт шагыйрь аны күтәреп, ике яңагыннан үпте дә яңадан урынына бастырды. Шаһинәгә бармагы белән дә кагыла алмавын үзенчә төзәтүе булды инде бу.

— Хушыгыз, бәхетле булыгыз!

— Эч пошырып йөрдегез сез дә!..— диде Ләйлә чыгышлый, ачу һәм көнләшү катыш. Ул Шаһинәнең бөтен серләрен белә, күрәсең, дустының яшьлек мәхәббәте белән очрашуыннан канәгатьсез калган. Бәлки болай гына аерылуларын теләмәгәндер.

Шагыйрь төн эчендә сулыгып калгандай озын гәүдәсе белән тәрәзәгә капланды. Нигә озатырга кушмады Шаһинә? Купеда хушлашу тәэсире белән китәсе килгәндер. Бәлки халык арасында андый-мондый сүзгә урын калдырасы килмәгәндер.

Байтак карап торганнан соң, «шагыйребез» акрын гына әйтеп куйды:

— Шаһинә-м...

Әйе, соңгы аваз алдыннан аз гына тотлыгу булды. Тирән мәгънәле сыман тоелды миңа пауза аша әйтелгән аваз. Ниндидер карарга килдеме кеше, нәрсәнедер раслдымы?

Минем дә үз тукталышым якынлаша, торырга, җыенырга вакыт. Шагыйрь чыкты, купе буш калды.

Гудогын кычкырта-кычкырта, юл ярып поезд алга чаба. Тирә-якта алтын-сары кырлар. Арыш серкә очырыр чак җиткән. Күз алдымда һаман шул ике кеше. Үзем өчен генә мин аларның берсен шагыйрь, икенчесен Шаһинә дип атаган идем. Бу исемнәргә аларның гадәт-холыклары туры килә. Берсе килешмәүчәнлеге, кайнарлыгы, ара-тирә дуамаллыгы белән. Икенчесе сабырлыгы белән, шартлылыкларга буйсына белүе, кемнәрнедер үзенә буйсындыра алуы белән. «Бәхетсез мәхәббәт» дигән сүз бар. Юк, мәхәббәт бәхетсез булмыйдыр ул. Бу ике кеше янында үткәргән төндә минем күз алдымда гаҗәеп бер матурлык ачылды. Таң нурына ачылган чәчәк төсле...

Гыйлемдар Рамазанов

# ЛИРИК ДӘФТӘРДӘН

## Илле яшьтәгеләр

Кичә генә кебек —
Дим ярында
Уйнап йөри идек — яшьтәшләр.
Бүген инде юбилярлар булып
Түргә менә минем иптәшләр.

Авыры да авыр тоелмады
Бергә булгач бөтен ил белән.
Ярты гасыр яшәр ил артыннан
Аяк бастык без дә иллегә.

Сәер төсле артка табан карау,
Эзләү узган яшьлек эзләрен.
Республикам!
Барысы да сиңа
Безгә булган рәхмәт сүзләре.
Кирәк түгел мактау кәгазьләре,
Зур исемнәр, затлы билгеләр,
Тик яшәсен, тик яшәсен күкрәп
Безнең белән яшьтәш ил генә.

## Татьянага хат

Килсә февраль солдат көне белән,
Җиңүле Май итсә тантана,
Сиңа сәлам, котлау озатам мин
Яудаш дустым Таня, Татьяна.

Безнең частьта син ялгызың идең,
Барыбызны үзеңә караттың.
Сине Пушкин Татьянасы итеп,
Өлкән апа күреп яраттым.

Утлар эчендә син
Илдә калган
Сылуларны искә төшердең,
Кирәк чакта безгә керләр юдың,
Тәмле итеп ашлар пешердең.

Һәммәбез дә сөя идек сине,
Берәү генә иде сөйгәнең.
Ә син аны — чая капитанны —
Висла ярларында җирләдең.

Без — дусларың
Сине онытмадык,
Очраштык без берчак яудан соң.
Энең өч балага ата бүген,
Ә син, Таня, һаман яп-яшь көе,
Кәләш көе торып калгансың.

Ярсу еллар, азмы юллар узды
Минем баштан, минем уемнан,
Синең күнелең, Таня, үткәннәрдә,
Синең күңелең — Висла буенда.

Үземне мин бер гаепле сизәм
Синең ялгызлыгың өчен дә,
Чая капитанны мин үлемгә
Бирмәс идем, килсә көчемнән.

Син — чал чәчле — һаман кәләш көе.
Бөтен гомерең — зур бер югалту.
Без гел синең белән.
Ләкин, Таня,
Мөмкин түгел сине юату.

## Туган җирдән читтә

Сагынма да, имеш,
Еракларга кит тә,
Уем туган җирдә,
Үзем аннан читтә.

Калка язгы гөлләр,
Кояш көлә күктә,
Тик мин генә моңсу
Туган җирдән читтә.

Сагынам салкынын да,
Карын, буранын да,
Күз алдымда гына
Иделем, Уралым да.

Күкшел тау башында
Куып ярсу атын,
Кайт дип чакыра төсле
Мине Салаватым.

Күрәм: кыеклардан
Көмеш тамчы тама,
Мәктәбеннән кызым
Әнә кайтып бара.

...Сагынма да, имеш,
Еракларга кит тә,
Мин гел туган җирдә
Туган җирдән читтә.

●

Март башы — яз башы.
Салкынча иртәләр.
Тик кояш калкына —
Ул җирне иркәләр.

Гүя саф терекөмеш —
Яп-якты яланнар.
Нәрсәдер сизенә
Шомыртлар, баланнар.

Кояшка тартыла
Каеннар, усаклар.
Кайдадыр чакыра
Бу юллар, сукмаклар.

Яз килә җиремә
Ашыкмый, тын гына.
Тулыша күңелгә
Моң гына, моң гына.

Бар язның ниндидер
Сихере, тылсымы.
Өлгерә йөрәктә
Яңа җыр шытымы.

## Астраханьга барсаң...

*Габдрахман Минскийга*

Ничәнче яз
Идел, Агыйделдән
Астраханьга акты ак бозлар,
Күптән, күптән дәү әнидер инде
Синең белән үскән яшь кызлар.

Ә син минем өчен
Әүвәлгечә
Балык тотып үскән егетсең,
Бер карасаң — сабыр аксакал син,
Бер карасаң — ташкын кебексең.

Юлым төшеп, барып күргәнем юк
Астраханьны — туган җиреңне,
Ул да синең төсле мәһабәттер,
Күңелең кебек иркендер инде.

Яшибез без ыгы-зыгы белән
Ике-өч елга бер кат күрешеп,
Ләкин мин Уфада килеш тоям
Казандагы йөрәк тибешең.

●

Нигә назлы карашларың
Күңелемнән китми икән?
Үтте язлар, җәйләр, көзләр...
Мәхәббәт үтми икән.

Нигә сине сагынуым
Канмый да бетми икән?
Ярты гомер үтеп киткән —
Мәхәббәт үтми икән.

Нигә бу вакыт дигәнең
Аз гына кәтми икән?
Еллар җилдәй үтеп тора,—
Мәхәббәт үтми икән.
Үтми икән.

●

Әле шау-шусыз туебыз
Кичә генә узган кебек,
Гүя син шул оялчан кыз,
Ә мин — басынкы бер егет.

Олыгаябыз. Тик картая
Дип өркетмә күңелне син,
Еллар уза. Акыл гына
Арта килә түгелме соң?

Артыбыздан яңа токым
Басып килә үкчәбезгә,
Әллә инде яшьлекләре
Сиздермичә күчә безгә.

●

Ярсы, диңгез, ярсы, әйдә,
Ярсуың гаҗәп түгел,
Миңа да бит бу дөньяда
Тын яшәү хаҗәт түгел.

Син бит, диңгез, җил иркендә,
Давылга юлдаш кына,
Минем ярсуларым тынар
Йөрәгем тынгач кына.

## Муса Гали

### Үземә кайтып барам

Гөлләр кала башын кагып,
Җилләр килә чәчем тарап,
Кайдан киләсең, туган, дип,
Аптырыйлар миңа карап.
Аптырыйлар, ахры, күреп
Төс-башымны, күзләремне,
Артта күпме юрау, сынау
Күмеп кала эзләремне.
Сынасыннар, юрасыннар...
Башкачарак басып барам.
Мин бүтәнмен, бүтән...
Чөнки
Мин үземә кайтып барам.
Татлы сүздән, буш мактаудан,
Буш дуслыктан качып барам.
Бар ялганга нәфрәт атып,
Мин үземә кайтып барам.
Җиңел басып, күкрәгемне
Язгы җилгә ачып барам.
Иртә төшкән ак кыраудан,
Җаным өшеп калтыраудан
качып барам.
Мин үземә кайтып барам.
Колагымда моңнар чыңлый,
Пакь дөньяга карап тынам.
Чишмәләрдә камыш җыры,
Елгаларда алсу томан.
Таң тамчысын эчә гөлләр,
Гөлләргә баш кагып барам.
Сагынып тәү сафлыгымны,
Алып кайгы, шатлыгымны,
кайтып барам...
Мин үземә кайтып барам.

### Серләр

Җиңел түгел сәер бу дөньяда
Еллар кичеп, серләр сүтүе.
Атлаганда, кара песи булып,
Юлың кисеп, вакыт үтүе.

Соңлап ачтым гади серләрне дә,
Үкендерер, ахры, шунысы.
Йолдызның да икән нуры сүнә,
Кояшның да кими җылысы.
Ак дигәнең кара булып чыга,
Һәм ак була кара дигәнең;
Бары алдау булган елмаюга
Азмы булды башым игәнем.
Булды көне,
гадилектән генә
Абындым дип, ташны каргадым.
Соңлап тойдым йомшак шәфкать-кулның
Минем гамьсез башны ярганын.
Соңлабрак килдегез сез миңа,
Әй, гомернең саран серләре.
Мин үзем дә, бәлки, ачылмаган
Бер сермендер һаман кемгәдер...
Тик үкенмәм, юрап, я ырымлап,
Мине-серне кемдер ачмаса.
Бөлмәм әле әмма юлларымда
Җирем бәхетен тоеп атласам.
Кирәк икән әгәр халкым өчен —
Йөрәгемне куям учыма...
Искәртә алам моны дошманыма,
Әйтә алам моны дусыма.

●

Барысы да үтә чиратлап,
Үтә томан, үтә кара төн;
Тау битенә яткан алсулык
Сөйли көннең үтәр сәгатен.

Ә авырга калган тын басу
Изрәп ятып башак тудыра.
Бактың исә, иртә көз тыны
Пәрәвезләр явын кудыра.

Сары яфрак төшә өзелеп,
Үтә яшен, тына күкрәүләр.
Сагышлы җыр элеп гөмбәзгә,
Ак торналар китә тезелеп.

Мәңгелекнең юлы аяусыз,
Качып калып булмый бер якта.
Килер ул көн, түгел еракта,
Басып торам мин дә чиратта.

Сүнгән шәфәкъ, төшкән яфрактай,
Китәчәкмен мин дә шул юлдан.
Хыялларым гына җиремә
Явып калсын ап-ак шомырттай.

Аяу көтмәм сездән тилмереп,
Әй, калачак алтын таңнарым,
Йөремәдем арткы ишектән
Җирдә дә мин әлеш ялварып.

●

Мин аптырап калдым бу дөньяга,
Миңа карап болыт чайкалды.
Көлә-көлә кояш тауга кунды.
Алтын эңгер япты акланны.
Мине күреп, чишмә кайнап чыкты,
Җыр көйләде камыш-күрәннәр.
Бит-күземә ак серкәләр бәреп,
Арыш дулап китте тирәмдә.
Ни хикмәт бу?.. Күзләремә карап,
Күл тирбәлде, шашып, дулкынлап,
Ут кабынды болыт читләренә,
Кошлар хәбәрләште чутылдап.
Кичке ялан буйлап йөгерә-йөгерә,
Ак каеннар килде каршыма;
Минме шулай шашам бу җиһанда,
Әллә җиһан микән ярсыган.
Кабынды да миңа җавап биреп,
Тәүге йолдыз бакты тын гына...
Җир-су тыныч, Җиһан бер көенчә.
Син гашыйксың, туган,
шул гына.

●

...Кичке урам, алчак яшьлек...
Тагы сезгә кайттым нигә?
Чәч үргечен тешләп, бер кыз
Тәрәз аша бакты миңа...
Ул көннән соң күпме сулар
Ярларыннан ташып акты.
Тапканнар күпме югалтты,
Югалтканнар күпме тапты.
Мәхәббәттә бу йөрәгем
Күпме килде тәүбәсенә.
Һәм, онытылып, тагын очты
Зәңгәр таулар түбәсенә.
Күпме җан тарткан эзләргә
Хыялларым сибелделәр.
Күпме кызлар, бер күз салып,
Горурлыгым җимерделәр.
Барысы да бүген ерак...
Тик әйт, гомер, нигә, нигә,
Чәч үргечен тешләп, һаман
Әлеге кыз карый миңа?

## Абдулхак Игебаев

### Сөенечем дә, көенечем дә

Юк, бикләнеп яшәмәм мин
Буш күңелләр утравында!
Сөенечем дә, көенечем дә
Булыр туган туфрагымда!

Ак уйларым, ак җил булып
Кагылып үтәр үләннәргә,
Сагышларым, томан булып,
Барып төшәр үзәннәргә.

Күз яшьләрем мөлдерәшер
Яфракларда саф чык булып,
Моңлы сазым очып йөрер
Илаһи бер кошчык булып!

Әрнүләрем, әченүләрем
Әрем булып шытып чыгар,
Явызлыкка каршы ярсып,
Йөрәгем гел набат сугар!

Изге эшем сулу белмәс
Гөлләр булып чәчәк атыр,
Өметләрем, теләкләрем
Кош юллары булып балкыр!

Юк, бикләнеп яшәмәм мин
Буш күңелләр утравында!
Сөенечем дә, көенечем дә
Булыр туган туфрагымда!

### Җырың гизә илләр арасын

Башкортстанның халык
шагыйре Мостай Кәримгә

Шигырьләрең нурдан тукылганмы,
Коелганмы әллә көмештән?
Алдыңмы син әллә җырларыңны
Чылтыр-чылтыр аккан инештән?

Зәңгәр Димнең былбыллары әллә
Шат җырларын бүләк иттеме?
Халкым моңы, чишмә булып, әллә
Синең йөрәк аша үттеме?

Адашканга туры юлдаш булып,
Яралының бәйләп ярасын,
Синең шигырьләрең, тынгы белми,
Гизеп йөри илләр арасын...

Галәм телендә дә сөйләшә ул,
Адәм телендә дә сөйләшә,
Авыр чакта, йөгем күтәрешеп,
Атлап бара бит ул янәшә!

Синең шигырең мең-мең дус өенә
Килеп керә ырыс[1]-кот булып,
Явыз дошманнарның йөрәгенә
Кадала ул үткер ук булып!

Адашканга туры юлдаш булып,
Яралының бәйләп ярасын,
Шигырьләрең, Мостай, һәр чак шулай
Гизеп үтсен илләр арасын!

## Каһарманнан якты эз кала

Җимешләрдән татлы сут кала,
Мәхәббәттән сүнмәс ут кала,
Һөнәрмәннән ырыс-кот кала,
Авыр заманадан йот кала,
Рәнҗетсәләр әгәр нахакка,
Күңел көзгесендә тут кала!

Сылулардан сылу йөз кала,
Зирәкләрдән зирәк күз кала,
Аксакалдан алтын сүз кала,
Каһарманнан якты эз кала,
Хәйләкәрнең зәһәр теленнән
Йөрәкләрдә яман биз кала!

Назлы яздан назлы гөл кала,
Чәчәннәрдән чәчән тел кала,
Изге яуда ауган солдатның
Саф намусы булып ил кала,
Туган җирен саткан бәндәнең
Кабериндә бары көл кала!

---

[1] Ырыс — бәхет (башкортча).

## Көзләр моңсулыгымы бу?

Җилләр бакыр тарак белән
Каеннарның чәчен тарый,
Сары чәчле каеннарга
Сары сагыш бөркегән күк,
Кояш та бик моңсу карый!

Каңгылдашып китә кошлар,
Ефәк каурыйларын кагып,
Аерылуы, ай-һай, авыр...
Дигән төсле оча алар
Уралыма кат-кат багып!

Моңаешып тора таулар,
Ямансулап ага Идел...
Көзләр моңсулыгымы бу?
Әллә дөнья хәсрәтеннән
Боегамы минем күңел?

Боега күңел, сыгыла күңел
Заманалар сагышыннан.
О! Дөньяда минем өчен
Кадерлерәк берни дә юк
Җир һәм кеше язмышыннан!

Ә кайгылар көтмәгәндә
Бәхет гөлен йолкып тора,
Канлы яулар газраиле
Сабыйларның баш очында
Айбалтасын тотып тора!

Көзләр моңсулыгы түгел,
Җир сагышы — моңнарымда!
Әй, кешелек, сизгер, нык бул,
Бар дөньяның язмышы бит
Синең көчле кулларыңда!

## Шатлык кирәк

Яшел бәрхетле болынга
Аллы-гөлле гөлләр кирәк,
Болын гөлләрен назларга
Талгын искән җилләр кирәк.

Күлләрдә парлап йөзәргә
Аккошларга канат кирәк.
Күңел кылын тирбәтергә
Җырчыларга талант кирәк.

Сәфәр чыккан юлчыларга
Иш булырлык юлдаш кирәк.
Бар тереклек дөньясына
Мәңге янар кояш кирәк.

Бәхетле гомер сөрергә
Гашыйкларга сафлык кирәк,
Гөрләтеп дөнья көтәргә
Кешеләргә шатлык кирәк.

Шатлык кирәк... бик-бик кирәк...

Әмма шатлык җитми әле.
Кояш һәр көн кыздырса да,
Кайгы яше кипми әле...

Җир тәнендә, җир җанында
Яу ярасы бетми әле...

**Феодосий Видрашку**

# ВАХТА

КамАЗ КӨНДӘЛЕГЕ

## Кереш урынына



Әгәр сезнең үзегез турында язсак, ә?

Аның күзләрендә шаян очкыннар кабынды.

— Минем турыда?.. Мин бит партия хезмәткәре. Әбезнең турыда гадәттә шулай язалар: «Ул зур речь белән чыкты» яки кыска гына итеп: «Чыгыш ясады», диләр... Шулай бит. Ә әдәби әсәрләрдә инде аның образы болайрак: гадәттә аңардан хатыны китә. Чөнки ул хатыннан үзе китә алмый. Яки райбашкарма председателе белән конфликтка керә... Күптән түгел генә минем янда бер әдип-кинематографист булды һәм төзелеш җитәкчеләре белән минем арадагы «кискен» конфликтлар турында сорашты... Конфликт булмавын белгәч, монда миңа эш юк, дип, «конфликт» эзләргә китеп барды...

Әйтик, районда беренче секретарь нәкъ үз урынында, икенче секретарь да акыллы егет, райбашкарма председателе белән дә алар дус яшиләр, ди... Шулай ук гаиләләрендә дә җил-давыл купмый, гадәти кешеләр кебек үз борчулары, үз мәшәкатьләре белән бергәләшеп балалар үстерәләр, ди... Мондыйларга әдәбиятта, театрда, кинода, телевидениедә урын булмаска тиеш түгелдер, мөгаен... Мин сезгә, иң яхшысы, гади коммунистлар, төзүчеләр турында сөйлим... КамАЗның төп әйдәүче көчен беләсезме? Ул әйдәүче көч — яшьләр. Аларның биредә уртача яше — егерме өч!

— Ә сезгә ничә яшь?

— Утыз алты,— секретарь көлеп куйды,— мин инде алар өчен Беляев абзый... Биздә унөч мең коммунист. Комсомолецлар да шул чаклы. Әлбәттә, барысы турында да сөйләп бетерү мөмкин түгел. Әмма кайберләре турында сөйләргә була.

Һәм Рәис Беляев — партиянең Чаллы шәһәр комитетының беренче секретаре — төзелештәге партия оешмасы турында сөйләп бирде...

### ТӨЗЕЛЕШ КӨНДӘЛЕГЕ

*Июнь аенда Кама автомобиль заводы һәм шәһәр төзелешендә беренче ярты еллыкта иң зур темпка ирешелде. Капиталь салымнар үзләштерү заданиесе — 120, төзү-монтаж эшләре планы — 136,4, промышленность объектлары төзелешендә төзү-монтаж эшләре планы — 152,6, торак, социаль һәм культура-көнкүреш объектларын салу планы 108,6 процентка үтәлде.*

Кечерәк кенә бер бина. Флагшток. Анда байрак җилферди. Биредә — партия һәр комитеты, команда пункты, штаб.

Икенче катта, җыелышлар залында — йөз иллеләп кеше. Төзелеш командирлары, этком секретарьлары. Бер-берсен сәламлиләр, сөйләшәләр.

Иртәнге сигез. Рәис Беляев керә. Җиңнәрен сызганган. Күлмәгенең өске төймәч ычкындырган, галстук төенен бушаткан.

— Хәерле иртә...

Беренче секретарь кулындагы папкасын өстәлгә җәеп сала, аннары залга күз шерә: барысы да урынындамы?

— Төзелештәге хәлләр билгеле,— дип, ул акрын гына тавыш белән сүз башй.— Газеталарда басылып чыкты. Барыгыз да укыгансыздыр... Яхшы. Агымдагы ләргә күчик... Полковник Хаустов. Шәһәрдә атна эчендәге оператив хәл. Өч нут.

Милиция начальнигы вак хулиганлык фактларының кимүе турында сөйли. Ә зуркларының элек тә булганы юк.

— Исерткеч эчемлекләр сатуны чикләүнең файдасы тиямә?

— Тия. Урамда исереп йөрүчеләр күренми. Әмма гадәттән тыш вакыйга бар. шина белән Алабугага аракы алырга барганнар. Эчкәннәр дә авария ясаганнар.

— Кайсы оешмадан?

Полковник Хаустов оешманы әйтә.

— Оешма җитәкчесе бассын.

Урта яшьләрдәге берәү торып баса, дәшми.

— Йөзең кояшта янган. Кызарасыңмы, юкмы — күренми. Минемчә, уңайсызланың кебек. Утыр. Бу мәсьәләне коллективта тикшерегез. Озакка сузмыйча. Килешкме?

Милиция начальнигына тагын бер сорау:

— Ә СКД ничек?

Мин инде КамАЗдагы кыскартылган сүзләргә күнектем. Мәсәлән, УАТ дигән сүз ә, УМС (Управление автомобильного транспорта, управление механизации строильства) һәм башка бик күп сүзләр.

Менә хәзер СКД. Ул сугышчан комсомол дружинасы дигән сүз икән. Ул Оларга — оператив комсомол отрядларына бүленә. Төзелештә җәмәгатьчелек этибен саклау эшен нигездә комсомоллар үзләре башкара. Алты оператив коммол отряды 260 егет һәм кызны берләштерә. Алар милициягә зур ярдәм күрсәтәә. Шунысы кызыклы: хәзер Чаллы шәһәре халкы 100 меңгә җиткән, ә милиционерр саны элеккечә үк калган. Әгәр андый-мондый хәл булса, милициягә түгел, СКД абына шалтыраталар икән...

Шәһәр комитеты секретаре соравына полковник болай дип җавап бирде.

— Комсомол дружинасы әйбәт эшли, Рәис Кыямович. Ярдәмнәре зур.

— Милиция начальнигына тагын сораулар бармы?

— Сораулар юк. Тәкъдим бар. Тәртип бозучылар турындагы белешмәне барк объектларга таратырга кирәк, җәмәгатьчелек аларны белеп торсын.

— Искә алыгыз, иптәш полковник. Хәзер сәүдә мәсьәләсе. Урыннан гына сөйргә мөмкин.

Залдан тавыш:

— Сәүдә хезмәткәрләре әйтсен: нигә яшелчәләр аз? Эшчеләр чират торып нидәр вакытларын әрәм итә...

Беляев кискен рәвештә таләп итә:

— Аңлатып бирегез!

Яшьрәк кенә берәү торып баса, ык-мык килеп нәрсәдер әйтә:

— Иптәшкәй, ике совхоз горкомга шалтыратты. Кыярлар саргая, диләр. Салат, ган картая, диләр. Ә бездә чират. Без бит сезгә сәүдә эшен җайга салу эшен пшырдык.

— Мин бит әле бер генә атна эшлим...

— Шуңа күрә дә әлегә җитди чара күрмибез сезгә карата. Горкомның авыл хуҗалыгы бүлеге белән элемтәгә керегез. Ә иртәгә иртән эшнең ничек торганын хәбәр итәрсез. Берсекөнгә дә. Ә дүшәмбе көнне оперативканы сездән башлыйбыз.

Чираттагы мәсьәлә: кешеләр килү. Төзелеш начальнигының көнкүреш эшләре буенча урынбасары эшкә урнаштыру, тулай торак белән тәэмин итүнең нормаль торышы турында әйтә.

— Ничек нормаль булсын,— дип сикереп тора милиция начальнигы.— Пропискасыз эшкә аласыз...

— Иптәшләр, партком секретарьлары,— дип дәвам итә сүзен Беляев.— Бу эшне дә үз контролегезгә алыгыз. Хәзер җәй көне. Эленке-салынкы йөрүчеләр күп. Аннан-моннан бер-ике атна эшли дә җайлырак эш эзләп китә. Безгә шәһәрне андыйлар белән чүпләргә ярамый.

Аерым объектларда эшләрнең торышы турында информацияләр, алдагы атнада эшләнәсе эшләр...

Шәһәр комитетында мондый оперативкалар атна саен һәр дүшәмбедә була, һәм аңа килгәндә беркем дә чакырганны көтеп тормый. Ә шәһәр комитеты секретаре оперативка башланганчы, иртәнге сигезгә кадәр, инде төзелешне урап кайткан, шәһәр урамнарын күзәткән, кешеләр белән сөйләшергә өлгергән була...

Оперативкадан соң күп тә үтми, мин аны Чаллыда беренче җир асты юлы төзелешендә күрдем. Муса Җәлил бульварын Гидростроительләр урамы кисеп үткән урында төзелә ул. Муса Җәлил бульвары — шәһәрнең төп транспорт магистрале. Биредән тәүлеккә егерме сигез мең машина үтә. Шул ук бульвар буенча трамвай юллары сузыла. Чаллы өчен трамвайлар Чехословакиядә ясала.

Әйе, мондагы зур транспорт төенен шәһәр төзелеше барышында ук хәл итәргә, тагын соңыннан кабат казырга туры килмәсен өчен барысын да алдан күреп эшләргә кирәк. Менә шуңа күрә дә шәһәр комитетының беренче секретаре биредә еш була.

Муса Җәлил проспекты... Аның озынлыгы өч километр ярым. Киң проспектның һәр ике ягында бишәр-ундүртәр катлы торак йортлар, башкаладагы колач белән салынган кибетләр, культура-көнкүреш бинаалары.

Күп катлы кирпеч йортлар — хәзерге заманның барлык таләпләренә җавап бирерлек тулай тораклар. Түбәсенә электр утлары белән йөк машинасы сурәте ясалган бинага КамАЗның генераль дирекциясе урнашкан. Бульварның уң ягында — яшь нарат урманы. Бу урманны Чаллы янында төзеләчәк гидростанциягә нигез салганда мәктәп балалары һәм комсомоллар утырткан. Ә урман эчендә шифаханәләр комплексы һәм бала табу йорты. Мондый йортлар тагын кирәк булачак әле. Ник дисәгез, узган ел бер мең бала туган булса, 1972 елның яртысы эчендә биредә биш мең кеше дөньяга килгән! Димәк, елга ун мең диган сүз...

Проспект бик матур булачак. Уң ягы биегрәк. Ә сул ягы Мәләкәс елгасы ярынарак төшеп тора. Шуңа күрә магистральләр — ике тигезлектә. Уртага агачлар утыртыла. Юкә агачлары, кенәфер куаклары. Алар чәчәк атканда тирә-якка хуш ислә бөркелеп торачак. Беренче секретарь бульварны шундый итеп күз алдына китерә...

— Карагыз әле,— ди Рәис,— һания Газизова артистлар алып кайткан. Барыйк әле, кемнәр икән?

һания Газизова — шәһәр комитеты инструкторы. Ул культура эшләре белән шөгыльләнә. 1971 елда «Новый мир» журналының беренче бригадасын да иң башлап ул каршылаган иде. Ә хәзер Чаллыда Советлар Союзының илле еллыгына багышланган кинофестиваль бара. Артистлар шул уңай белән килгән.

Автобустан Иван Переверзев, Владимир Белокуров, Николай Гриценко, Людмила Хитяева, Римма Макарова, Любовь Румянцева, Земфира Цехилова төшә.

— Бернича минутка гына минем янга керүегезне үтенәм.

Рәис Беляев кабинетына Чаллы шәһәренең зур масштаблы картасы эленгән. Куе яшел фон эчендәге ак кубиклар булачак урамнарны, кварталларны күрсәтә. Кама, Мәләкәс елгалары, гидроэлектростанциянең сусаклагыч бассейны зәңгәр төскә буялган. Каршы як стенада — заводлар схемасы. Ике километр киңлектәге яшел полоса шәһәрне промышленность зонасыннан аерып тора.

— Сезнең барыгызны да кинофильмнардан беләбез, яратабыз,— ди Беляев.— Ә очрашулар бик сирәк. Килүегез өчен рәхмәт, эшегездә уңыш телим...

Һания Газизова Мәскәү артистларының кинотеатрларда, тулай торакларда төзүчеләр белән күп мәртәбә очрашуларын сөйләде. Көннәр бик эссе иде. Әмма артистлар һәр көнне берничәшәр урында очрашуларга катнашканнар, берсе дә ардым дип зарланмаган.

Мәскәү белән турыдан-туры бәйләнеш өчен төзелгән Бегиш аэродромында (АН-24 самолеты Мәскәүгә 2 сәгать 15 минут оча) самолет көткәндә, Николай Гриценко сокланып болай сөйләде:

— КамАЗда без күргәннәр берни белән дә чагыштырырлык түгел. Монда чын геройлар эшли. Без, сугышны кичкән кешеләр, биредә эшләүче яшьләр арасында Покрышкиннарны, Кожедубларны, Жуковларны күрәбез. Әйе, Жуковларны, безнең көннәрнең тыныч хезмәт армиясе командующийларын... Бу төзүчеләрнең характерларын тулырак итеп сәнгать образларында гәүдәләндерәсе иде...

## ХАТ

*Хөрмәтле Беляев иптәш!*

*Шәхси эш белән мөрәҗәгать итеп, сезнең вакытыгызны алуым өчен гафу итегез. Мин яхшы аңлыйм: Сезнең КамАЗда гына да 35 мең «шәхси» эш бар, өстәвенә, тагын көн саен никадәр кеше килә, ничәмә-ничә кеше хат яза...*

*Әгәр минем төзүчелек һөнәрем булса, хат язып Сезне борчымас идем, туп-туры юлга чыгар идем, чөнки беләм: Сезнең төзелештә төзүчеләр бик кирәк. Әмма эш шунда: мин педагог. Университетны тәмамлаганнан бирле Ереван шәһәрендә рус теле һәм әдәбияты укытам.*

*Сезгә төзүчеләр комсомол путевкасы белән килә бит. Ә мин инде күптән комсомол яшеннән чыктым, егерме еллык эш стажым бар. Эшем өчен комсомолның Әрмәнстан Үзәк Комитеты, партиянең район комитеты, Әрмәнстан ССР Верховный Советы Президиумы Почет грамоталары белән бүләкләндем.*

*Соңгы дүрт елда мәктәптә завуч булып эшлим.*

*Менә инде ике ел КамАЗ белән хыялланам. Сезнең бөек төзелештәге вакыйгалар турында газета-журналлардан укыйм, телевизион тапшыруларны карыйм. КамАЗда җиңел түгеллеген беләм, авырлыклардан курыкмыйм.*

*Мин бәлки туп-туры юлга да чыккан булыр идем. Ләкин сез бер сварщикның берничә көн эш эзләвен сөйләдегез. Аны СУ-1 дән дә, «Автозаводстрой»дан да кире җибәрәләр. Ә ул бит сварщик!.. Ә укытучылар Чаллыга кирәкме? Минем укытасым бик килә,— көндезгедәме, кичкедәме, башлангычтамы — барыбер.*

*Хөрмәтле Рәис Кыямович!*

*Мин беләм, Сезнең меңнәрчә зур һәм «вак» эшләрегез бар, укытучы хатын укып утырырга вакытыгыз да юктыр. Шулай да үтенеп сорыйм: КамАЗга килергә мөмкинме миңа — шул турыда хәбәр итсәгез иде. Минем өчен иң мөһиме — эш! Әгәр хәзергә мәктәптә эш юк икән, мин җиен төзелештә эшләргә дә риза. Яңа мәктәп бинналары салынадыр бит, аларда эшләргә укытучылар кирәк булыр (хәтта быелгы сентябрьдән үк). Мине чиратка куйсагыз иде.*

*Түземсезлек белән җавап көтәм: Чаллыга килергә мөмкинме миңа?*

## ҖАВАП

*Сезнең хатыгыз каралды. Шәһәр халык мәгарифе бүлеге эшкә урнашу мөмкинлеге булачагын хәбәр итә.*

*1972 елның 1 июленә килеп җитүегезне сорыйбыз.*

**Чаллы шәһәр мәгариф бүлеге.**

— Мондый хатлар күп киләме?

— Әлбәттә, күп, хәтта бик күп...

Партиянең шәһәр комитеты оештыру бүлеге инструкторы Мөнәвәрә Хөснетдинова килгән хатлар белән эш итә. Комсомол яшеннән дә чыкмаган әле үзе. Шулай да КПСС члены. Кешеләр белән эшләргә мәктәптә үк өйрәнгән. Аннан — комсомол, завод...

Мөнәвәрәнең күзләре ягымлы. Тавышы — самими, йөрәккә ятышлы.

— Безгә меңнәрчә хат килә. Төзелеш кешеләрне магнит кебек үзенә тарта. Алар, беренче чиратта, безгә, партия органына, мөрәҗәгать итәләр. Кеше партиягә мөрәҗәгать итә икән, аңа, димәк, зур игътибар белән җавап бирергә кирәк. Безнең эштә иң начары — сүз бирү белән чикләнү. Һәрберсенә хәлне аңлатырга, дөресен әйтергә кирәк...

Көнлек почтаны иң элек беренче секретарь карап чыга.

— Миңа хатлар күп нәрсәне күз алдына китереп бастырырга ярдәм итә,— ди ул.— Әгәр теге-яки бу оешмадан хатлар күбәя икән, димәк, анда эшләр шәптән түгел. Бик тиз чара күрергә кирәк. Бездә аноним хат язучылар юк диярлек.

Күбәүләр шәһәр комитетына бернинди язусыз, болай сөйләшү, киңәш-табыш өчен киләләр. Алар да иң элек Хөснетдинова янына керәләр. Теге яки бу оешманың җитәкчесе, месткомы, парткомы хәл итә алмаслык мәсьәлә булганда гына ул Беляев янына барырга киңәш бирә.

## Кабул итү

Сишәмбе. Бүген Татарстан АССР Верховный Советы депутаты Рәис Беляевнең гражданнарны кабул итү көне. Мин дә аның эш бүлмәсендә утырам.

Шунда ук — шәһәр комитеты хезмәткәрләре: партия комиссиясе председателе, промышленность-транспорт бүлеге мөдире, төзелеш һәм шәһәр хуҗалыгы мөдире урынбасары һәм Мөнәвәрә Хөснетдинова.

Бала күтәргән яшь кенә бер ханым керә. Әйбәт киенгән, чәч толымнарын биек итеп баш түбәсенә өеп куйган, аякларында модалы туфли. Баласы белән тулай торакта яши икән. Әмма баланы карарга кеше юк. Әнисе килергә риза, бүлмәдәш кызлар да моңа каршы түгел, һәрберсе аңа урын бушатып, башка бүлмәгә күчәргә әзер. Әмма...

— Василевский белән сөйләштегезме? — дип сорый Беляев.

— Ул бик кырыс кеше...

— Ә сез? — дип, горком секретаре сораулы карашын Мөнәвәрәгә төби.

— Мин аның урынбасары белән сөйләштем. Ярдәм итә алмый.

Беляев телефон трубкасына үрелә.

— Иптәш Василевский!.. Күптән күрешкәнебез юк... Эшләр әйбәтме? Тыңла әле: минем янда ике хатын-кыз утыра. Берсенә егерме яшь, икенчесенә... өч ай... Тулай торакта өченче хатын-кыз өчен — беренче хатын-кызның анасы, икенчесенең әбисе өчен урын кирәк... Кыен икәнен аңлыйм... Миңа шундый хәл килеп чыккан... Бәлки вагоннардан карарсың...— Секретарь трубканы читкәрәк алып, анадан сорый,— Василевский ярты вагон бирә. Канәгатьме? Әйбәт, алайса. Әниегезне алып килегез дә хәзергә шунда яшәгез.

Димәк, төзелештә тагын бер кеше артачак. Чөнки яшь ана компрессор машинисты икән...

Ишек ачыла. Зифа буйлы, чибәр ханым.

— Утырыгыз.

— Рәхмәт.

— Ни йомыш?

Ханым уңайсызлана — таныш түгел кешеләр, гадәти булмаган урын.

— Ни йомыш?

— Торак мәсьәләсе...

— Эшлисезме?

— Сварщик. Әлегә эшләмим. Яшь бала белән.

— Бер баламы?

— Кечкенәсе бер, ә гомумән өчәү... Кечкенә вагонда торабыз. Бик тыгыз... Мәктәп бик ерак... Икесе мәктәпкә йөри.

— Ә ирегез?

— Ул «Сантехмонтаж»да эшли. Үзе беркая да йөрми, ояла...

Чиратыгыз еракмы?

— Илле тугызынчы... Чиратка язганда кечкенәсе юк иде шул әле...— Ханым кинәт җанланып китә, елмаеп һәм шул ук вакытта горурланып сүзен дәвам итә:

— Кайберәүләр әрли, нигә сезгә кечкенә? — диләр. Бәлки мин әле тагын табармын. Аларның ни эше бар?..

Рәис Беляев беравык уйга кала. Аның үз әнисе унбер бала табып үстергән. Унбер! Барысы да исән, таза. Күбесе югары белемле.

— Әйе шул, аларның ни эше бар,— һәм бүлмәдәгеләргә борыла.— Бала үстерү дә партия эше... Ә сезгә шуны әйтәм: ярдәм итәргә тырышырмын. Чиратта торучылар белән сөйләшергә кирәк, аңларлар...

Илле яшьләр тирәсендәге, чал чәчле ир кеше керә. Идарә начальнигы урынбасары булган. Начальник белән никтер «борчагы пешмәгән». Начальник аннан котылу өчен ансат юл тапкан — штат кыскарту.

— Ә башка эш тәкъдим итмәдеме?

— Юк.

— Ничек инде ул алай?

— Үзең әзлә, ди.

— Закон бар бит: штаттан кыскартылган кеше эшкә урнаштырылырга тиеш. Бу житәкченең бурычы.— Шәһәр комитеты секретаре кызып китмәскә тырыша. Әмма бу очракта кызып китсә дә табигый иде кебек.— Хәзер сезнең начальникка шалтыратмыйм. Иптәшләр аны чакырырлар, аңлатырлар. Бу эш оештыру бүлегенә тапшырыла...

Коммунистлар партиясенең уннарча ел дәвамында камилләштерелгән үзара мөгамәлә, дисциплина турында язылган һәм язылмаган нормалары бар. Әмма партия хезмәткәрләренә еш кына партия уставында да, партия карарларында һәм инструкцияләрендә язылмаган, исәпкә алынмаган хәлләр белән очрашырга туры килә.

Мәсәлән, Чаллыда зур оешмаларның берсендә партия сафына алу буенча җыелыш үткәрелә. Партиягә производство алдынгыларын, яшь эшчеләр, белгечләрне кабул итәләр. Башта барысы да алдан уйлаганча, үз җае белән бара. Менә чираттагы иптәш турында фикер алышу башлана. Бу иптәш кандидатлык стажы чорында шактый активлык күрсәткән, җыелышларда кискен чыгышлар ясаган, хәтта газетага тәнкыйть мәкаләсе дә язган. Әмма кайбер фактларны бозып күрсәткән икән, җыелышка катнашкан партия члennарының берсе бу вакыйганы казып чыгара, бәхәс башланып китә. Егет җыелышта үзен кыю тота һәм эшнең ничек булганлыгын ачыктан-ачык сөйләп бирә. Ул газета хәбәрчесенә фактларны әйткән, ә хәбәрче аларны ашык-пошык блокнотына теркәп барган. Соңыннан, егеттән ризалык та сорап тормастан, аның исеме белән газетада хәбәр бастырып чыгарган. Газета басылып чыккач, инде төзәтмә кертү мөмкин булмаган. Шул газета аркасында егеткә иптәшләренең мөнәсәбәте үзгәргән: имеш, ул ялган фактларны язган. Менә хәзер моңа партия оешмасы тиешле бәя бирергә тиеш. Партия оешмасы секретаре ашыга, алгы бүлмәдә кешеләр көтә, көн тәртибендә тагын әллә никадәр каралася мәсьәлә бар. Берәүләр егетне партиягә алу ягында, икенчеләре каршы. Егет үз фикерен туп-туры әйтә, кимчелекләргә күз йоммый, һәр эшне ахырына кадәр башкарып чыгарга омтыла — болар чын коммунистка хас сыйфатлар. Ә секретарь үзе дә каршылар ягында. «Тагын кемгә сүз бирик?» — дип сорый. «Тавышка куярга кирәк»,— диләр залдан.

һәм тавышка куялар.

Күпчелек егетне партиягә алу ягында. Бары тик дүртәү генә (шулар арасында секретарь үзе) каршы кул күтәрә.

Партия членлыгына яки кандидатлыкка кабул ителгән һәр кешене гадәт буенча секретарь кул биреп тәбрикләргә тиеш. Бик табигый: бу очракта да секретарь, президиум председателе, урыныннан торып, «Партия членлыгына кабул ителүең белән чын күңелдән котлыйм»,— дип, егетнең кулын кыса. Ә шул ук кулын ул ике минут элек егеткә каршы күтәргән.

Мин бу вакыйга турында шуңа яздым: партия эшендә бернинди инструкциядә язылмаган нечкәлекләр мөһим роль уйный. Менә, әйтик, бу очракта бернинди ялгышу юк. Әлбәттә, һәр партия члены кебек үк, секретарь да каршы яки уңай тавыш бирергә хаклы. Устав бозылмаган. Әмма күпләр өчен күңелсез хәл килеп чыккан. «Ничектер сәер килеп чыкты,— диде миңа ул егет.— Секретарь миңа каршы тавыш бирде, үзе аннары тәбрик итте. Ул кайсында хаклы иде соң: миңа каршы тавыш биргәндәме, әллә тәбрик иткәндәме? Мин бу турыда уйланмыйча булдыра алмыйм, дөрес бит».

Минемчә, секретарь да ул кичне тыныч кына өенә кайтып китмәгәндер...

Сүз читкәрәк китте бугай, шәһәр комитеты секретаренең эш бүлмәсенә кайтыйк.

...Менә ишектә — Саша Клюев. Мин аны кичә КамАЗдагы иң яхшы бригадирлар советында, төзелеш начальнигы Николай Максимович Иванцов янында күргән идем. Ул Беляевкә куптәнге танышына мөрәҗәгать иткәндәй:

— Исәнмесез, Рәис Кыямович,— ди.

— Сәлам, Саша. Нигә сөмсерең коелган?

— Күңелсезлек килеп чыкты әле, Рәис Кыямович.

— Сөйлә.

Кичә ул Иванцовка һәм иптәшләренә тәүлеккә йөз мең кирпеч салуы турында сөйләгән иде. Ә бүген нинди дер күңелсезлек турында әйтә.

Эш шунда икән: КамАЗ төзелешендә эшләүчеләр буш вакытларында үзләре өчен йорт салалар. Шундый йортларның берсе инде әзер. Шулай да кучәргә рөхсәт итмиләр. Бәлки, сәбәбе җитдидер, Саша ул турыда белми, әмма ордер алган эшчеләр тавыш куптара, рөхсәтсез-нисез күчмәкчеләр.

— Син нәрсә, Саша? Ничек инде ул рөхсәтсез-нисез? Башбаштаклык бит бу!

— Мин берни эшли алмыйм, Рәис Кыямович... Шуңа күрә киңәшкә дип сезгә килдем.

— Үзең дә шуннан квартира аласыңмы?

— Әйе.

— Менә нәрсә, Саша. Син бригадир һәм төзелештә абруең да зур. Башбаштаклыкка юл куярга ярамый...

— Ә сез сәбәбен беләсез иде.

— Белербез. Син юкка гына килмәгәнсеңдер инде. Ә башбаштаклыкны туктат. Кешеләр белән сөйләш. Алар бит бульдозер түгел, аңларлар.

Секретарь шундук селектор кнопкасына баса.

— Горисполком?

— Әйе, Рәис Кыямович.

— Эшчеләр үзләре салган йорт ни хәлдә?

— Санэпидстанция күченергә рөхсәт итми. Коммуникацияләр тәгәлләнеп бетмәгән.

— Ә кемдә гаеп?

— Тикшерербез, Рәис Кыямович... Аннары исемлек тә каралмаган. Өлгереп булмый. Торак йортлар күп өлгерә...

— Өлгермисезме? Кешеләр тәүлеккә йөз мең кирпеч салырга өлгерә, ә сез исемлек карарга өлгермисез. Беләсеңме бер кирпечнең авырлыгын? Белмисеңме? Өч ярым килограмм... Исемлек... Шул йорт янына бар да эш нидән тора — бел. Аннары миңа хәбәр итәрсең...

Ә Сашага:

— Ишеттеңме? Мин хәзер горисполком председателе урынбасары белән сөйләштем. Ул хәзер председатель урынына калган. Дүшәмбе көнне мине эзләп тап, өйдәнме, моннанмы — теләсәң кайдан. Шәһәр комитеты коммуникация өчен җаваплы кешеләр белән шөгыльләнер... Эшләрләр. Ә мактап өчен сезгә рәхмәт... Аларга да белдер. Кара аны: тәртип булсын!

Ул көнне Рәис Беляев шәхси эшләре белән килгән утыз кешене кабул итте.

— Мин ялгышаммы? дип сорыйсыз... Кем ялгышмый икән? Кайчагында берәр карар кабул итсәң, аннан уйланасың — дөресме, ялгышмы? Төрле чак була. Менә, мәсәлән, шундый очрак. Узган ел, уку елы башланыр алдыннан, шул нәрсәне белеп алдык: бер төзү оешмасы җитәкчесенең: «Мәктәп уку елы башлануга әзер булыр»,—

диган вәгъдәсе коры сүз булып чыкты. Төзелеш мәйданына барып карагач идем — эштә бернинди киеренкелек юк. Теге иптәшне шәһәр комитеты бюросына чакырдык. Күп сөйләшмәдек: әгәр 1 сентябрьгә мәктәпне өлгертмисең икән, партбилетыңны өстәлгә чыгарып саласың. Ул эшнең тәмамлануы турында 28 августта рапорт китерде. Без мәсьәләне бик кискен куйдык. Мин кабат-кабат бу утырыш турында уйланам. Чөнки партиядән чыгару белән куркытып эшләтү — дөрес метод түгел. Әмма ни эшлисең — эш шартлары гадәттәгечә түгел шул...

## Сентябрьдә төзү эшләре

Миллион — гадәти сумма. Сентябрь аенда төзү-монтаж эшләре өчен һәр тәүлектә бер миллион 100 мең, бер миллион 300 мең сум акча тотылды. Төзелеш эшләренә 33 миллион 155 мең сум акча тоту планы арттырып үтәлде.

## КамАЗны бөтен ил төзи

— Мондый темплар белән эшләү кыен түгелме? — дисез. Мин хакны түгел, туп-туры әйтәм: кыен. Әмма үз намусың алдында оятка каласы килми. Безнең төзелешкә нинди зур игътибар! Безгә СССР Министрлар Советы Председателе А. Н. Косыгин, Политбюро членны, КПСС Үзәк Комитеты секретаре А. П. Кириленко килде, СССР Министрлар Советы Председателе урынбасарлары, КПСС Үзәк Комитетының җаваплы хезмәткәрләре килеп тора. Без һәр көнне КПСС Үзәк Комитетының, хөкүмәтебезнең кайгыртучанлыгын, ярдәмен даими сизеп торабыз. Шулай ук төзелешкә Татарстан республикасы органнары да зур практик ярдәм күрсәтәләр. КПСС өлкә комитеты секретарьлары Ф. Ә. Табеев, М. Т. Троицкий күбрәк вакытларын, мәгаен, бездә үткәрә торганнардыр. Аларның хәтта Чаллыда даими эш бүлмәләре бар. КамАЗ төзелеше — бөтен илебез күз алдында. Шулай булгач, бөтен көчне биреп эшләмәскә мөмкинме?.. Менә карагыз, илебезнең барлык почмакларында КамАЗ өчен тырышалар.

Рәис Беляев газета материаллары тулган папканы ача. Кыска гына хәбәрләр. Менә аларның кайберләре.

### КАМАДАГЫ ГИГАНТ ӨЧЕН

*СССР Госстроеның һәм Автомобиль промышленносте министрлыгының проект оешмалары коллективы автозавод комплексын ходка җибәрү проектларын вакытыннан элек тулысынча эшләп тапшырырга йөкләмә алды.*

*Воронеж шәһәрендәге авыр механик пресслар заводы һәм Горький исемендәге Киев автомат станоклар заводы КамАЗ өчен картерлар ясауга хезмәт итә торган куәтле махсус пресслар, картер капкачлары һәм арткы күпер суппортларын эшкәртә алган автоматик линияне вакытыннан элек проектлаштыруны һәм 1973 елда заводка тапшыруны күз алдында тота. 1974 елда, билгеләнгәнгә караганда, ике-өч айга элегрәк заводка югары җитештерүчәнлекле 50 механик пресс һәм 91 ярымавтомат станок эшләп тапшырылачак.*

*Узел машина заводы коллективы срогыннан элек 10 нан 30 тоннага кадәр йөк күтәрә торган краннарны проектлаштырырга, ясарга һәм заводка тапшырырга йөкләмә алды.*

*Мәскәү «Автозил» берләшмәсе, Ярославль «Автодизель» берләшмәсе, Горький «Автогаз» берләшмәсе һәм Минск автомобиль заводы коллективлары автомобильнең мөһим детальләрен җитештерү өчен технологик проектларны эшкәртергә йөкләмә алдылар. Аларда Кама заводы өчен 7500 квалификацияле эшче һәм инженер-техник хезмәткәр әзерләнәчәк.*

## ГЕНПЛАН ХУПЛАНДЫ

*СССР Министрлар Советы янындагы гражданлык төзелеше һәм архитектура буенча Дәүләт Комитеты, РСФСР Госстрое, КПССның Татарстан өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының берләштерелгән утырышы булды. Анда Чаллы шәһәрен төзүнең генераль планы хупланды һәм раслату өчен РСФСР Министрлар Советына тапшырырга дигән карар кабул ителде.*

*Проектның баш архитекторы ЦНИИЭП директоры Б. Р. Рубаненко.*

## ТОЛЬЯТТИДА ЯҢА ЗАВОД

*Идел автомобиль гиганты белән рәттән тагын бер зур завод күтәрелә. Ул күршесенә һәм Кама автогигантына ел саен йөз меңнәрчә генераторлар, стартерлар эшләп чыгарачак. Идел автозаводы, «Промстройпроект»ның Тольятти бүлеге, «Электропроект»ның Куйбышев бүлеге коллективлары һәм илебезнең башка институтлары күптән түгел яңа предприятие өчен техник проектларны әзерләп бетерделәр.*

...Газеталардан кисеп алынган мондый хәбәрләр бик күп. Мәскәү, Ленинград, Киев, Тбилиси, Иркутск, Чиләбе, Ереван, Баку, Кишинев, Днепропетровск... Хәер, аларның барысын да санап чыга башласаң... «Камгэсэнергострой» парткомы секретаре Назиров Чаллы белән бәйләнешле урыннарны картада билгеләргә тырышып караган. Шул нәрсә ачыкланган: илебездә бу шәһәр белән бәйләнешкә кермәгән бер генә урын да юк икән!..

# Яңарак документлар

Әлбәттә, болар вакыт үтүдән саргаер һәм килер бер заман, бәя биргесез архив материаллары булып әверелер. Арзанлы контор папкаларына пөхтә итеп тегелгән бу кәгазьләр әлегә яңа. Алар КамАЗ төзелешенең беренче адымнарын сөйли.

**Белешмә**
**Чаллы партия оешмасының составы турында**

| ЕЛ | Шәһәр | Авыл |
|---|---|---|
| 1969 | 3409 | 1591 |
| 1970 | 4965 | 1614 |
| 1971 | 8077 | 1590 |
| 1972 | | |
| Елның 1 яртысы | 9704 | 1571 |

КПССның Чаллы шәһәр комитеты шәһәрдәге партия оешмаларын гына түгел, районнагы барлык комитетларны да берләштерә.

Югарыда китерелгән таблица турында уйланыйк. Чаллы шәһәре коммунистлары (3409 кеше) ике ел ярым эчендә яңа килгән 6295 коммунистны учетка алалар, оешмаларга туплыйлар һәм актив партия эшенә кушалар. һәм алар белән бергәләп җитмеш мең төзүчене яңа үрләр яуларга әйдиләр. Әлбәттә, бу эштә авыл коммунистлары да ярдәмгә килә. Алар торак һәм туклану мәсьәләләрендә булышалар.

Документлар Чаллы коммунистларының зур оештыру эшләре, бик күп йокысыз төннәре турында сөйли.

Мин 1971 елда КамАЗ төзү эшенә үз өлешләрен кертергә теләүчеләрнең ничек килеп урнашуларын күрдем. Тулай торакларда урын юк иде. Шәһәрдәге сигез мең семьяның һәрберсе берәр, икешәр, кайберләре өчәр кешене квартирага кертте, ә меңнәрчә кеше авылларга урнашкан иде. Төзелешнең иң кыен елы иде бу. Җәй

буе диярлек, шулай ук көзен дә чиләкләп яңгыр койды. Коммунистлар төзелешкә килүчеләрнең барысын да торак белән тәэмин итеп бетермичә тынычланмадылар. Яңа килүчеләрне 50—60 километр ераклыктагы авылларга да илтергә туры килә иде. Кешеләрне торак белән тәэмин итү — партиянең иң мөһим бурычы иде.

Электәге бишьеллыкларның удар төзелешләрендә чыныккан тәҗрибәле төзүчеләр, партия җитәкчеләре килде, яңа гына мәктәп тәмамлаган егетләр, кызлар килде. «Автозаводстрой» төзелеш идарәсенең хәзерге начальнигы Владислав Александрович Фоменко элек Братскида промышленность комплексы белән идарә иткән, КамГЭСның баш инженеры Владимир Александрович Альфиш Балаков ГЭСы төзелешендә эшләгән, «Автозаводстрой» парткомы секретаре Владимир Петрович Кирюхин — тәҗрибәле партия хезмәткәре, Астрахань шәһәреннән.

Бер мең ике йөздән артык кеше партиянең шәһәр номенклатурасында тора. Аларны эшкә шәһәр комитеты бюросы беркетә. Күптән түгел уздырылган шәһәр комитеты пленумында Рәис Беляев Чаллыда 127 партия оешмасы, 260 цех комитеты, 400 партия группасы булуын сөйләде. Алар КамАЗ төзүчеләре коллективының һәм автозавод эшчеләренең төп әйдәүче көче.

Коммунистларның мондый эшчәнлеге һәм коллективның шундый темплар белән үсеше илебез төзелеш практикасында гел очрамый. Бирелә шундый хәл булган. Советларның җирле органнарына сайлаулар вакытында Республика сайлау комиссиясеннән Чаллы шәһәр Советына шалтыраталар: узган сайлауларга караганда бу сайлауга катнашучыларның 30 меңгә якын үсеше дөресме, әллә берәрсе ялгышканмы? Моны раслап җавап биргәч тә ышанмыйлар, шәһәр комитетына да шалтыраталар. Аннан гына ышанырга мәҗбүр булалар.

Төзүчеләрнең шундый зур коллективын туплау, әлбәттә, бик катлаулы эш. Ә аны нигытү, киләчәк үсешен кайгырту һәм тәрбияләү — тагын да катлаулырак.

Партия комитеты төзелеш башында ук шундый карар кабул итә: «Хезмәт ияләрен В. И. Ленин васыятьләре рухында, коммунизм идеяләренә бирелгәнлек, хезмәткә коммунистик мөнәсәбәт рухында тәрбияләү, буржуаз карашлар һәм гореф-гадәтләрдән тулысынча арыну өчен көрәш — барлык коммунистларның, җитәкчеләрнең, инженер-техник хезмәткәрләрнең беренче бурычы. **Коллективның моральполитик хәле өчен җаваплылык производство планнарын үтәү белән бер үк дәрәҗәдә бәяләнә».**

Меңә завод һәм шәһәр проектларын йөзгә якын институт эшләвен әйттеләр. Шуңа карамастан, барлык мәсьәләләр оператив, хәзерге заман фән һәм техникасына ярашлы итеп хәл ителә. Нинди генә кыенлыклар булмасын, завод билгеләнгән вакытка төзелеп бетәчәк, машиналар эшләп чыгарылачак. Партия оешмасы алдында заводны төзү һәм ходка җибәрү бурычы гына түгел, кешеләрне тәрбияләү бурычы да тора. Завод төзелеп беткәч, төзүчеләрнең бер өлеше башка төзелешләргә китәр. Әмма Чаллыда эшләгән вакытларында аларда, яңа җәмгыять төзүче буларак, үзгәреш яхшы яккамы, начар яккамы — моның өчен партия оешмасы җаваплы.

Әле архив шүрлекләренә салынырга өлгермәгән документлар өнә шулар турында сөйли.

## Авырлык үзәге

Автозаводның генеральный директоры — Лев Борисович Васильев, СССР Автомобиль промышленносте министры урынбасары. Элегрәк ул Мәскәү кече метражлы автомобильләр заводы директоры булган.

Автозаводның генеральный дирекциясе һәм парткомы хәзер нинди эшләр белән шөгыльләнә?

Лев Борисович белән партком секретаре, экономик фәннәр кандидаты Аркадий Андреевич Родыгиннан мин шул турыда сораштым.

Бирелдәге партком әле яшь, аның оештырылуына бер елдан аз гына артык. Шулай да ул ике меңләп коммунистны берләштерә. Ә анда хәзер унике меңнән артык кеше эшли. Бу, Родыгин әйткәнчә, 1974 елда беренче автомобиль эшләп чыгарачак һәм

илебез халык хуҗалыгы өчен йөк машиналары эшләп чыгаруны юлга салачак, завод ның өзлексез эшләвен, машиналарның дөнья стандартлары дәрәҗәсендә булуын тәэмин итәчәк коллективның үзәге.

Шулай итеп, хәзер дирекция һәм парткомның төп бурычы — барлык техник документацияләрне булдыру, аларны бетон һәм металл корылмага әверелдерү эшенә төзелеш барышына контрольлек итү, кадрлар әзерләү, җиһазларны үз вакытында китерүне тәэмин итү.

Бирегә 35 мең ярым технологик җиһаз, йөзләрчә автомат линияләр монтажланырга тиеш. 1974 елның башында ук инде заводта меңләгән квалификацияле эшче эшләячәк... Ә боларның барысын бүген әзерләргә кирәк.

— КамАЗ төзүчеләрнең үзләрен заводта эшләргә калдыру проблемасы ничек тора?

— Бу мәсьәлә эшчеләрнең һөнәренә, сәләтенә бәйле. Чөнки һәр төзүче машина ясаучы була алмый бит.

— Күп кенә төзүчеләр бирегә калырга, автомобиль ясау һөнәрен өйрәнергә телиләр.

— Без моны истә тотабыз... Заводта эшләргә калырга теләүче һәр кешегә картотека ачтык. Гариза биргәннәрнең һәркайсы исәпкә алына.

— Ә төзүчеләрне автомобиль ясау өчен кирәкле һөнәрләргә өйрәтү эше алып барыламы?

— Безнең шәһәр шартларында мондый һөнәрләргә өйрәтү кыен эш. Моның өчен база кирәк — завод. Һөнәргә өйрәтү илебезнең автозаводларында алып барылырга тиеш. Әлбәттә, вакыты килеп җитәр — завод каршында үз уку йортларыбыз булыр... Эшче көчләренең төп базасы Чаллы һәм тирә-яктагы район, шәһәр урта мәктәпләре булачак. Парткомда хәзердән үк урта мәктәпнең югары классында укучыларны автомобиль төзү нигезләре белән таныштыру проблемасы каралды.

Аркадий Андреевич кадрлар әзерләү, аларда төзелә торган завод өчен кирәкле сыйфатлар тәрбияләү турындагы фикерләре белән уртаклаша.

— Без, беренче чиратта, коммунист эшчеләрне кабул итәргә тырышабыз,— ди ул.— Шундый зур коллектив формалашканда, эшчеләрнең еш алмашып торуы бик зур зыян китерә. Без хәзер коллективның үзәген булдырабыз һәм аның саф, таза булуы өчен тырышабыз. Инженер-техник хезмәткәрләр белемле булсын: аларның кырык проценты партия члены яки кандидаты. Коммунистларның алтмыш проценты югары белемле.

Әле күптән түгел генә генеральный дирекция парткомы, «Камгэсэнергострой» парткомы белән берлектә, ремонт-инструменталь заводының төп объектын төзүче коммунистларның җыелышын үткәрде.

Төрле комитетларга караган уникe партия оешмасы коммунистлары заводны тиешле вакытында ходка җибәрү чаралары турында хуҗаларча бергәләшеп киңәштеләр. Бернинди тар, ведомствочыл караш булмады. Заказ бирүчеләр һәм төзүчеләр арасында мондый дусларча мөнәсәбәт бик еш булып тормый.

Миңа тагын шундый очракны сөйләделәр. Хөкүмәт карары нигезендә төзелешкә җибәрелгән эшчеләр һәм белгечләр үзләренең электәге эш хакының яртысы күләмендә өстәмә акча яки ярты ел дәвамында, һөнәр үзләштергәнче, тариф ставкасы алырга тиешләр. Ә күпләр моңардан баш тарта. «Безгә эш фронты бирегез, без пенсионерлар түгел, акчаны эшләп тә ала алабыз, өстәмә түләү безгә кирәкми»,— диләр.

Шулай итеп, төзүчеләр коллективын коммунистлар заводның чын хуҗасы булырга әзерлиләр.

## Евгений Никанорович сөйли

Кама автомобиль заводы төзелеше начальнигының беренче урынбасары Евгений Никанорович Батенчукны анда белмәгән кеше юк. Шоферлар да, участок начальниклары да, тулай торакларлардагы тәрбиячеләр дә яхшы белә аны.

— Батенчук белән дә сөйләшегез әле,— дип киңәш итте миңа Раис Беляев.

Мин аны беренче мәртәбә 1971 елның язында күргән идем. Селектор буенча диспетчерлар аңа:

— Евгений Никенорович, теплоход белән мең дә ике йөз студент килә,— дип хәбәр иттеләр.— Разнарядка элеккечә каламы?

— Барлык студентлар палаткалар әзер булганчы теплоходта кала. Эшкә машиналар илтер. Алты йөзе — төзелеш индустриясе базасына, алты йөзе — юллар салырга.

— Евгений Никанорович, Мәскәүдән кирпеч төягән транспорт килде. Биш йөз мең данә.

— Главмостстройга хәбәр итегез...

— Евгений Никанорович, Казаннан җитмеш повар килеп төште...

Шулай өзлексез дәвам итә.

Иртәнге сәгатьләрдә Евгений Никанорович рапортлар кабул итә, боерыклар бирә, үзенә буйсынган подразделение башлыклары белән әңгәмәләр уздыра, калган вакытын төзелеш мәйданында үткәрә.

Икенче мәртәбә мин аның белән В. И. Ленинның тууына багышланган тантаналы кичәдән соң очраштым. Кайсыдыр СМУ начальнигы аңардан үзенә бирелгән йөз эшчене урнаштыруда киңәш сорый иде.

— Син эшчеләрне үзең сорадың бит.

— Үзем сорадым.

— Ә нигә башта ук аларны урнаштыру ягын уйламадың?

— Белмәдем...

— Үзең хәл ит... Ә булдыра алмыйсың икән, иртән минем янга килерсең.

Сугыштан соң ук Сочи янындагы Красная Поляна гидростанциясен төзегән, Иркутск ГЭСын төзүгә катнашкан кеше белән сөйләшергә күптән кызыгып йөри идем. Ул Якутиядә Вилюй елгасында мәңгелек туң җирдә гидростанция төзү белән җитәкчелек иткән. Аның эшләгән урыннарын санап үтү белән генә дә күз алдына бернинди кыенлыклар алдында югалып калмаучы батыр кеше килеп баса.

Без Евгений Никанорович белән «Камгэсэнергострой» идарәсе бинасының өченче катында — аның эш бүлмәсендә сөйләштек. Бу сөйләшүне мин магнитофонга язып бардым.

Батенчук миңа нәрсәләр сөйләде.

— Мин әле Иркутскида эшли идем,— диде ул.— мине Иван Трофимович Новиков чакырып алды. Хөкүмәт карар чыгарган — Вилюй елгасында ГЭС төзергә кирәк. Семьям Иркутскидан китәргә риза булырмы икән — мин шул турыда уйланам. Риза булмаса, димәк, мин анда үзем генә яшәргә тиеш булам. Өйгә кайттым. Бәхетем — хатын да, балалар да китәргә риза булдылар. Алай гына да түгел, олы кызым гел ашыктыра: «Гел бер урында күпме яшәргә мөмкин? — ди.— Биш ел узды, җиде ел узды, менә инде ун ел була — без һаман Иркутскида яшибез. Урын алыштырырга әллә кайчан кирәк иде инде».

Алты айдан соң гына хатын әйберләрне җыештырды һәм балалар белән Мухтуйга килде. Бер елдан соң Мирный шәһәре булачак урынга килдек. Палаткалар гына иде әле. Ленинград комсомоллары булачак урамнарны планлаштырдылар. Беренче урам — Ленинград проспекты. Хәзер анда чыннан да Ленинград проспекты. Ә ул вакытта палаткалар гына иде. Мәскәү комсомоллары үз урамнарын Мәскәү проспекты дип атадылар. Хәзер дә ул шулай атала. Аннары — Ленин урамы, комсомол урамы. Мирный шәһәре шулай төзелде.

Вилюй ГЭСын төзү бик авыр шартларда барды. Андагы кыенлыкларны минем беркайда да күргәнем юк. Төзелеш кирәк-яракларын ерактан, зур шәһәрләрдән китерергә кирәк иде. Ә тирә-якта гел тайга, юллар юк. Йөкләр башта Мухтуйга китерелә. Елгалар, сазлыклар тутрач, Мирный шәһәреннән теньякка таба, Лаптевлар диңгезе ягына 900 километр баргач кына төзелеш урынына килеп җитәсең. Юл бары тик кыш көне генә. Барысын да юлга чыкканда алдан әзерләргә кирәк. Берәр нәрсәне онытмыйсыңмы — бер ел көтәргә мәҗбүрсең.

Мәңгелек туң җирдә дөньяда беренче электростанцияне без җиде ел салдык. 500 кеше орден-медальләр белән бүләкләнде...

Ә КамАЗда мин инде икенче ел эшлим. Бу гаять зур төзелеш. Күз алдына китерүе дә кыен. Төзелешне өйрәнү, аны тулысынча үзләштерү өчен миңа, мәсәлән, алты ай вакыт кирәк булды. Бу төзелеш — кешеләре буенча да, эш төрләре буенча да, техника буенча да гаять катлаулы. Тәүлектә эшләнәсе эшләрне сменаларны, бер сәгатьтә эшләнәсе эшләрне оештыру — берсе дә гадәттәгечә түгел.

Зур коллективларның һәрберсе бригададан башлана. Эшлекле бригадирлар, бердәм бригадалар булдыру — бу зур эш. Аларның эшенә дөрес юнәлеш бир,— һичшиксез уңышка ирешәсең. Бригадалар — армиядәге взводлар белән бер.

Кешеләр яңгыр астында да, салкында да эшгән зарланмыйлар. Киң профильле эшчеләр торган саен күбәя — алар — сварщик та, бетон коючы да. Без андыйларны хуплыйбыз, безгә андыйлар күбрәк кирәк. Тәҗрибәле механизаторлар да күп бездә. Монда техниканың иң яңа казанышлары килә, бик күп килә, әмма безнең егетләр алар белән эш итә беләләр.

Тагын бик мөһим нәрсә бар. Безнең партия хезмәткәрләре кайнар, кешеләрне эшкә ашкындыра белүчеләр. Комсомол оешмасы да зур көч. Ул унбер мең комсомолны берләштерә. Аның секретаре Юрий Титов — менә дигән егет, чын комсомол башлыгы. Биредә комсомол оешмасы көчле, мин элек катнашкан төзелешләрдәгегә караганда да көчлерәк. Комсомолның яшьләргә йогынтысы бик зур. Хәтта комсомолга кермәгән яшьләр дә комсомолны үз оешмасы итеп исәплиләр.

Беләсезме, алар шыңшып йөрүчеләргә каршы ничек көрәшәләр? Минемчә, кечкенә эштә дә, зур эштә дә иң әшәкесе — шыңшып йөрү. Шундый бер булдыксызны мин РИЗда күрдем. Яңгырдан, пычрактан зарлана. Иптәшләре аңа: «Туктыйсыңмы син, юкмы? Үзеңнең генә түгел, безнең кәефне дә бозасың. Эшләргә кирәк, ә син шыңшып йөрисең»,— дип тиргәделәр.

— Быел узган елга караганда җиңелрәктер?

— Әлбәттә, узган ел мин монда килгән генә идем, күп нәрсәне белми идем. Быел инде барысын да беләм диярлек. Бүген ни эшләнәсен, иртәгә ни эшләнәчәген беләм.

Партия эше мәсьәләләренә кучәбез.

— Шундый партия оешмасында тору зур бәхет. КПССның Татарстан өлкә комитеты, минем карашымча, актив сугышчан штаб. Шәһәр комитеты да. Шәһәр комитеты җитәкчеләргә КамАЗны тизрәк төзеп бетерүгә ярдәм итүне беренче бурычы итеп саный. Һәм без барлык эшебездә партия оешмасына таянабыз. Мин шулай исәплим: партия оешмасына таянмаган җитәкче җитәкче түгел...

## Учаклар

Телефон чыбыкларын краннар өзеп уза, җир асты кабельләре салырга ярамый — һәр җирдә казу эшләре бара. Элемтәнең иң ышанычлысы — рация.

— Алтынчы, мин — беренче, җавап бирегез.

— Алтынчы тыңлый.

— Утыз минуттан сездә булам. Җыелма тимер-бетонны бушату эшләре ничек бара?

— Беренче, мин — алтынчы. Баганаларны китерделәр. Бушаталар. Җиденчедән автобус килмәде әле.

— Җиденче, беренче җавап бир!

— Керамзит китерделәрме?

— Юк әле.

— Кырык минуттан сездә булам. Минем белән элемтәдә булыгыз.

Һәр көнне иртәнге сәгать җидедә Анатолий Викентьевич Котвицкий төзелеш буйлап йөри. Аңа Чаллыда төзелә торган культура-көнкүреш биналары карый.

Төзелеш начальнигы, Социалистик Хезмәт Герое Николай Максимович Иванцовтан мин шуны белдем: мәктәпләр, больницалар, балалар бакчалары, кибетләр, ашханәләр, көнкүреш биналары, культура сарайлары салу бер идарәгә — «Соцкультстрой»га тапшырылган. Моның белән җитәкчелек итәрдәй кеше табу җиңел булмаган. Ул объектларның күбесе әле проектта, яки нигезе салынган хәлдә генә булган.

Чирәм җирләрдә студент отрядлары белән җитәкчелек иткән, Казан шәһәре янында Халыкара яшьләр лагере төзү эшләрен оештырган коммунист Анатолий Викентьевич Котвицкий КамАЗга Казаннан, төзүче инженерлар институтын тәмамлап килә. Аны килү белән шәһәр комитетының төзелеш бүлеге мөдире итеп раслыйлар, бюро члены итеп сайлыйлар. Анатолий беренче секретарьның уң кулы булып әверелә. Әлбәттә, белемле, тырыш кешенең үз урынында булуы һәркем өчен яхшы. Һәм ул кеше тагы да җаваплырак эш белән җитәкчелек итәр дәрәҗәдә үзен таныткач, аның белән аерылышу да җиңел түгел. Шулай да Беляев Котвицкийны иң катлаулы төзелеш участокларының берсенә куярга дип үзе тәкъдим ясый. «Син көчле, матур,— ди ул Котвицкийга, шаяртып,— яшең утыз дүрттә, буең ике метр чамасы — бу йөкне генә күтәрә алырсың...»

— Җиденче, мин — беренче, җавап бирегез.

— Җиденче тыңлый, Анатолий Викентьевич.

— Мин әле генә алтынчыда булдым... Панельләр ташый торган машина нигәдер күренми... Ачыклагыз. Ярты сәгатьтән мәктәп янында булам...

Яңа шәһәрдәге яңа мәктәп. Утыз ике класс бүлмәсе, актлар залы, киң экранлы кинозал, кухня, буфет, кабинетлар, китапханә... Мәктәп кенә түгел, сарай.

Анатолий Викентьевич мәктәпне хуҗаларына тапшыру хәстәре белән йөри. Мин Ленинградтан панно ясарга килгән яшь художникларның бәхәсен тыңлыйм. Алар Котвицкийдан мәктәп алдындагы мәйданны тигезләтүен, аны кара туфрак белән түшәтүен, үлән чәчтерүен таләп итәләр, беренче звонокка кадәр ямь-яшел булып торсын! Ә Анатолий Викентьевич мәктәп ачылу көнендә пионер дружинасы җыю, яңа шәһәрдә беренче пионер учагы ягу өчен урын эзләп йөри.

...Ике палубалы «Мәскәү» теплоходы. Каюталарда һәм палубаларда «Соцбыткультьстрой» ял базасына путевкалар алган эшчеләр.

Кама елгасы. Алексей Максимович Горький әсәрләреннән үк таныш җыр:

**Город на Каме, где незнаем сами...**

Кама елгасы бу урында киң. Елганың уң ягында — Алабуга шәһәре, урманнар — Шишкин картиналарыннан таныш урыннар.

Көн кояшлы, җылы. Без инде Кама буйлап бер сәгать йөзәбез. Елга төзелешкә йөкләр китерә, кешеләргә су бирә, ял бирә.

Ярга чыгабыз. Ярдан ерак түгел — саф сулы тирән күлләр. Күл буенда — егерме кешелек, утыз кешелек зур палаткалар тезелеп киткән. Ял итәргә килүчеләргә ятак әйберләре өләшәләр: матрац, мендәр, ак җәймә. Күңелле шау-шу. Караңгы төшү белән уннарча учаклар кабына, күлгә күмелгән бәрәңгеләр пешә. Учаклар тирәсенә утырышканнар шауламыйлар, никтер әкрен сөйләшәләр. Мөгаен, бала чакларындагы учакларны, пионер учакларын искә төшерә торганнардыр.

Бер учак тирәсендә минем танышлар — Валерия Шамилевна белән Юрий Михайлович Масленниковлар. Икесе дә партия хезмәткәрләре. Валерия — «Камгэсэнергострой» парткомы секретаренең идеология буенча урынбасары, ә Юрий — партиянең шәһәр комитеты хезмәткәре. Күлмәк җиңен терсәгенә кадәр сызганган зур буйлы бер кеше Масленниковка:

— Иртәгә таң белену белән җиләк җыярга барырбыз,— ди.— Моннан бер чакрым тирәсендә генә җиләкле аланнар күп. Узган ял көнне ике сәгать эчендә бер бидон җыйдык.

Ул Котвицкий булып чыкты.

Күл өстендә музыка яңгырый — аргы якта биниләр. Ә монда гитарага кушылып җырлыйлар:

Тирә-якта КамАЗ,
Ә без уртада...

Таныш тавыш:

— Ә егерме елдан нинди җырлар җырларбыз икән?!

Бу — партком инструкторы Рита Низковских тавышы. Ул, комсомол комитеты белән берлектә, КамАЗда союздаш республикалар фестивале оештыру белән шөгыльләнә. Шуңа күрә бик табигый: илнең төрле почмакларында иҗат ителгән җырлар КамАЗга аның аша килә.

— Безнең җырларны җырларлар,— дип җавап бирә аңа Котвицкий.

Һәм сугыш алды елларында туып, ата-ана тәрбиясен яртылаш кына күреп үскән буын вәкилләре үзләре җырлаган җырларны сөйләп киттеләр.

— Ә сугыштан соңгы елларда нинди җырлар җырлый идек әле:

Балкый учактай
Зәңгәрсу төннәр.
Ут-суны кичкән
Безнең әтиләр.

Җырны Валерия башлап җибәрде, аңа башкалар да кушылды. Балалар җыры зурлар башкаруында Кама өстенә җәелде...

Аннары әңгәмә бүтән юнәлеш алды. Карагыз хәзер: кешеләр ничек киенә... Авылдамы, поселоктамы — һәр өйгә кер: менә дигән мебель, шүрлек тулы китап; телевизор, радио, газ плитәсе... Телевизорны кабызып җибәрсәң, Уралдамы син, Идел-Кама буендамы — Мәскәү дикторы хәерле кич теләп елмая... Ә Мәскәүдән Чаллыга бары ике сәгать очарга кирәк... Шулай да рухи яктан бары да тигез түгел әле. Чын кешеләр, батыр, яхшы күңелле, белемле, принципиаль кешеләр бар. Шул ук вакытта намуссыз, әшәке, усал кешеләр, гомумән, әрәмтамаклар да күп әле. Андыйлар кайчан бетәр икән?..

Рәис Беляев белән сөйләшүне хәтергә китерәм.

— Казаннан кинәт кенә чыгып китүе җиңел булды дип уйлыйсызмы? — дигән иде ул.— Комсомол өлкә комитетының беренче секретаре булып эшләдем, аннары партия райкомы секретаре... Күнегелгән шәһәр, дуслар, семья — үзең беләсең... Мине өлкә комитетына чакырдылар да әйттеләр: «Барасыңмы?» Күңелдән җавап әзер иде. Тиздән бюро карары да булды. Хатын да каршы килмәде. Килдем Чаллыга. Каршымда — кою цехы салыначак кыр. Зур таш куелган, аңа: «Бирелә Кама автомобиль Батыры салыначак», дип язылган. Дулкынлануымны яшермим. «Сине бөек эшкә җибәргәннәр»...— дип уйладым. Һәм, беләсезме, гомеремдә беренче тапкыр үз-үземә ант бирдем. Була бит кайчагында шулай, үз-үзең белән тантаналы сөйләшү... Һәм мин бу җиргә ныгып урнаштым. Мин бу җирне аяк табаннарым белән генә түгел, йөрәгем белән тоям. Патетика, дисезме? Юк, патетика түгел. Мондый минутларда киләчәк буыннар язмышын да уйлыйсың. Минем бабайлар буынын бөек революцияне иҗат итү мәңгеләштерде. Минем әтиләр буыны шушы революция яулап алган социаль стройны яклады. Сезнең буын, абыйлар буыны, сугыш җимергән корылмаларны торгызды, әйләнә-тирәдә без көн дә күрә торган төзелешләрне башкарды. Минем буын, электәге өч буын тәҗрибәсе, белеме, ышанычы белән рухланып, яңа төзелешкә керешә. Ул инде җимерекне торгызу белән шөгыльләнми, ул бары тик төзи һәм моңа кадәр яулап алынганнарны яклый. Хәзерге буын, минем белән, сезнең белән, безнең әтиләр белән менә бу Батырны төзи. КамАЗ төзүчеләрнең уртача яше егерме өч дибез икән, моның олы мәгънәсе бар. Бу буын моңа кадәр ирешелгәннәрнең барын да үзләштерде һәм плюс ул хәзерге заман фәннәрен дә белә... Менә мин шулар турында уйландым. Күрәсеңме, партия хезмәткәрләре дә кайвакыт шагыйрь кебек хисләргә чума...

## ХКК турында әңгәмә

КамАЗга килгән һәркем: «Мондый гигант эшләр ничек идарә ителә икән?» — дип уйламый калмыйдыр.

Үзган ел Евгений Никанорович Батенчукның меңнәрчә кешеләр, йөзләрчә меха-

низмнар, катлаулы техника, йөз меңнәрчә тонна йөкләр белән тиз һәм тыныч идарә итүен күргәч, күз алдыма зур тәҗрибәле армия командующие килеп басты.

— Моңа кадәр күрелмәгән шундый зур заводлар комплексын төзи торган мондый зур коллективта дисциплина һәм оештыру эшләре ничек тәэмин ителә соң?

Мин бу сорауны бетончылар бригадасы парторгы Анатолий Андреевич Кузнецовка бирдем.

Ул кулларын җәеп үзенең эш урынына күрсәтте.

Күз алдыгызга китерегез: буе бер километрга якын, алты йөз метр киңлектәге, ун метр тирәнлектәге котлован. Котлованның аргы ягында — металл челтәрләр көчле прожекторлар нуры астында ниндидер фантастик урмандагы яфракларын койган агач ботаклары булып күренә. Краннар гүләве, электросварка чытырдаулары, бетон ташый торган машиналарның ухылдавы, пневматик чүкечләр тыкылдавы... Тиздән бу урында чуен һәм төсле металлар кою буенча илебездә иң зур заводларның берсе калкып чыгачак. Елга алты йөз мең тонна. Ә хәзергә биредә — бригадалар. Алар көнен дә, төнен дә, яңгыр яуса да, буран булса да, ачык күк астында эшлиләр. Биредә сөйләшү кыен — шау-шу, берни ишетелми. Без вагонга кердек. Монда — чиста, уңай. Стенада — «КамАЗ төзелешендә — социалистик индустрия» газетасының беренче битеннән Николай Шемякин елмаеп карап тора. Ул үзе ялга киткән. Егетләр аның рәсемен юри элеп куйганнар: янәсе, бригадир гел үзләре белән булсын!

— Сезне КамАЗның нигезе кызыксындырамы? — диде Анатолий. — Әйе, һәр төзелешнең нигезе, фундаменты бар. Әмма КамАЗда тагын бер нигез әверүча мөһим. Ул нигез һәртөрле корычтан да, тимер-бетоннан да ныграк. Бригадаларга берләшкән кешеләр, коммунистлар, комсомоллар белән ныгытылган коллектив.

Николай Шемякин бригадасында — биш коммунист: Виктор Ведерников, Алик Пак, Гөлфия Сабирҗанова, Валерий Громов һәм Анатолий Кузнецов. Барысы да бетончылар, шул ук вакытта балта осталары да. Бригадада өч звено. Звенолар оештырганда барысы җыелып килешәләр: беренче звенода Виктор Ведерников белән Алик Пак, икенчесендә — Валерий Громов белән Гөлфия Сабирҗанова, өченчесендә — парторг үзе эшләргә тиеш. Комсомоллар да — алар ундүрт кеше — шулай ук звеноларга бүленә. Һәр звено үз вәкилләрен бригада советына сайлый. Бу органда бригада тормышындагы бәрлык мәсьәләләр хәл ителә.

«Жилстрой-2»дән Рәис Сәлахов бригадасы КамАЗчыларга шундый чакыру ташлый: заданиене һәр көнне, һәр атнаны, һәр айны һәр объектта югары сыйфатлы итеп, арттырып үтәргә. Ә инженер Виктор Деревизов бригадасы һәр ике кеше өч кеше өчен эшләргә йөкләмә ала. Күптән түгел генә демобилизацияләнгән диңгезче Виктор Ведерников бу чакыру лозунгларын стенага кадаклаганда комсомол секретаре Василий Поляковка әйтеп ташламасынмы: «Без алардан киммени?! Әйдә, без дә үз лозунгыбызны язып кадаклыйбыз». Һәм шулай итеп аларның үз лозунглары да пәйда була: «КамАЗ өчен син бүген ни эшләдең?»

Кузнецов кесәсеннән таушалып беткән блокнот чыгарды.

— Безнең бригадада утыз дүрт кеше. Һәр бригада членына мин шулай дим: «Мин синең өчен җавап бирәм, син минем өчен. Әйдә, бер-беребезнең йөзен кызартмыйк». Бездә озын сүз сөйләү юк. Бригадирмы син, мастермы яки парторгмы — эшеңдә дә, үзеңне тотуыңда да башкаларга үрнәк бул. Бригадада яшьләр күп, аларның сүзгә, акыл сатуга әллә ни исләре китми. Шәхси үрнәк булсын аларга. Шул чакта инде алар сиңа һәр вакыт таяныч. Хәтта тискәре ХКК кулланырга туры килсә дә...

— Ә нәрсә соң ул ХКК?

Бригада гомуми бригада наряды буенча эшли икән. Ә хезмәт хакы һәр бригада членының хезмәткә катнашу коэффициентына карап түләнә. Бу алым коллективны тагы да ныграк берләштерә, хуҗалык исәбе буенча эшләүнең файдасын конкрет күз алдына китереп бастыра. Хезмәткә катнашу коэффициентын һәм кемгә күпме хезмәт хакы тиясен бригада советы билгели. Әгәр эшче тырышлык, хезмәткә намуслы караш күрсәтә икән — аңа уңай ХКК билгеләргә, коэффициентны арттырырга мөмкин. Тискәре коэффициент билгеләнгән очраклар да булгалый. Менә, мәсәлән, шундый бер вакыйга була. Әйбәт кенә егет дустының туена бара һәм эшкә чык-

мый. Өченче көнне генә эшкә килә. Гафу итегез, имеш, башка кабатламам. Ә аның аркасында смена бик каты киеренкелек белән эшләргә мәҗбүр була, задание чак кына өзелми кала. Ничек хәл итәргә? Һәм бригада советы шундый карарга килә: ХКК ын 0,8 гә киметергә. Димәк, ул ярты айда 100 сум хезмәт хакы алырга тиеш булса, аңа бу юлы 80 генә сум түләнә. Әлбәттә, бригадада күбрәк уңай коэффициент билгеләнә: мәсәлән, 1,1; 1,2, хәтта 1,3. «Мактау чаралары,— ди Кузнецов,— шелтә чараларына караганда көчлерәк тәэсир итә». Һәм бригада планны үтәми калган ай юк. План үтәлеше күбесенчә: 150, 200, хәтта 250 процент...

Вагон ишеге ачылды.

— Анатолий Андреевич,— дип эндәште бер кыз.— Бер машина урынына ике машина җибәргәннәр. Нишлибез?

Анатолий миннән гафу үтенеп чыгып китте. Бер сәгатьтән генә тирләп, кызарып кайтып керде. Күлмәк изүләрен чишеп җибәргән.

— Хәзер бетон заводы шәп эшли,— диде ул.— Бетонны артыграк та җибәрәләр. Мондый чакта ялны онытасың — бетон эленке-салынкы эшләгәнне яратмый.

Аның эшләвен дә күрдем мин — артыннан күз иярми, әйтерсең туганнан бирле бетончы. Ә ул бу һөнәргә әле күптән түгел, КамАЗга килгәч кенә өйрәнгән. Ә Чаллыга килгәнче Ерак Көнчыгышта эшләгән, урман ташыган, старшина булып катерда йөзгән. Бригадада аны бетончы һөнәренә әлеге хәрби диңгез флотыннан кайткан Виктор Ведерников өйрәткән. Бригадада яңа килгән кешене һөнәргә тиз өйрәтәләр. Бу — партия кушкан эш.

Парторг чит кешеләр күзенә күренми торган башка бик күп мәшәкатьләр турында да сөйләде. Эш фронты белән тәэмин итү, кайнар аш булдыру, эш киемнәрен киптерү, бригада членнарын йөртү өчен машина булдыру. Саклык кассасы мәсьәләсе дә шәптән түгел. Бригада хезмәт хакы ала торган урыннан ул егерме километр ераклыкта. Ә хезмәт хакыннан зарланып булмый — кием-салымга, ашауэчүгә генә кер態 бетәрлек түгел. Шәһәр үсә, тора-бара квартира да бирерләр — йорт кирәк-яракларына, мебель алырга акча кирәк булачак. Якын-тирәдә газета киоскалары да юк—аның өчен дә егерме километр шәһәргә йөреп булмый бит инде.

— Менә шундый мәшәкатьләр барысы да минем өстә,— дип йомгаклады сүзен Анатолий.

Инде кичке сәгать ун. Аның иртәгә иртүк торасы, ике баласын мәктәпкә, кечесен балалар бакчасына озатасы бар.

— Ә кайда торасыз?

— Ерак түгел. Поселокта, вагонда. Ике бүлмә. Тиздән квартира булыр дип өмет итәбез...

Булыр, әлбәттә!..

Шәһәр комитетының беренче секретаре белән «Якты йолдыз» колхозыннан кайтып килəбез...

Бу көнне көндезге нәкъ 12 дә район аша давыл узды. Күптән түгел генә сайланган колхоз председателе Фәнис Вәлиевкә нинди дә булса ярдәм кирәкмиме — без Кадыйр авылына шуны белергә барган идек.

Без килгәндә Фәнис кырдан кайтып кына кергән иде. Өермә, чабылган борчакны туздырып, чокыр-чакырга тутырган икән. Барлык колхозчылар һәм ярдәмгә килеп өлгергән шефлар (төзелешне механикалаштыру идарәсе эшчеләре) уңышны саклап калганнар...

Шәһәр комитеты секретаре канәгать.

Чаллыга кайтып җиткәндә төмам караңгы төште. Беляев шаяртып мыңа болай диде:

— Карагыз әле, нигә кеше шулай күп йокларга тиеш соң? Медицина әһелләре кешене азрак йоклату әмәлен нигә эзләмиләр икән... Мин, төзелешкә килгәннән бирле, иртәнге дүрттә торам. Саф һава, тынлык... Инде яп-якты. Бездә бит Мәскәүгә караганда иртәрәк таң ата... Караңгылык пәрдәсе әкренләп эреп юкка чыга... Бу вакытта эшләве шундый рәхәт... Гомумән, кешелек дөньясы йокыга бик күп вакытын сарыф итә...

«Чулпан» кинотеатры тирәсендә бәйрәмчә шау-шу. Бүген эш көне ләбаса, тантана-мазар буласы түгел иде. Әйдә, «Чулпан» янына киттек!

Мәйдан тирәсендә төрле төстәге утлар яна: «Без КамАЗ төзибез». Краннар белән зур плакатлар куялар, кызлар мәйдан уртасындагы урак һәм чүкеч монументын буйыйлар. Флагштоклар янында Юра Титов, Рита Низковских һәм комсомол комитетының башка хезмәткәрләрен очратабыз.

— Нишләп болай куптыгыз? — ди Рәис Беляев.

— Мәйданны бизибез.

Узган декадада җиде йөз бригада производство заданиеләрен арттырып үтәгән. Шулар хөрмәтенә иртәнге 7 дә хезмәт даны флаглары күтәреләчәк икән...

Шәһәр тирәли бетон юллар сузыла. Алардан өзлексез машиналар йөреп тора. КамГЭС поселогы белән Яңа шәһәр уртасында туктап калсаң, уң кулда да, сул кулда да гигант төзелеш панорамасын, Чаллының матурлыгын һәм куәтен күрәсең. Төннәрен электр утлары диңгезе яңа икмәк заводыннан водопровод трассасына кадәр утыз километрга сузыла. Кама өстенә, ГЭС плотинасы төзелә торган урынга, төзелеш мәйданнарына көчле прожекторлар ут көлтәләре сибә. Кырлар өстендә гөрелте төннәрен дә тынмый.

Беляев белән без Яңа шәһәрдән кырга чыктык. Тип-тигез кыр. Әле бирегә бульдозерлар, экскаваторлар җир актарырга керешмәгән.

— Менә монда культура сарае булачак,— ди шәһәр комитеты секретаре.— Алар икәү. Берсе КамГЭС поселогында, берсе бирегә булачак. Аннан — никах йорты, музей, яшьләр йорты, писнерлар шәһәре. Ә тегендә — киң проспект. Плотина төзелгәч, Кама суы монда ук килеп җитәчәк. Яңа Чаллы шәһәре булачак яр буеннан ук башланып китә.

Ул беравык уйланып торды.

— Яр буе урамы әллә ничә километрга сузылачак. Яр буйларына, кара туфрак түшәп, шомырт агачлары утыртачакбыз. Яз көннәрдә тирә-як ак чәчәккә күмеләчәк...

Беляев тагын туктап калды. Мөгаен, ул яр буйларында шаулап чәчәк атып утырачак бакчаларны күз алдына китергәндер...

Чаллы — Мәскәү.

М. ХӘМИТОВ тәрҗемәсе.

Җәүдәт Кәлимуллин

# ЯПЬ-ЯШЬ КЕНӘ БУЛСА ДА...



Ни майтардылар икән Казан кызлары?..

Бригадир мотоциклын еракта ук сүндереп калдырды да бәрәңге басуына килеп керде. Басуда бәрәңге дә чүпләнеп беткән, кызлардан да җилләр искән иде.

— Кыз-ла-а-ар!.. Кайда сез, йолдызлар!..

Тирә-як тып-тын. Ык елгасы ярларыннан тибеп чыккан чишмәләр генә җырлап агып яталар. Агачларга инде алтын төсе йөгергән. Алар чишмә тавышларын ниндидер бер моңсулык белән тирә-якка тараталар.

— Кызлар, кайда сез?

Җавап урынына җыр ишетелде:

> Йөрер идем тугаенда,
> Кайтсам Ык буйларына...

Кем җырлый моны? Җырчы үзе кайда?

Җыр озак дәвам итмәде. Кышлыкка дип өеп куйган печән чүмәләсе артыннан көлә-көлә бер кыз килеп чыкты.

— Җырны бүлдегез, абый...

— Җыры булыр, сеңелем. Аннан, син нигә әле «йөрер идем тугаенда» дип моңланып утырасың? Шул тугайда лабаса инде син,— диде бригадир, ни әйтергә дә белмичә.— Башкаларыгыз кайда?..

— Бөрлегән җыярга киттеләр, иптәш бригадир.

— Шаяртмагыз әле, сезгә җыр булсын да бөрлегән булсын.

— Елыйкмы әллә инде, абый кеше,— Рокыя кинәт җитдиләнде.— Әнә тракторчыгыз елаганы да җиткән инде. «Бу Казан кызлары җен кебек эшлиләр. Миннән булмый. Билем авырта. Моторым да тартмый дип, сабан төрәннәрен көяштә ялтырата-ялтырата, өенә кайтып китте...»

— ...Минзәлә якларында булган бу көннәр онытырлыкмы соң!.. Андагы гүзәл табигать, кече күңелле, кунакчыл, җырга-биюгә әвәс кешеләр. Рокыялар, Тауасты Байлары авылында торып, ул елны колхозга шактый зур ярдәм иттеләр. Авылның үз кешеләренә әйләнеп бетә яздылар. Гәрәбәдәй сары итеп алар юып чыгарган авыл өе идәннәренә карап карчыклар хәйран калалар иде.

— Минем улыма да шундый бер кыз насыйп булсын иде, ходаем,— дип, башларын кага-кага сокланалар иде.

Колхозда булган көннәрдә Рокыя бер мәсьәләне хәл итә алмыйча аптырый иде. Каян килә икән бу кешеләргә моң, җырга, биюгә булган мәхәббәт? Бәлки, әнә шул Ык елгасы ярларыннан җырлап аккан чишмә суларын эчеп үскәнгә шулайдыр ул. Гаҗәп түгелмени, кичен авыл клубына бер карт белән карчык килеп керә дә, баянчы егет каршына килеп, кызларга шаян сүзләр әйтә-әйтә, болай дип җырлап җибәрәләр:

Тыпыр-тыпыр биегәндә
Авыртмыймы тәпиең?
Егет белән биегәнгә
Орышмыймы этиең?

Шулай, гаҗәп булды ул Рокыяларның Минзәлә якларына барулары! Урып-җыю чорында колхозга ярдәмгә дип җибәрелгән кызлар заводка бирнә белән кайткандай булдылар. Тауасты Байлары авылының юмарт әбиләре аларга йомшак итеп басылган киез итекләр, тәпән-тәпән бал, май-корт төяп җибәрделәр. Җитмәсә, колхоз идарәсе кулга күп итеп акча да бирде.

— Бу чаклы тырыш кызларны күргәнебез юк иде әле, рәхмәт сезгә, сеңелләр, безнең якларга юлны онытмагыз,— дип, аларны Казанга бөтен авыл диярлек озатып калды.

Әлеге төбәктә булуның Рокыя өчен тагын бер истәлекле ягы калды. Минзәлә шәһәрендә ул яшьлек дусларын очратты. Аларның кайберләре инде хәзер Минзәлә театрында танылган артистлар. Икенчеләре — районның культура йортында эшләп яталар. Хәзер Казанда яшәүче артистка Дания Нуруллина да Рокыяның балалык дусты иде. Өй каршыларында алар бергәләп никадәр уен уйнадылар, биделәр, җырладылар. Шул чакларда Дания Рокыяга болай дип әйтә торган иде:

— Син, дустым, биюче булып китәрсең әле. Мин дә театр уйнарга яратам. Әйдә, тотыйк та икебез дә театр училищесына керик.

...Даниянең әти-әниләре музыка яратучы кешеләр иде. Шуңа күрә алар кызларының теләген хуплап кына каршы алдылар.

Ләкин Рокыяның әтисе Сабир абый башкачарак фикер йөртте. Тормышның төбеннән диярлек чыккан, унҗиде яшендә үк авылдан китеп, Донбассның атаклы «Мария» шахтасында күмер чапкан, аннары Казанда, завод-фабрикаларда озак еллар эшләп, коллективтан зур рәхмәтләр ишетеп, дәүләт һәм хөкүмәтебезнең бүләкләрен алып пенсиягә чыккан кадровый эшченең карары катгый булды. Ул кызының да үзе һәм әнисе юлыннан китүен тели иде. Чөнки Рокыяның әнисе Хәтимә апа да бөтен гомерен синтетик каучук заводында эшләп уздырган. Ул да хәзер пенсиядә.

— Кызым, син инде буй җиттең диярлек. Заводка өйрәнчек булып керергә дә бик вакыттыр,— диделәр Сабир абый белән Хәтимә апа.

Әти кеше бигрәк тә коры куллы. Ул бер дә ике сөйләгәнне яратмый. Шуңа күрә бердәнбер кызының булачак тормыш юлын билгеләгәндә ул озын-озак уйларга бер дә урын калдырмады. Ул гынамы? Рокыяның бабасы Фатыйх та яшьтән үк оныгының колагына эшче һөнәренең әйбәтлеге турындагы сүзләрне тукып үстерде. Фатыйх бабайның моңа хакы бар иде. Ул да еллар буена Казанда бетончы булып эшләде. Хәзерге синтетик каучук заводының нигезендә Фатыйх бабай аркасына кузла киеп ташыган кирпечләр аз түгел. Ул сүзгә генә түгел, әнә шулай физик эшкә дә бик батыр булган. Яшь вакытта тегермән ташын берүзе күтәргән, дип сөйлиләр аның турында. Булгандыр да. Әлки районының Яңа Чаллы авылында яшәүче

өлкән буын кешеләре ут йөрәкле Фатыйхны, бәлки, хәтерлиләрдер әле. Шушы пәһлеван уналты яшьтән үк Бәләй дигән байда батрак булып торган. Байның зур хуҗалык эшен берүзе башкарып килгән. Сабан туйларында мәйдан тоткан. «Сабан туе җитәр алдыннан баем минем каршыда күгәрчен булып гөрләп йөри башлады,— дип сөйли торган иде Фатыйх бабай оныгы Рокыяга.— Хәлеңә кергән була, кәефләреңне сораша. Баксаң, моның тел төбендә этлек ята икән. Байның Закир исемле улы бар иде. Бәләй дәдәң шуны сабан туе батыры итәргә хыяллана, имеш. Ә Закир чебен тими чер итә торган нәзберек малай. Бай малае нинди булсын тагын? Шулай да байның өмете зур. Син инде, энем, ди ул, Закирга маңгай терәп маташма, буш итмәм үзеңне. Күлмәк-ыштан алып бирермен, ди. Мин инде байның күңеле булсын дип, миңа зәһәрләнмәсен дип, аның шартына күнгән дә булам. Ләкин мәйданга чыккач, барысы да онытыла да китә. Һәм Закирны җиргә алып сылаганымны сизми дә калам».

...Шулай. Димәк, хәл ителде. Рокыя бабасы, әтисе һәм абыйсы юлыннан китәчәк. Һәм бер көнне аны «Теплоконтроль» заводында эшләүче абыйсы икенче цехка җитәкләп килде. Бу 1964 елда Рокыя урта мәктәпне тәмамлагач булды. Абыйсы аны цехка кертеп калдырды да китеп югалды...

Рокыя эшкә тиз өйрәнде. Бер-ике ай дигәндә ул цехтагы дистәләгән операциянең яртысын диярлек үзләштереп өлгергән иде. Сыйфат та начар түгел. Нәкъ менә шул көннәрдә комсомолларның отчет-сайлау җыелышы булды. Анда Рокыя да чыгыш ясады. Берәү дә көтмәгән иде. Ләкин бу кыз бик ачуланып, борчылып сөйләде. Залдан сорау бирделәр. «Ул үзе бер дә брак ясамый микәнни соң?» — диделәр. Җыелышны алып баручы торып басты һәм белешмә китерде: «Рокыя Гарифуллина көйләгән приборларның берсе дә диярлек заводка кире әйләнеп кайтмаган. Сыйфат таләп итәргә иптәш Гарифуллинаның мораль хакы бар»,— диде ул.

Аны шушы җыелышта цех комсомол бюросы члены итеп сайладылар. Эшнең дә иң җитдиен — «Комсомол прожекторы» эшчәнлеге өчен җаваплы итеп билгеләделәр. Бу вакытта инде бу тырыш кыз үзен эшкә өйрәтүче апасын да узып киткән иде. Ул цехтагы дистәләгән операциянең барысын да биш бармагы кебек белә. Шуның өчен яшьләр арасында беренчеләрдән булып аңа «Коммунистик хезмәт ударнигы» исеме бирелүгә берәү дә гаҗәпләнмәде. Лаек иде ул моңа.

Ләкин тормыш синең алда ак палас кына җәеп тормый шул. Рокыя өчен дә шулай булды. Ул энергетика техникумына укырга керергә җыенган иде. Техникум ишеге аның өчен ачылмады. Эшне бары бер балл хәл итте. Инде бер авыз пешкәч, суны да өреп кабарга кирәклеге яхшы мәгълүм иде. Кыз, төн йокыларын бүлеп, янә дәресләкләргә чумды. Абыйсын аптыратып бетерде. Аның да ярдәме зур булды. Икенче елны Рокыяны техникумның III курсына кабул иттеләр.

Уку еллары тиз үтте. Һәм бер көнне Рокыя әтисе кулына диплом алып кайтып тоттырды. Әй куанды инде Сабир абый! Белә ул укуның кадерен. Чөнки аның үзенә зур белем алырга мөмкинлек булмады. Нибары дүрт класс белән чикләнергә туры килде. Шулай да ул тормыш университетларын шактый узды. Документ-мазар язарга дисәң, күршегә ярдәмгә керми. Русчасын да чатнатып белә, шуңа күрә ул дипломга язылган «Техник-технолог по счетно-измерительным приборам» дигән сүзләрне шартлатып укып бирде. Аннары: «Китер, кызым, моны минем документлар янына төйнәп куйыйк»,— дип, сандыгына үрелде. Рокыя: «Әле, әти, эш урынында да күрсәткәнем юк бит»,— дигәч кенә яулыкны чишми калды.

Аннан соң бу бөтерчек кебек кыз семьяга шатлыклы хәбәрләрне берсе артыннан берсен кайтарып кына торды. Менә аны В. И. Ленин юбилее медале белән бүләкләгәннәр. Ә инде сигезенче бишьеллык йомгаклары буенча аңа Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирелгәч, Казанның Авангардная урамында яшәүче Сабир абыйлар йортында чын бәйрәм булды. Күрше-күләндә яшәүче әбиләр бу шатлыклы хәбәрне тирә-якка сиптеләр...

...Апрель аеның матур көннәре иде. Завод эшчеләре клубка РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат күрсәтергә багышланган җыелышка килделәр. Кешеләрнең күңелендә бәйрәм тантанасы. Өлкәннәрнең күкрәкләрендәге орден-медальләрдән күзләр чагыла. Бу яктылыкка Рокыя күкрәгендәге Ленин юбилее медале сипкән нур да өстәлә. Җыелыш башланды. Һәм Рокыя өчен колак ишетмәгән яңалык әйтелде. «Мин депутатлыкка кандидат итеп 1946 елда туган, комсомолка Рокыя Сабир кызы Гарифуллинаны тәкъдим итәм»,— диде заводта абруе зур булган эшче абый.

Шулай итеп, аны Казан-Идел буе сайлау округы хезмәт ияләре сигезенче чакырылыш РСФСР Верховный Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәттеләр һәм сайлаулар көнендә бертавыштан сайладылар да.

...«Татарстан» поезды республикабыз киңлекләре буенча чаба. Ул Казанга якынайган саен тизлеген арттыргандай булды. Машинист әйтерсең лә Рокыяның сагынуларын сизә. Бер атна эчендә дә завод, эти-әнисе, дуслары сагындырып өлгерде! Хәзер менә барысы: горурлык, соклану һәм сагыну хисләре бергә кушылган, ахрысы. Беренче кат депутат булу, беренче тапкыр сессиядә катнашу, беренче тапкыр Кремльдә булу, Патша-кыңгырау, Патша-пушканы күреп хәйран калу, Татарстан депутатлары делегациясе составында очучы космонавт Андриан Николаев белән истәлекле фотога төшү — барысы да беренче тапкыр!

Поезд инде туган шәһәргә якынлаша. Ә күңел һаман да әле Мәскәүдә. Син хәзер инде заводта приборлар көйләүче генә түгел — халык хезмәтчесе — депутат та. Рокыя РСФСР Верховный Советы Председателенең урынбасары булып сайланды. Шушы вакыйга белән котлап, аның кулын кысканда академик М. Д. Миллионщиков болай дигән иде:

— Тормыш коллизияләре без уйлаганнан күбрәк һәм катлаулырак. Күп укыгыз, өйрәнегез, законнарны яхшы белегез. Депутат эшчәнлегегездә алар сезнең беренче таянычыгыз булыр!

Депутат М. Д. Миллионщиков — РСФСР Верховный Советы Председателе. Димәк, ул әйткән сүзләрне үтәү Рокыяга, аның урынбасары буларак, фарыз да фарыз инде. Бу сүзләрнең хаклыгына төшенү өчен айлар, атналар да кирәк булмады. Мәскәүдән, сессиядән кайтып, юл чемоданын куярга да өлгермәгән иде диярлек, депутатка бер зур хат китереп бирделәр. Конвертка: «РСФСР Верховный Советы Председателе урынбасары депутат Р. С. Гарифуллинага»,— дип язылган иде. Хат Кемерово якларыннан килгән. Тигез һәм вак хәрефләр белән язылган дәфтәрне укып чыгу өчен дә шактый вакытлар кирәк булды. Хатта «буталчык язмыш» тарихы бәян ителгән иде. Хатның авторын илленче елларда шактый гына зур күләмдә дәүләт әйберен урлауда катнашуы өчен озак елларга иреген мәхрүм иткәннәр. Хат стиле буенча маҗаралы повестька, детектив хикәягә тартым. Шулай да җинаятьченең тел төбеннән бер нәрсә аңлашыла: ул төрмәдән алданрак чыгарга тели. Һәм үзен «акларлык» карарлар, төрле циркулярлардан озын өзекләр китерә. Аларның кайчан, нинди орган тарафыннан чыгарылуларын әйтә, номерларын күрсәтә.

Егерме җиде яшендә үк кыек эшкә керешеп, үз башын төрмәгә илтеп тыккан бу кешенең язмышы күңелдә каршылыклы уйлар тудырды. Бер яктан карасаң, ул — зур җинаятьче. Хәзер шуның җәзасын ала. Шул ук вакытта зур хәрефтән язарлык булмаса да, ул барыбер кеше. Кем белә, бәлки, аңа хәзер Рокыяның әтисе хәтле яшьтер. Ул инде байтак вакыт төрмәдә утырган. Ни семьясы, ни баласы, ни тормышы юк. Туры юлдан атлаган булса, барысы да булган булыр иде...

Рокыя хатны читкә этәреп куйды. Ни дип җавап язарга моңа? Гамәлдәге законнарны яхшы белергә кирәк. Ләкин маңгаеңда җиде сыр булса да, тормышның барлык четерекле мәсьәләләренә законнарны туры китереп бетерү мөмкин микән? Шулай да уйлап карарга кирәк әле. Һәм ул район, республика прокурорлары янына юл тотты.

— Төрмәдә төшкә хәтле төш, төштән соң закон сөйләрләр,— дип дөрес әйтәләр шул,— дип шаярттылар прокуратурада.— Бу, иптәш депутат, кешенең нечкә хисләренә кагылу өчен язылган хат. Җинаятьчеләр алар бик сизгер халык. Җилнең кай якка искәнен беләләр. Әйдә, яшь кызның сәләтен сынап карыйк, янәсе. Бәлки, мине азат итү өчен берәр төрле эш кузгатып җибәрмәсме дип уйлаганнардыр. Әгәр закон бозылу бар икән, алар күп тартынып тормыйлар — турыдан-туры Верховный судка язалар.

«Димәк, бу мине бармак тирәли йөртергә теләгән.» — Рокыя прокуратурадагы сөйләшүдән соң шулай уйлады. Кем белә, бәлки, алай да булмагандыр. Хисләргә бирелеп китәргә ярамый. Чөнки син хәзер дәүләт кешесе. Шуңа күрә Рокыя бу хатны «Ни язылган булса шуны карау өчен» РСФСР Верховный судына җибәрде. Аннан ике җавап килде. Аларның икенчесендә хатның тиешле органнарда каралачагы хәбәр ителгән иде. Хат авторы дөресен язган булса да, ялган язган булса да, ул барыбер каралмый калмый. Тәртип шундый.

Халык депутатны үзенең хезмәтчесе итеп саный. Бу исә депутатның җилкәсенә зур йөк булып төшә. Син аның таләбен дә үтәргә, ул күрсәткән хөрмәтне дә дөрес аңларга тиешсең. Кешеләргә ярдәм итә алсаң, рәхмәт укыйлар, данлыйлар. Депутатка булган гозер-сораулар аз булмый. Аларның зурысы-кечкенәсе була. Рокыя сайлаучыларны, гадәттә, айга бер тапкыр, айның беренче сишәмбе көнендә завком бүлмәсендә кабул итә. Кайчакта кешеләр хатларны эш урынында да, эштән кайтканда да, болай гына урамда туктатып та бирәләр. Билгеле, сорауларның, үтенечләрнең шактые җирле Совет депутатлары хәл итә торган мәсьәләләр булып чыга. Ләкин, мин Мәскәү белән генә эш итәм дип, борын чөеп булмый. Чөнки һәр үтенеч артында җанлы кеше тора. Аның үз хәсрәте, үз соравы. Беренче һәм икенче сменаларда эшләгәндә шактый авырга туры килә, вакыт җитми иде. Бер оешмага барасың — инде эш сәгате тәгәлләнгән була, икенчесенә киләсең — җитәкче җыелышка киткән. Соңыннан өлкәнрәк иптәшләр киңәш бирделәр: «Син мәсьәләнең асылын аңлатып кәгазь генә язып җибәр. Бездә депутатлар сорауларына бик игътибар белән карыйлар»,— диделәр. Дөрес әйткәннәр. Хәзер эш шактый җиңеләйде. Депутат вазифасын башкару эшенә дә шулай тора-бара өйрәнәсең икән ул.

«Милләтнең теләкләрен җиренә җиткерү юлында җан фида булсын! Аларны булдыру өчен бер тамчы каным кипкәнче иҗтиһад итү иң мөкатдәс вазифам дип игътикад кылам...» Бу юллар укучыларга бик таныш. Татар әдәбияты классигы Ш. Камалның «Депутат» исемле мәгълүм хикәясенең герое — Государственная думага китәргә җыенучы депутат — вокзалга үзен озатырга төшкән кешеләр алдында шундый нотык тотарга ниятли. Күпме фантазияң бар, шул хәтле ялганла, күпме тел куәсең бар — шуның чаклы буш вәгъдә бир!

Вәгъдәләр сабын куыгы төсле аллы-гөлле төскә кереп зурая баралар. Ләкин гомере аз була шул тәти куыкның, бик тиз шартлый ул. Сатирик планда бирелгән бу образның гыйбрәт өчен булса да файдасы бардыр дип уйлый Рокыя. Безгә әнә шундый буш вәгъдәләр бирү, барысын да булдырам дип күкрәк кагудан сакланырга кирәк. Чөнки безнең халык депутатны андый буш вәгъдәләр өләшү өчен сайламый. Һәм аңардан булдыра алмасны таләп тә итми.

Рокыя эшли торган икенче цех турында, «Сезгә бөтен завод кына түгел, ил йөзе төбәлгән», диләр. Мондый чагыштыру нигезсез түгел. Чөнки завод җитештерә торган продукция әзер килеш менә шушы цехтан чыгарыла. Икенче цех шәп приборлар бирә икән, бөтен завод мактала. Киресе булса — бөтен коллектив йөзе кызара. Рокыя моны эшче буларак та, депутат буларак та яхшы аңлый. Кулыннан килгәнчә, барысын да эшләргә тырыша. Кайчакта башка цехларның гөнаһлары өчен дә бу цех коллективы җавап бирергә тиеш. Чөнки цехка әзер детальләр башка цехлардан алына. Браклылары да булгалый. Бирелә аларны җыялар гына. Цехтагы эшчеләрнең күбесе яшьләр. Аларга тәҗрибә җитми. Рокыя алар турында уйлаганда үзенең цехка беренче тапкыр аяк басу көннәрен искә төшерә. Өлкәннәрнең ярдәме никадәр зур роль уйнавын яхшы белә ул, яшьләргә мөмкин кадәр күбрәк ярдәм итәргә тырыша. Менә Мари якларыннан килеп заводка эшкә урнашкан кыз Галия Абдуллина фикере: «Мин шушы яшемә җитеп Рокыя кебек яхшы күңелле кешеләрне күргәнем юк иде әле. Мин генә микән?! Нинди генә авыр хәлләрдә калсак та, иң башлап аңа барып егылабыз. Юк, депутат булган өчен генә түгел, ул моңарчы да шундый ук ярдәмчел иде. Аның өлкәннәрдәй акыллы киңәшләре, ярдәме чын күңелдән була. Моның өчен ул синнән бер нәрсә дә таләп итми. Тырышып эшләсәк, аңа шул җиткән. Мин аңа әниемә сөйләмәгән серләремне дә әйтә алам. Ул безне гел туры-га, яхшыга өндәп тора. Менә, аның киңәше буенча, быел техникумның кичке бүлегенә укырга кердем». Ә заводта озак еллар эшләүче Дания Мәрданова: «Рокыя яшьләрне үз тирәсенә магнит кебек тарта ул»,— диде.

Менә, шулай итеп, бу цехта остазлык, өлкәннәрнең ярдәмен тоеп яшәү кебек матур сыйфатлар бар. Хезмәт һәм яшәү өчен уңай микроклимат тудырыла. Аның үзәгендә — Рокыя Гарифуллина.

...Күптән түгел Казан шәһәр партия активы җыелышы булды. Активта сүз шәһәр хезмәт ияләренең авыл хезмәтчәннәренә булышлыгы турында барды. Шәһәр коллективлары күрсәтәчәк конкрет эшләр планы билгеләнде. КПСС өлкә комитетының икенче секретаре Ф. И. Панин речен тыңлаганда, Рокыя блокнотына билгеләр куя барды. Аерым саннарны зур итеп язып куйды.

Трибунадан сөйләгәндә аның күңеле янәдән Ык буйларына, Минзәләнең гүзәл кешеләре янына әйләнеп кайткандай булды. Тагын барыр әле Рокыя авылга ярдәм итәргә, һичсүзсез, барыр. Депутат буларак та, эшче буларак та, һәм моннан берничә ел элек Минзәләнең күркәм табигатьле төбәгендә бригадир абыйсы тарафыннан бүленгән җырны дәвам итәр:

...Яшел болын, бөдрә таллар
Гел минем уйларымда.



Мансур Шиһапов,
Әхмәт Рәшитов

# ТӘГӘРМӘЧЛӘРНЕҢ ТАНЫШ ҖЫРЫ



Әле анда, әле монда буй калкыткан кылганнар талгын җилнең рыясыз иркенә буйсынып, битараф кына чайкалалар. Офыктан кызарып кояш чыгып килә; ул — тереклекнең бөек падишасы, әйтерсең иртәнге чыкларда коенган да сафланып, яшәреп киткән.

Мөхәммәт ага вагон тәрәзәсеннән иртәнге хозурлыкка сокланып бара. Мең кат күреп тә күңелне, хыялны ялыктырмас гүзәллек булыр икән! Мондый чакта йоклап яту оят, валлаһи, оят!

Аның әтисе Әхмәткәрим абзый: «Иртән йоклаганның бәхете булмас, кояш белән бергә торырга кирәк»,— дип әйтә торган иде. Бердәнбер арык ат белән җир ерткалап көн күргән ярлы мужикларның бәхетләре булгандырмы, юктырмы, әмма Мөхәммәт ага күңелендә мондый мизгелләрдә сөенеч-шатлык ташып тора, башка берсеннән-берсе матуррак уйлар килә — җырлыйсы килә башлый.

Гастрольләр менә тагын артта калды. Республика күчмә театры артистларын Казагыстанның һәр каласында алкышлап каршыладылар, һәр спектакльдән соң аларны чәчәкләргә күмделәр, хәерле юл теләп, бәхет теләп озатып калдылар. Әйе, чит җирләрдә яшәүче туганнарыбыз Казан якларыннан килгән спектакльләрне, концертларны, китапларны зарыгып көтеп ала шул! Көтеп ала һәм шуннан туган тәэсирләрен хәтерендә изге бер хатирә итеп, кадерләп саклый.

Соңгы елларда коллектив Идел буе өлкәләрен иңләп йөрде, аннары Казагыстан, Үзбәкстан, Кыргызстан шәһәрләре һәм авылларында булды. Әгәр аның маршрутын

картага төшерсәк, без анда Ульяновск, Сызрань, Саратов, Астрахань, Волгоград, Баку, Караганда, Алма-Ата, Душанбе, Семипалатинск, Свердловск, Пермь, Чусовая, Березники кебек эре һәм вак калаларның исемнәрен укыр идек.

Менә хәзер дә алар ерак сәфәрдән — Целиноград өлкәсеннән кайтып киләләр. Мөхәммәт ага Хәмзин җитәкчелегендәге труппа бу якларда тамашачыларга берничә спектакль күрсәтте. Шуларның иң уңышлысы, минем, татар әдәбияты классигы Шәриф Камал әсәре буенча куелган «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакле булгандыр. Үткән заманның кара пәрдәсен күтәреп, иске тормыштагы дин әһелләрен фаш иткән, хакыйкать һәм ялган, яктылык һәм караңгылык көрәшен чагылдырган бу комедия төрле яшьтәге һәм төрле элтәге тамашачыларны көлдерде дә, уйландырды да. Өлкә үзәгендә чыга торган «Коммунизм нуры» газетасында казакъ язучысы Н. Оразов зур гына мәкалә язып чыкты. Анда Татарстанның атказанган артисты Мөхәммәт Хәмзин уены турында шундый юллар да бар иде:

«Хәмзиннең сәхнәдәге һәрбер шегыль-хәрәкәте Хаҗи әфәнденең карикатур кыяфәтен күп санлы детальләр аша сурәтләүгә юнәлдерелгән. Аның бар килеш-килбәте ачы мыскыллауга дучар. Кырык ел бергә яшәгән хатыны алдында икейөзләнгән Хаҗи әфәнденең финалда мәсхәрә булуыннан рәхәтләнеп көләсең».

Мөхәммәт аганың кырык елга сузылган иҗат юлында маяк булып кабынган мондый рольләр аз булмады. Ул тудырган персонажлар галереясенә килеп керсәң, заманалар һәм дәверләр, характерлар һәм кичерешләр гаммасы, теләк-омтылышлар һәм фикерләр карурманы уртасында адашып калгандай буласың. Кем генә юк бирелә! Мирхәйдәр Фәйзинең «Галиябану» драмасындагы мактанчык һәм тәкәббер Исмәгыйль, Риза Ишморатның «Үлмәс җыр»ындагы Бельгия патриоты Андре Тиммер-



*Ш. Камалның «Хаҗи әфәнде өйләнә» спектакленнән күренеш.*

манс, Л. Митрофановның «Кәчләрәк янсын йөрәк» спектаклендәге инженер Юрьев, Н. Хикмәтнең «Сөер кеше» әсәрендә адвокат Әхмәт Риза, Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт»ендәге укытучы Сәлим Гәрәевич...

Драматург Хәй Вахитның «Беренче мәхәббәт» пьесасы буенча куелган спектакльләр Татарстан тамашачыларына яхшы таныш. Алар төрле театрларда төрле режиссерлар тарафыннан куелдылар. Ләкин Республика дәүләт күчмә театры постановкасы алар арасында аерым игътибарга лаек иде. Бу уңышта, билгеле, М. Хәмзиннең дә өлеше зур булды.

Ул гәүдәләндергән укытучы Сәлим Гәрәевич үз эшен яратып башкара, җәмәгать эшләрендә актив катнаша. Ләкин аның күңеленә төер булып утырган авыр үткәне бар. Ул шуңа хафалана, шуңа үз-үзен битәрли. Тамашачы бу кичерешләрне тулысынча аңлап, аңа ышанып, элекке гамьсезлеген шелтәләү белән бергә, хәзерге фаҗигале хәсрәтен дә уртаклашып утыра, күңеленә үтә якын ала. Артист осталыгы тамашачыга бу хәлнең бөтен драматизмын җиткерә.

Мөхәммәт ага үз язмышын күчмә театр белән моннан 27 элек бәйләде. Сугыштан соңгы авыр, киеренке чор иде бу. Коллективның материаль хәле мөшкел, иҗади көчләр җитешми. Режиссер Габдулла ага Юсуповны туктаусыз бер мәсьәлә борчый: коллективны саклап калып булырмы, юкмы? Инде азмы-күпме традициясе булган, үз тамашачыларын тапкан иҗат оешмасы алдына әнә шундый сорау килеп баса.

Сәхнә эшенә чын күңелдән бирелгән җитәкче мәсьәләне бер якка һәм фәкать уңай якка хәл итү өчен көчен дә, вакытын да кызганмый. Шундый авыр вакытта, күктән төшкән бәхет кебек, коллективка Совет Армиясе сафларыннан кайткан Мөхәммәт Хәмзин, Фәридун Юнысов, Тайфур Кичубаев, Зәйтүнә Хәлиуллина, Зәкия Туишевалар килә. Театр берәз тернәкләнгәндәй була. Репертуарга зур сынаулар кичергән халкыбызның күңел кылларын тибрәтердәй, заман темасына язылган әсәрләр сайлап алына. Мирсәй Әмирнең «Тормыш җыры», Г. Насрыйның «Күңел дәфтәре», А. Корнейчукның «Украина далаларында» әсәрләре буенча куелган спектакльләрне авыл тамашачылары хуплап каршылыйлар.

Ләкин көчле оештыручы, коллективның административ җитәкчесе һәм режиссеры булган Габдулла Юсуповның Галиәсгар Камал исемендәге татар дәүләт академия театрына эшкә күчүе Күчмә театрны кабат авыр хәлгә куя — аннан соң бер-бер артлы режиссерлар алышына башлый, кайбер артистлар сәхнә белән бәтенләйгә саубуллашалар. Бу торгынлык берничә елга сузыла.

Ниһаять, хәлне төзәтү өчен Татарстан Культура министрлыгы ашыгыч чаралар билгели. Театрның директоры итеп Мөхәммәт Хәмзин, ә режиссер итеп сәнгать өлкәсендә зур казанышлары булган Сөләйман ага Вәлиев-Сульва куела. Коллективка эш өчен тиешле шартлар тудырыла: театрга аерым бина бирелә, труппа яңа кадрлар белән тулыландырыла. Моннан тыш театр республикабыз районнарында гына түгел, башка өлкәләрдә яшәүче татар хезмәт ияләре алдында да чыгыш ясау хокукын яулап ала. Театрда репертуарга караш нык үзгәрә. Ул түбән зәвыклы тамашачыларга исәп тотып алынган һәм мәгънәсез эффектка корылган урта кул әсәрләрдән акрынлап арына бара. Театр афишаларын, татар драматурглары тудырган тирән эчтәлекле, заманча яңгырашлы пьесалар белән беррәттән, башка халыкларның драматургиясе хәзинәсеннән алынган әсәрләр дә бизи башлый. Н. Исәнбәтнең «Рәйхан», Р. Ишморатның «Үлмәс җыр», Г. Минскийның «Тапшырылмаган хатлар», Х. Вахитның «Беренче мәхәббәт», Л. Митрофановның «Кәчләрәк янсын йөрәк», Г. Мазинның «Бүген һәм иртәгә», В. Лаврентьевның «Иван Буданцев», Г. Мдиванинің «Терезаның туган көне», Д. Юлтыйның «Карагол», Д. Медведенконың «Юлда яткан таш» әсәрләренә нигезләнеп куелган спектакльләр әнә шундыйлардан. Замандашларыбызның тормышын, хезмәтен чагылдырган бу спектакльләр татар матбугатында һәм гастрольләр вакытында башка республика, край, өлкә газеталарында басылган рецензияләрдә уңай бәя алдылар, Күчмә театрның зур казанышлары дип бәяләнделәр.

Әлбәттә, уңышлар җиңел генә килмәде. Мөхәммәт Хәмзингә төн йокыларын сарыф итеп баш ватарга да, төрле оешмаларга йөри-йөри нәрсәдер үтенергә, ялварырга да туры килде. Нишлисең бит, сәнгать мәшәкатьсез булмый. Аның каравы,

коллектив ныклап аякка басты. Шунысы олы куаныч — хәзер ул тупланган, бердәм көч, олы таләпләр алдында да югалып калмаска сәләтле. Аның бүген горурланып телгә алырдай спектакльләре, үзе тәрбияләп үстергән күренекле культура эшлеклеләре, артистлары бар. РСФСРның атказанган артисткасы Вера Минкина, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Кәшифә Тумашева һәм Татарстанның халык артисткасы Зәкия Туишева, Татарстанның атказанган артисткасы Бибинур Галиуллина, Татарстанның атказанган культура работнигы Сәет Шәкүров, сәхнә ветераннары Газиз Гыйматов, Зәйтүнә Хәлиуллина, Фәридун Юнысов, Мәнирә Шаһидуллина, Фердинанд Фарсин һәм башкаларның чын иҗат эшчәнлеге нәкъ менә шушында, Республика күчмә театрында башланды дисәк, һич ялгышмабыз. Аларның һәркайсы үзләре белән кулга-кул тотынып эшләгән олы җанлы дусларын — Татарстанның атказанган артисты Мөхәммәт Хәмзинне, аның соклангыч оештыру сәләтен һәр вакыт олы ихтирам белән искә алалар, аңа киңәш итәләр, аннан ярдәм сорыйлар.

Үзе киң күңелле, тиз аралашучан булгангамы, гомер буе аңа яхшы кешеләр генә очрап торды шикелле. Әле сәнгать дөньясына беренче адымнарын гына атлаганда ук язмыш аны татар культурасының күренекле вәкилләре Салих Сәйдәшев, Кәрим Тинчурин, Ситдыйк Айдаров белән таныштырды. Лаеш якларындагы Янтык дигән авылдан Казанга артистлык һөнәрен өйрәнергә килгән иде Мөхәммәт ул вакыт. Академия театры каршындагы студиядә укып та йөрде — укытучылары аның моңлы тавышына, музыка кораллары бер тотып карауда көй чыгара алуына сокланганнар иде. Ләкин егет, вакыйгалар агышын тизләтергә теләпме, бер елдан соң Уфа сәнгать техникумының турыдан-туры өченче курсына китеп барды. Аны яхшы билгеләренә генә тәмамлап, Хаҗи Бохерский җитәкчелегендәге Авыргазы районы



*Башкорт драматургы Д. Юлтыйның «Карагол» спектакленнән күренеш. Карагол — М. Хәмзин.*

колхоз-совхоз театрында эшләде. Аннан тагын Казан... Бу юлы инде ул музыка училищесын сайлады. Ә 1939 елда аны Идел буе хәрби округының яңа гына оештырылган җыр һәм бию ансамбленә солист итеп алдылар. Һәр борылышында сөенече дә, көенече дә сагалап торган авыр һәм мактаулы иҗат юлы әнә шулай башланды.

Авыл малае... студент... җырчы... драма артисты... Республика күчмә театры җитәкчесе. Бу — аның тормыш баскычлары. Аларда никадәр якты хатирәләр, тырыш хезмәт белән үткән онытылмас көннәр. Әнә шуңа күрәдер инде хезмәтенә күрә хөрмәтен дә кызганмадылар Мөхәммәт агадан. Совет сәнгатен үстерүдәге тырышлыгы, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә актив катнашканы һәм культура учреждениеләрендә күп еллар буе нәтиҗәле эшләгәне өчен ул «Почет билгесе» ордены һәм «Аеруча хезмәт күрсәткән өчен» медале белән бүләкләнде. 1960 елда аңа «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде. Ә иң мөһиме — үзенең якты, кешелекле таланты белән ул күпме тамашачының мәхәббәтен казанды, кешеләрдән рәхмәт сүзе ишетте.

Юк, язмышына үпкәли алмый Мөхәммәт ага — башкаларны сөендерә алуы белән генә дә ул үзен бәхетле санарга хаклы. Озын гомер юлы менә хәзер аларга таныш җыр кейләгән чуен юллар сыман тигез, сикәлтәсез булмаса да, мәгънәле үтелгән, матур эстәлекләр калдырган.

Купеларның берсе ачылды да коридорга олы яшьләрдәге бер ханым чыкты. Мөхәммәт ага, уйларыннан бүленеп, аңа борылып карады. Ә-ә, Мөнирә Шаһидуллина икән. Әйбәт артистка, театрда иң ихтирам ителгән кешеләрнең берсе. Яшьләр һәр вакыт аңа охшарга тырышалар.

— Нәрсә, Мөхәммәт абый, Казан сагындыра мәллә — иртә таңнан чыгып баскансың?

— Анысы да бардыр инде, Мөнирә... Менә юллар турында уйланып барам әле. Кеше гомерендә күпме юл үтелә бит.

— Әйе... байтак җыйналгандыр шул. Ә алда үтәселәре әле күпмедер...

Алар, хыялга бирелеп, тәгәрмәчләрнең таныш җырын тыңлап баралар. Кояш офыктан шактый югары күтәрелгән инде.

**Всеволод Остроумов,**
архитектор, Казан инженер-төзүчеләр институтының архитектура кафедрасы доценты

# XVIII—XIX ГАСЫРЛАРДА КАЗАНДА ТАТАР КОРЫЛМАЛАРЫ АРХИТЕКТУРАСЫ

Моннан йөз ел элек А. Герцен «Провинциядән хат»ында: «Казан ике башлангычлы, ягъни Европа-Азия шәһәре... Гомумән, Казанның әһәмияте бик зур, ул — ике дөньяның очрашу-көрешү урыны. Аның көнбатыш һәм көнчыгыш башлангычы булган икән,— ул башлангычны сез һәр чатта очратырсыз,— монда алар бер-берсенә өзлексез йогынты ясап дуслашканнар, ниндидер үзенә хас үзенчәлек төшкил итә башлаганнар»,— дип язган [1].

Татар культурасы, сәнгате һәм архитектурасы үзенең башлангычын урта гасыр чорыннан, Идел буе Болгар дәүләтеннән ала. Совет галимнәре А. Смирнов, П. Дульский, Б. Засыпкин, А. Башкиров, Н. Воробьев, архитекторлар Ф. Вәлиев, С. Айдаров болгар культурасының бер Казан татарларына гына йогынты ясамавын, бәлки Урта Идел буендагы башка халыклар — чуваш, мари, удмурт, мордва һ. б. белән дә бәйләнеше барлыгын дәлилләделәр. Тикшеренүчеләр әйтүенә караганда, болгар культурасы үзенең тарихи үсешендә акрынлап башта борынгы татар, аннан хәзерге татар культурасына күчә. Сакланып калган борынгы архитектура корылмалары һәм Болгарда, Биләрдә, Суварда, Юкәтауда үткәрелгән археологик казылмалар болгар культурасының борынгы Русь культурасы белән дә, Көнчыгыш культурасы белән дә бәйләнештә булуын раслыйлар. Идел буе болгарларының торак йортлары, борынгы шәһәр урыны, хәрби һәм культура корылмалары калдыкларына карап, без алар белән борынгы рус архитектурасы арасында да беркадәр уртаклык булуын күрәбез. Шулай ук Алтын Урда корылмаларына «Мамлюк Египты», Сирия һәм Әзербайҗан архитектураларының зур йогынтысы булуын да күрмәскә мөмкин түгел.

Болгар белән Көнчыгыш корылмалары арасында уртаклык бигрәк тә арка (көймәләп эшләү) системасында һәм аның колонналар белән бергә килүендә, дүртледән сигезлегә яки түгәрәккә күчү урыннарында үзенчәлекле «Мамлюк киселеше» булуда (Болгардагы Кечкенә манара, Никольский чиркәве һ. б.), манараларның тәбәнәклегендә, болгар корылмаларының гарәп тибындагы кайбер орнаментлар — яфрак сыман үрелгән чәлтәр, бау, жгут, мәңгелек төен, пальметта (пальма яфрагы төсле орнамент) белән бизәлүендә күренә [2].

Алтын Урда ханнарыннан Берке үткәргән исламлаштыру аркасында, Идел буе Болгар территориясендә гыйбадәт йортларын төзү тиз җәелеп китә. Нәкъ шушы чорда монголларга кадәрге заманда башланып киткән таш-кирпеч архитектурасы яңа көч белән үсә башлый. Тәрәзә һәм ишек уемнары, ук сыман яки филгә охшашлы форма

[1] А. И. Герцен. Письмо из провинции. Сб. соч. в 30 томах. Т. I. М. Изд. АН СССР. 1954.

[2] Ф. И. Валеев. Орнамент казанских татар. Казань. 1969. Стр. 15.

алып, үзенә бертөрле «кәнчыгыш барокко-сы» орнаменты белән бизәлә. Биналарны эшкәрткәндә ташка һәм гипс плиталәргә кисеп бизәк ясау, стеналарны керамика (майолик плиталәр) белән каплау киң рәвештә кулланыла. Дөрес, соңга таба керамика чикләнгән төстә кулланыла башлый.

Билгеле ки, XII гасырда болгар мастерлары һәм архитекторлары Владимир, Юрьев, Польский шәһәрләренә акташлы сарайлар салырга чакырыла, ул заманда бу якларга Болгар патшалыгыннан Идел һәм Кама ярларында табыла торган известьташ ташыганнар [1].

Күрсәтеп үтәргә кирәк: урта гасыр болгар һәм рус культурасы, архитектурасы үсеше өчен кайбер шартлар — климат, техник чаралар, төзү материаллары бертөсле булуга карамастан, ике халыкның яшәү рәвешенә һәм традицияләренә зур йогынты ясаган «кабилә һәм халыкара» экономик һәм политик элемтә, шулай ук христиан дине белән мөселман дине үз рольләрен уйнаганнар.

Архитектураның үсеше җәмгыять үсеше белән, теге яки бу халыкның көнкүреш һәм тормыш укладының тарихи һәм социаль-экономик шартлары белән тыгыз бәйләнгән.

XV—XVI йөзләрдә үк Казанда шактый зур таш корылмалар булган. Алар турында Иван Грозныйның якыннарыннан берсе — князь Андрей Курбский үзенең «Казан патшалыгы турында хикәя»сендә образлы итеп сөйли. Ул сигез манаралы мәчет, Казан Кремленең биек башнясы һәм башка таш корылмалар булуы турында әйтеп уза. 1560 елның хуҗалыкны статистик-экономик яктан исәпкә алу кенәгәсендә Казан ханы патшалыгы хуҗалыгында искиткеч таш пулатлар булуы искә алына.

Казан Кремле һәм хәзерге Татарстан территориясендә Н. Калинин һәм башка галимнәр тарафыннан үткәрелә торган археологик казылмалар татарларның XV—XVI йөзләрдә үк биналарны каплауда ташка һәм гипс плиталәргә кисеп бизәк ясау куллануын һәм аның киң таралуын раслыйлар. Шушы вакытта һәм шул ук максат белән, ләкин шактый ким күләмдә майолик керамика да кулланылган. Борынгы Болгар дәүләте архитектурасы памятникларын һәм шактый күп сакланган Казан ханлыгы чоры таш кабер өслекләрен тикшерү Идел болгарлары орнаменталь күренешенең Казан татарлары орнаментлары белән уртаклыгы барлыгын раслый. Ә профессор А. Смирнов, археология мәгълүматларына нигезләнеп, хәзерге Казан татарлары архитектурасының борынгы болгар төзелешләре һәм шәһәрләре каралтыларыннан башлап үсеп китүен раслый [2].

Архитектура да үзалдына аерымланган хәлдә үсмәгән, ул һәрвакыт башка халыкларның, шул җөмләдән рус халкының, җирле традицияләр йогынтысында булган. Бу йогынты, ягъни архитектураның ике — татар-рус башлангычы — очрашуы Казан ханлыгы буйсындырылганнан соң тагы да ныграк сизелә башлаган. XVIII йөздән башлап Казан памятниклары архитектурасында күбрәк өстенлек итүче архитектура стиле белән җирле милли традицияләрне чагылдырган халык сәнгатенең бергә кушылуы күзгә ташлана. Бу турыда В. Егоров түбәндәгеләрне әйтә: «Провинция корылмалары архитектурасы күренешләрендә төп ике, бер яктан, илнең дәүләт үзәгеннән килә, икенче яктан, бик зур халык массасы тарафыннан кертелә торган көч үзара очраша. Ике культура очрашкан заманда провинция шәһәрләрендә халык сәнгатенең төрле вариациядә урындагы шартларны чагылдырган профессиональ сәнгатьнең бергә кушылуы аеруча тиз барган. Шулай итеп, милли сәнгатьнең реалистик башлангычын формалаштыруда провинция шәһәрләре көчле лаборатория ролен үтәгәннәр» [3].

Рус архитектурасы һәм сәнгате белән күп гасырлар буена үзара тыгыз элемтәдә булган татар халык архитектурасы һәм сәнгатенең үзенә генә хас милли колорит һәм мотивларны саклый торган алымнары һәм чаралары була.

XVIII йөзнең икенче яртысында Казан архитектурасында гыйбадәтханә һәм башка биналарның гөмбәзләрен, түшәмнәрен һәм стеналарын сылап ясалган орнамент белән бизәү зур урын ала. Бу бизәүләр рус провинциаль «барокко»сы белән чәчәк-үсемлек характерындагы татар орнаментының бергә кушылуын хәтерләтә [4].

---

[1] В. Н. Татищев. История Российская с самых древних времен. 1774. Стр. 79; В. П. Доброхотов. Древний Боглюбов город. 1852. Стр. 70.

[2] А. П. Смирнов. Волжские булгары. М. 1951. Стр. 78.

[3] В. В. Егоров. Казанские архитекторы XVIII—XIX вв. КИСИ. 1956.

[4] Ф. И. Валеев. Орнамент казанских татар. Казань. Таткнигоиздат. 1959. Стр. 16.

Үатар сәүдәгәрләре рус хәлләләреннән калышмаска тырышалар, хәтта үз корылмалары төзелешендә рус бароккосы юнәлешендәге стильләрдән файдаланалар. Шулай да төзүчеләр архитектураның аерым өлешләрендә милли орнамент мотивларын киң рәвештә кулланалар.

XVIII—XIX йөзләрдәге Казан мәчетләре архитектурасы да игътибарны үзенә җәлеп итә. Гәрчә алар гыйбадәтханәләр булса да, аларга карап, син алла, муллалар һәм мәзиннәр турында түгел, бәлки шушы сәнгать памятникларын иҗат иткән кешеләр, нык һәм күп гасырларга сакланырлык «таш елъязмалар»ны тудырган талантлы халык осталары турында уйланасың.

Казанда Мәрҗани мәчете (К. Насыйри урамы, 17 нче йорт) 1766 елда татар сәүдәгәрләре Мортаза Йосыф улы, Әбүбәкер Ибраһим улы, Исхак Измаил улы һәм атасының исеме билгесез Якуб акчасына салына. Таш мәчетне 82 эшче төзи, чама белән төзелеш 5 мең сумга төшә.

Бина үзе дә, көньяк ягына чыгып торган янкорма — михраб та туры почмаклы. Ул ике катлы: икенче катта — мәчет үзе, беренче катта ярдәмче бүлмәләр, келәт урнашкан. Икенче катның стеналарында стильләштерелгән коринфа капителе белән тәмамланган пилястрлары — бер ягы белән стенага кереп торган дүрт кырлы колонналары бар. Тәрәзә уемнары ярым көймә сыман арка, бик нык өскә сузылган тәрәзә йөзлекләре белән әйләндереп алынган. Беренче катның тоташ стеналарыннан пилястрларның аскы өлеше башлана, алар арасында берничә бик тәбәнәк тәрәзә эшләнгән. Мәчетнең түбәсе дүрт кыеклы, аның өстеннән сигез кырлы манара күтәрелә. Аның өске өлешенә зур булмаган түгәрәк мәйданчык эшләнгән. Ул мәзиннең азан әйтү урыны булган. Бина туп-туры көньякка — Мәккәгә карый, мәчеткә аның төньяк ягыннан керелә. Ишегалды кечерәк ике манарасы һәм капкалары булган таш койма белән әйләндереп алынган. Бинаны бизәкләү архитектурасында рус бароккосы гомуми фонында милли колоритның ачык сизелеп торуын күрсәтеп үтү кызыклы. Тышкы пилястрларның коринфа капительләренә һәм бинаның эчке өлешендәге гөмбәзләренә өстәмә рәвештә лалә чәчәге бизәкләре эшләнгән. Бу мотив татар орнаментында киң җәелгән һәм лалә чәчәге урынына яфраклар белән әйләндереп алу гадәткә кергән рус бароккосыннан аерылып тора.

Мәчетнең авторлыгын В. Егоровның архитектор В. Кафтыревка кайтарып калдыруы нигезсез түгел[1]. В. Кафтыревның Мәскәүдә берничә ел «танылган архитектор Ухтомский командасында» эшләве билгеле. Ул команда бетерелгәч, В. Кафтырев 1763 елда Казанга килә. Мәчетнең архитектура үзенчәлекләренә анализ ясаганнан соң, анда милли мотивлар булуын күрү һәм, шуларга нигезләнеп, аны төзүдә татар мастерлары катнашуын раслау кыенлык тудырмый. Шул ук вакытта бинаның бизәлешендә үзенчәлекле барка «Кафтырев детальләре»н дә күрәбез: стеналарны пилястрлы итеп эшләү, почмакларны пилястр белән ныгыту, тәрәзәләргә зиннәтле йөзлекләр кую. Боларның барысын да В. Кафтырев башка биналарны (К. Маркс урамы, 17 нче йорт, хәзерге 7 нче номерлы шәһәр больницасы һ. б.) бизәүдә киң куллана.

Мәрҗани мәчете белән янәшә дип әйтерлек, XVIII йөзнең иң азагында Апанаев мәчете (К. Насыйри урамы, 29 нчы йорт) салынган. Сакланып калган иске документ раславынча, бу мәчетне төзү белән Мәскәүдән килгән, әмма исеме билгесез калган архитектор җитәкчелек иткән. Ике катлы бу таш бина да туры почмаклы, шулай ук аның көньягында чыгып торган янкормасы — михрабы бар. Бина матур итеп эшләнгән манара белән тәгәлләнә. Бинаның тышкы күренеше милли бизәкләү элементлары да булган барокко стиленә якын. Бинаның алгы ягын пилястрлар, сырланган кәрниз бизи. Мәчетнең интерьеры (бинаның эчке күренеше) бик үзенчәлекле. Гөмбәз сыман түшәм капламы сәнгатьчә бай итеп бизәлгән, мичләре ялтыравыклы керамик кафель белән капланган. XIX йөзнең беренче чирекләрендә губерна архитекторы А. Шмидт проекты буенча Екатерининский урамында (хәзерге Тукай урамындагы 40 нчы йорт — манарасыз хәлдә сакланган) һәм Яңа бистәдә (хәзерге М. Гафури урамы, 34 а номерлы йорт) мәчетләр төзелә.

Тукай урамындагы мәчетнең тышкы архитектура бизәлеше белән шул архитектор төзегән Ягодный бистәсендәге Свешников бинасы (Гладилов урамы, 22 нче йорт) ара-

[1] В. В. Егоров. Казанские архитекторы XVIII—XIX вв. Докторская диссертация. КИСИ, 1956.

сында уртаклык бар. Тәрәзә өсләренә ясалган көймә сыман куышлардагы сандрик нурлар аеруча үзенчәлекле детальләрдән санала. Формасы ягыннан бина туры почмаклы. Мәчетнең төньяк ягында сигез кырлы нигезгә цилиндр рәвешендәге бик матур манара урнашкан. Өстәрәк аны коелган челтәрле тимер рәшәткәле мәйданчык әйләндереп алган. Манара алтынланган шпиль һәм аңа беркетелгән шар, урак сыман ай белән тәгәлләнә.

Яңа бистә мәчетен А. Шмидт бөтенләй башкача хәл итә: бинаның стеналарын каткат итеп урнаштырылган калаклар белән бизи, икенче катның тәрәзә өслекләре сылап эшләнгән детальләр, гади кәрниз туры почмаклы тешләр белән ясалган. Турыдан-туры түбәдән калкып чыккан манараның архитектурасы да үзенчәлекле: дүрт кырлы нигезенә таба тарая барган өч цилиндр урнаштырылган, аларның өсләре гади кыршау белән әйләндереп алынган, астагы ике цилиндр өстенә көймәле уемнар, өстәгесенә куышлар ясалган. Манара тәбәнәгрәк шпиль, шар һәм ай белән тәгәлләнә. Бинаның архитектурасы гражданлык төзелешләренә якын, бары тик манарасы гына аерылып тора.

А. Шмидт урындагы милли архитектура үзенчәлекләрен бик игътибар белән өйрәнә. 1826 елда ул Казан губернасындагы барлык борынгы корылмаларны исәпкә алып, беренче тапкыр Идел болгарлары архитектурасын тикшерә, аларның зурлыгын үлчи.

1832 елда «1827 нче елда архитектор А. Шмидт тарафыннан натурадан төшерелгән борынгы Болгар хәрабәләре архитектура сызымнары» исемле кызыклы альбом төзелгән һәм басылып чыккан. Хәзер бу альбом — сирәк очрый торган библиографик материал булып санала. Йөз елдан артык вакыт эчендә Идел болгарлары борынгы корылмалары тагы да җимерелә төшкән, кайберләре бөтенләй юкка чыккан. Шуларны реставрацияләүдә яки яңадан торгызуда бу альбом хәзерге архитекторларга зур ярдәм итә.

Казандагы мәчетләрнең башкаларын төзү XIX йөзнең урталарына, XX йөзнең башларына туры килә. Андый мәчетләрнең берсе — үзенең элекке күренешен саклаган Азимов мәчете (Фәтхуллин урамы, 15 йорт). Бу бинаның эклектик формадагы бизәлешендә «мавритан стиле» өстенлек итә. Бина бер катлы, кызыл кирпечтән салынган. Мәчеткә керү урыны төньяк стенасыннан аерым торган манараның ике ягында стенага ук терәп ясалган ярым колонналы парадный ишек формасында. Тәрәзәләренең өске өлеше түгәрәкләп эшләнгән, үзенә бер төрле рамнар, үзенчәлекле тәрәзә йөзлекләре белән әйләндереп алынган. Алгы кәрниз калку һәм мул итеп ак таштан төрле детальләр белән бизәлгән. Манарасы аеруча матур булуы, мәһабәтлеге белән аерылып тора. Сигез кырлы нигездә валик формасында бизәлгән нечкә озын манара күккә менә. Өстә цилиндр ук сыман аркалар белән тәгәлләнә, аның өстенә кирпечтән бизәкләп кыршау эшләнгән, аннан ак таштан ясалган, челтәрле җиңел тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган азан әйтү мәйданчыгы башлана. Ул шулай ук ак таштан эшләнгән челтәрле кәрниз белән ныгытылган. Манара урак сыман айлы шактый биек шпиль белән очлана. Азимов мәчете архитектурасында эклетик элементлар булуга карамастан, ул төзелеш эшләренең сыйфаты, детальләренең сәнгатьчә эшләнеше һәм аныклыгы белән аерылып тора. Мәчет матур биек манарасы белән шәһәр силуэтын баета һәм XIX йөзнең икенче яртысы архитектурасының кызыклы бер истәлеге булып тора.

Болак арты һәм Кабан буйлары (хәзерге Нәриман, Тукай, Киров, Париж Коммунасы, Татарстан урамнары) революциягә кадәр татар районнары булган. Монда алар 1552 елгы вакыйгалардан соң күчерелгәннәр.

Сакланып калган легенда нигезендә монда, ягъни Кураишевода, «Патша болыны»нда атаклы Чакунның әтисе Оту князь тарафыннан мәчет төзелгән. Соңга таба «Патша болыны»ның бер өлеше Печән базары дип йөртелә башлый (Киров урамындагы бензин салу станциясе янындагы район). Печән базары — «Казан карыны» үзенчәлекле көнчыгыш колоритына ия булган шәһәрнең атаклы урыннарыннан берсе була. Базарда бөтен шәһәр яңалыкларын һәм тузга язмаган хәбәрләрне ишетергә мөмкин булган. Кечкенә кибетләрдә, түбә астындагы озын эскәмияләрдә яки җиргә тезеп куйган хәлдә милли аяк киемнәре, кием-салым, баш киемнәре, ювелир әйберләр һәм төрле көнчыгыш халыкларының татлы ашамлыклары белән сату иткәннәр. Монда терлек, солы һәм печән сатылган. Базарда, иртәдән алып караңгы төшкәнгәчә, төрле төстәге чуар халык массасы гөж килә. Тавыш, шау-шу, сатучыларның чакыру та-

вышларыннан базарда сатучылар товар алучыларга караганда күбрәк төсле тоела. Бу базардан якын гына Болгар номерларында яшәгән татар халык шагыйре Габдулла Тукай үзенең «Печән базары яхут яңа Кисекбаш» поэмасында, XII йөздәге Кисекбаш легендасының сюжет һәм формасын файдаланып, Печән базары образында татар муллаларының, сәүдәгәрләренең һәм башка байларның наданлыгын, тинтәклеген, саранлыгын, төрле хорафатларга ышануын һәм масаюларын камчылый. Печән базарында һәм аның әйләнә-тирәсендә таш биналы постоялый дворлар, тәбәнәк лапаслар, сәүдә кибетләре төзелә. Ул биналарның байтагы хәзер дә саклана: тоташ кирпеч стена белән әйләндереп алынган, тимер рәшәткә куелган кечкенә генә тәрәзәле яки бөтенләй тәрәзәсез калын стеналар, гөмбәз сыман авыр түбә, эчке яктан калын бикләре белән тимердән коеп эшләнгән ишекләр.

Легенда раславынча, кайчандыр «Патша болыны» булган урында — Печән базарында җирле архитектор А. Песке тарафыннан XIX йөзнең урталарында агач мәчет урынына таш мәчет корылган. (Киров урамы, 74 нче йорт.) Бинасы — ике катлы, астына мәчеткә керү ишеге ясалган. Манарасы (соңгы йөзнең утызынчы елларында сүтелгән) аерым торган. Бина үзе туры почмаклы, югарыда түгәрәк барабан формасындагы нигезле зур гөмбәз. Мәчетнең ике ягыннан тәрәзә уемнары ук сыман итеп эшләнгән сәүдә бина̀лары төзелеп киткән. Бинаның алгы өлешен һәм манараны бизәүдә рус, җирле татар һәм көнчыгыш мотивлары файдаланылган. Сакланып калган фотография һәм сызымнарга нигезләнеп, архитектор С. Айдаров мәчетне реставрацияләү проектын эшләде. Аның тарафыннан Казаков мәчетен (Гражданский урамы, 2 нче йорт) реставрацияләү проекты да башкарылган. Бу мәчет 1876 елда «потомственный гражданин» хаҗи Назир улы Мөхәммәтҗан Казаков акчасына төзелгән.

Безнең гасырның 20 нче елларында — НЭП заманында инженер Печников тарафыннан Кабан арты мәчете (һ. Такташ урамы, 26 нчы йорт) корылган. Бик тузган иске агач мәчет урынына салынганга, аны Иске мәчет дип атаганнар. Бинаның архитектурасы бик күп төрле геометрик сызык-детальләре файдаланылган саф модерн рухында башкарылган.

Мәчетләрдән башка шәһәрдә халле кешеләрнең, бай татар сәүдәгәрләренең торак биналары сакланган. Бу биналар җирле милли архитектура традицияләре нигезендә эшләнгән. Аларның күпчелеге XIX йөздә төзелгән, тышкы күренешләре буенча аларның татар авылларындагы хәлле крестьян йортлары белән байтак охшашлыгы бар. Болар — күбрәк бурап салынган ике катлы биналар, еш кына беренче каты — таш, икенчесе — агачтан төзелгән була. Архитектура бизәкләве ягыннан аларның төп үзенчәлеге ук яки киль сыман фронтонында, пилястр һәм кырып эшләнгән түгәрәк рәшәткәләрдә, шулай ук йортларның чиста яшел, зәңгәр, ак һәм сары төстәге куе буяулар белән юллыюллы итеп буялуында да. Шәһәр буржуйларының кайбер йортларын алгы як түбә куышлыгын чәчәкләрдән ясалган зиннәтле букет формасында «тормыш агачы» стилендә бизәкләү кулланылган. Болар барысы йортларга үзенә бертөрле милли колорит биргән.

Шулай ук агачка кисеп бизәк ясау, төрле кабарынкылар кертү ысулы белән агач өсләрен фактуралау киң таралган. Бөтен стеналар, кәрниз, тәрәзә йөзлекләре һәм капкачлары, баганалар, капка һәм коймалар агачка кисеп ясалган бизәкләр белән бизәлә. Алгы якны бизәүдә Казан татарлары орнаменты мотивлары өстенлек ала.

Каюм Насыйри урамы әле хәзергәчә үзенең татарлар яшәгән шәһәр районы булуының кайбер үзенчәлекләрен саклый. Монда сәүдәгәрләр яшәгән, шуңа күрә барысы да аларның таләпләренә һәм зәвыкларына буйсындырылган. Хәзергәчә сакланган йортларда күбесенең аскы каты — коймәләп эшләнгән калын түшәмле таш стеналар. Алар гадәттә лабаз һәм склад итеп файдаланылганнар. Өске катлары — агач, торак йортлары. Бер яртысында — хуҗалар яши торган тору бүлмәләре, монда бөтенесе аларның милли тормыш рәвешләренә һәм көнкүреш таләпләренә туры килә. Икенче яртысы исә рәсми рәвештә кунакларны кабул итү бүлмәсе булып саналган. Монда инде һәммәсе сәүдәгәр хуҗаның зәвыгына һәм модага буйсындырылган. К. Насыйри урамындагы 11 нче йорт — үзенең архитектура күренеше белән шул заманның типик мисалларыннан берсе. Җирле милли мотивлар орнаментлап бизәлгән фронтонда, бертөсле куе буяуда чагыла. Йорт койма белән әйләндереп алынган, капкасы бизәлгән.

Бу районның үзенчәлекле төзелешләре

фонында бай сәүдәгәрләрдән Апанаев (Тукай урамы, 67), Хөсәенов (К. Насыйри урамы, Кабан күленә каратып салынган) йортлары аерылып тора һәм алар үзләренең милли орнаментка бай булулары белән җәлеп итәләр. Өйдән тыш, сәүдәгәрләргә ишегалдында зур ярдәмче каралтылар, келәтләр һәм өй белән аларны тоташтыра торган ябык коридор эшләргә, зур-зур үлчәүләр куярга кирәк була. Еш кына таза тормышлы шәһәр кешеләре икенче кат биеклегендәге күрше йортлар белән тоташтыра торган галерея белән мавыкканнар (К. Насыйри урамы, 5 нче йорт).

Балконнар, фронтоннар, болдырлар, киң террасалар иң яраткан архитектура элементлары була. Иң киң таралган төсләрдән кызыл, сары, шәмәхә, яшел, зәңгәр төс санала. Шундый төстәге пыялалар аша төшкән кояш нурлары бүлмәләрне гадәттән тыш матур күренешле итә.

Татар йортлары бүлмәләре эчке күренешенең характерлы үзенчәлегеннән берсе — кафель белән капланган мич. Орнаментлы кафельләр Казан заводларында ясалган һәм аларга ихтыяҗ күп булган. Шундый мичләр, мәсәлән, Зур Мещан (хәзерге Нәриман) урамындагы Сәйдәшев һәм Болактагы Сәйфуллиннар йортында була.

Казан архитектурасында яңа агым — эклектика һәм модерн барлыкка килгәч, XIX йөзнең икенче яртысында атаклы татар буржуйларының үзалдына аерылып торган йортлары төзелә башлый. Бу чорда биналарның тышкы күренешенә чын мәгънәсендә татар милли архитектурасы үзенчәлекләрен биругә күп омтылыш ясала, әмма ул көтелгән нәтиҗәне бирмәгән. Архитектор Амонг шундый типик буржуаз йортны — Шамил өен (Тукай урамы, 74 нче йорт) эклетик формадагы феодал архитектура стилендә төзи. Аның татар милли архитектурасы белән бернинди уртаклыгы булмый. Шул ук чорда төзелгән икенче ярым йорт (хәзерге Киров урамындагы 42 нче йорт) төрле көнчыгыш стильләреннән алынган архитектура элементлары белән бик бай итеп бизәлгән. Бу йорт та татар милли архитектурасыннан бик ерак тора. Шулай да детальләренең бик җентекләп эшләнүе һәм бизәкләү эшләренең яхшы сыйфатлы булуы аркасында бинаның күркәмлеген әйтеп узарга кирәк.

Капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсеше биналар архитектурасыннан татар халкының практик сәнгате үзенчәлекләрен кысрыклый башлый, әмма яңа төзү материаллары һәм конструкцияләр куллану ул заман архитектурасы өчен прогрессив күренеш була.

Безнең илебез күп милләтле, кардәш социалистик республикалар Союзына кергән һәр халык күп гасырлар дәвамында үзенең сәнгать хәзинәсен туплаган. Халык иҗаты, көнкүреш тарихы, үткән заман тормышы памятниклары сыйфатында аларны саклау һәм карау — совет кешеләренең изге бурычы. Архитектураның иске искиткеч гүзәл әсәрләре Ватанга мәхәббәт, үз халкының бөек узганына ихтирам тәрбияли, ә аларны өйрәнү хәзерге яңаны төзергә ярдәм итә торган белемнәр белән баета. Яңа сәнгать бөтенләй буш урында барлыкка килми, бәлки үткән заман сәнгать иҗатының гаять бай традицияләренең иң яхшыларын үзенә ала: традиция һәм новаторлыктан башка чын мәгънәсендә сәнгать була алмый.

Фәрит Хатипов

# ПРОЗАБЫЗДАГЫ ПСИХОЛОГИЗМ ТУРЫНДА

Үзенең бер хезмәтендә В. И. Ленин, матур әдәбият әсәрләрен күздә тотып: «Биредә бөтен хикмәт индивидуаль обстановкада, әсәрдә бирелгән типларның характерларын һәм психикасын анализлауда»[1],— дип язган иде. Аның бу сүзләреннән күренгәнчә, әдәби әсәрләрдә характерларның психикасын анализлау — индивидуальлекнең мөһим бер күрсәткече һәм шул ук вакытта типиклыкка ирешүнең әһәмиятле шарты итеп тә карала.

Бөек революцион-демократ Н. Г. Чернышевский да әдәби әсәрләрдә геройларның «күңел диалектикасы»на зур игътибар бирде. Бу турыда сөйләгәндә ул беренче нәүбәттә персонажның киеренке уй-хисләр агышын, шуларның катлаулы диалектикасын тасвирлауны күздә тотты. Менә аның бөек психолог Толстой турындагы фикере: «Граф Толстойның игътибары барыннан да бигрәк хисләрнең һәм фикерләрнең агышына, хәрәкәтенә юнәлгән»[2].

Шулай итеп, югарыда китерелгән фикерләрдә без әдәби әсәрдәге психологизм турында сүз барганлыгын аңлыйбыз. Ә конкретрак якын килгәндә, психологик әсәрнең үзенчәлекләре нидән гыйбарәт соң?

Сурәтләү предметы ягыннан психологик проза белән лирика арасында беркадәр уртаклык бар. Һәр икесе дә рухи халәтне чагылдыра. Аерма тик динамика характерында. Лирик әсәр уй-хисләр тезмәсенең тик бер генә буынын, бер генә күзәнәген алып сурәтләсә, психологик проза аны агымда, хәрәкәттә чагылдыра. Биредә уй-хисләр, бер-берсенә ялганып, процесс тудыралар.

Психологизм сюжет структурасына да сизелерлек яңалык алып килә: биредә хәл-вакыйгаларга кысыла төшәргә, уй-хисләр агымына урын бирергә туры килә. Безгә билгеле булганча, Флобер хәтта тышкы күренешләрне бөтенләй кысрыклап чыгарып, тик күңел хәрәкәтенә генә монополия бирү хакында да хыялланган. «Минем бернәрсә турында да булмаган китап язасым килә,— ди ул бер хатында.— Һавада җир берниндн тераүсез торган кебек, берниндн тышкы таянусыз, үзеннән-үзе, тик үз стиленең эчке көче белән генә эленеп торырдай китап, бөтенләй диярлек сюжетсыз, яки, һәрхәлдә, сюжеты күренмәстәй диярлек китап язасым килә, ул миңа гүзәл булыр сыман тоела. Сәнгать үскән саен эфирлырак төс ала барачак»[1].

Ләкин әдәбият практикасы мондый күрәзәлекне расламады. Чөнки психиканы тирәлектән, тышкы дөньядан аеру чынбарлыктагы табигый бәйләнешне өзүгә китерер иде. Стендаль, Бальзак, Диккенс, Флобер, Теккерей, Мопассан, Достоевский, Л. Толстой, М. Шолохов, Ә. Еникиләрнең иң яхшы әсәрләре сюжетында хәл-вакыйгалар белән уй-хисләр агымы аралашып

[1] В. И. Ленин. Полное собрание сочинений. Т. 49. Стр. 57.
[2] Н. Г. Чернышевский. Полное собрание сочинений. Т. 3. М. ГИХЛ. 1947. Стр. 422.

[1] Густав Флобер. Письма. 1831—1854. М.—Л. 1933. Стр. 229—230.

урнаша, хәрәкәтчәнлекне тудыруга вакыйгалар да, тойгы-фикерләр дә бердәй катнаша.

## I

Бездә психологик прозаның күренекле остасы дип хаклы рәвештә Әмирхан Еники санала. Ул кеше күңеленең утә йомшак тибрәнешләрен, уй-хисләр агышын, бормалы юлларын, тышкы сәбәпләр йогынтысында туган кискен борылышларын, рухи дөньяның үз эчендә бара торган драматик көрәш-бәрелешләрне үзенә бер төрле зирәклек белән тоеп, сизеп тора. Әдип катлаулы чынбарлыкны гүя ки эчке яктан яктырта, аның кеше психологиясендә чагылышын күрсәтә. Кайберәүләр аның иҗатын музыкага, уен коралларының тагы — скрипка моңына тиңлиләр. Бу, билгеле, тиккә генә түгел. Музыка, лирика шикелле үк, Ә. Еники дә кешенең рухи халәтен, моңын, настроениесен, хыяломтылышларын, уй-кичерешләрен зур пөхтәлек белән рәсемләп бирә. Шуңа күрә аның әсәрләрен матур көй тыңлаган кебек укыйсың, соңыннан музыка колакта яңгырап торган кебек, Еники әсәрләренең моңы да күңелгә йогып кала. Талантлы художник соңгы утыз еллар эчендә иҗат иткән әсәрләре белән безнең прозада үзенә бер төрле мәктәп тудырды.

«Аның әсәрләре, сахра елгасы кебек, ашыкмый гына, талгын гына ага — сюжет җепләре күренер-күренмәслек кенә үреләә, әмма ул җепнең берсен дә суырып алып булмый — югыйсә, бауның сүтелүе мөмкин»,— дип яза Ибраһим Абдуллин «Коралдашым-сабандашым турында» дигән мәкаләсендә[1]. Чыннан да, Ә. Еники үзенең хикәя-повестьларында маҗаралы, кискен борылышлы, җитез хәрәкәтле, эффектлы вакыйгалар белән мавыкмый. Еш кына ул утә гади, гадәти, ләкин шуның белән бергә бик кешелекле, тирән мәгънәле, кешеләргә якын-кадерле хәл-вакыйгаларны ала да, шуларның хәрәкәте дәвамында, шуларга бәйле рәвештә үк кеше күңеленең моңарчы без белмәгән якларын чигеп-рәсемләп бирә. Менә аның «Матурлык» хикәясе. Карап торуга бер дә алай искитәрлек нәрсә юк. Җәйге ялга кайтышлый шәкертләр Бәдретдиннәрдә тукталып, чәй эчеп чыгалар. Ләкин шушы гади күренеш аркылы әдип никадәр тирән хисләрне сөйләп, хикәяләп бирә. «Матурлык» дигәч тә, зиннәтле пулатлар да, чибәр туташлар да тасвирланмый монда. Киресенчә, соң чиккә җиткән ярлылык, шәкерт әнисенең рәхимсез чәчәктән ямьсезләнеп калган йөзе сурәтләнә. Матурлык исә икенче нәрсәдә — ана белән баланың бер-берсен өзелеп яратуында, беткәнче аңлау, кадерләү, юатуларында. Хикәянең тар рамкасында Ә. Еники әнә шундый олы, гуманистик якты хисне зур шагыйрьләргә тиң художество көче белән бирә алган.

Яки менә алып карагыз «Туган туфрак» сюжетын: шәһәр кызы Клара бабасының туган-үскән якларын, гомер иткән нигезен барып күрә. Һәрбер авыл кешесенә таныш картиналар. Ләкин шул уңай белән Клара күңелендә туган хисләрне, яңа, тансык тойгыларны без Ә. Еники хикәяләрендә генә очратабыз. Дөресен әйткәндә, хикәядә без әнә шул хисләр агымына ияреп, мавыгып барабыз.

Хикәянең башында мондый деталь бирелә. «Ничек кенә булмасын, бабасының «туган туфрак» дигәнен Клара ихтыярсыздан элек үзе барып йөргән әнә шул Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләре белән бер төсләрәк итеп күрә иде»[1],— ди Ә. Еники. Ягъни «туган туфрак» дип йөртелә торган бик тирән мәгънәле абстракт төшенчәне Кларaның тар, конкрет мәгънәдә аңлаганлыгы күренә. Әмма, поездадан төшеп, авыл туфрагына басу белән бик якын итеп, якты йөз белән каршылаган туганнарын, авыл кешеләрен күргәч, аларның җыр әйткәндәй көйләбрәк «канатым», «якты күзем», «иркәм», «күз нурым», «иркә туташ», «бәбкәм», «ике күзем», «аккошым» дип ягымлы эндәшүләрен ишеткәч, табигатькә якын җирдә генә була торган шигърият белән танышкач, ул бу төшенчәнең бик тирән эчтәлекле булуын, туган туфракның җанга якын, газиз икәнлеген аңлый. Әсәрдә әнә шул яңа аңхиснең нинди күренешләр тәэсирендә тууы сурәтләнә. Икенче төрле әйткәндә, автор авылны, авыл кешеләрен тасвирлаудан да бигрәк, аларның Клара күңелендә нинди хисләр уятуын яктырта.

Гомумән, психологизмның иҗтимагыйполитик тирәлек белән кушылуы, уйхисләрнең фәлсәфи яңгыраш алуы Ә. Еники әсәрләренә («Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз

[1] Әмирхан Еники. Йөрәк сере. Өфе. Башкортстан китап нәшрияты. 1963. 3 бит.

[1] Әмирхан Еники. Сайланма әсәрләр. 2 том. К. 1971. 195 бит.

чәчәге», «Әйтелмәгән васыять» һ. б.) хас күренеш. «Әйтелмәгән васыять» тирәсендә байтак шау-шулар булып алды. Кайбер иптәшләр шул уңай белән үз хыялларында әрәк ясап куйдылар да, үзләре үк шуннан әркеп калдылар. Асылда исә хикәядә бик кешелекле, җитди, мөһим теләк-фикерләр тасвирлана. Иң әүвәл шунысына игътибар итик: әсәрнең баш герое Акъәби — гомере буена хәләл көче белән кән күреп яшәгән киң күңелле хезмәт кешесе, ягъни зур хөрмәткә лаеклы, җәмгыятьнең төп терәгән тәшкил итүчеләрнең берсе. Хикәядә әнә шуның уй-фикерләре, яшь буынга әйтеп калдырасы теләкләре сурәтләнә. Озын тормыш юлы үтеп зур тәҗрибә туплаган, башкорт халкының акыл-зиһенен үзенә сеңдергән, илгә күп белгечләр үстереп биргән, социаль казанышларның бөеклеген-зурлыгын тирән тоючы, моның өчен ихлас горурланып яшәүче ана күңелендә шәхси рәхәтлек дәгъва итү кебек индивидуалистик омтылышларның эзе дә юк, ул җәмгыять тормышының нигезләрен тәшкил иткән мәсьәләләр хакында, ил булып яшәүче халык, аның туган җире, рухи байлыклары турында уйлана. Шушы бик кадерле, якын, изге нәрсәләргә — ата-бабалар җиренә, тәрбияләп үстергән халкына, туган теленә, хезмәт, яшәү рәвеше белән бәйле рәвештә барлыкка килгән гореф-гадәтләренә, культура байлыкларына мәхәббәт тәрбияләргә тели, яшь буынга шул хакта васыять әйтеп калдырмакчы була. Ул халык тормышын рухи тәссезләндерүдән сак булырга өнди, киләчәк буыннар тормышын тагын да матуррак итеп күрергә тели.

Фәлсәфи тирәнлек, сурәтләнгән хисләрнең эстетик тәэсире җәһәтеннән «Тауларга карап» хикәясе Ә. Еники әсәрләре арасында да беркадәр үзенчәлеклерәк урын алып тора булса кирәк. Олы художникларга хас булганча, Ә. Еники монда катлаулы, драматик киеренке тойгы-кичерешләр гаммасын, геройның хәят-яшәеш турындагы тынгысыз уйларын тасвирлый. Табигатьнең бар камиллеге, зирәклеге, күп төрле бәйләнешләре тормышның мәңгелеген тәэмин итү максатына буйсындырылган. Өзеклек аркылы өзлексезлек, дәвамлылык, мәңгелек барлыкка килә.

Ике герман сугышы Локман карт нәселенең җаннан газиз ике кешесен — улы белән оныгын чәчәктәй гүзәл чагында тартып ала. Нәселнең өзелеп калу куркынычы бөтен реальлеге белән алга килеп баса. Ләкин шулай да, автор сурәтләвенчә, үлемгә караганда үлемсезлек, мәхәббәт көчлерәк булып чыга. Локман картлар өенә оныкның фронтта кушылган хатыны белән баласы килеп төшә. Шушы нарасый Локман картларның ике буыны өзелеп калган нәселен кабат ялгап, тергезеп җибәрә. Шулай итеп, гәрчә әсәр шәфкатьсез сугыш корбаннары турында язылса да, ахыр чиктә тормышның, яшәүнең мәңгелеген раслый.

Ә. Еники кешеләр мөнәсәбәтләренең һәм язмышының эчке, психологик тирәнлекләренә үтеп кереп, шул тирәнлектә яткан драматизмны үзенчә бер осталык һәм тәгәллек белән ачып бирә белә. Аның повестьларының («Рәхмәт, иптәшләр!», «Йөрәк сере», «Саз чәчәге», «Рәшә», «Вөҗдан») психологик сюжетында күңел хәрәкәте тагын да дәвамлырак рәвештә тәсмерләнә. Аның «Рәхмәт, иптәшләр!» повестенда, мәсәлән, иптәшләрчә тәнкыйть-киңәшләр йогынтысында ферма мөдире Нургали күңелендә уй-хисләр өермәсе кубуы, аның рухи дөньясына сизелерлек яңалык өстәлүе, геройның үзен һәм кешеләрне, аларның эш-әхвәлләрен, тирәюньне, тормышны яңача күрә һәм таный башлавы тасвирлана, шуларга бәйле рәвештә мөһим иҗтимагый проблемалар, дәүләт күләмендә хәл ителәсе мәсьәләләр күтәрелә. Автор шул ук вакытта психологик процессның гел алай туры сызык буенча гына бармавын, дөньяның үзе кебек үк, шактый катлаулы, каршылыклы һәм газаплы-шатлыклы булуын да басым ясап күрсәтә.

Бездә күренекле проза әсәрләрен психологизм ноктасыннан карап тикшерү гадәткә кермәгән. Нилектән бу? Уй-тойгылар әллә роман-повестьлардан бөтенләй төшеп, читтә торып калганнармы? Ләкин бит «Намус», «Җәяүле кеше сукмагы», «Сүнмәс утлар», «Онытылмас еллар», «Әтил суы ака торур» һәм башкалар киеренке кичерешләр, тынгысыз уйлар белән тулы әсәрләр.

Тикшерү шуны күрсәтә: боларда, чыннан да, Стерн, Достоевский, Толстой романнарындагыдай күңел хәрәкәте тоташ агым булып бармый диярлек. Композициянең шактый зур өлешен тышкы хәлләр тезмәсе алып тора. Ләкин моңа карап кына әле рухи дөнья язучылар игътибарыннан бөтенләй төшеп калган дип булмый.

Г. Бәширов һәм башка кайбер язучылар,

мәсәләң, гадәттә теге яки бу тышкы хәлләр йогынтысында, шул мизгелдә күңелдә ялган җыйнак уй-хисләр күзәнәген бирел баралар. Уй-хис нинди дә булса тышкы факт белән бәйләнештә туа да кабат дәвам иттерелми, берсе икенчесенә ялганып, тоташып килми, вакыйгага үтеп китү белән бергә сүнә. Гүя ки язучы эчке дөньяга вакыйга барышында гына ара-тирә карап куйгалый. Бу караш, күңел картиналары күпчелек очракларда берничә җөмлә белән генә белдерелә. Чөнки язучы тышкы хәлләргә шул минутта турыдан-туры катнашы булган уй-кичерешләрне генә кәгазьгә төшерә, бүтәннәрен, вакыйгаларга турыдан-туры барып тоташмаганнарын күрсәтеп тормый. Шуңа күрә романда кеше күңеленең башлыча өске катламы ачылган кебек тоела. Мондый рәвештә сурәтләү бигрәк тә җитәкче кадрларның үз эшләренә бәйләнешле уй-фикерләрен, баш миендә туган планнарын тасвирлаганда еш очрый. Вакыйга-фактләр гүя ки тышкы дөньядан кеше күңеленә үтеп керәләр. Романда әлеге уй-пландардан тыш борчылып уйлану, хәтергә беркетеп кую, искә төшерү, сорау-җеләнү төсмерләрен күрергә була. Уй-кичерешләрнең дәвамлы агышын чагыштырмача сирәгрәк очратабыз.

Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясенә эпик киңлек хас. Ләкин аның белән бергә без монда геройларның рухи дөньяларын да шактый ачык төсмерли алабыз. Трилогия илебездәге зур иҗтимагый борылышлар, кискен социаль үзгәрешләр, бәрелеш-көрәшләр чорында төрле сыйныф-катлам вәкилләренең, төрле характер ияләренең нәрсәләр уйлавын, ни кичерүен, бераүләрнең йөзе тәүге тапкыр сөенечтән балкып китүен, икенчеләрнең кайгыга батуын, өченчеләрнең тирән уйларга бирелүен, иҗтимагый хәлләр белән бергә күңелләрдә дә борылыш туууын күрсәтә. Тарих этаплары кеше күңеле аркылы уза. Алар төрле социаль катлам вәкилләренең психикасына төрле эз салып үтәләр. Кешеләрнең уй-кичерешләре аркылы әсәрдә мөһим фикерләр чагыла.

Моны яктыртуда билгеле бер закончалык бар. Киң планлы, күп геройлы әсәрдә автор кайсы персонажга текәлебрәк караса, кайсы образ сюжет тармагын үзе белән ияртеп алып китсә, шул каһарман психологик яктан да ачыла башлый. Шулай итеп, образга гомумән дикъкать юнәлгән чагында, аның рухи дөньясы да читтә торып калмый, органик бер өлеш буларак рәсемләнә.

Трилогия мәйданының кыл уртасында буйдан-буйга Хәлим образы хәрәкәт итә. Унбиш елга сузылган иҗтимагый-тарихи вакыйгалар барышында Хәлим безнең күз алдында үзгәрә: сабый баладан җиткән егеткә әверелә. Бер үк вакытта ул эчке яктан да, уй-кичерешләре, карашлары, бәя-мөнәсәбәтләре белән дә үзгәрә, динамика эчке яктан да күренә. Беркатлы уй-кичерешләрдән, балачыл хыяллардан, дөньяны әкияттәге өлге буенча күз алдына китерүләрдән җитди мәсьәләләргә күчә, табигать, яшәеш, кешеләр, сыйныфлар, бәхет, сәнгать һ. б. турында сораулар туа, яңа хис-тойгылар барлыкка килә. Зур художник буларак, И. Гази бу өлкәдә дә, ягъни балалар психикасын яктыртуда да, матур художестволы ачышлар ясады. Гадәттә эчке һәм тышкы дөнья үзара тату, бердәмлектә яши. Ләкин шуның белән бергә кайчак шәхеснең үз-үзен тотышы рухи халәтенә бик үк туры килеп тә бетми. Менә Хәлим белән Кафиянең үсмер чак тойгылары, күңелләренең үзара хәбәрләшеп торулары тасвирлана. Икесе дә бер төбәктә эшлиләр. Ләкин үзара бер сүз дә әйтешмиләр. Кафия — кызлар тирәсендә, Хәлим — малайлар янында сөйләшә, уйнаган, көлгән була. Ләкин икесе дә бу сүзләрнең, уен-көлкеләрнең бер-берсенә төбәлгән булуын сизеп-тоеп торалар. Ул тирәдән берсе китүгә, икенчесе дә кинәт тынып кала, сайравыннан туктаган кош кебек, сөйләшми башлый. Биредә хис турыдан-туры бәреп чыкмый, күңелдә саклана, аны берсе дә әле вакытыннан элек селкеп салырга, ямен җибәрергә теләми. Монда үсмер чак горурлыгы һәм оялчанлыгы ирек бирми, күңел диалогының асыл мәгънәсе тик бер-береңне аңлаган кешегә генә барып җитә, читләр өчен исә гадәти көлү-чыркылдаулар булып кала бирә.

«Онытылмас еллар»да, гомумән, телдән әйтелгән сүз белән күңелдәге уй мөнәсәбәте шактый кызыклы. Нәрсә турында сүз баруга карап, сөйләм я эпик, я лирик характерда була, ягъни я хәл-вакыйгаларны бәян итә, яки сөйләүченең эчке дөньясында барган процессны, күңелнең иң түрендә яшеренеп яткан серләрен, шик-шөбһәләрен, икеләнүләрен ачып бирә. Күп очракта уй телдән әйтелгән әлеге сүзләрнең дәвамы буларак тасвирлана. Ләкин кайбер геройларда, бигрәк тә каршылык-

лы характер ияләрендә, мәсәлән, Гафият ишеләрдә, телдән әйтелгән сүз белән күңелдә кайный торган фикер, гәрчә бер үк нәрсә уңае белән булса да, бер-берсенә туры килеп бетми, берсе икенчесеннән шактый аерылып тора. Сүз бер төрле, уй икенче төрле булып чыга. Заманалар болгавыр мәлдә, әнә шул болгавырлыкны исәпкә алып, Гафият чит кешеләргә күңелен ачып бетерми, фикерен яшерә. Гафиятнең телдән әйткәне — томанлы, уйдагысы, телдән әйтелмәгәне — бик конкрет, нәкъ менә тыңлап торучыга кирәклесе. Ләкин Гафият нәкъ менә шунысын тышка чыгармый.

Нурихан Фәттахның «Этил суы ака торур» романы бүгенге прозабызда шактый үзенчәлекле урын алып тора. Әсәрнең төп яңалыгы — тормыш материалында, моңарчы язучылар кулы тимәгән, укучыларга аз таныш булган өлкәне сурәтләп бирүдә. Нурихан Фәттах халкыбызның ерак үткәнен, моннан мең еллар элек булып үткән хәлләрне, борынгы бабаларыбызның тормыш-көнкүрешен, шөгыль-кәсепләрен, сәнгать-мәдәниятен, уй-тойгыларын, гореф-гадәтләрен, үзенчәлекле йолаларын, кыскасы, Болгар дәүләте дәверен, үтә киеренке көрәш вакыйгаларын сәнгатьчә тасвирлап бирде.

Муса Җәлилнең «Алтынчәч», Галимҗан Ибраһимовның «Казакъ кызы», Фәтхи Бурнашның «Дала давы» («Казакъ кызы»), Мохтар Әуэзовның «Абай» әсәрләрендәге кебек үк, монда да таркау ырулар көрәше, ырулар тартышы-интригалары хәтсез урын ала. Шуңа күрә әсәрдә коллар — «каралар», игенчеләр, көтүчеләр, балыкчылар, сакчылар, сугышчылар, сәүдәгәрләр, табиплар, чичәннәр һәм башка социаль катлам вәкилләре, һөнәр ияләре белән беррәттән шушы ыруларның башлыклары — биләр, ханнар образы да шактый җентекле сурәтләнә. Автор, үз геройларының эш-хәрәкәтләрен күрсәтү белән бергә, күп кенә хәлләрдә аларны эчке яктан ача, уй-тойгыларын, психологиясен сурәтли. Яшәү рәвешендәге үзгәлек фикер сөрешендә, хис итү-кичерешләрдә дә чагыла. Иң әүвәл автор әлеге даими талаш шартларында геройларның борчылулы уйлар белән яшәүләрен күрсәтә. Бу борчылудан ханнар, биләр дә имин түгел. Ырулар ызгышы, сарай интригалары, сәүдәнең тоткарлану ихтималы, табигатькә бәйлелек, хаста-сырхау хәлләре геройлар күңеленә хәвефле уйлар сала. Власть ияләренең рухи дөньясын дәүләт, идарә, политика, сугыш, оборона, сәүдә, байлык, йола мәсьәләләре, ыру һәм туганлык мөнәсәбәтләре туктаусыз тыгызлап тора.

Диннәрнең алмашынуы, искесеннән, мәҗүсидән, тирән эчке газаплар белән баш тартып, яңасын курка-өркә кабул итү чорын сурәтләгән әсәрдәге персонажлар күңелендә йола һәм аның кануннары, табыну, хорафат кебек нәрсәләрнең урын алуы бик табигый. Йола кануннары аеруча баш герой Тотышның рухи дөньясына әрнеткеч йогынты ясый, аның шатлыгын-куанычын тартып ала. Тотыш — гайрәтле, баш бирмәс, ярсу күңелле, билгесез омтылыш белән яшәүче, кайнар йөрәкле, тиз кабынып китүче, алдын-артын уйламыйча карар кабул итүче егет. Аның шатлыгы да, кайгысы да — капма-каршы шушы ике күренеш — бер үк чыганактан, үзенең ярсулы йөрәгеннән килә. Ул йола кануннарының эзлексез булуын, бер очракта бар нәрсәдән дә көчле саналып та, икенче мәлдә алтын-байлыкка буйсынганын күреп сизеп яши, яңа кабул ителә торган мөселман диненең кешелек кадерен кимсетүенә, колларны хайваннар хәленә төшереп түбәнсетүенә аптырап карый. Ялкынлы мәхәббәте хакына ул, ике дә уйламыйча, борынгы бабалар йоласыннан баш тарта, әмма хәтәр ситуациядә аның күңелен шомлану, үкенү хисләре дә биләп ала.

Тотыш «Кыйссаи Йосыф» сюжетына тиң киеренке вакыйгалар эчендә тасвирлана. Ул киеренкелекне, бер яктан, үзенә бәйләнешсез хәлләр китереп чыгарса, икенче яктан, моңа әлеге йөгәнсез холкы сәбәпче була. Иң кискен, җитез тышкы вакыйгаларны рәсемләгәндә дә автор аның эчке дөньясын истән чыгармый. Дошманның өч алыбына каршы көрәшкә чыккан вакыттагы хисләрен, алыш барышында, дәһшәтле минутта сөйгәне Тәңкәне искә төшерүен, аңына килгәндәге, терелеп аякка баскандагы тәүге сөенечле тойгы-кичерешләрен тасвирлый, сугыш вакытында каршылыклы карарларының яшен тизлегендә алмашынып торуын күрсәтә. Каршылыклы уйлар аның каршылыклы положениесеннән килеп чыга. Тышкы хәрәкәттәге борылыш иң әүвәл герой психикасында башкарыла. Шул үк вакытта мондый күчешләр, әле бер яктан, әле икенче яктан торып сугышу күренешләре ыру талашларының бик үк принципиаль булмаганлыгын күрсәтү өчен дә китерелгән.

Алдарак без психологизм белән лирика арасындагы беркадәр якынлыкны күреп киткән идек. Лирика сюжетына хас булган сүлпәнлек психологик проза сюжетына да күчә. Вакыйгалы сюжетларга караганда психологик сюжет шактый салмаклана, темпы акрыная. Әмирхан Еники әсәрләренең сабыр-талгын агышы, әлбәттә, авторның сүз җаен, тәмен белеп, кабаланмыйча, салмак, иплә сөйләү табигатеннән генә килми. (Ихтимал, моның да азмы-күпме роле бардыр.) Ләкин шулай да психологик әсәрләрдә сюжет салмаклыгын тудырган мөһим фактор — ул уй-тойгыларның бөртекләп, детальләп тасвирлануы.

Ләкин шуның белән бергә, әлеге уй-кичерешләрнең эчке табигатенә хас булган бер үзенчәлек — аларның конфликтлы характеры, уй-тойгылар драматизмы сүлпәнлекне киметүгә, хәрәкәтне җитезләтүгә дә булыша. Бу мәгънәдә психологик көрәшләр дә, вакыйгалар каршылыгы да сюжетны киеренке итүдә бердәй роль уйныйлар.

Безнең прозада эчке көрәшнең, «ике мин», «ике фикер» тарткалашуының төрле төсмерләрен күрергә була. Гариф Ахуновның «Хуҗалар» романында, мәсәлән, Шәвәли карт уйлары гомум кабул ителгән реаль бәяләргә каршы килә, гомум караш белән карт фикерләре бәрелешкә керә. Язучы аның гомер кояшы батып барган чордагы уй сөрешен тасвирлый. Картның күзенә бөтен нәрсә буявы уңган төс белән күренә. Иң якты хатирәләре артта калган. Бөтен кешеләрне шатландырган ачыш-яңалыклар да аны куандырмый. Чөнки Татарстан җирендә сугыштан соң гына барлыкка килгән нефть промышленносте, аның карашынча, балаларын үз янынннан тартып алып, картны ялгыз калдырды. «Ә бит ул шушы тап-таза беләкле, сабыр һәм төпле акыллы Арслангалие кулында яшисе ата иде бит. Кадер-хөрмәт күреп, ил карты булып кына яшисе кеше иде ул. Яши алмады шул. Алмады, үзгәрде заманалар, үзгәрде дөньясы, бөтенесе үзгәрде, яньп-көеп беткересе! Торырлар ие әле ул нефтесеннән башка да. Көбәшләр торган, җир маеның нәрсә икәнен дә белмәгән. Арба күчәре майларлык кына дегетне Бөгелмәгә барып та, инде бер дә булмаса, башкорт якларына чыгып та тапкан булырлар иде. Бозылды дөнья, үзгәрде, тәмам көен җибәрде бу җир мае...»[1]. Аңа нефть эзләгән җирдә җир җылыкайның кысыр ятуы да, Арслангалиенең кала кешесе булып, «сыерчык оясындагы кебек, таш йорттан борынын гына чыгарып ятуы да» ошамый. Гомумән, бу үзенчәлекле картның катлаулы, каршылыклы, гомум бәягә туры килми торган уй-мөнәсәбәтләре романда бик реаль, төгәл, мастерларча тасвирланган.

Шушы ук авторның «Чикләвек төше» повестенда («Казан утлары», 1971, № 10) шактый оригиналь характер — партия, халык, дәүләт эшен йөрәгенә үтә якын кабул итүче, җиренә җиткереп, булсынга эшләүче, әйткән сүзе белән дә, кылган гамәле белән дә һәр чак туры, намуслы булып калучы, кыенлыкларның күзенә карап баручы һәм тик шундый тормышны гына табигый дип санаучы принципиаль коммунист, шул ук вакытта кеше йөрәген сизгер аңлаучы Халикъ Саматов образы сурәтләнә. Шундыйрак характер тудыру — ул һәр язучының хыялы. Ләкин ул һәр вакытта да безнең күз алдына тере, жанлы булып килеп басмый иде. Әгәр дә Г. Ахуновның кечкенә повестенда образ укучыны ышандырырлык дәрәҗәгә ирешкән икән, монда башка художество сыйфатлары белән беррәттән психологик моментның да бер кадәр роле бар. «Хуҗалар»да Шәвәли картның караңгы уй-фикерләре уңай карашлы авторның мөнәсәбәте яктылыгында бирелсә, биредә, киресенчә, Халикъ Саматов характеры, эш-гамәлләре нэпман, вак сәүдәгәр кызы Рокыя мөнәсәбәте-бәясе, уй-кичерешләре аркылы үткәреп бирелә. Тагын да төгәлрәк әйткәндә, тирә-юньдәге хәлләрнең, Халикъ эшләренең Рокыя күңелендә чагылуы, катлаулы уй-кичерешләр тудыруы сурәтләнә.

Үзенчәлек шунда ки, повестьны хикәяләүче геройның, әлеге Рокыяның кешеләргә, аларның эш-хәрәкәтләренә мөнәсәбәте, бәясе аның ире, хикәяләү объекты Халикъ принципларыннан шактый нык аерылып тора. Кимчелекле герой исеменнән хикәяләү әдәбиятта гомумән сирәк очрый. Рокыяда мещан-обыватель психологиясе ярыйсы ук тирән тамыр җибәргән. Шуңа күрә Халикъның дәүләт эшенә беткәнче бирелгәнлеге, үзен-үзе аямавы хикәяләүчегә аңлашылып җитми, ул моны табигый нормадан үтеп киткән дип, «сантыйлык» дип саный. Шулай итеп, Халикъның якты холык-гамәлләре караңгырак

[1] Гариф Ахунов. Хуҗалар. К. 1968. 136—137 битләр.

фонда бирелә. Ә бу фонда яктылык тагын да ачыграк күренә. Хикәяләүче герой тискәре дип бәяләгәнне укучы уңай яктан кабул итә.

Атилла Расихның «Ике буйдак» романындагы доцент Заһид Сафич образы барыннан да бигрәк характерының, уй-хисләренең үтә катлаулы, конфликтлы булуы белән аерылып тора. Баштарак аның тышкы һәм эчке дөньясы гармониядә яшәгәндәй тоела. Пөхтә, күркәм, мөлаем. Лекцияләрен бик әйбәт сөйли, гыйльми әдәбиятны мавыгып, ләззәтләнеп укып бара. Ул үзенчә мохтаҗларга ярдәм кулын сузарга тели. Хәтта бу омтылышында беркадәр арттырып та җибәргәли: бер үк эш урынын ике кешегә вәгъдә итеп ташлый. Ләкин чынында исә аның фикер-карашлары шактый тиз үзгәреп тора, кылган гамәле теләгенә каршы килә. Заһид Сафичның күңелен даими икеләнү, эчке бәхәсләр биләп алган. Шуңа күрә дә бу образны иҗат иткәндә автор аеруча эчке драматик диалогка, тавышсыз репликаларга, күңелдә барган фикерләр көрәшенә еш мөрәҗәгать итә. Тора-бара без геройның тышкы ялтыравыгы белән эчке ярлылыгы арасындагы зур контрастны күрә башлыйбыз.

Әсәрдәге икенче герой — Рәхим образы аркылы автор көчле ихтыярлы, югары омтылышлы, фәнни тикшеренү эшен дәртләнеп, үзен-үзе аямыйча башкаручы патриот галим тибын иҗат итте. Язучы Рәхимне дә җанлы кеше итеп, аны кайгышатлыклары, мәхәббәт-нәфрәтләре, уйхисләре белән сурәтләргә тырышкан, гыйльми эзләнүләрне, экспериментларны оештыруга, интим мөнәсәбәтләргә бәйләнешле фикерләрен, тойгыларын тасвирлаган. Ләкин шулай да Заһид Сафич фонында Рәхим психологиясе беркадәр тоныграк чыккан. Байтак очракларда автор психик процессның хәрәкәтен күрсәтми, уйның исемен, темасын гына әйтү белән чикләнә. Геройның уе белән мәсьәләнең төрле якларын капшап каравын, аларга ни дәрәҗәдә күзе җитүен, иңли алуын, ягъни һәрбер мәсьәләне хәл иткәндә бара торган катлаулы уйлану процессын без күрмибез. Гүя ки ул экспериментларны уй катнашыннан башка гына үткәрә.

Рәхим психологизмы мәсьәләсенә карата Ибраһим Нуруллин болай дип язган иде: «Үзе турында, кешеләрнең аңа мөнәсәбәте турында уйларга, эчке дөньясында казынырга аның вакыты да, теләге дә юк. Менә ни өчен язучы, психологик анализ дигән булып, героеның күңеленә тыкшынмый, хис-тойгыларын тәфсилләп сөйләп маташмый»[1]. Шушыңа охшаш концепцияне кайбер художество әсәрләрендә дә очратырга була. Айсылу турында Гомәр Бәширов болай ди: «Аның бала вакытында да, буйга җиткәч тә үзе турында уйларга бөтенләй диярлек вакыты калмый иде»[2]. Ләкин нәкъ менә монда художество такты, сизгерлек җитеп бетми дә инде. Без бит һәр персонажның үзе башкарган эшләргә, тышкы хәл-вакыйгаларга һәм шулай ук үзенең рухи дөньясына да анализ ясавын таләп итеп куймыйбыз. Ул уй-кичерешләрне бөтенесен күреп торучы автор хикәяли. Күренекле язучылар уйның кеше ихтыяры белән бер юнәлештә генә акмавын, үзләренә яңа юллар-ерганаклар ярып баруын сурәтлиләр. Г. Бәширов үзе үк, мәсәлән, Хәдичә түтинең намаз укып утырган җиреннән уйлары төрле якка сибелүен, өсте-өстенә өелүен, истәлекләр дөньясына алып китүен, берсе икенчесен тутыруын тасвирлый.

Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар»ында үлемнең акрынлап, күзгә карап килү очрагы тасвирлана. Мондый хәлдә фаҗига, финал хакында уйланмыйча булмый. Ләкин шулай да Ибраһим Гази геройның уйларын үлем белән генә чикләми, аңа бөтенләй кагылышы булмаган яшәү, тормыш турындагы уйларын сурәтли. Баязитов иң хәтәр моментта үзенең олы кызын, аның төнге сменага эшкә җыенуын күз алдына китерә, типографиядәге хәрефләрнең искерүен, кәгазь запасының саегуын исенә төшерә, мәсьәләне ревком каршына куярга ниятли — хыял-планнар әнә шунда өзелә.

Әлбәттә, психологизм үзе генә художестволылык күрсәткече була алмый. Шулай икәнлегенә ышану өчен бүгенге әдәбиятыбыздагы күренекле әдипләребезнең кайбер әсәрләренә күз ташлау да җитә. Фатих Хөснинең, мәсәлән, «Мәйдан» повестенда («Казан утлары». 1971. № 7), Габдрахман Әпсәләмовның «Яшел яр» романында («Казан утлары». 1969. № 6, 7, 8) рухи халәт бу талантлы язучыларның башка әсәрләренә караганда да тирәнрәк, җентеклерәк яктыртыла. «Яшел яр»да хәтта эчке дөньяны тышкы вакый-

---

[1] И. Нуруллин. Иңесен яклый. «Соц. Татарстан». 1970, 7 март.
[2] Г. Бәширов. Намус. К. 1951. 41 бит.

галар эффекты белән артык мавыкмыйча тасвирларга омтылу, хикәяләү стилендәге яңа бер тәсмер сизелеп кала. «Мәйдан» повестенда көчле каршылыклары Ф. Хөсни каләменә хас булган юмористик бизәкләрдә ачыла, анда без Хәдичәнең үз күңелендәге шик-шөбһәләрен янында барган сыерына сөйләве кебек Чеховча, ләкин шаян рухта бирелгән күренешләрне очратабыз. Гомумән, мавыгып укырлык әсәрләр алар. Ләкин шулай да мондагы уйкичерешләр моңарчы безгә ярыйсы ук таныш булган әзер сюжетларга салынган сыман тоела. Гәрчә «Яшел яр» авторы укытучылар профессиясен, хатын-кызларның тормыштагы урынын бик биеккә куеп сурәтләсә дә, моның өчен мул гына итеп күтәренке-сентименталь картиналар, Г. Әпсәләмов каләме өчен хас булган югары стиль тасвирлары, мөлаем-нәзакәтле диалоглар, монологлар кертсә дә, геройләр характеры, әсәрнең идея-проблематикасы масштаблы төс алмаган. «Яшел яр» мәгълүм дәрәҗәдә «Тапшырылмаган хатлар»ның яңа вариантын хәтерләтә. Тормышның үзенчәлекле якларын тирәнтен тикшермәү, төптән уйланмау, әзер схемалар белән канәгатьләнү нәтиҗәсендә әлеге повесть һәм роман, гәрчә психологик тирәнлек белән аерылып торсалар да, урта кул әсәрләр булудан узмаганнар.

Соңгы вакытларда, өлкән әдипләребез белән берРәттән, урта буын язучыларыбыз да кеше күңеленә тәкәлебрәк карый башладылар. Моның шулай икәнлеген Н. Фәттах, Г. Ахуновның алдарак телгә алып кителгән әсәрләре, С. Батталның «Сигезенчесе кем?», Э. Касыймовның «Гомер ике килми», Г. Мөхәммәтшинның «Йөрәктәге эзләр», А. Гыйләҗевнең «Өч аршын җир», «Зәй энҗеләре», «Урталыкта» исемле роман-повестьлары раслый. «Өч аршын җир» әсәрендә А. Гыйләҗев давыллы утызынчы елларда иҗтимагый тормышта барган көрәш-бәрелешләрнең, каршылыкларның кеше психологиясендә үзенчәлекле чагылышын яктырта, моның катлаулы якларын сурәтли, ягъни милекчелек карашын кешедә була торган башка хис-тойгылар, кичерешләр белән бәйләнештә күрсәтә, бер очтан мәхәббәт, коллектив, туган җир, бәхет проблемаларын да күтәрә һәм нәкъ менә шулай итү аркасында геройның эчке дөньясы бик тирәннән ачыла.

Язучы үзенең әсәрләрендә герой характерының формалашуына яки яңа юнәлеш алып китүенә шул кеше тормышында булып узган тышкы хәлләрнең йогынты ясавын, күңеленә, бөтен рухи дөньясына тирән эз салып үтүен күрсәтә, икенче төрле әйткәндә, характер формалашуында әйләнә-тирәнең, средaның ролен бик гыйбрәтле индивидуаль күренешләр аркылы чагылдыра. «Зәй энҗеләре»нең баш герое Гәрәй Шамин бер урында күңеленнән болай дип сорый: «Минем кайсы учакларда кызып, кайсы сандалларда чүкелеп, нинди казаннарда сугарылуымны беләсезме?»[1] Язучы менә шушы геройның катлаулы натура булуын, аның характерын формалаштырган тискәре һәм уңай чыганакларны ачып күрсәтә.

«Урталыкта» повестенда исә автор кеше булган кешегә, аның эшенә ихтирам, талант, иҗат мәсьәләләрен куя. Язучы проект институты инженеры Сәгыйтнең һәм хәтта бөтен бер буынның билгеле бер шартларда иҗади кризиска килеп керүен, повесть ахырында аннан чыгарга теләк туюын, дәрт кузгала башлавын тасвирлый. Менә шушы иҗади активлык уяна башлавын автор шактый зур вакыйга дип бәяли. Ләкин әсәрдә конструкторның үз идеясен тормышка ашыру процессы яктыртылмыйча кала. Җитәрлек дәлилләнмәү, художество чаралары белән исбатланмау аркасында геройның яңадан дәрләп кабынып китүен исә күңел кабул итми.

* * *

Кеше күңеле, рухи дөнья — шул ук объектив чынбарлык ул, кеше тормышының бик мөһим өлкәсе. Яңа җәмгыять төзү бер үк вакытта кеше рухы өчен көрәшүне дә күздә тота. Шуңа күрә партия Үзәк Комитеты совет язучыларының II съездына җибәргән хатында язучылар алдына «кешеләрнең уй-тойгыларын тирәнтен белү, кичерешләренә ихлас сизгерлек күрсәтү» бурычларын куйды.

Без еш кына «герой күңелендә казыну» рәвешендәге сүзләрне кулланырга яратабыз. Ләкинныклабрак уйлап карасак, казынып, бик тирәнгә киткәнебез, бүгенге көн кешесенең күңел төпкелләрен заман таләп иткәнчә ачып бирә алганыбыз юк әле. Биредә безнең язучыларны зур ачышлар көтә. Үз нәүбәтендә бу өлкәдә тәнкыйтьтән дә иҗади сизгерлек, психологизмның табигатен өйрәнү һәм гомумиләштерү сорала.

[1] Аяз Гыйләҗев. Зәй энҗеләре. К. 1965. 176 бит.

Роберт Әхмәтҗанов

# ЗАМАН УТЛАРЫ

*«Казан утлары»ның 1972 елгы 1—8 саннарындагы шигырьләр турында.*

## Әдәби мирас

Сүземне әдәби мирас мәсьәләсеннән башлап китәргә телим. Бездә әдәби мирасны барлау, аны, вакыт тузаныннан аралап, бүгенге укучыга тәкъдим итү эше, ничектер үз агымына куелган. Әле бүген дә бу изге эш без көткән югарылыкта тора дип әйтеп булмый. Мәрхүм әдипләрнең төрле сәбәпләр аркасында үз вакытында дөньяга чыга алмаган әсәрләрен, алар хакындагы истәлекләрне, хат һәм документларны матбугатта күрсәтү шул язучылар иҗат иткән чорның атмосферасын, вакытын кабат яңарта. Нәтиҗәдә аларның иҗаты яңа гомер белән яшәп китә шикелле.

Журнал, бу әһәмиятле миссияне башлап җибәреп, бик әйбәт эшләде. Без аның узган саннарында И. Гази, Ш. Мөдәррис һәм Г. Хуҗи иҗатлары белән кабат очраштык.

Кайбер иптәшләр сугыш һәм сугыштан соңгы еллар поэзиясен «өйрәнү чоры» гына дип бәяләп китмәкче булалар. Янәсе, бүгенге көннәр таләбеннән чыгып карәганда, 50 нче еллар шигърияте укучыларны тирән мәгънәле әсәрләр белән куандыра алмаган. Мондый фикер белән килешеп булмый. Андый бәячеләргә болай диясе килә: иптәшләр, аермыйк әле елларны еллардан, алар арасында киртә дә, чик тә юк ич! Алар — тоташ. Еллар, чорлар бер-беренә күпер булып сузылалар. Бүгенге кайбер казанышларыбыз да шул еллар җирлегеннән килмимени?..

Ул елларны һәм ул елларда иҗат иткән шагыйрьләрне миңа аз булса да күрергә туры килде. Ул еллар да иҗат ялкыны белән кайнап, дәртләнеп яшәгән еллар иде. Бүгенге көннәрнең шигърия запасы әле дә булса шул окоплы кырлардан, яңа гына блиндажлар тузанын кагып, автоматын тыныч көннәр каләменә алыштырган, түшләрен орден һәм медальләр бизәгән фронтовик әдипләр рухыннан килә кебек. әдәби-эстетик кыйммәтләре ягыннан да бер дә түбән түгел иде ул еллар иҗаты! Дөресен әйткәндә, инде без ул елларда язылган әсәрләрне кулыбызга бик сирәк алабыз, яисә бөтенләй алмыйбыз... Сугышның соңгы елында һәм җиңү салютыннан соң туган яшь буын аларның күбесен бөтенләй белми дә. Ә менә әдәби мирасны өйрәнү, вакыт-вакыт үткәннәргә дә борылып карау һич зарар итмәс иде безгә!

Менә мин журнал битләрендә Ш. Мөдәрриснең сигезьюллык шигырьләре белән яңадан очрашам. Шундый тыгыз хисле, ялкынлы, ашкынулы шигырьләр! Алар әдәби осталыклары, камиллекләре ягыннан да бүгенге шигърияттә үрнәк булырлык әсәр-

лəр. Бу шагыйрьлəрнең шəхси якларында да соклангыч сыйфатлар күп иде. Алар — əдəбиятыбызга яшь алмаш тəрбиялəүгə күп көч куйган иптəшлəр. Алар бу юнəлештə чын күңелдəн бирелеп, үз-үзлəрен онытып эшлəделəр.

Шəрəф Мөдəрриснең тəмамланмый калган җыры — «Полк намусы» исемле трагедиясе — гражданлык накалының югарылыгы, иҗат палитрасының байлыгы, окоп һəм блиндаж шартларында, ил азатлыгы өчен барган бөек көрəш фонында коммунистның тулы канлы образын тудыру һəм аның җитəкчелек көчен күрсəтү юнəлешендəге уңышлары белəн үзенə бер героик сəхифə ул. Шигъри трагедия иҗат итү, күп планлы, полифоник сугыш симфониясе тудыру шагыйрьдəн күп көч талəп иткəндер.

Бүгенге көннəрдə, яшь поэзиянең тыныч офыкларында безнең лирик шигырьлəр, тыныч көйлəр, идиллиягə якын парчалар калгып утырганда, шундый ялкынлы, киң сулышлы, эпик колачлы əсəрлəргə күз төшерү, аларны киң масштаблы булулары ягыннан үрнəк итү зарар итмəс иде безгə.

Гомумəн, бу əдиплəрнең гаять бай шəхси-иҗтимагый гомер сəхифəлəре безне, яшь əдиплəрне, иҗатта һəм тормышта шактый күркəм сыйфатларга өйрəтер иде...

«Казан утлары»ның килəчəктə дə шундый əдəби мирас сəхифəлəрен киңрəк, тулырак, эзлеклерəк яктыртуын телик. Алда əле безне төрле иҗади шəхеслəр, мирасыбызның яңа үрнəклəре белəн очрашулар көтə дип ышаныйк.

## Əдəби осталык.
## Якты тəрəзəлəр

Бүгенге көн шигърияте өчен иң хас күренеш шул: кайсы гына шагыйрьгə мөрəҗəгать итмə — өлкəнме ул, яшьме — алар иҗатында заманның катлаулы сулышы, аның каршылыклы көрəш дулкыннары, чорның рухи йогынтысы нык сизелə. Дөрес, форма төрлелеге əллə ни зур түгел, күбрəк иске эзлəргə кайтылган, ярлар — анык, сулар — тонык, кояш — баш очында, гөллəр — үз төсендə. Кыскасы, традицион рамкалар тотрыклырак, стабильрəк. Күп əсəрлəр, əйткəнемчə, элеккечə традицион калыпта-көйдə; күбесенчə, 10×9 үлчəмендə язылалар. Сүзлəр арсеналына карыйм: элек-электəн үз хəзинəбездə булып та, ни сəбəптəндер бүгенге əдəби телебездəн төшереп калдырылган, моңарчы нигəдер актив кулланылмаган сүз энҗелəребез шигъриятебездə үзлəренең лаеклы һəм хаклы урыннарын көннəн-көн күбрəк ала бара. Тик менə бу өлкəдə таякны артыграк «бөгеп» җибəрмибез микəн, дигəн сорау да туып куйгалый. Мондый сорау да бик үк урынсыз түгел кебек, минемчə. Чөнки, архаикада артык казыну, инде бүгенге көндə җан өреп булмаслык казылма мамонт кебек сүзлəрне дə чүплəү урынсызрак кебек. Дөрес, безнең күп кенə сүз энҗелəрен үз урыннарында ялтыратасыбыз бар əле. Əмма инде шигърият тəнендə биологик активлыкларын җуйганнарын түгел. Терелəрен! Безнең «җиксенү», «җисмəн», «җилбəз», «җилбəгəй», «җилеш» кебек үзлəреннəн дə шəбрəк, төгəлрəк адекватлары табылмас үз сүзлəребез бар. Боларны мин мисал өчен генə китерəм. Алар — бихисап.

Безгə шулай ук заманның үзе алып килгəн неологизмнардан да, интернациональ сүзлəрдəн дə баш тарту кирəкмидер. «Безнең юлда вакуумнар юк», ди үзенең бер шигырендə Хəсəн ага Туфан. «Вакуум» сүзе бу очракта үз урынын тапкан шикелле. Чөнки аны «бушлык» сүзе берничек тə алыштыра алмый. Аның яңгырашы да, шигырьгə биргəн мəгънəви һəм эмоциональ төсмере дə бүтəн. Мин, шигъриятка үзебезнең сүз энҗелəрен кайтару белəн бергə, неологизмнарны да кыю кертүчелəр ягында. Моңардан безнең сүз байлыгыбыз артачак кына!

Безнең шигъриятта үлчəмнəр күбесенчə традицион калыпта дигəн идем. Əмма шигырьлəр эчтəлеклəре, һавалары, моңнары белəн бер-береннəн яхшы ук аерылып торалар. Димəк, эш əдипнең үзенə генə хас дөньясында, əсəрнең эчтəлегендə, художникның иҗади осталыгында икəн!

Əдəби осталык турында сөйлəгəндə, минем шагыйрь Гамил Афзалның тарихи-социаль темага язылган, лирик җылылык белəн сугарылган яңа шигырьлəрен китерəсем килə. Аларда замандашыбызның эстетик карашлары да, мохиткə заманча менə-

сәбәте дә бер сулышта бирелгән. Шагыйрьнең шигърият турындагы бер строфасы бу хактагы бөтен бәхәсләрнең, мәкаләләрнең үткенләгән бер фокуска туплый сыман:

**Син — йолдызлы кич һәм серле иртә,**
**Таң җилләре сине иркәләр;**
**Чын шагыйрьләр сине байрак итә,**
**Кәсепчеләр ыштыр итәләр.**

Гамил Афзалча дөнья, контрастлар, көтелмәгән борылышлар дөньясы бу! Аның бу бәйләмендә шулай ук тау һәм басуларның кичке моңын, табигать һәм вакыт мелодикасын оста сиземләү чагыла. Менә кечкенә генә бер этюд:

**Көн сүрелде.**
**Яшькелт һава җиләс,**
**Иренеп кенә эңгер таралыр,**
**Тупыл башларына тияр-тимәс,**
**Күк болытлар ага каядыр.**
**Яфрак шавын сөйләп тирә-якка**
**Төн буена җилләр йөрерләр.**
**Тәрәзәне кага шундый чакта**
**Киткән дуслар,**
**Үткән гомерлар.**

Бик табигый дөнья, бар да — күңел теләгәнчә!

Шигъри тәрәзәләр арасында Сибгат Хәкимнең уты биек һәм серле яна. Күңелне җылы әңгәмәгә тартып, үзенә чакырып яна! Рамнарын кайсы Гыйльметдин ясагандыр, ә уты җете, уты Сибгат Хәкимнеке! Уйланулар уты. Мәңгелек ут!

**Дугадан соң чирек гасыр. Дуга.**
**Белгородка кабат кул бирдем.**
**Тәрәзәмне ачтым, мәңгелек ут**
**Карап чыкты эчен номерның,**
**Карап чыкты бөтен почмакларын,**
**Янәсе, кем яши!**
**Ут: таныйм...**
**Мин дә таныйм, солдатларның таныш**
**Йөзен күрдем шушы утта мин.**

Шагыйрьнең «Үлгәннәргә хәтта моң кирәк» дип исемләнгән әлеге шигырьләр циклы — Татарстанны Европа белән, вакытны вакыт белән, язмышларны язмыш белән бәйләгән җитди лиро-эпик елъязма. Иркен, җылы тойгыларга юмарт шигърият янында укучы үзен учагында уты янган җылы өй эчендә итеп хис итә. Әйе, юмарт шигърият бәйләнчек түгел, ул сиңа яфрак булып та ябышмый, күзеңә күбек булып та керми. Монда инде яхшы шигырь генә түгел, шигъри «өй» хуҗасының киң күңеле, юмарт хуҗа икәнлеге дә сизелеп тора.

Юл уңаеннан мин шундый якты тәрәзәле, җылы өйләрнең тагын берсенә юлыктым.

**Бөдрә болытларның арасыннан**
**Фәкать миңа гына**
**Балкып торды Кояш, алып мине**
**Алтын михрабына.**

Бу — Нури Арсланов авазы. Журналның 6 нчы санында басылган яңа шигырьләре аның бер үзе өчен генә түгел, бүгенге татар шигъриятенең яңа үсеше итеп бәяләнерлек әсәрләр. Әлеге циклдагы «Кайтар мине», «Асау атым», «Күкчәтау», «Шомлы төндә», «Дантон әйткән диләр» кебек шигырьләр — тирән тәҗрибә уты балкыткан, олы мәгънә белән тулы әсәрләр. Нигә шул чаклы тарта соң үзләренә бу утлар? Сәбәбен шагыйрьдән сора. Үзе әйтер:

**Киңделәр дә керделәр.**
**Кереп түргә менделәр.**
**Уйнадылар, көлделәр**
**Шатлыклар йөрәгемдә!**

**Шатлык ул килә генә:**
**Олыга да, кечегә дә,**
**Дусыңа да, ишеңә дә**
**Яхшылык теләгенә:**

Циклда әйбәт шигырьләр күп, ә шулай да «Шомлы төндә» шигыре үзенчә бер шедевр!

Төнен, күңелгә шом салып, бер эт улый:

**Таңда китәм, шуңа улый, дисәм,**
**Мин түгел бит аның иясе.**
**Ни шомлыкка икән тагын бусы,**
**Ничек юрап, нәрсә диясе!!**

**. . . . . . . . . . . . . . . .**

**Ә теге эт улый шомлы итеп,**
**Аһ, әгәр дә улау киметсә**
**Эчләремә тулган сагышларны,—**
**Мин кушылыр идем шул эткә.**

Күрәсез, эт турында гына язылган. Заманчамы бу? Әйе, бик заманча! Мәгънәле, уйчан, фәлсәфи, сәхнәдән түгел, ялгыз гына, кулга алып укый торган (созерцательный) шигырь. Биредә кешенең табигатькә мөнәсәбәте дә, кешене кеше иткән гүзәл сыйфат — сабырлык та, гуманлылык хисе дә бар. Боларны мин нәкъ менә интеллектуаль поэзия үрнәкләре дияр идем.

Бүгенге заманда, техник прогрессның куәтле адымнары ясалган чактә, таш һәм металл арасында әнә шулай табигатькә, андагы җан ияләренә кешеләрчә мөнәсәбәт тойгысы бик табигый теләк буларак алга килә. Бүген Җир һәм Су, Җир һәм биосфера турындагы проблемалар тиктомалдан гына тумаган. Цивилизациянең һәм культураның табигатькә мөнәсәбәте проблемасы гасырлар буена килгән. Бу мәсьәлә бүген бигрәк тә зур актуальлеккә ия. К. Маркс 1868 елның 25 нче мартында Ф. Энгельска язган хатында болай ди: «Нәтиҗә шундый, әгәр дә культура стихияле рәвештә үссә, ә аңлы рәвештә максатка юнәлтелмәсә, аның артыннан бушлык кына торып калачак»[1].

Бу тирән мәгънәле сүзләрнең безнең заманга да, безнең иҗат дөньябызга да турыдан-туры мөнәсәбәте бар!

Шулай икән, табигый ки, тормыш-яшәү аренасы булган табигатьнең, кешенең табигатькә мөнәсәбәтенең шигъри сферага да бүген актив үтеп керүе бик вакытлы. Менә безнең бүгенге поэзиябез өчен беренче проблема. Борчылып, ачынып, дулкынланып язылган әсәрләр бар икән, аларда, автор үзе телиме-юкмы, яшәешебез турында бер проблема орлыгы булса да салынган була. Ә андый әсәрләр аз язылмый бездә.

Илдар Юзеевнең «Карурман» поэмасында да табигать һәм кеше темасы калку итеп куелган. Әсәрнең лирик герое «тавыш тизлегендә очкан самолетта» Идел ярларыннан «Карурман» җырын ишетә. Ул бабасының васыятьләре эзеннән бара. Әсәрнең төп мотивы мондый:

**... Кеше серләр эзли күк йөзеннән,**
**Җир астыннан, диңгез төбеннән,**
**Йолдызларга оча, атомнарның**
**Кара урманына күмелә.**

**. . . . . . . . . . . . . .**

**Ләкин кеше, ашыгып барган чакта,**
**Туар матурлыгы хакына,**
**Сандугачлы кара урманнарны**
**Күпер итә аяк астына...**

Илдар Юзеев — киң полотнолы әсәрләр, поэмалар остасы.

Гәрчә алынган проблемасы әһәмиятле, җитди булса да, сәнгать әсәре буларак, шагыйрь бу юлы әлеге поэмасын бер бөтен, программ әсәр итеп очлап җиткермәгән

[1] К. Маркс һәм Ф. Энгельс. Сайланма хатлар. Госполитиздат. 1948 ел. 202 бит.

дияр идем. Аннан соң бабасының: «Күктә очсаң да, җирне онытма!» дигән кинаяле сүзләре шагыйрьнең үзе өчен дә инде бик яңа түгел. Кабатланган фикер. Кимчелекне, барыннан да элгәре, әсәрнең шигъри тукымасы образлар, метафоралар системасына нигезләнүдән һәм характерларның тормыш күренешләренә турыдан-туры актив мөнәсәбәтләрен чагылдыру-сурәтләүдән битәр, аның сөйләүгә генә корылган булуыннан, вакыйганың артык хроникаль булуыннан эзләргәдер... Шуның белән берге әдәби әсәрне чын сәнгать таләпләре югарылыгыннан торып хәл итмәгәндә гәрчә ул халыкның киң популяр җырларына нигезләнсә дә, халыкчан һәм популяр булып җитә алмый әле.

Шулай да «Карурман» поэмасы, шагыйрьнең киң гомумиләштерүләргә, ассоциацияләргә корылган яңа биеклеге булып җитмәсә дә, гомумән, уңай, җылы тәэсир калдыра.

Әгәр шигырь, үзенең художество бизәкләреннән, сурәтләү чараларыннан өстен булырга омтылып, саф социологик караш-фикерләрне генә алга сөрә икән, ул, поэтик әсәр булудан бигрәк, публицистик мәкаләне хәтерләтә башлый. Монда Хәсән ага Туфанның әһәмиятле генә темага язылган «Кайтмый калган дуска» исемле шигыре шундыйрак тәэсир калдырды. Иллюстрация өчен бер генә өзек китерик:

... Әзерләнә фюрер сугышка;
Диктаторлык культы терелә
Көнбатышта, Берлин астында,
һәм Нерондай Бенито Римда
Азатлыкны дарга астыра,
Көнбатышта культлар терелә.

Дөрес, шагыйрь биредә бик изге хисләр белән кабынган, ул олы дуслык хатирәсен, көрәшчә дусын сагына, ил үткән кыен, давыллы юлларны күз алдыннан кичерә. Шулай да биредә — иҗатта үз шигъри мәктәбен тудырган өлкән шагыйрьнең эпик колачы, кыскасы, Туфан осталыгы җитеп бетмәгән...

Яшьләрдән Равил Фәйзуллинның «Лирик шигырьләр» циклы үзенең яктылыгы, табигатьнең, поэтик сиземләүнең төп асылын, «кабыгын арчып», бераз «ялангачландырып», кыскасы, бөтен тулылыгы, нюанслары белән укучыга җиткерергә омтылышы ягыннан аерылып тора. Биредә шагыйрьнең сурәтләү чараларының халыкчан төкъбире дә ачык күренә. Менә «Этюд-рәсем» дип аталган беренче шигырь. Яшь ана баласын йөзәргә өйрәтә:

Биеккә-биеккә
төбәлгән карашы.
Зәңгәр күк фонында —
Кояш та баласы.
Тотенсез, шартлаусыз
аларның арасы...

Аяз күк фонында кояш һәм бала сурәте. Әйтерсең лә Давид Сикейросның тынычлык турындагы фрескасыннан бер фрагмент! Табигый, илаһи! Әмма тагын да әйтеп китмичә булмый, шундый югары зәвык белән язылган полотноларга янәшә генә җиңелчә зәвыкка корылган менә мондыйрак үрнәк тә бар:

Курыкма, кол, елмай!
Кирәкми аһ-ваһлар...
Савапка торырлык
безнең бу
гөнаһлар!
Кол, елмай!..

Журналның 5 нче саны — бүгенге поэзиябезнең үзенә күрә нәни бер антологиясе. Бирелгән һәр шигырьгә аерым-аерым тукталып үтү җисмәни мөмкин түгелдер. Әмма шулай да иң характерлы үрнәк булырдай әсәрләрдән Радиф Гатауллин шигырьләрен («Утызынчы яз» дигән уңышлы гына циклын да кертеп), Марс Шабаевның табигать — заман — шәхес проблемасына караган шигырьләрен, Әхсән Баяның бәхәсле, ярсу,

заманча актив шигырьләрен, Гәрәй Рәхимнең тел бизәкләренә бай шигъри «челтәр-ләр»ен җитди уйланып, бирелеп язылган әсәрләр рәтенә кертер идем.

Зәки Нуриның «Яза авыл, яза диңгез» дигән новелласы шигъри орлыкның строфадан-строфага үстерелеше белән, вакыйганы соңгы аккордта гына гомумиләштереп, көтелмәгән нәтиҗә белән тәмамлап куюы ягыннан кызыклы:

Авыл яза, диңгез яза,
Хатлар көн дә йөреп тора.
Әйтерсең бер мәхәббәтне
Бөтен дөнья күреп тора.

Бу елгы журналда Галимҗан Латыйпның да җылы гына язылган, яңача дәрман белән сугарылган тапкыр шигырьләре бирелгән. «Шатлык һәм кайгы» дигән шигырендә:

Ә кайгыны беркем дә
Күтәралмый бирүзе.
Чөнки кайгы төбендә
Ята елан мөгезе,—

кебек халыкчан метафоралар бар.

Ләкин шигырьләрне күп очракта әсәрнең эчке дисциплинасы булмау харап итә. Шуның белән бергә, халыкчанлыкка охшарга тырышу, халыкчан сурәтләр ясарга омтылу карага ак җеп белән теккән сыман ярылып ята. Халыкчанлык ул жаргон да, имитация дә түгел. Халыкчанлык бүтән сыйфат. Ул — табигый.

Вакыт-вакыт без иҗатка җаваплылыкны киметеп җибәрәбез дә, әдәби җилбәзәклеккә бирелеп, үзебез сизмәстән, уенчык күл дулкыннарында уенчык аккош кебек тирбәләбез:

Читләтүең — чикләвеңме!
Бер кыюга — мең тыю...
Ах, аллә сиңа рәхәтме
Кеше җаннарын кыю!

Сөйсәң сөй, сөймәсәң сөймә,
Урталыгың — үртәвең.
Ах алла, мин үталмыйммы
Җилпеп күлмәк итәген...

Яисә:

Ах алла, мин көталмыйммы
Сабырлыгың сынганын!

Ирексездән Кармен монологы хәтергә килә. Юк, моңарчы бер дә җилбәзәклек күрсәтмәгән, сәләтле шагыйрә Саҗидә Сөләйманова, кызганычка каршы, журналга әнә шундый салончарак зәвыклы шигырь биреп куйган.

Без, хаклы рәвештә, Советларның бөек, бердәм семьясындагы һәр ирекле, хөр милләте кебек үк, үзебезнең милли казанышларыбыз белән горурланабыз. Соңгы елларда язылган шигырьләргә генә күз төшерик: алар моңа дәлил. Ләкин мәсьәләгә риторик, «лобовой» якын килү күренешләре дә бар. «Мин — татар» дигән риторик дәгъваны, минемчә, әсәрнең художество чараларында эретеп, нәфис итеп, чын милли нәкышле сәнгать әсәре итеп бирергә дә мөмкин булыр иде бит. Күп очракта без моны артык туры ярып кына хәл итәбез:

Бу көйләрдә
Көнбатыш та, көнчыгыш та түгел,
Үз аһәңе шушы якларның.
Бу моңнарда мин тарихын таныйм,
Кан тибешен таныйм татарның.

К. Булатова шигырендә дә башта әйткән нәфислек, татар сүзенең сәнгатьчә кулланылышы җитми кебек.

Бездә берәр авторның аерым бер уңышлырак әсәренә карап, аның бөтен иҗаты, шул бер уңышлы шигыре буенча хәтта шагыйрьнең шигъри дөньясы турында фикер йөртү гадәткә кергән. Аерым уңышлы детальләр, табышлар, алар нинди генә уңышлы булмасыннар, әлегә барыбер шагыйрьнең шигъри дөньясы түгел, бәлки иҗатының аерым өлгеләре генә. Һәр шигырьнең кичерешләр һәм иҗат газаплары аша килгән поэтик биографиясе булырга тиеш. Әнә шундый шигъри биографияләрдән төзелә ул шагыйрьнең иҗат дөньясы! Озак төзелә! Кайчак шагыйрьнең билгеле бер тынлык кичергән чагы да булуы бар. Шунда аның хакында «пассивлашу» дигән ашыгыч караш та туар. Әмма бу чор шагыйрьнең «тирәнлеккә», «тамырга» үскән чагы булырга мөмкин.

Иҗатның «тын үсеш» периодын Э. Хэмингуэйның мәгълүм айсберг теориясе мисалында аңлату бик урынлы булыр кебек. Айсбергның — йөзмә боз тавының — без су өстендәге өчтән бер өлешен генә күрәбез, ә калган ике өлеше — тирәндә, суга күмелгән.

Әйткәнемчә, шагыйрьнең иҗади дөньясы, аның поэтик биографиясе тирәннән, төптән күтәрелә, иҗат газаплары эчендә туа, дәвамлы кичерешләр эчендә туа. Аның каравы, үзенең поэтик дөньясын тудырган әдип — бәхетле әдип!..

Мәгълүм ки, кайбер әсәрләр, алар ничек кенә төзек, ыспай эшләнмәсеннәр, укучыда резонанс тудыра алмыйлар. Резонанс юк дип мәкалә-рецензияләр дә язып карыйлар аларга, үзенчә тылмачлык та иткәлиләр. Әмма барыбер әсәр тирәсендә тынлык кына. Әллә ул шул салкын айсбергмы, мәгънәсе төптәрәкме? Әллә алар салкын рациональ гакыл җимешләре генәме? Мин бу хәлне, барыннан да бигрәк, әсәрнең үзенең поэтик биографиясе белән дөньяга килмәвендә дияр идем. Мондый әсәрләрдә җанлы шигъриятнең кайнар каны типми сыман...

Мин Камил Мостафинның журналда чыккан шигырьләрен, субъектив фикерләргә бирелмим дип, кайта-кайта укыдым. Җыентыкларын да укыганым бар иде. Аның шигырьләре, бер караганда, романтик рух белән дә өртелгәннәр, вакыйгаларның иң җитди штрихларын гына, характерлы төсмерләрен генә тотып калырга омтылалар сыман. Сүз дә юк, төзек, җыйнак, матур гына шигырьләр! Үз тәэсирләремне ачыктаначык әйтүдән авторның хәтере калмасын, ничектер пөхтә, әмма сәхнә бутафориясе кебек салкынрак тәэсир калдырды алар миндә. Техник осталык белән төзелгән шигырьләрнең нигезендә китапчыл романтика ята кебек. Шигырьләрне укыганда, авторның исемен күрмәсәң, кайсы еллар әсәре бу? дигән сорау да туар иде, ихтимал. Бу нәрсә дә, бәлки, үз иҗат биографияң анык булмаудан киләдер? Мәсәлән, менә «Тачанкалар» дигән шигыре, эчтәлеге белән димим, конструктив элементлары, сүзләр төзелеше белән ничектер 30 нчы еллар шигырьләренә охшаш сыман. Аның «Йөгән» дигән шигыреннән бер өзекне мин авторның үзенең интонацион бүленешләре белән китерәм:

**Уйларыбыз инде**
**ак ватманга**
**кырыс чертеж булып**
**яттылар.**
**Тик һаман да**
**аның сызыклары**
**үсмер чакның серен саклыйлар.**

Бу интонация үткән еллар поэзиясен хәтерләтә. Бу минем шәхси фикерем генә, әлбәттә. Һәрхәлдә, мин шулай кабул итәм. Биредә мин шулай ук әдипкә ниндидер рецепт та тәкъдим итәргә җыенмыйм. Бәлки, бу аның үзенең принципиаль юнәлешедер? Шагыйрь әле үсештә. Шулай булгач, аның иҗатына кагылган бу фикерләр һич тә ниндидер абсолют бәягә дәгъваламыйлар...

Минемчә, авторга күбрәк рус поэзиясе дөньясы йогынты ясый кебек.

Югарыда китерелгән мисаллар шулай ук билгеле дәрәҗәдә безнең һәркайсыбызга да кагыла. Сер түгел, еш кына чын иҗат утында тумаган, салкын, «балык канлы» шигырьләр дә дөньяга чыгып куйгалый.

«Казан утлары» — зур, олы иҗат мәктәпләре журналы. Анда кеpү — кердeлeчыктылы булмасын, ә вакыйга саналсын иде.

Тагын. Иҗади эзләнүләрнең бер яссылыкта, бер юнәлештә баруы вакыт-вакыт үзен нык сиздертә. Бер үк образ, бер үк әйләнмә, бер үк чалымнар шагыйрьләрдә кайчак уртакка да әверелә.

Зөлфәтнең җылы һәм образлы язылган, уйландыра торган «Еpактагы гудок» исемле бер шигыре бар. Ераклашып барган поездга карап, шагыйрь:

Узды поезд, бер вагонда исә
Минем урын китте
буш инде,
Алда торган җәйләр — минсез җәйләр,
Аппак кышлар —
минсез кыш инде...
Китте поезд,
мин эшлисе эшләр,
Мин йөрисе юллар киттеләр...—

ди.

Чираттагы 5 нче санны ачабыз. Анда Мөдәррис Әгъләмовның «Хәерле юл сүзгә!» дигән шулай ук кайнар хисле, темпераментлы гына шигыре басылган.

Әнә шулай бер китәрбез дә без
һәм кайтмабыз,
тол калырлар көзләр.
Тол калырлар җәйләр, кышлар, язлар,
без үтелгән юллар тол калырлар...

Күрәнә ки, ике шигырьнең дә поэтик ачкычы бердәй, бер яссылыкта. Бу ике шигырьнең хикмәте бер образ орлыгыннан шытканын күрү кыен түгел. Ә шигырь язган кеше шигъри орлыкның ни икәнен бик яхшы белә инде ул! Орлыгы гына булсын! Аннан соң шигырь языла инде! Әлбәттә, мин биредә образ турыдан-туры күчереп алынган дияргә җыенмыйм. Шулай да мондый охшашлыктан безгә ераграк, саграк булу хәерле.

Менә тагын бер мисал. Мин биредә, ике авторның шигырьләреннән икешәр юл алып, аларны янәшә куям:

Саргылт чәчле, зәңгәр күзле кыздай
Көз сыенды безнең кочакка.
(1963 ел.)
Сары чәчен иңнәренә салып,
Назлы кызлар сыман минем тездә
Көз утыра...
(1972 ел.)

Беренче вариант инде моннан ун ел элек дөнья күргән. Ә соңгы вариант «Хәерле юл сүзгә!» дигән шигырьдән китерелде. Ике шигырьдә дә, мисалдан күренгәнчә, көз сары чәчле кыз образында китерелә. Беренче авторда ул «безнең кочакка сыенса», М. Әгъләмовта исә «тездә утыра»! Мин моны мәзәк өчен түгел, ә безнең бер-беребез иҗатына әнә шулай игътибарсызрак каравыбызның типик бер иллюстрациясе буларак китерәм.

Безгә бер-беребезгә шигырьләрдәге образларны, төсмерләрне кабатлау гына түгел, шигырь исемнәрен дә, җыентык атамаларын да кабатлау килешми. Моннан янә үзенә бер проблема килеп туа: приоритетка һәр чак хөрмәт булырга тиеш! Иптәшеңнең, каләмдәшеңнең иҗатына саксыз карау — үзеңне хөрмәт итмәү дигән сүз ул.

Тагын алда телгә алынган шигырьдә:

Ил уллары хезмәтләрен илгә
бирерләр дә
китеп югалырлар...—

дигән юллар бар.

Гомер чылбыры — тоташ. Бер уллар китсә, икенче уллар һәр даим килеп тора... «Югалырлар» сүзе, бу очракта, үзенең фәлсәфи-логик трактовкасы ягыннан бик үк төгәл түгел, дию.ем. Әлбәттә, аерым шәхесләр кабатланмый. Ләкин бит шагыйрь бу урында аерым шәхесләр турында сөйләми, ә бәлки «ил уллары» дигән гомуми төшенчә белән эш итә.

Ни өчен тагын мин бу шигырьгә тукталдым? Мәсьәлә менә нәрсәдә. Дөньяның, җир тормышының фанилыгын әнә шул рәвешле «ике җирдә икең — дүрт» кебек гади, раслауны, исбатны сорамый торган, болай да котылгысыз күренешләрне шигырьгә салып әйтү безнең шигъриятгә бүген еш-рак күренә башлады. Мондый әсәрләр үзләренең чишелешләре, эшләнешләре белән түгел, ә бәлки, сайлаган темалары, масса зәвыгына ярашырга-җайлашырга омтылышлары белән отты ралар.

Бер мәшһүр шагыйрь әнә шул «китүләр» хакында, фәлсәфи һәм тыйнак кына итеп болай дип язган иде:

**Яктырыр һаман хәвефсез бу җиһан,**
**Кузгалмас хәтта җирдәге бер тузан!**

Чыннан да, хас шулай түгелмени?

Миңа М. Әгъләмовның журналның 8 нче санындагы «Учак урыннары» дигән шигыре үзенең самимилеге, яңалыгы, борчулы хисләре белән ошады. Логикасы тормышчан, актив, ышандырырлык: биредә инде тынгысыз шәхес үзе бар, сәләтле шагыйрь каләме сизелә!

Поэзия, әлбәттә, гавами төшенчә; ул безнең бөек ачышлар заманында уй-тойгыларны трансформацияләүнең бер юнәлеше, эмоциональ төре. Бер халык, бер ил поэзиясе дә бер-береннән «кытай стеналары» белән бүленмәгән! Шулай икән, бу өлкәдә безнең гавами мәктәбебез, аудиториябез бар дигән сүз. Өйрәнүләр — һәр шагыйрьнең гомерлек юлдашы. Бу өлкәдә испан Лоркаданмы, поляк Тувимнанмы, төрек Хикмәттәнме, илебездәге рус һәм башка тугандаш милләт шагыйрьләреннәнме, яисә үзебезнең классикларыбызданмы, иҗади өйрәнүнең бер гөнаһысы да юк. Бу исә илебездә милли культураларның үзара үрелеп-якынлашып үскән чагында, интернациональ рух белән баеп, сугарыла барган чагында хупланырлык күренеш кенә! Әлбәттә, өйрәнү иҗади булганда. Без биредә бер-беребезне кабатлау, таптану, образлы итеп әйткәндә, бер шигъри йортны икенче бер йорт өчен «бүрәнәгә сүтү», акрынлап-акрынлап сүтү, ниһаять, шуңа охшаш тагын бер шигъри йорт «тезеп-сипләп» кую кебек саф механик күчерү, шуның соңгы нәтиҗәсе булган эпигонлык турында сүз дә алып бармыйбыз, билгеле! Әммә, кемнән генә өйрәнсәң дә, сүзең шигъри булсын, укучы йөрәгә кабул итәрдәй булсын, үзеңнеке булсын! Шигърият, гәрчә газеталарның әдәби рубрикаларында «шигърият агачы» диелсә дә, ул агач түгел, көчсә-каерысын ярып, аңа чит-ят бөре ялгап үстереп булмый. Поэзия дә, кеше организмы кебек үк, ялгауны, күчереп утыртуны кабул итми. Поэзия күзәнәкләрендә дә биологик сыешмау-килешмәү дигән нәрсә бар. Әгәр дә кем дә кем алда әйтеп киткән биологик закончалыкка хилафлык кыла икән, ул барыбер әдәби конъюнктурадан башка нәрсә тудыра алмый. Бу «иҗат», өрелгән шар кебек, йөрәк белән күк арасында очып йөри — очып та китми, җиргә дә төшми. Чөнки ул иҗатчының үзенең чын илһамы түгел, ә сүз куыгы гына! Әдипнең иҗат үзенчәлеге, осталыгы аның табигыйлегеннән башлана. Ә инде салкын исәп-хисап, салкын гакыл белән ясалган шигырьләрдә бизәк-нәкышләр дә ясалма була. Мондый шигырь — чын шигырьнең карачкысы, муляжы гына.

Менә шушы төштә инде әдәби тәнкыйтьнең зарурлыгы бөтен киңлегенә ачылып китә. Мин поэзия турындагы бу күзәтүне язганда һич тә безнең шигырь тәнкыйтенә битараф булып кала алмыйм. Шуның өстенә, әлеге саннар андый тәнкыйтькә аеруча мул.

## Тәнкыйть — шигърият юлдашы

Безгә килачакта журналның һәр санын аерым тикшерү кирәктер. Юкса, безнең аваз бүгенге әдәби хәрәкәт күгендә реактив очкыч авазыдай артка кала. Яңа әсәрләрне укып-күзәтеп баруда оперативлык, өлгерлек җитми, тәнкыйть күзе җитми.

Без һәртөрле йомгакларны яратабыз. Алар инде безнең традициягә әйләнгән.

Йомгакларга без туйга җыелгандай бик теләп җыелабыз. Йомгаклап та куябыз. Ләкин ничегрәк йомгаклыйбыз соң? Без Тукай клубыннан таралуга, йомгак та «сүтелә» башлый. Нигә дисәң, күбебез бер-беребезнең иҗатын укымыйбыз, белмибез, ә бары якынча гына, ишетмеш-белмеш буенча гына фикер йөртәбез. Гомуми резонанска бирелеп кенә кул чабабыз. Менә шушы «Казан утлары»нда басылган берничә шигырь белән генә син берәр шагыйрьне йомгаклап кара инде! Ул бу йомгакка ничек сыйсын ди? Ул бит һәр даим хәрәкәттә. Ә бит без күбесенчә бу «йомгакка» журналда чыккан әсәрләр белән генә дә керәбез. Күп вакыт бер ике шигырь белән дә керәбез. Аннан соң шул бер-ике шигырь буенча тәнкыйтьче ясаган йомгак, ел үтеп, икенче елның яртысына, хәтта аннан да ары тәгәрәп китүчән була. Ел эчендә иҗатта нинди үзгәрешләр тумас? Ә йомгак шул хәлендә тәгәрәвендә дәвам итә. Инде инерция белән тәгәри. Ә бит принципиаль, объектив тәнкыйть иҗаттагы һәрбер үсеш-үзгәрешне объектив бәяләп барырга тиеш. Тәнкыйтьче ул — әдәби үсешнең гадел хөкемдары, үзенә бер арбитры! Тәнкыйтьче өчен гражданлык намусы — доктор өчен Гиппократ анты белән бер булырга тиеш. Бу кулларда гаделлек бизмәне чайкалмасын иде!

Гадел булу гына да җитми. Гадел булу өстенә, тәнкыйтьче әле тирән белемле, зур эрудицияле галим кеше дә булырга тиеш. Шунсыз ул әдәби күренешләр турында тәпле фикер әйтә алмаячак. Шагыйрьнең гражданлык йөзе турындагы мәсьәләне алыйк. Безнең тәнкыйтьтә ул әле һаман берьяклырак аңлатылып киленә шикелле. Миңа калса, чын мәгънәсендә гражданин булу өчен шигырь азагына өчәр өндәү билгесе куеп, «Мин гражданин!!!» дип оран салу гына җитми. Ә бәлки, шушы көндәлек тормышта, шушы мәшәкатьле дөньяда туган халкыңның шатлык-куанычларын, кайгы вә сагышларын уртаклашып яшәү кирәк. Безнең һәркайсыбыз кирәкле уртак эш башкара, юлыбыз — уртак. Без — төрлеләр. Әмма бу йөк безнең барыбызның да җилкәсенә тигез төшә. Шулай икән, безнең арада әдәбият язмышын хәл итү өчен күктән җибәрелгән пәйгамбәрләр юк һәм булуы да мөмкин түгел!

Халыкчанлык һәм гражданлык — бертуган төшенчәләр. Кәрәшләр тулы бу яшәештә иманыңа тугрылыклы булып, халкың белән бергә иңгә-иң яшәү — үзе гражданлык. Хәтта туган җирнең үлән-чәчкәсе хакында җырлау да — гражданлык. Ниһаять, мондый цивилизация һәм техник прогрессның металл кочагында кешенең кеше булып, шагыйрьнең шагыйрь булып калуы — үзе гражданлык! Гражданлык ул тормышка һәм аның һәртөрле күренешләренә һәр даим гадел мөнәсәбәт эчендә шыта, үсә, чәчәк ата.

Әдәбиятта гражданлык турында үзәк матбугатта да, бездә дә күп санлы чыгышлар булды һәм булып тора. Бу төшенчәне теоретик яктан җентләгәндә без ялгышмыйбыз, безнең фикерләр бу яктан хрестоматиягә кертерлек. Ә менә көндәлек әдәби хәрәкәттә без әле күп вакыт бу төшенчәне берьяклырак аңлыйбыз. «Гражданлык та гражданлык!» — дип кабатлый торгач, хәтта әдипнең гражданлык активлыгы белән аның делецлык активлыгын бергә бутый башладык шикелле. Әдип тормышта кайный, ишекләрне кыю ачып керә, мәсьәләләрне кабыргасы белән куя. Әлеге активлыкның үтә шәхси мәнфәгатьләрне алга сөргән активлык булуы да мөмкин. Аннан соң без, шул рәвешчә дәвам итеп, гражданлык төшенчәсен шул чаклы примитив аңлауга барып җитәбез ки, без әдипнең иҗаттагы гражданлык активлыгы белән аның тышкы, саф биологик-импульсив активлыгын бергә бутап йөртә башлыйбыз. Болар икесе ике нәрсә!

Буш вәгазь һәм коры дидактика да кайчагында гражданлык битлеге артына яшеренергә тырыша.

Инде иҗади зәвыклар мәсьәләсенә килик.

Шунысы гаҗәп, бүгенгә чаклы шигърияттә примитивизм турында беркем дә, бер тәнкыйтьче дә бер сүз әйткәне юк.

Менә бер типик хәл: тәнкыйтьчеләр генә түгел, хәтта бүтән жанр, әйтик, проза вәкилләре дә шагыйрьгә: «Син инде алай кырлап-сырлап торма, турыдан әйт!» — дип киләләр. Дөрес, гадилек бер хәл ул. Бу кадәресе аңлашыла. Ә бит шигырьнең прозадан аермалыгы да, шигырьне шигырь иткән нәрсә дә шунда: ул күбрәк образлысынландыру категориясе белән эш итә торган жанр. Күргәнеңне турыдан-туры сөйләп кенә бирсәң, ул проза, ай-һай, проза гынамы әле, аның да үтә лобовое, гади информация генә булыр иде. Проза да бит гомумиләштерүләр һәм образлар системасы

белән эш итә. Аннан соң шагыйрьләргә бирелә торган тагын бер типик бәя, бусы күбрәк рецензияләрдә очрый инде: «Шагыйрь күкләргә менми, шигырен бизәкләргә төрми, катлауландырмый, аның шигыре бик гади». Нинди бит әле? дигән сорау туа. Гадиме, әллә примитивмы? Үтә гадилекне шулай мактау төссез, шаблон, бернинди шигъри осталыкка ия булмаган кустарьчылыкка юл ача түгелме соң? Гади тел белән язылган дигәне күбрәк метафорасыз, тоташ сөйләп чыгылган тезмәләр хакында инде. Ә метафора, образлы тел белән, хисләр белән өртелгән, кирәк урында киная һәм фәлсәфи гомумиләштерүләр белән язылган шигырьләр чуар, купшы, халыктан ерак, аңлашылмый булып чыгалар, имеш! Шигырьне укучыга «чәйнәп бирү» нигә? Түбән зәвыкка адымның башы нәкъ менә шундый «бәяләрдән» башлана да инде!

Бүгенге заманда, кеше миен интеграллар һәм исәп-хисап машиналары алыштырган заманда, экспериментлар, атом генераторлары, лазерлар һәм циклотроннар чорында халыкны, укучыны интеллектуаль тәрбияләү, иң зур матурлык фәне булган кеше күңеленә олы мәхәббәт тәрбияләү — төп проблемаларның берсе санала.

Шагыйрьләр ишәя, шигырь мәктәбе киңәя, инде белемле кешегә импотентлыкка якын тойгыларны рифмага салу бер дә кыен мәсьәлә түгелдер! Төрле үлчәмдә, төрле калыпка салып та! Чү! Сабыр... Менә шушында инде хәлнең иң хәтәре яшеренгән... укучы карашында шигырьнең бәясе төшәргә мөмкин. Дөрес түгелмени? Без адым саен шундый күренешкә тап булабыз, берәү әйтә: «Мин дә, брат, шигырь язам әле, әлегә бастырганым гына юк». Янсә икенче берәве: «Мин дә, энекәш, шигырьдән башлаган идем; менә хәзер инде, күрәсеңме, романнар язам. Иҗатның беренче адымы әнә шулай шигырьдән генә башлана инде ул, аннан, акрынлап, «прозага...» Бу сүзләргә тагын комментарий кирәкмидер шикелле. Алар үзләре сөйлиләр. Димәк, яңа бурычларыбыз нидән гыйбарәт? Барыннан да элек, шигъри иҗатның абруен тагын заманча бер баскычка күтәрү. Аны һәртөрле коммерция һәм шаблон күзлекләреннән югары күтәрү. Моннан, димәк, үзеннән-үзе аңлашылганча, без алдан телгә алган интеллектуаль зәвыкны югары үстерү шартына әйләнеп кайтырга мәҗбүрбез.

Бүгенге шигырь — интеллектуаль шигырь.

Бүгенге шәхес — культуралы, интеллектуаль, көрәшче шәхес. Гаделлек сакчысы. Менә шушы урында инде шәхеснең гражданлыгы да, әдәби осталык та, халыкчанлык та һәм иҗат өчен һава белән су кебек зарур булган башка сыйфатлар да бергә берләшә.

Димәк, бүгенге шигърият үзенең югары интеллектуаль тойгы-фикерләргә бай булуы белән бәяләнергә тиешледер.

## «Йомгак»ның очы

Шаблон ничек туа?

Аның механизмын аңлау артык кыен түгел. Ул, әлеге дә баягы, шигъри иҗатка уптым-илаһи караудан, әдәби тәнкыйтьнең сайлыгыннан, үзенең дә санауга, комплиментарлыкка һәм схематизмга нигезләнгән булуыннан, шигъриятка берьяклы, утилитар карашыннан киләдер. Мондый тәнкыйть, гадәттә, шигъриятнең инструментовкасы дигән төшенчәдән ерак тора. Әйтергә кирәк, һәр авторның иҗат лабораториясенә зирәклек белән үтеп кереп, аның индивидуаль үзенчәлекләрен һәм һәр аерым әсәрнең заманча рентабельлеген күрсәтү җитми әле.

Тәнкыйтьтебез адресына әйтелгән бу фикерләрдән: «Бу кеше — тәнкыйтьнең дошманы икән!» дигән фикер калмасын тагын. Мин чыгышымның тәнкыйтькә караган өлешен: «Тәнкыйть — поэзиянең юлдашы»,— дип, юкка гына атамадым.

Тагын бу өлкәдәге котылгысыз хакыйкатьтә тукталмый буймый: әгәр дә шагыйрьнең күңел дөньясы сиңа ошап бетми икән, билгеле ки, аның шигырьләре дә сиңа ошамаска мөмкин. Бу — бер дә гаҗәп түгел. Мондый очракта аңа карата скептик фикер күңелне биләп алырга да мөмкин. Сер түгел, бездә шәхеснең ошавы-ошамавына карап, аның иҗатына да шундый мөгамәлә яшәп килә.

Ә менә бу яктан инде объектив тәнкыйть чын батырлык үрнәге күрсәтә! Шәхси вә субъектив карашлар инде тәнкыйть сферасы түгел. Тәнкыйтьченең кыйбламасы — принципиальлек, антипатияләр һәм симпатияләрдә дә үз-үзен җиңәрлек принципиальлек.

Мин Балтик буе республикаларының үзәк әдәби журналларындагы поэзия буенча тәнкыйть мәкаләләрен кызыксынып күзәтәм. Анда һәр әдипкә аерым индивидуаль якын килenә. Тәнкыйть үзе дә шигъриятнең үзе кебек — иҗади тоемнарга, нюансларга гаҗәп бай! Аларда һәр әдипнең үз төсмере, үзенчәлеге бар.

Чын иҗат, индивидуаль иҗат нинди дә «тигезләүне», стандартка салуны кичерә алмый.

Шаблонның тууы нәкъ менә әдәби тәнкыйть фәнендә җентекле классификациянең булмавыннан, иҗади процессның асылына кермәүдән киләдер.

Ә бит һәр шәхеснең, ничек кенә булмасын, үз төсмере, үзенең стихиясе, үз полутоны, үз атмосферасы, ниһаять, үз дөньясы бар! Аларны ничек тигезлисең дә ничек бутыйсың?

Мин аларның авазларын аерым-аерым ишетәм. Менә лирик-романтик пландагы Р. Гатауллин, менә фикри шагыйрь Р. Фәйзуллин, эмоциональ зарядлы Зөлфәт, менә фольклор-этнографик юнәлешле М. Әгъләмов, менә сүзләр стихиясен яраткан Г. Рәхим, менә орнаменталист Р. Харис, халык авыз иҗатыннан килгән Рәшит Әхмәтҗанов...

Поэзиядә боларның һәркайсының кабатланмас үз урыны бар. Бу иптәшләрдән тыш әле исемнәре әледән-әле «Казан утлары» журналы битләрендә күренгән шагыйрьләрдән Р. Вәлиев, Ф. Сафин, К. Сибгатуллин, Ә. Рәшитов, Ә. Гадел, З. Насыйбуллин, Ф. Гыйззәтуллина, Б. Сөләйманов, С. Гәрәева һ. б. күпләрнең исемнәрен дә саный китсәң, бүгенге шигърият аренасы әдәби алмашка нинди мул дип сокланасың.

Үзем үк таныйм, мин дә санауга күчтем бугай. Исемнәр әле болай да кала. Нишлим, журналга кергән һәрбер авторның исемнәрен генә санау да бик озынга китәр иде...

Исемнәре, әйе, күп! Шигырьләр дә күп! Әмма иҗади табышлар төрлелеге һәм муллыгы бик үк шатландырырлык түгел диясе килә.

Соңгы вакытта, минемчә, традицион формаларга кайтуны гел уңай күренеш дип артык бәяләп килүдәндерме, форма өлкәсендә эзләнүләр юк дип әйтерлек. Бездәге: «Булмаганны эзләмәскә, булганны дәвам иттерергә!» — дигән карашны, минемчә, бу яктан бик үк прогрессив караш дип әйтеп булмый. Эзләнү дигәндә, билгеле, буш пространствода капшану күздә тотылмый. Бу — поэзиядә яңа төсмер, баерак сурәтләү чаралары тудыру юнәлешендә эзләнү, эшлекле эзләнү. Үзеңнең шигъри дөньяңны төзү ул әзер калыплар белән генә барып чыкмый, билгеле. Аннан соң кайберәүләр, тоталар да, ачынып: «Нигә хәзер Такташлар юк?» диләр. Андыйларга: «Такташлар булмаганга Такташлар юк», дип кенә җавап биреп тә булмый. Биредә чорны, мохитны, шәхеснең кабатланмавын ничек инде истән чыгарасың? Әйе, Такташлар бөек. Ләкин аларны нигә кабатларга? Бу теләк аларга хөрмәт белән карамау дигән сүз түгел, киресенчә, аларны үз пьедесталларында калдыру һәм аларның кабатланмас исеменә төрле куллар кагылудан саклау өчен дә кирәктер.

Иҗатта мәйдан — чиксез!

Заман яңа проблемалар куя тора.

Шуларның үзәгендә — Кеше һәм аның интеллектуаль дөньясы, гаделлеккә һәм хаксызлыкка, иҗатка һәм төзүләргә, җимерүгә һәм көчләүләргә аның заманча мөнәсәбәте тора.

Әле шигырьгә тар урынчылыктан арынып, гомумкешелек карашлары югарылыгыннан фикер йөртү кирәк. Өй түшенчәсе — заман давылларыннан ышыклана торган шәхси кабырчык түгел. Синең өеңә дә шул ук галәмнең радиоактив дулкыннары кагыла. Искелекнең тузаны синең дә күзеңә керә.

Әмма гомумкешелек карашлары дигәч тә, бу — гигантомания һәм пацифистлык карашлары дигән сүз түгел, бу — туган җирнең үз улы булу тойгысы тудырган карашлар!

Бу җәһәттән шагыйрьләрне шигъри атмосфераның үтә тыгыз катламнары көтә!

Бу тыгыз катламнарда янсаң да ярый, ичмасам!

«Казан утлары» журналы исә киләчәктә дә әдәби мирасыбызга мәңгелек ут булып, иҗат индивидуальлекләренә хөрмәт уты булып, иҗади эзләнүләрне яктыртып, кыскасы, «Казан утлары» — заман утлары булып, балкып янсын!

Флүн Мусин

# ЮГАРЫ СӘНГАТЬЛЕЛЕК ӨЧЕН

*Бүгенге проза турында сөйләшәбез*

Бу сөйләшү башланганга инде шактый вакыт үтте. Игътибар белән күзәткән укучы аның саннан-санга колач җәя һәм җитдиләнә баруын күрер. Сөйләшүгә яңадан-яңа авторлар килеп кушыла. Алар үз мәкаләләрендә хәзерге прозаның төрле якларына игътибар итәләр, аның төрле мәсьәләләрен күтәрәләр. Әмма барлык чыгышларны бер хис — прозабызның идея-эстетик дәрәҗәсе турында тирәнтен уйлану, аның сыйфатын тагын да күтәрү хакында чын күңелдән кайгырту хисе үзара якынайта.

Хәзерге татар прозасының тематикасы укучыда азмы-күпме канәгатьләну тойгысы уятырга мөмкин. Һәрхәлдә, әдипләребезне заман тормышына игътибарлары җитмәүдә гаепләргә урын юк. Сер түгел, элегрәк елларда бу яктан әллә ни мактана алмый идек. Хәзер прозаикларыбыз заман белән бергә атларга, республика тормышындагы зур үзгәрешләрне оператив рәвештә әдәбиятта чагылдырырга омтылалар.

Әмма бирелә икенче бер хәл борчу уята. Әдипләребез заман тормышына, аның яңа күренешләренә активрак мөрәҗәгать иткән саен алар иҗатының сәнгатьлелеге кими бара шикелле. Һәрхәлдә, соңгы еллар прозасының заман темасына багышланган күп кенә әсәрләре белән танышкач шундыйрак фикергә киләсең. Кыскасы, прозабызның эстетик дәрәҗәсен күтәрү, минемчә, хәзер һичкайчандагыга караганда да актуальрәк тора. «Казан утлары» битләрендә бара торган сөйләшүдә катнашучыларның нәкъ менә сыйфат мәсьәләсенә басым ясаулары да шушы хәл белән аңлатыладыр, күрәсең.

Бу мәкаләдә мин дә бүгенге прозабызның идея-эстетик дәрәҗәсенә, сыйфатына кагыла торган бер-ике мәсьәләгә тукталмакчы булам.

## Исем һәм җисем

Соңгы вакытта теге яки бу милли әдәбиятның җитлеккәнлеге турында сөйләгәндә роман жанрының прозада үзәк урынны алуын төп дәлилләрнең берсе итеп китерәләр. Дөрестән дә, роман әдәбиятның иң камил һәм синтетик формасы һәм ул, һичшиксез, прозаның җитлеккәнлеген күрсәтә торган факт булып саналырга хаклы.

Безнең прозага килсәк, аның алтмышынчы елларда нык җитлегүе турында сөйли торган әсәрләр рәтендә мин иң беренче булып А. Расихның «Ике буйдак» романын әйтер идем. Аңарда әдип хәзерге тормышның безнең әдәбият өчен яңа булган өлкәләренә тирәнтен үтеп керә. Әмма фән дөньясын күрсәтү авторның бердәнбер

максаты түгел. А. Расих бу дөньяның үзенчәлекле якларын сурәтләү белән генә чикләнми, бәлки анда хәзерге тормышның гомум игътибарга лаеклы мәсьәләләрен эзли. Әсәрдә гражданлык хисе белән рухи мещанлык арасында кискен көрәш бара. Ул үзәк геройлар Рәхим Шәйхрамов белән доцент Заһид Сафичның үзара мөнәсәбәтләрендә туган конфликтта тулы гәүдәләнеш таба. Әсәрдә мондый конфликт булу аның сюжет-композициясен дә гаҗәп төзек иткән. Анда һәр детальнең, һәр образның үз урыны бар һәм алар барысы бергә әсәрнең төп идеясен ачуга булышалар. Кыскасы, заманның мөһим мәсьәләләрен күтәрү, әсәр идеясен һәм образларны эзлекле рәвештә үстерелгән динамик конфликтта ачу, кеше тормышының шәхси һәм иҗтимагый өлкәләрен үзара органик бәйләнештә карый алу — «Ике буйдак»ның уңышын тәшкил иткән төп факторлар.

Соңгы елларда бездә моннан башка да күп кенә романнар дөнья күрде. Әмма аларның барысы да прозаның җитлеккәнлеге турында сөйлиме? Мин үзем бу сорауга уңай җавап бирә алмыйм. Чөнки безнең кайбер романнар үз жанрларының таләпләренә җавап бирә алмыйлар, ягъни аларның исемнәре җисемнәренә туры килми. Мисалга минем бөтенләй уңышсыз яки бик йомшак әсәрләрне түгел, бәлки күп кенә күркәм сыйфатларга да ия булган романнарны аласым килә. Менә А. Гыйләҗевнең «Урамнар артында яшел болын»ы. Ул, барыннан да элек, авторның идея-эстетик эзләнүләрендә кызыклы үзгәрешләр хасил булу белән дикъкатьне җәлеп итә. Мәгълүм ки, бу китапка кадәр язылган әсәрләрендә А. Гыйләҗев күбрәк заман герое булудан ерак торган шәхесләр белән кызыксына иде һәм аның иҗаты берьяклырак төс ала башлаган иде. Үзенең беренче романында исә автор үзәккә күп яктан уңай булган шәхесне куя. Ул — журналист Идрис. Уңай герой дигәч, ул үзе тагын әллә ни шаккатырырлык эшләр дә эшләми. Аннан соң Идрис, гомумән, гадәттән тыш шәхес булуга дәгъва итми. Ул — гадәти кеше, аның шәхси тормышы да ал да гөл түгел. Мәсәлән, авыру хатыны Диләә аны тирән кичерешләргә дучар итә. Балалары булмауны герой авыр кичерә. Әмма Идриснең үзенә карата ихтирам уятырдай бер матур сыйфаты бар. Ул тормышта гаделлек өчен тырыша. Дөрес, монда да герой әллә ни батырлыклар күрсәтми. Гомумән, күпләр белән полемикага кереп, автор бу образ аша тормышның без кечкенә дип уйлый торган мәсьәләләрендә зур тенденцияләр күрүче кешене, шуларда гаделлек өчен көрәшүчене күрсәтергә тели.

«Урамнар артында яшел болын» романының тагын бер әһәмиятле сыйфаты аңарда заман героен интеллектуаль шәхес итеп күрсәтергә омтылуда чагыла. Мәгълүм ки, безнең күп кенә әсәрләрдә уңай геройлар еш кына рухи яктан шактый чикләнгән һәм ярлы шәхесләр булып алга басалар. Алар үзләренең көндәлек тормышлары һәм хезмәтләреннән башка нәрсә белән рәтләп кызыксынмыйлар. Замандашларыбызны болай ярлыландырып сурәтләүгә каршы чыгып, А. Гыйләҗев үз геройларын рухи ихтыяҗлары, интереслары киң һәм күп төрле булган шәхесләр итеп күрсәтергә тели. Дөрес, биредә автор һәр вакыт максатына ирешә дип булмый әле. Әсәрдәге сәнгать, фән һәм техника, халыкара хәл һәм политика буенча телгә алынган кайбер мәгълүматлар һич тә геройның интеллектуаль дәрәҗәсе югары булу турында әйтмиләр. Алар, бу сөйләшүдә катнашкан тәнкыйтьче Р. Сверигин бик хаклы әйткәнчә, «авторның күп белүен, эрудициясен күрсәтү» өчен генә китерелгәннәр кебек.

Гәрчә, «Урамнар артында яшел болын»да кызыклы гына мәсьәләләр һәм күзәтүләр очраса да, ул әле, дөресен генә әйткәндә, роман булып җитмәгән кебек. Беренчедән, әсәр шактый таркау чыккан. Моның төп сәбәбе исә романда бөтен җепләрне бер ноктага җыярдай конфликт тудырылмауда. Гомумән, әсәрдә геройлар арасында азмы-күпме конфликтны хәтерләткән бер генә җитди бәрелеш тә юк. Кайчак каршылыклар килеп чыкса да, алар бик тиз һәм җиңел хәл ителәләр. Мисал өчен Булавина белән Жаденконың үзара мөнәсәбәтләрен генә алыйк. Биредә тормышка хуҗаларча һәм формаль караш бәрелеше нигезендә авторга кызыклы гына конфликт тудырырга мөмкинлек бар иде. Ләкин геройларның үзара мөнәсәбәтләрен бу рәвешле катлауландырырга теләмәгәндәй, язучы алар арасындагы каршылыкны җиңел генә хәл итә дә куя. Бераздан без Булавина белән Жаденконы бер дә юктан гына кәеф бозышып татулашкан дуслар хәлендә күрәбез.

Аннан соң Идриснең көндәлек тормышта гаделлек өчен көрәшүен дә роман проблемасы итеп каравы кыен. Аны кечерәк жанрларда яктырту урынлырак булыр

иде. Тагын шунысы бар: әсәрдә сурәтләнгән ике эше генә Идрисне көндәлек тормышта гаделлек өчен көрәшүче итеп күрсәтергә ярдәм итә. Сүз аның Айдар белән Булавинага ярдәм кулы сузуы турында бара. Идриснең өченче эше исә, минемчә, аның дәрәҗәсен генә төшерә. Дерестән дә, кызу эш өстендә үзенә печән чабып яткан Мөзәкирне колхоз председателе Степановның ачуланып өенә кайтарып җибәрүен Идриснең дөньядагы иң зур гаделсезлек дип кабул итүе һәм председательне дошман күрә башлавы әсәрдә бик үк акланмый. Минемчә, Идриснең бу эше стаканда давыл куптару төсен ала һәм ул, әлбәттә, герой файдасына сөйләми. Ә бит әсәр ахырында гына Идриснең шушы эшен күрсәтү өчен автор Мөзәкир турында, аларның авылдагы тормышы турында бөтен роман дәвамында сөйләп килә. Бу линия әсәрдәге төп вакыйгалар агышыннан аерылып тора һәм аның роман тукымасында артык нәрсә булуы әллә каян күзгә ташлана. Сорау туа: моның ише үзен акламаган күренешләрнең һәм детальләрнең күбәюен нәрсә белән аңлатырга соң? Төп сәбәпләрнең берсе әлеге дә баягы, эзлекле үстерелгән үзәк конфликт булмауга кайтып кала. Конфликт булмаганда, автор контрольне югалта, «йөгәнсезләнә» һәм теләсә кая ташлана, нәрсә туры килсә, шул хакта яза башлый. Нәтиҗәдә әсәр күләм ягыннан күзгә күренеп үсә. А. Гыйләҗев романы белән дә, минемчә, шундыйрак хәл килеп чыккан.

«Фронтовиклар» исемле романында М. Мәһдиев тә башкаларны кабатлаудан качарга, тормыш турында үзенчә фикер йөртергә тели. Автор үз теләгенә байтак дәрәҗәдә ирешкән дә. Сәбәп — тормыш хакында аның үзеннән чыгып фикер йөртүдә. М. Мәһдиев безнең прозада инде шактый киң яктыртылган теманы — сугыштан соңгы авылны сурәтләүгә үзенчә килә, аның яңа якларын һәм мәсьәләләрен күрә алган. Әгәр дә безнең бу темага багышланган әсәрләрдә сугыштан соңгы авылның кыен тормышын бөтен барлыгы белән күрсәтү төп максат булып торса, М. Мәһдиев үз игътибарын башлыча тормыш-көнкүреш һәм әхлак мәсьәләләренә юнәлтә, болар хакында тапкыр һәм җор тел белән сөйли, гаҗәп үткен күзәтүләр ясый. Шундый сыйфатлары белән әсәр журналда басылып чыгуга ук тәнкыйтьнең дә дикъкатен җәлеп итте. Мин биредә Ф. Хәсни һәм Т. Галиуллин белән Ф. Урманчиев рецензияләрен күз алдында тотам. Аларда шундый үзенчәлек күзгә ташлана. Ф. Хәсни үз рецензиясенә «Мөхәммәт Мәһдиевнең «Фронтовиклар» дигән романына бер караш» дип искәрмә биргән. Моңардан рецензент әле романга бер караш ташлау белән генә канәгатьләнгән кебек нәтиҗәгә килергә мөмкин. һәм ул шулай килеп чыккан да. Рецензиядә Ф. Хәсниның әсәр белән беренче танышудан туган тәүге тәэсирләре, аерым күзәтүләре белән уртаклашуы, романга катгый хөкем карары чыгарырга теләмәве сизелеп тора. Т. Галиуллин белән Ф. Урманчиев рецензиясе дә, гәрчә беренче басмасында («Кызыл таң». 5 август, 1972 ел) «Тормышның үзе кебек» дигән конкретрак мәгънәле исемгә ия булса, икенче басмасында инде («Татарстан яшьләре». 5 октябрь, 1972 ел) «Яңа әсәрне укыгач» кебек абстракт исем алган. Исемнән соң «Уйланулар, фикерләр, тәкъдимнәр» дигән икенче бер баш бирелгән. Боларга караганда, бу рецензиядә дә роман турында хәлиткеч фикер әйтелергә тиеш түгел иде кебек. Әмма рецензентлар үз вәгъдәләрендә тормыйлар, чыгышларын: «Роман үзенең идея-тематик эчтәлеге белән генә түгел, эстетик дәрәҗәсе белән дә бүгенге әдәбиятыбызның зур казанышларыннан берсе дип бәяләнергә хаклы», кебек сүзләр белән бетерәләр. Бу инде әсәргә катгый һәм ачык хөкем карары чыгарылган дигән сүз.

Үзләренең рухлары буенча рецензияләр бер-берсенә шактый охшаганнар. һәр икесендә дә романдагы аерым тормышчан эпизодларга, авторның үткен күзәтүләренә, тапкыр теленә соклану өстенлек ала. Рецензентларның бу хисләрен күп кенә очракта минем дә уртаклашасым килә. Чыннан да, инде алдарак әйтелгәнчә, әсәрдә укырга кызыклы эпизодларны, мәгънәле характеристикаларны, авторның үткен күзәтүләрен, тапкыр әйтемнәрен байтак табарга була. Әмма болар белән танышканда артыграк хискә бирелеп, рецензентлар чама хисе дигән нәрсәне югалталар кебек. Нәтиҗәдә рецензияләрдә әсәргә аек аналитик караш, аны роман итеп, эстетик яктан бер бөтен организм итеп карау җитенкерәми. Әгәр Ф. Хәсни үзенең рецензиясендә беренче тәэсирләре белән генә уртаклашуын басым ясап әйтүе сәбәпле, бу хәл әле берникадәр акланса, Т. Галиуллин белән Ф. Урманчиев рецензиясендә инде, романга соңгы

инстанциядәге бәя бирелгәч, әсәргә аек аналитик һәм масштаблы караш булуы мәҗбүри төс ала иде.

Тормыш җирлеге нык һәм кызыклы детальләргә бай булган «Фронтовиклар» романына жанр таләпләреннән чыгып карасак, анда әле барсы да ал да гөл булмавын күрербез. Рецензияләр белән танышкач, күңелдә аларда әсәргә кызыклы детальләрнең арифметик суммасыннан чыгып бәя бирелә кебегрәк тәэсир кала. Ә бит чынлыкта романның эстетик кыйммәтен һәм уңышын мондый фактор белән генә һич тә билгеләп булмый. Аннан соң, гомумән, роман әдипнең бар күргән-белгәннәрен тутыра торган ниндидер «әдәби капчык» түгел. Прозаның иң камил һәм иң катлаулы формасы булган романның кыйммәте ахыр чиктә анда күтәрелгән проблеманың әһәмияте, аның сәнгатьчә никадәр эзлекле һәм тирән хәл ителүе, үзәк герой образының һәм конфликтның идея-эстетик яңгырашы белән билгеләнә. Әгәр шушы хәлиткеч моментлар тиешле кондициягә җиткерелмәсә, роман жанр буларак үзен аклый алмый.

М. Мәһдиевнең «Без — кырык беренче ел балалары» повесте турында язганда тәнкыйтьче Р. Мостафин аңарга әсәрне «бер ноктага тупларлык һәм таралып китүдән саклап торырлык зур һәм яңа фикер — идея бердәмлеге» җитмәвен, шул сәбәпле, повестьта «урыны-урыны белән әдәби детальләр үзмаксатка әйләнүен» күрсәткән иде һәм, минемчә, дөрес күрсәткән иде. «Фронтовиклар»га килсәк, аңарда мондый үзәк фикер, проблема бар. Дөрес, ул Т. Галиуллин белән Ф. Урманчиев уйлаганча түгел. Алар роман проблемасын башта «ил белән халык тормышының сугыштан соңгы бер чорын, киеренке, катлаулы, әле солдат киемен дә салырга өлгермәгән фронтовиклар язмышы белән бәйле чорын» сурәтләүдә, аннары «ил иминлеген саклап калган фронтовиклар язмышын, аларның тыныч тормышка кайтуын» чагылдыруда күрәләр. Турысын әйтергә кирәк, роман «ил белән халык тормышының сугыштан соңгы киеренке, катлаулы чорын» күз алдына бастыру кебек зур эпопеяларга хас булган олы масштаблы максатка дәгъва итми. М. Мәһдиевнең теләге күп мәртәбә тыйнаграк. Ул әсәр герое Рушадның түбәндәге сүзләрендә ачык чагыла: «Флот сине нәрсәгә өйрәтте? Намуслы булырга! Сугыш үзе — намус эше иде. Син зурысында намусыңны сакладың. Ә кечесендә?» Икенче төрле әйткәндә, дәһшәтле сугыш кырында ил алдындагы изге бурычларын намус белән үтәгән фронтовиклар тыныч тормышның гадәти шартларында да үз исемнәренә тап төшермәскә, элеккечә һәр нәрсәдә намуслы һәм гадел булырга тиешләр, дигән фикер ята бу әсәрнең нигезендә. Күренә ки, «Фронтовиклар»ның идеясе А. Гыйләҗев романындагы идея белән шактый авазлаш яңгырый.

Кичәге фронтовикларның характер сыйфатлары, дөньяга карашлары әсәрдә башлыча мораль җирлектә, шәхси тормыш мәсьәләләренә мөнәсәбәттә ачыла. Үзәк герой Рушадның фронтовиклыгы да күп очракта аның мәхәббәттә, хатын-кызга мөнәсәбәттә намуслы һәм гадел булуында күренә. Конкретрак әйтсәк, аның үзен яраткан Нәркис белән Мәсрүрәне алдыйсы, аларның саф хисен пычратасы килми һәм Рушад бу хакта аларга турыдан-туры әйтә. Ул үзенең саф мәхәббәтен эзли, ә аны Ләйләгелдә тапкач, Рушадка яшәүнең мәгънәсе тагын да ачыграк күренә башлый.

Кыскасы, романда яшь геройның мораль сафлыгына, аның әхлак мәсьәләләренә бик житди каравына басым ясала. Берничә генә эпизод ярдәмендә гәүдәләндерелсә дә, авторның бу фикере әсәрдә шактый нигезле чагылыш тапкан. Әмма Рушадны мондый планда күрсәтү никадәр кызыклы булмасын, ул гына әле романның үзәк героен чын мәгънәсендә фронтовик итеп тасвирлау өчен тулы нигез була алмый. Рушадның үзе укыткан класста тәртип урнаштыруын шактый тәфсилләп сөйләү дә җитми әле монда. Моның шулай икәнен автор үзе дә аңлый, күрәсең. Бер урында ул райком секретаре авызыннан фронтовикларның иҗтимагый тормышта да актив катнашырга тиешлекләрен, «авылны, районны торгызу, хуҗалыкны ныгыту» шулай ук фронтовиклар эше булуын әйтә. Гәрчә әлеге сүзләр турыдан-туры Рушадка адреслансалар да, Рушад мәхәббәттән башка өлкәләрдә үзен бик пассив тота, коры күзәтүчегә әверелә. Бу — Рушадны икенче фронтовик Гата белән чагыштырганда ачык күренә. Т. Галиуллин белән Ф. Урманчиев та үз мәкаләләрендә моңа игътибар итәләр һәм Рушадның Гата янында «төссезләнеп, сыекланып» калуын күрсәтәләр, кичәге диңгезченең «кирәк дәрәҗәдә көчле, кыю, принципиаль кеше булырга» тиешлеген әйтәләр.

Дөрестән дә, Рушадка мондый сыйфатлар җитенкерәми әле. Гата исә бу яктан Рушадка караганда шактый өстен тора. Дөрес, бу герой образын гәүдәләндерүдә дә авторга әле эзлеклелек җитми. Ф. Хөсни бу образның «гаять дулап башланып та, ахырга таба тыныклана төшүен» искәртә һәм сугыштан соңгы тыныч тормышта геройның характерын күрсәтерлек «киеренке урыннар» табылмавын моңа төп сәбәп итеп ала. Кыскасы, романдагы аерым кызыклы эпизодларны һәм детальләрне сокланып санаган арада, сүз арасында гына үзәк геройның әле тиешле кондициягә җиткерелмәгәнлеген искәртеп, рецензентлар, үзләре дә сизмәстән, әсәрнең зур кимчелеген ачып салалар. Мәгълүм ки, әгәр кешенең йөрәге авыру икән, ул аяк-кулы сызлаусыз булудан гына үзен сау-сәламәт итеп сизә алмый.

«Фронтовиклар»дагы үзәк геройны гәүдәләндерүдәге бу кимчелекләр ахыр чиктә конфликт мәсьәләсенә барып тоташалар. Авторның тормыш катлаулылыгы урынына аның чуарлыгы белән күбрәк кызыксынуы әсәрдә конфликтның йомшак булуына китергән. Эзлекле үстерелгән үзәк конфликтның булмавы, беренчедән, әсәр идеясенең һәм образларның өстәнрәк гәүдәләнүенә китерсә, икенчедән, романның сюжет-композициясендә шактый таркаулык тудырган. Нәтиҗәдә бу әсәрдә дә аерым эпизодларны һәм күренешләрне бирү үзмаксатка әверелә башлый, аларны автор уртак бер максатка хезмәт иттерә алмый. Менә мәктәп директоры Сабир белән аның хатыны Гөлчирәнең уй-кичерешләре яки Галиәхмәт карт белән Гайнелвафа карчык турында сөйләүче эпизодлар. Болай үзләрен генә алганда, алардан шактый гыйбрәтле һәм кызыклы гына новеллалар чыгарып булыр иде, әмма фронтовикларга багышланган романга аларның ни катнашы бардыр — бу миңа аңлашылмады.

Бер сүз белән әйткәндә, «Фронтовиклар»ның журнал варианты белән танышкач, миндә әсәр әле роман буларак тиешле кондициягә җиткерелмәгән дигән тәэсир калды.

Сүз уңаенда «әсәрнең журнал варианты» дигән төшенчәгә тукталып үтәсе килә. Бездә бу төшенчәне еш һәм бик теләп кулланалар. Әгәр дә теге яки бу әсәр журналда чыккач катгыйрак фикер әйтә башласаң, авторның үзеннән дә, башка кайбер кешеләрдән дә еш кына шундыйрак җавап ишетәсең: «Алай кырт кисәргә ашыкма, бу бит әле журнал варианты гына. Менә ул аерым китап булып чыксын, шунда инде ныклап сөйләшергә булыр». Ә инде моннан шундый нәтиҗәгә килергә була: димәк, әдәби журналда әсәрнең әле эшләнеп бетмәгән варианты гына басыла икән, ә тулы кондициягә ул бары нәшриятта, аерым китап булып чыкканда гына китерелә икән. Кайбер укучыларда исә: «Туктале, бу чиле-пешле журнал вариантын вакыт әрәм итеп укып тормыйм, менә әсәр аерым китап булып чыксын, шунда рәхәтләнеп укырмын», дигән дөрес булмаган фикер дә туарга мөмкин.

Ярый, әсәрнең журнал вариантын шулай өлгереп җитмәгән җимеш итеп карыйк, ди. Ә нәшрият варианты һәр вакытта да «өлгергән», «пешкән» буламы соң? Сорауга уңай җавап бирү кыен. Минем үземнең, мисал өчен, соңгы елларда чыккан купчелек әсәрләрнең журнал һәм нәшрият вариантларында принципиаль аермалар, үзгәрешләр күргәнем юк. Кайчак бер генә аерма күзгә ташлана: нәшриятта дөнья күргән аерым китап вариантында журнал редакциясе кыскарткан артык детальләр һәм эпизодлар кабат торгызылган була.

Башланган сүзгә кире әйләнеп кайтып шуны әйтәсе килә: соңгы вакытта бездә роман язуга омтылыш бермә-бер көчәйде, бу эш хәтта үзенә бер модага әверелде. Роман язуны заман модасына әйләндерү исә кайбер очракларда жанр таләпләренә игътибар кимүгә яки аларны санга сукмауга китерде. Әсәр жанры кайчак объектив идея-эстетик факторлардан чыгып түгел, ә бәлки авторның субъектив теләге белән генә билгеләнә башлады. Кайбер романнарны укыгач, еш кына күңелдә автор бу катлаулы жанрга үзенең иҗади мөмкинлекләрен чамаламыйчарак алынган, дигән уй туа. Ә мондый фактлар ахыр чиктә, романнар күп язылса да, алар әле һәр вакытта да әдәбиятның җитлеккәнлеге турында сөйләмиләр дигән нәтиҗәне ясарга мәҗбүр итәләр.

Мәгълүм булганча, хәзерге әдәби хәрәкәт төрле жанрларның үзара якынаюы, бербереңә үтеп керүе белән характерлана. Бу тенденция безнең прозада да үзен әледән-әле сиздерә. Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повестенда һәм А. Расихның «Ямашев» романында, мәсәлән, новеллалылык күзгә ташлана. И. Газиның «Оны-

тылмас еллар»ына исә, бигрәк тә трилогиянең икенче китабына, романистик хикәяләү алымнары үтеп керә. Әйтергә кирәк, кайчак әдәби практикада теге яки бу жанрның классик формасын үзгәртү, яңарту тәнкыйтькә дә дучар була. Мисал өчен Ч. Айтматов әсәрләре повесть чикләреннән чыгып романга якынаюы өчен тәнкыйтьләнделәр. Ләкин, әгәр повесть үзенең идея-эстетик кыйммәте буенча романга якынлаша икән, минемчә, моның өчен әдипне мактарга гына кирәк. Әгәр инде безнең кайбер романнарга килсәк, алар, киресенчә, урта кул повестька якын торалар. Аңлашыла ки, мондый «романнар»ның идея-эстетик кыйммәте дә шул кадәр генә була. Мин үзем, мәсәлән, Ә. Еникинең «Төнге тамчылар» һәм «Әйтелмәгән васыять» кебек хикәяләрен кайбер романнардан күп өстен куярм.

Заман темасын роман жанрында яктыртырга алганда язучыларыбызның әле-дән-әле уңышсызлыкка очраулары, минемчә, беркадәр тормыш материалының характеры белән дә аңлатыла. Мәгълүм ки, биредә авторларга еш кына әле «утырмаган», билгеле бер калыпка салынмаган, ә бәлки үсү-яңару процессындагы материал белән эш итәргә туры килә. Бу бигрәк тә республикадагы яңа төзелешләргә багышланган әсәрләргә хас.

Күз алдында формалашып килүче мондый чынбарлыкны роман кебек масштаблы жанрда гәүдәләндерү өчен әдиптән аеруча зур сәләт һәм иҗади энергия сорала. Әдәби практика исә кайбер прозаикларның тормыштагы яңа күренешләрне һәм процессларны сәнгатьчә тулы канлы итеп гәүдәләндерергә көчләре җитмәвен күрсәтә. Аерым алганда, Ә. Баяновның «Ут һәм Су» романы шул хакта сөйли. Әсәрдә аерым кызыклы фикерләр, тормышчан детальләр һәм хәтта образлар (мәсәлән, Борис Филинов образы) очраса да, тулаем алганда, тәнкыйть аның әле роман булып җитмәгәнлеген күрсәтте. Минемчә, монда төп сәбәп тормыштагы яңа күренешләрне оператив рәвештә яктыртканда сәнгатьчә тирән фикерләү җитмәүдә. Әйтерсең лә автор әсәрдә үзенең иҗат фантазиясен ныклап эшкә җигәргә, мәсьәләнең асылына төшенергә теләми һәм өстә яткан аерым детальләрне, фактларны сурәтләү белән канәгатьләнә. Чыннан да Ә. Баяновка бу әсәрдә әле тормыш турында эзлекле һәм дәлилле фикер йөртү, аны үсештә карау җитми. Бу хәл романның әдәби тукымасына да тәэсир иткән. Анда эчке бөтенлек юк, сюжет-композициясе дә яңа башланган төзелеш мәйданын хәтерләтә: анда әле хуҗасызлык һәм таркаулык хөкем сөрә, байтак күренешләрнең һәм эпизодларның чын урыны ачыкланмаган.

Яңа төзелеш чынбарлыгына тирәнтен үтеп керә алмау, өстә яткан аерым күренешләрне яки ситуацияләрне тасвир кылу белән генә чикләнү Б. Камалов белән М. Хәбибуллинның да бу темадагы уңышсызлыкларына сәбәпче булды. Аларның «Урамнар киңәя» һәм «Тау белән тау очрашмаса да» исемле повестьларында Чаллы якларында башланган тирән иҗтимагый-рухи үзгәрешләрне сиземләве кыен. Чөнки аларда әле бу чынбарлыкның яңа мәсьәләләре һәм конфликтлары күтәрелми. Бу авторлар өчен яшь драматург Д. Вәлиевнең «Дәвам» исемле пьесасы күп яктан үрнәк булырлык. Анда автор яңа тормыш материалына җитди аналитик караш белән карый алган һәм Чаллы тормышында заманыбызның мөһим мәсьәләләрен, конфликтларын таба алган. Бу уңыш ахыр чиктә Д. Вәлиевнең Чаллы чынбарлыгын яхшы белүе, аның эчке үсеш тенденцияләрен тирәнтен сиземләве белән бәйләнгән. Алдарак каралган әсәрләрнең авторларына исә мондый сыйфатлар җитенкерәми. Аларның үзләре сурәтләгән тормышны шактый өстән белүләре сизелә.

Шулай итеп, биредә безнең алга әдипнең чынбарлык белән бәйләнеше мәсьәләсе килеп баса. Әйтергә кирәк, бу бәйләнеш бездә кайчак формаль төс ала һәм тышкы детальләрдән генә чыгып билгеләнә башлый. Соңгы вакытта язучыларның тормыш белән элемтәләре ныгу турында сөйләгәндә моңа дәлил итеп авыл районнарында әдәби атналыклар үткәрүне китерәләр. Сүз дә юк, бу — кирәкле чара. Атналыкларның бигрәк тә әдәбиятны пропагандалау ягыннан әһәмияте зур. Бу өлкәдә актив эшчәнлеге өчен Татарстан язучылар союзы күчмә Кызыл байрак белән дә бүләкләнде. Әмма мин атналыкларны язучының тормыш белән бәйләнешен ныгыту чарасы итеп карый алмыйм. Чөнки язучы тормышны үз күңеленә тынгы бирми торган иҗат объекты һәм илһам чыганагы итеп караганда гына, бу юлда армый-талмый эзләнгән тәкъдирдә генә аның тормыш белән тыгыз бәйләнеше турында сөйләргә мөмкин. Әдәби атналыкларны үткәрү тәртибе исә мондый мөмкинлекне бирми. Аларның безнең прозада

бернинди эзсез диярлек үтә килүләре дә моңа ачык дәлил. Мин үзем ничә еллар рәттән үткәрелеп килүче бу атналыкларда катнашу нәтиҗәсендә язылган бер генә әйберне беләм. Ул да булса — Балтач әтәченә багышланган хикәя. «Балтач әтәче турында язу» дигән сүз миңа хәзер «Лаеш шулпасы эчү» кебек образлы әйтем булып яңгырый.



## Аяк белән дә төрлечә йөрергә була...

Әдәби практика кабат-кабат бер хакыйкатькә ышандыра: тормышны тирәнтен өйрәнү аны сәнгатьчә гәүдәләндерү юлында актив һәм тынгысыз эзләнүләр белән бергә барырга тиеш. Биредә минем хикәяләүнең интеллектуаль, образлы булырга тиешлегенә аеруча басым ясыйсым килә. Чөнки, беренчедән, тормыш эчтәлеген мөмкин кадәр сәнгатьчә мәгънәлерәк итеп бирү мәсьәләсенә әдипләребез әле һаман аз игътибар итәләр. Икенчедән, проза турындагы сөйләшүдә катнашкан И. Нуруллинның «Аяк белән йөрүгә ни җитә?» дигән мәкаләсендә бу мәсьәләгә кагылышлы кызыклы гына фикерләр әйтелә. Хөрмәтле тәнкыйтьчебез анда реалистик сәнгать чынбарлыкны **ничек, нинди формаларда** һәм **нинди чаралар** белән гәүдәләндерергә тиеш дигән гаять зур мәсьәләне күтәрә. Аның бөтен пафосы Р. Мостафин мәкаләсендә телгә алынган «тышкы охшашлыкка нигезләнгән традицион хикәяләү стиленә» яклауга юнәлдерелгән. Р. Мостафин үзенең проза турындагы сөйләшүне башлап җибәргән мәкаләсендә бу стиль белән генә чикләнү ярамаганлыгын, әдипләребезнең дөнья әдәбияты туплаган бай тәҗрибәдән дә файдаланырга тиешлекләрен әйткән иде. Бу фикер белән бәхәскә кереп, И. Нуруллин әлеге традицион хикәяләү стиле «моңарчы реализмның «табигый хәле», олы юлы булып килде һәм, шикләнми әйтергә мөмкин, киләчәктә дә шулай булып калачак», ди. Әйтергә кирәк, бу — әдәбият фәне өчен яңа белдерү түгел. Моның белән И. Нуруллин үткән елларда үзәк матбугатта булып узган мәгълүм бәхәсләрне дәвам иттерә кебек. Билгеле булганча, бу бәхәсләр тормышны үз формасында сурәтләүне яклаучылар белән сәнгатьчә шартлылык алымнарын файдаланырга өндәүчеләр арасында барды. Беренче принципны иң актив яклаган әдәбиятчы С. М. Петров, мәсәлән, тормышны үз формасында сурәтләүне «натураль» агым дип атады, аның реализм методына адекват булуын һәм классик реализмның иң зур казанышлары нәкъ менә шушы агым белән бәйләнгәнлеген белдерде. Күренә ки, И. Нуруллин С. М. Петров белән бер карашта тора.

Әмма әлеге бәхәсләрдә катнашучылар реалистик методны тик бу агымга гына кайтарып калдыру яки аңа гына өстенлек бирү реализмны ярлыландыра, аның тормышны сәнгатьчә танып-белү мөмкинлекләрен чикли, норматившлыкны тудыра дип бәяләделәр. Чөнки дөнья әдәбиятында чынбарлыкны үз формасында гына сурәтләмичә, гипербола, гротеск, аллегория, фантастика һәм башка шундый сәнгатьчә шартлылык алымнарына да мөрәҗәгать иткән күп кенә реалистик әсәрләрне табарга була. Рабле, Свифт, Бальзак, Гоголь, Щедрин, Франс, Чапек һәм башка олы художникларның иҗаты әнә шул хакта сөйли. Дөрес, бу әдипләрнең әсәрләре еш кына сатирик жанрга карый. Әмма сатираның мөһим бер үзенчәлеге «чынбарлыкның реаль пропорцияләрен үзгәртеп сурәтләүдән» гыйбарәт булуын һәм моның өчен әдипләрнең сәнгатьчә шартлылыкка мөрәҗәгать итүләрен И. Нуруллин бу әсәрләрне реализмнан читләштерүче бер күренеш итеп карый. Аның болай фикерләвеннән, әгәр әсәр тормышны үз формасында чагылдырмый икән, димәк, ул реалистик була алмый, дигән нәтиҗәгә киләсең. Ә бит Свифт, Щедрин, Чапек һ. б. ларның сатирик әсәрләре реализмның югары үрнәге икәнлеге барыбызга да билгеле.

Әгәр инде без, И. Нуруллинга кушылып, социалистик реализмның төп критерие рәвешендә әлеге традицион хикәяләү стилен алсак, ул вакытта без Маяковский, Брехт, Неруда, Назыйм Хикмәт һ. б.ларның иң яхшы әсәрләрен бу метод әдәбиятыннан читләштерергә тиеш булабыз.

Аннан соң «натуральлек»кә, тормышны үз формасында, үз кыяфәтендә сурәтләүгә артык табынуның художникны натурализмга китереп чыгаруы да ихтимал бит. Ә

инде натурализмның социалистик реализм белән бернинди алыш-биреше булмавы һәркемгә мәгълүм. Бу уңайдан Г. Ибраһимовның түбәндәге фикере хәтергә килә: «Тормыш кисәкләрен шул килеш фотографияләп, дөньяга ташлау юлы белән төзелгән әсәрләрнең кыйммәте юк. Минемчә, әдәби әсәрләр тормышның каты көрәшле, күп катлаулы, бай каршылыклы тирән процессларын иҗат механизмы аркылы, җанлы сурәтләрдә гәүдәләндерү, чагылдыру юлы белән язылганда гына социалистик реализмга ирешеп булачак» [1]. Реаль чынбарлык күренешләрен «иҗат механизмы аркылы» үткәреп сурәтләү бурычы исә сәнгатьчә анализ һәм тасвир чараларының күп төрле булуын сорый.

И. Нуруллин бер нәрсәдә һичшиксез хаклы: безнең әдипләр әле чыннан да тормышны үз формасында гәүдәләндерү принцибы бирә торган мөмкинлекләрдән, бу өлкәдә классиклар туплаган бай тәҗрибәдән тиешенчә файдалана алмыйлар. Мисалга әсәрләрдә пейзаж кулланууны гына алыйк. Классикларыбыз безгә пейзажны сәнгать чарасы итеп файдалануның күркәм үрнәкләрен биреп калдырдылар. Г. Ибраһимовның карт имән образы үзе генә ни тора! Моңа кадәр күпме еллар «башка һәммә нәрсәне кырып барган» балталарга, пычкыларга да бирешмәгән, «каты җилләрне уйнап кичерә торган тирән тамырлы» бу карт имәнне көннәрдән бер көнне язгы яшен «бөтен тирә-як туфраклары белән суырып» ыргыта. Октябрь революциясенең иске җәмгыять көчләрен тәбе-тамыры белән себереп ташлавын күрсәтү өчен моннан да уңышлырак тасвир чарасы табып булырмы икән! Шушы ук әдипнең кызыл чәчәкләре дә революция тудырган яңалыкның, яңа кешеләрнең искелек белән авыр көрәштә җиңеп чыгуларын зур тәэсир көче белән чагылдыралар.

Пейзаж, табигать күренешләре бүгенге проза әсәрләрендә дә әледән-әле күзгә чалыналар. Әмма алар әсәр идеясен образлы итеп гәүдәләндерү чарасы булудан бигрәк, еш кына тынчу бүлмәдән алҗып чыккан геройга иркенләп бер сулыш алу, хозурлану өчен генә хезмәт итәләр.

Әмма шулай да, үткәндәге реалистик әдәбиятта хәзерге әдипләргә үрнәк булып торырдай мисаллар күп булса да, бүгенге язучыларны тормышны үз формасында сурәтләү юнәлешендә генә эш итәргә чакыру, аларның башка юнәлешләрдә эзләнүләренә пессимистик карау белән килешәсе килми. Чөнки бу иң революцион метод булган социалистик реализмның бөтен рухына, табигатенә каршы килә. Безнең интенсив рәвештә үзгәреп, яңарып торучы чынбарлыгыбызны сәнгатьчә тулы канлы итеп гәүдәләндерү кирәклеге үзе үк бу өлкәдә бертуктаусыз һәм кыю эзләнүләрне сорый. Дөрес, бу эзләнүләр үзмаксатка әверелмәскә, ә бәлки конкрет ихтыяҗлардан чыгып һәм иҗади тестә алып барылырга тиеш. Ә бездә форма оригинальлегенә омтылу кайчак фикер сайлыгын яшерү теләгеннән генә була. Икенче бер очракларда исә, И. Нуруллин бик хаклы әйткәнчә, дөнья әдәбияты тәҗрибәсенең безнең өчен яңа булган алымнары механик рәвештә үзләштерелә һәм ул, табигый, әдипләрне бары уңышсызлыкка гына китерә. Ләкин бу безгә һич тә «Көнбатыш Европа әдәбиятларындагы шартлы һәм фантастик алымнар белән азыкландырып прозаны алга таба әйдәүнең тиешле нәтиҗә бирмәячәге көн кебек ачык. Моның хәтта зарар китерүе мөмкин», дигән нәтиҗә чыгарырга нигез була алмый. Эш бит художникның нинди чаралар куллануында түгел, бәлки аларны нинди максатта куллануында. Ахыр чиктә мәсьәлә әдәбият-сәнгатьне «эч пошудан һәм симезлектән җәфа чигүче «югары катлау ун меңнәргә»ме, әллә инде «илнең чәчәге, аның көче, аның киләчәге булган миллионнарча һәм ун миллионнарча хезмәт ияләренә» (Ленин) хезмәт иттерүгә бәйләнгән. Шул «югары катлау ун меңнәрнең» теләкләренә һәм интересларына буйсынучы буржуаз әдәбиятта, француз язучысы Роб-Грийе әйткәнчә, художник еш кына **нәрсә** турында сөйләве өчен түгел, бәлки **ничек** сөйләве өчен генә үзен җаваплы сизә. Әнә шуннан инде модернизм, форма «шаккатыризмы» туа.

Халыкка, бөтен кешелеккә хезмәт итә торган социалистик реализм әдәбиятында исә художникның **нәрсә** турында һәм бу хакта **ничек** сөйләве бердәй әһәмияткә ия. Аларның берсен икенчесеннән өстен куярга ярамый. Чөнки бу әдәбият, бер яктан, әдипләрнең идеаллар һәм омтылышлар уртаклыгын, икенче яктан, сәнгатьчә эзләну-

---

[1] **Г. Ибраһимов. Әдәбият мәсьәләләре. Казан. 1960. 219 бит.**

ләрнең һәм чишелешләрнең күп төрле булуын шарт итеп куя. Аңлашыла ки, монда ниндидер нормативлыкка, нивелировкага урын була алмый. Бу уңайдан Назыйм Хикмәтнең шундый сүзләрен искә төшерү урынлы булыр: «Әдәби форма өлкәсендә мин хәзер мәгънәлелекне бирүнең теләсә кайсы ысулын таныйм, аларны аңларга һәм үзләштерергә тырышам. Тик бер шарт бар: алар оста кулланылсыннар, аморф түгел, чыннан да мәгънәле булсыннар һәм эчтәлекне аеруча яхшы бирүгә булышсыннар» [1].

Бу сүзләрнең хаклыгын күп милләтле совет әдәбияты үзе раслый. Үзләренең иҗат палитраларын баету өчен илебез әдипләре соңгы вакытта сәнгатьчә шартлылык алымнарына ешрак мөрәҗәгать итә башладылар. Аерым алганда, миф белән кызыксыну көчәйде. Көнбатышта исә бу нәрсә үзенә бер модага әверелде. Әмма анда да миф төрле художникларны төрле максатта кызыксындыра. Буржуаз әдәбиятта ул укучының игътибарын заманның актуаль мәсьәләләреннән читкә юнәлтү өчен файдаланыла. Ә менә Американың һәм Африканың күп кенә прогрессив язучылары мифка заманның мөһим мәсьәләләрен, социаль каршылыкларын тагын да кискенрәк төстә һәм ачыграк гәүдәләндерү өчен мөрәҗәгать итәләр. Мәсәлән, күренекле Америка язучысы Дж. Апдайкның «Кентавр» исемле романында миф гади хезмәт кешесенең рухын һәм саф күңелен калку итеп гәүдәләндерү өчен файдаланыла. Нужа чигеп һәм төрлечә кыерсытылып яшәүче укытучы Колдуэлл, көндәлек тормыш кыенлыкларыннан аерылып үзенең хыялый дөньясына күчкән чакларында, борынгы грек мифологиясе герое — кентавр Хиронга әверелә. Бу вакытта ул мифик затлар яшәгән заманнарга китә һәм андагы тормышка соклана. Колдуэлл-Хирон үз илендәге гаделсезлекләр белән килешә алмый, башкача яшәү турында хыяллана. Шулай итеп, бу романда миф гади хезмәт кешесен физик һәм рухи яктан изә торган социаль тәртипләрне сәнгатьчә кире кагу чарасына әверелә.

Совет әдәбиятында мифны файдалануның иң уңышлы мисалы итеп Ч. Айтматовның «Ак пароход» повестен санарга була. Кыргыз халкының ничек килеп чыгуы турында сөйләүче борынгы легендага — Ана болан легендасына мөрәҗәгать итеп, шуның аша әдип әсәрдә заманыбызның иң мөһим мәсьәләләреннән берсен — табигатьне саклау мәсьәләсен зур фәлсәфи көч белән күтәрә. Әгәр повестьта кыргызларның ерак бабаларын үлемнән коткарып калган Ана болан турындагы легенда булмаса, әсәрнең идея-фәлсәфи яңгырашы бермә-бер кимер иде, ә маралларны ату әсәрдә гадәти браконьерлык күренеше генә булып калыр иде.

Сүз уңаенда башка күп кенә әдәбиятларда дастан традицияләре белән кызыксыну көчәйгәнлеген дә әйтеп үтәргә кирәк. Аларга әдипләр төрле максатларда мөрәҗәгать итәләр. Үзебезнең әдәбиятта Н. Фәттахның «Этил суы ака торур» романында дастан сюжеты алымнары борынгы болгар чынбарлыгын күрсәтү өчен файдаланыла. Дастан сюжеты йогынтысы, аерым алганда, акбүреләрнең болгарлар белән сугышын тасвирлаган, Тотышның Аппакка мәхәббәтен һәм аларның фаҗигале язмышын сурәтләгән эпизодларда аеруча сизелә. Тагын да конкретрак әйтсәк, автор Тотышның Аппакны эзләп йөрүләрен сурәтләгәндә роман белән «Бабахан дастаны» арасында шактый аваздашлык сизелә. Бу дастандагы, Таһир һәм Зөһрә кебек, Тотыш белән Аппак та бер-берсеннән көчләп аерылдырылалар, аннары егет дөнья гизеп үзенең сөйгәнен эзли, соңыннан инде кавыштык дигәч, алар һәлак булалар. Болай дастанча хикәяләү борынгы кешенең мәхәббәт культын чагылдыру ягыннан, минемчә, һичшиксез кызыклы. Ә менә бу алымны авторның төп максатын ачу ягыннан карасак, безнең алга бөтенләй башка күренеш килеп басар. Н. Фәттахның үзенең белдерүенчә, романда бердәм Болгар дәүләтенең оешуын күрсәтү максат итеп куелган. Гәрчә әсәр шушы фикерне үзәккә куеп һәм шул турыда киң планлы хикәяләү белән башланса да, Ф. Хөсни әйткәнчә, «ахырга тарая-тарая барып, ниһаять, бәк балаларының «башсыз» тәвәккәллекләрен, сөешү-мәхәббәт романтикаларын бик тәфсилле сурәтләү белән очлана». Кыскасы, Болгар җирендә барган зур тарихи процессларның үзәгендә торырга тиеш булган Тотышның бары мәхәббәткә мөкиббән киткән затка — мәҗнүнгә әйләнеп калуы һәм авторның төп максаты да тора-бара шул хакта хикәяләүгә генә

[1] Проблемы становления реализма в литературах Востока. Рус телендә. Мәскәү. 1964 ел. 255 бит.

кайтып калуы романның идея-эстетик яңгырашын бермә-бер киметкән. Ә бу исә әсәрдә дастан алымы уңышлы файдаланылмаган дигән сүз.

Әйе, иҗат палитрасын баету прозаикларыбыз өчен әле җитди бурыч булып тора. Бу бурычны уңышлы үтәү өчен аларга туган халкыбызның бай иҗат мирасына һәм дөнья әдәбияты тәҗрибәсенә активрак мөрәҗәгать итәргә кирәк. Әгәр бу эш аек акыл белән һәм иҗади төстә башкарылса, минемчә, мәсьәлә һич тә аяк белән йөрүдән баш тартып кул белән йөри башлау кебек булмас иде. Дөресрәге, ул прозабызның эстетик дәрәҗәсен тагын да күтәрергә булышыр иде. Тормышны тирәнтен өйрәнү белән бергә, әдипләребезнең шушы юлда да актив эзләнүләрен һәм яңа ачышларга ирешүләрен телисе килә.

Ә менә күп кенә таҗик, төркмән һәм үзбәк прозаикларын дастан традицияләре, күренекле әдәбият галиме М. Пархоменко фикеренчә, заман темасына багышланган әсәрнең сюжет-композициясен оештыру ягыннан кызыксындыралар. Дастан сюжетының мөһим типологик сыйфатлары итеп М. Пархоменко аңарда вакыйгаларның зур тизлек белән үсүен, конфликтларның һәм коллизияләрнең бик киеренке һәм драматик төс алуын билгели һәм хәзерге әдипләрне нәкъ менә шушы сыйфатлар кызыксындыруын әйтә. Ә бит безнең хәзерге кайбер әсәрләргә мондый сыйфатлар бик тә җитми, аларда киеренке заманыбыз турында хикәяләү еш кына артык сүлпән һәм ялыктыргыч төс ала. Дастан традицияләренең әлеге әдәбиятларда ничек файдаланылуын күрсәтү өчен бер генә әсәргә — үзбәк язучысы Ә. Мохтарның «Чинар» романына тукталыйк. Н. Фәттах кебек, Ә. Мохтар да дастан героеның дөнья гизеп йөрүе алымына мөрәҗәгать итә. Роман инде туксанның өске ягына чыккан Әчил картның чит илдән кайткан улы Әзимҗан белән республиканың төрле почмакларында яшәүче күп санлы балаларының һәм оныкларының хәлләрен белеп йөрүен тасвирлый. Күренә ки, бередә геройның дөнья гизү максаты Н. Фәттах романындагыдан шактый аерыла. Ә. Мохтар әлеге сюжетны дастанга хас детальләр һәм бизәкләр белән тулыландыра. Әчил карт ил гизеп йөргәндә төрле хәлләргә очрый, Әзимҗанга төрле легендалар һәм тарихлар сөйли. Әмма боларның барысы турында хикәяләү — никадәр мавыктыргыч булмасын — автор өчен үзмаксат түгел. Дастан алымы бередә гади кышлак карты Әчилнең олы күңелен ачу, аны тормыштагы һәр нәрсә өчен үзен җаваплы сизүче ил атасы итеп күрсәтү максатында файдаланыла. Әчил юлында очраган бер хәлгә дә битараф кала алмый, я шатлана, я борчыла, гаделсезлекләрне юкка чыгарырга тырыша. Шулай итеп, «Чинар» романында дастан алымы заман героеның олы рухын, якты образын гәүдәләндерү чарасына әверелә.

Җыеп әйткәндә, бу мисал, Ч. Айтматов повесте кебек үк, халыкның бик борынгыдан килә торган иҗат мирасының безнең көннәрдә дә әдипләрнең әдәби осталыгын үстерүдә, иҗат палитрасын баетуда мөһим чыганак була алуын раслый. Тик ул чыганактан дөрес файдалана белергә генә кирәк.

# ҖЫРЛАСАҢ ҖЫР...

*«Җырлар китабы»н укыганда...*

Киң катлау укучылар өчен чыгарыла торган җырлар җыентыгы берничә ел рәттән «Халык җырлый» исеме белән басылып килде. Аны З. Хәйруллина әзерли иде. 1972 елда шул ук типтагы җыентык «Җырлар китабы» исеме белән чыккан. (Тик нигәдер аның исеме русчага «Народ поет» дип тәрҗемә ителгән.) Аны әзерләүче дә башка кеше икән — филология фәннәре кандидаты Илбарис Надиров. Шулай булгач, бу китапны кулга алгач та, аны «Халык җырлый» басмалары белән чагыштырып карау теләге туа. Тәзүче бу басмага нинди принципиаль яңалыклар керткән? Китап яхшырганмы, әллә элеккеге дәрәҗәсендә калганмы?

Баштан ук әйтеп үтим, «Җырлар китабы» элеккеге басмаларыннан, һичшиксез, яңа якка аерылып тора. Бу яңалык иң элек китапка кертү өчен **җырлар сайлауда** күренә. Табигый, китапның төп өлешен соңгы елларда таралган яңа җырлар алып тора. Алар арасында профессиональ һәм үзешчән композиторлар, шагыйрьләр тарафыннан иҗат ителгән җырлар, халык лирикасының иң матур үрнәкләре — бигрәк тә Н. Исәнбәт сүзләре белән җырлана торган, безнең көннәрдә генә популярлашып киткән «Син сазыңны уйнадың», «Бик ерактан килдек без» кебек классик әсәрләрнең урын алуы мактауга лаек.

Кайбер искергән җырларны төшереп калдыру исәбенә җыентыкның бу басмасында халык иҗаты әсәрләренә шактый зур урын бирелгән. Арада әле популярлашып өлгермәгән, әмма моңа һичшиксез лаек әсәрләр дә байтак. «Бакалы», «Берберебездән бизмиек», «Кодалар җыры» кебекләр әнә шундыйларның үрнәкләре булса кирәк. Төзүче мондый җырларны халык арасында популярлаштыру нияте белән кертүендер. Һичшиксез, изге теләк. Халык җырларына зур гына урын бирү исә китапның эстетик дәрәҗәсен күтәрә, аның шигъри моңын баета.

Китапның гомуми төзелеше дә бераз үзгәргән. Әйтик, «Халык җырлый»ның соңгы басмасында җырлар 13 тематик төркемгә бүленеп бирелгән иде. Арада «Төрле җырлар», «Тәрҗемә җырлар» дигән беркадәр мәгънәсезрәк бүлекләр дә бар иде. «Җырлар китабы»нда тематик төркемнәр саны киметелгән, тыгызланган. Әйтергә кирәк, бүлекләр нигездә төгәл һәм матур төзелгән.

Китапның ахырында «Алфавит эчтәлеге» бирү аның белән файдалануны, аерым әсәрләрне эзләп табуны җиңеләйтә.

Җыентыкны хронологик принцип нигезендә төзергә омтылу матур тәэсир калдыра. Беренче бүлекнең эчтәлеген, мәсәлән, гасыр башындагы дәһшәтле вакыйгалар белән бәйле революцион җырлар тәшкил итә: «Интернационал», «Варшавянка», «Совет власте өчен»... Моннан соң «Партия һәм Ленин турында»гы җырлар килә: «Ленин юлы — безнең юл» (халык җыры), «Күңелем Ленин белән сөйләшә» (С. Хәким сүзләре, Х. Вәлиуллин музыкасы), «Ул Казанда яшәгән» (М. Ногман сүзләре, Р. Яхин музыкасы). Бу җырларның байтагы безнең көннәрдә иҗат ителгән. Әмма аларның эчтәлеге, музыкаль-поэтик аһәңе гаять киң — ул үткәнгә дә, бүгенгегә дә, киләчәккә дә карый кебек. Ә инде шул елларда туган халык җырларында исә, чор таләп иткәнчә, өндәү, чакыру авазлары, публицистика өстенлек ала. Дәһшәтле чорда шигъри гадилек таләп

итеп. Шуның белән бәйле рәвештә, ул еллардагы җырлар гади рифмалар, төгәл ритмнар, ачык фикерле кыска җөмләләр белән язылганнар.

Ә инде Ленин турындагы җырларга якты юл, кояш нурлары, таң йолдызы образлары килеп керә.

Тәрәзәмне ачып куйсам,
Күренә Идел буйлары.
Якты дөньяга чыгарды
Безне Ленин юллары.

*(«Ленин юлы — безнең юл».)*

Хронология таләп иткәнчә, алга таба «Гражданнар сугышы», «Туган ил, туган як, Татарстан» исеме белән бирелгән бүлекләр килә. Монда инде җырларның шигъри яңгырашы, образлар системасы катлаулана төшә. Бу бигрәк тә «Бөек Ватан сугышы, тынычлык һәм халыклар дуслыгы» дигән бүлектә күзгә ташлана. Сугыш хис тирәнлеген, фикер житдилеген, тойгылар ташкынын таләп итте. Чорның шундый таләпләре җырларда да чагылмый калмады. Аларның теле чарланды, образлары катлауланды, фикерләре тирәнәйде. Ватанның иминлеген саклап калу кебек изге эш турында башкача җырлап та, сөйләп тә булмый иде кебек. Бу бигрәк тә шул елларда туган халык җырларында ачык күренә.

Һаваларда очкан аккошларның
Каурыйлары күлгә коела,
Таң алдыннан тәрәзәгә шакып,
Кайтып керер кебек тоела.

*(«Аккошлар».)*

Ә инде китаптагы профессиональ җырларның алсак, аларның иң зур күпчелеге, шул исәптән сугыш турындагылары да, безнең көннәр эстетикасын чагылдыра. Моны, мәсәлән, Н. Арсланов белән Җ. Фәйзинең «Билгесез солдат кабере янында» исемле тирән драматизм белән сугарылган җырында да күрергә мөмкин.

Ялгыз кабер тора тау башында,
Бер билгесез солдат күмелгән...
Тол аналар, ятимнәрнең монда
Энҗедәй саф яше түгелгән...

Китап 1972 елда чыккан. Ел ахырында совет халкы СССРның 50 еллык юбилеен бәйрәм итеп үтте. Бу — совет интернационализмының халыкара тантанасы иде. Шул олы вакыйга белән аваздаш рәвештә җыентыкта халыклар дуслыгы темасын чагылдырган җырларның ярыйсы ук зур урын алуы аның идея-эстетик дәрәҗәсен тагы да югарырак күтәрә. «Казакъ дустыма» (С. Хәким сүзләре, Җ. Фәйзи музыкасы), «Вьетнам солдатына» (Н. Дәүли сүзләре, А. Ключарев музыкасы), «Мари кызы Улина» (С. Хәким сүзләре, Җ. Фәйзи музыкасы) кебек җырлар нәкъ әнә шул турыда сөйли.

Шулай да китапның иң зур һәм иң матур бүлеген «Мәхәббәт җырлары» алып тора. Бүлекнең ярыйсы ук зур өлешен халык лирикасы әсәрләре тәшкил итә. Төзүче бу мәңгелек якты хис турындагы меңләгән җырларның иң гүзәлләрен генә сайлап биргән.

Җыентыкның һәрбер бүлегенә махсус тукталып тормастан, анда чагылыш тапкан бер житди закончалык турында әйтеп үтәсе килә. Китапның эстетик дәрәҗәсе бүлектән бүлеккә күтәрелә бара һәм иң соңгы «Борынгы җырлар» бүлегендә үзенең кульминациясенә җитә. Соңгы бүлектә еллар-гасырлар аша безгә килеп җиткән гүзәл җырлар урнаштырылган. Ә инде XX гасыр җырларын алсак, әлеге күренеш бездә җыр жанрының үсеш процессын, тора-бара шагыйрьләрнең осталыгы артуын, поэзиянең идея-эстетик дәрәҗәсе камилләшүен чагылдыра кебек...

Китапның гомуми төзелеше турында сөйләгәндә, бер искәрмә дә әйтеп үтәсе килә. Күрсәтелгәнчә, җыентыкта «Борынгы җырлар» дигән махсус бүлек бар. Ә менә «Бакалы», «Балавыз шәм», «Бадьян балы» кебек татар халкының, һичшиксез, борынгы җырлары бөтенләй башка бүлектә урын алган. Бу җырларның архаик теленә генә игътибар итеп карыйк:

Олы юлдан узган да шул кәрваннарның,
кәрваннарның
Һаваларга оча ла шул, әй, тузаны,
һай тузаны.
Ир егетләр бергә лә шул дус булсалар,
дус булсалар,
Сиэелмидер гомерләрнең, әй, узганы,
һай узганы.

*(«Бакалы».)*

Һәрхәлдә, мондый җырлар үзләре белән рәттән урнаштырылган «Табын җыры» (Ә. Ерикәй сүзләре, Р. Яхин музыкасы), «Туй җыры» (М. Хәсәен сүзләре, А. Вәлиуллин музыкасы) кебек әсәрләр белән берничек тә аваздаш була алмыйлар.

Бас, кодача, бас, бажа!
Булсын әйдә тамаша!
Йөзең якты, сүзең татлы!
Дип әйтәләр ләбаса, шул.
Җырла, дуслкай! Бие, туган!
Мәҗлес барсын таңгача.

Китаптагы башка кайбер җырларның да урыны дөрес сайланмаган кебек. «Син сазыңны уйнадың» (Н. Исәнбәт сүзләре, ...елык музыкасы), әйтик, «Мәхәббәт җырлары» бүлегенә кергән. Ә уйлап карасаң,

бу җырның гомуми эчтәлеге, андагы хис-тойгылар өермәсе интим лирикадан күп тапкыр киңрәк бит:

Үтте ул даулы гомерләр,
Кан-көрәштә яңгырап.
Саклаганмын тик күңелдә
Шул көрәшнең моңнарын.

«Мәхәббәт җырлары» бүлегендә урын алган «Бер егет кайтты флоттан» (М. Ногман сүзләре, А. Монасыйпов музыкасы), «Казан кызы» (Н. Арсланов сүзләре, З. Хәбибуллин музыкасы), «Башыңдагы шәлъяулыгың (Х. Мәхмүтов сүзләре, Л. Айтуганов музыкасы) кебек әсәрләр «Күңелле җырлар» бүлегендә булса, урынлырак булыр иде шикелле. Дәлил өчен, күрсәтелгән һәрбер җырдан өзек китермичә, соңгысының бер куплетын гына алыйк:

Башыңдагы шәлъяулыгың
Маңдаң мәллә яшелгә?
Мин сине яратам күптән,
Сөйсәң, син дә яшермә!

* * *

Китерелгән гомуми күзәтүләрдән соң китапның эченәрәк керик, хәзерге җырлар белән якыннанрак танышып карыйк. Алар арасында без «Сибелә чәчәк», «Асылъяр», «Зәңгәр төймә» кебек киң таралган халык җырларын да, «Киек казлар» (Х. Туфан сүзләре, М. Макаров музыкасы), «Башка берни дә» (С. Хәким сүзләре, М. Мозаффаров музыкасы), «Кама буе — туган як» (Р. Әхмәтҗанов сүзләре, Ф. Әхмәдиев музыкасы) шикелле, халыкның ихтирамын казанган профессиональ җырларны да очратабыз. Мондый матур җырлар җыентыкта бик күп. Аларның һәркайсы турында да рәхәтләнеп һәм тәфсилләп сөйләп булыр иде. Ләкин сүзне озынга сузмастан, бер җөмлә белән генә болай диик: **җыентыкның төп өлешен бүгенге көндә киң таралган, шигъри-музыкаль дәрәҗәсе югары торган** җырлар тәшкил итә. Бу — тәэзченең уңышы дип бәяләнергә тиеш.

Ә инде китапка һәм җыр авторларына зуррак таләпчәнлек белән карый башласак, башка кайбер нәрсәләргә дә игътибар итәргә тиеш булабыз. Башта ук күзгә ташланганы — китапта 98 авторның җыры китерелгән. Шулар арасында зур урынны әдәбиятка бөтенләй катнашы булмаган «үзешчән» шагыйрьләр алган. Җырлары яхшы булса — бер хәер иде. Юк шул! Примитив үзешчәнлек ташкыны чын сәнгатьчә осталыкка һөҗүм итә. Беркатлы җыр сүзләре көчле музыка канатына таглып да ил гизәргә китә. Ягъни кайвакыт композиторлар үзләренең гүзәл көйләренә шундый ук гүзәл сүз сайлый белмиләр. Үзеннән-үзе җырлап торган шигырьләр кайвакыт кәгазьдә генә кала, ә шикле җырлар радиодан яңгырый, халык арасына тарала, кабат-кабат төрле җыентыкларда басыла. Әнә шуның нәтиҗәсе буларак, хәзерге җырлар арасында гаять күп шаблоннар, штамплар пәйда була, бихисап кабатлаулар килеп чыга. Конкрет мисалларга күчик. Бик күп җырларда еш кына бер үк темалар, бер үк күренешләр, фикерләр кабатлана. Мәсәлән, моннан берничә ел элек бездә нефтьчеләр турында роман, повесть, поэмалар һәм, әлбәттә, җырлар язу киң таралган иде. Проблема бик актуаль булганга, бу күренеш табигый дип бәяләнергә тиеш, билгеле. Шул уңайдан нефтьчеләр турында уннарча җырлар туды. Дөрес, аларның байтагы тиз арада онытылды, халык репертуарында урын ала алмады. Әмма калганнары — «Җырлар китабы»нда басылганнары арасында да күптән таушалган шаблон образлар, кабатлаулар җитәрлек икән. Мисалга «Ямьле безнең Минзәлә-без»дә дә **кара алтын** образы (Э. Шәрифуллина сүзләре, Ә. Бакиров музыкасы), «Безнең Азнакаебыз»да да (Г. Моталлапов сүзләре, С. Әхмәтов музыкасы), «Казан-Уфа»да да (М. Хәсәен сүзләре, А. Ключарев музыкасы). Шул ук **кара алтын** образын без алга таба да тагы бер биш-ун тапкыр очратабыз. Менә шундый зур темаларга бик күп кешеләр тотынгач, аның иҗтимагый-эстетик яңгырашы таушала башлый. Моңа карап зур проблема үзенең тарихи-социаль әһәмиятен югалтмый, әлбәттә. Тик аның сәнгатьчә чагылышы беркадәр вагая, таушала, тәссезләнә.

Безнең көннәрдә — республикабызда бер-бер артлы яңа шәһәрләр туган чорда — бу турыда язу да киң таралды. Һәм бу да табигый күренеш, билгеле. Халкыбызның музыкаль-поэтик репертуары ил тормышындагы зур үзгәрешләрдән читтә тора алмый. Тик бу җитди социаль-политик темага багышланган җырлардагы шаблоннар да зур проблеманы ваклый. Әйтик, өлеге җыентыктагы җырларда бөтен шәһәрләр һәм авыллар үсәләр. Казан да «нурланып үсә», Шәйморза да, Чаллы белән Чистай да үсә. Бу турыда укучы «Казан» (Х. Вахит сүзләре, М. Мозаффаров музыкасы), «Балкый Шәйморза утлары» (М. Ногман сүзләре, С. Садыйкова музыкасы), «Кам-

АЗ — безнең горурлык» (М. Хәсәен сүзләре, З. Хәбибуллин музыкасы), «Чистай вальсы» (Ф. Әхмәдиев сүзләре һәм музыкасы) кебек һ. б. кайбер әсәрләрдә укый ала.

Бер үк темаларның, күренешләрнең бер үк формада кабатлануын башка бик күп җырларда да күрергә мөмкин. Мисал өчен туган як турындагы җырларга игътибар итик.

Төрле авыллар, өлгалар, күлләр, гомумән — туган як турында җыр иҗат иту — халык иҗатыннан килгән, гасырларга сузылган матур традиция. Әнә шул традиция нигезендә туган халык җырларының иң матур үрнәкләре җыентыкта да урын алган: «Кондырак болыннары», «Зәй буйлары», «Арча». Бу иҗади традицияне шагыйрьләр һәм композиторлар да күтәреп алды. Нәтиҗәдә «Ямьле безнең Иделдә» (М. Садри сүзләре, М. Мозаффаров музыкасы), «Туган ягыбыз — Биләр» (А. Әхмәтов сүзләре, И. Шәмсетдинов музыкасы), «Ык буйлары» (Г. Зәйнашева сүзләре, К. Бакиров музыкасы) кебек җырлар туды. Тулаем алганда — бу начар күренеш түгел, әлбәттә. Тик бу җырларның бик күбесе бер-берсенә игезәкләр кебек охшаганнар. Уңган кызлар дисеңме, батыр егетләрме, урманнар, тугайлар, киң басулармы — болар һәркайда да бар. һәм алар шул килеш коры санап чыгу, констатация рәвешендә генә җырларга күчәләр. Аларда бернинди яңалык, җитди үзенчәлек, хәтердә калырдай шигъри образлар булмый. Шуңа күрә безнең кайбер җырлар газета информацияләрен хәтерләтәләр. Менә М. Садри сүзләре белән җырлана торган «Ямьле безнең Иделдә» җырыннан бер куплет (М. Мозаффаров музыкасы).

Аккош кебек теплоходлар
Туктыйлар портыбызда,
Кабыналар яңа утлар
Иделдә — йортыбызда.

Мондый гади информация, декларация формасында гына язылган җырлар бездә аз түгел. Г. Моталлапов белән С. Әхмәтовның «Безнең Азнакаебыз» җырыннан бер генә куплет алыйк:

Дан казанды илебездә
Кара алтын — җир мае.
Азнакайдан үсеп чыкты
Бөек хезмәт герое.

Күрсәтелгән һәм башка кайбер җырларга образлылык, шигъри нәфислек, күңел түрендә урын алырдай хис-тойгы нечкәлеге җитеп бетми. Җыр кешенең күңелен тетрәтергә, аңарда хис-тойгылар, тирән фикерләр ташкыны кузгатырга тиеш. Ә менә А. Әхмәтов белән И. Шәмсетдиновның «Туган ягыбыз — Биләр» җыры бернинди хис-фикер уята алмый. Чөнки ул коры декларациягә нигезләнә:

Урманга бай, кырларга бай
Туган ягыбыз — Биләр.
Бездә үскән егетләрне
Арыслан кебек диләр.

Билгеле булганча, «Ямьле Агыйдел буйлары», «Шөгер», «Сарман» кебек халык җырлары татар халкы яши торган бик күп җирләрдә таралган. Чөнки халык җырлары гадәттә киң гомумиләштерүгә нигезләнә, изге хисләрне матур шигъри образлар, тирән фикерләр, үзенчәлекле афористик тәгъбирләр ярдәмендә гәүдәләндерә. Ә менә төрле авыл-өлгаларга карата кайбер шагыйрьләр һәм композиторлар иҗат иткән җырлар турында алай дип булмый. һәм моның төп сәбәбе әлеге җырларның эстетик дәрәҗәсе белән бәйләнгән булса кирәк...

Китапның бите саен туган якны сагыну турында укыгач, аптырап каласың: соң кайларда тилмереп йөри икән безнең шагыйрьләр? Әйтик, Гөлшат Зәйнашева? «Туган җирем — Татарстан» дигән популяр җырында ул:

Кая гына китеп,
Кайларга бармадым,
Сагынып кайттым Иделем таңнарын,—

дип җырлаган иде. «Очрашу җыры»нда сүзләр бераз үзгәргән:

Килдем, дуслар, Идел-диңгез кичеп,
Сезне сагынып, кошлар кебек очып.

Бу ике җырында шагыйрь үзе турында сөйләсә, «Яшь гомер»дә сагыну хисе икенче бер затка күчә:

Яшьлектә сөйгән яр
Сагындым, килеп ал,
Сине көтәм һаман дип әйтер кебек.

Менә мондый типик сагынулар бер Зәйнашева җырларында гына түгел. Алар башка шагыйрьләрдә дә җитәрлек. Мәсәлән, Н. Дәүли «Татарстан минем республикам» исемле җырында үзенчә сагына:

Еракларга киткән тургайлар да
Сагынып кайта туган йортына.

«Туган як» дигән җырында М. Мазунов шул ук сагыну турында күбрәк иҗекле юллар белән сөйли:

Ә сине, ә сине, ә сине, туган як,
Бар микән сагынмый торган чак?!

Х. Вахит «Яз айлары»нда аеруча көчле сагыну хисләре кичерә икән:

Яз айлары сагынуымны
Тирәнәйтә бермә-бер...

Ә инде мәсьәләгә җитдирәк килсәк, сагыну, бигрәк тә туган якны, туган илне

сагыну — ул беркем дә тел-теш тидерә алмастай изге хис. Тик бу турыда бер үк тәгъбирләр белән уннарча тапкыр кабатлагач, аның әһәмияте бетә, изгелеге сүрелә, ул бернинди хис тә уятмый, гади шаблонга, штампка әверелә. Аннан соң, дөресен әйткәндә, сагыну мотивы безнең көннәр өчен ул кадәр актуаль да түгел. Сугыш елларында, мәсәлән, ул типик күренеш иде, бөтен халык йөрәген биләгән дөнья күләм бер изге тойгы иде. Поэзиядә дә ул шулай күтәрелде. Ә безнең көннәрдәге сагыну турындагы җырларның байтагы — әлеге гүзәл традициянең уңышсыз дәвамы гына. Хәзер туган якны сагынып тилмерәсе юк. Һәм аны коточкыч зур проблема итеп поэзиягә сөйрәү дә, бу турыда шаблон алымнар белән кабат-кабат сөйләү дә үзен акламый.

«Җырлар китабы»н укый башлагач, тагы бер кызыклы хәлгә тап буласың: безнең яшьләр-кызлар һәм егетләр гел **җырлап** кына йөриләр икән. Мисалга, Г. Насрый сүзләренә җырлана торган «Сайра син, тургай»ның бер куплеты:

> **Җырладылар** яшь егетләр,
> Кушылды кызлар,—

дип башлана. Шуның нәтиҗәсе буларак:

> Күкрәкләрендә балкыды
> Алтын йолдызлар...—

дип тәмамлана куплет. Җырда яшь колхозчыларның фидакарь хезмәте турында бер сүз дә юк. Әйтерсең аларга җырлап йөргән өчен генә орден-медальләр таганнар...

«Буразналар» җырында Г. Зәйнашева «**Җырлар җырлап** кырга чыгам» дисә, Р. Ишморатның «Гөлсинә»се «**Җырлыйжырлый** эшкә бара...» икән. Ә инде «Очрашу җыры»нда шул ук Г. Зәйнашева барыбызны да җырларга чакыра: «**Җырлыйк**, дуслар, бергәләп **җырлыйк**, дуслар!..»

Җыр — халыкның мәңгелек юлдашы. Кеше үзенең кайгысын да җыр белән уртаклаша, шатлыгын да җыр теле белән сөйли. Бәлки, шуңа күрәдер бездә җыр җырлау турында шул кадәр күп языла. Моңа каршы килеп булмый, билгеле. Кешенең тормышы яхшы, күңеле күтәренке икән — җырласын! Ләкин халык тормышындагы гаять тирән рухи үзгәрешләр һәр вакыт, һәрбер җырда бер үк сүзләр, бер үк тәгъбирләр, бер үк эмоциональ яңгыраш белән әйтелгәч, әлеге җырлардан колак тона, читкәрәк китеп, тынычрак урын эзли башлыйсың...

Хәзерге җырларда бер үк темаларның, күренешләрнең күп тапкырлар кабатлануы турында шактый озак сөйләп булыр иде. Мисалларга да аптырап торасы юк. «Җырлар китабы»нда алар җитәрлек.

Темалар, төп фикерләр, идеялар кабатлангач, төрле сурәтләү чаралары да — эпитетлар, чагыштырулар, шигъри параллельләр дә бернинди үзгәрешсез бер җырдан икенчесенә күчеп йөри. Хәзерге җырларда кызлар да, киленнәр дә, хәтта егетләр дә **уңган**, һич югы, **матур** була. Егетләрнең кайвакыт **батыр** булуы да мөмкин. Ә инде җырда сүз бодай, кыр, нефть турында барса, аларның һәркайсы, һичшиксез, **алтын** булырга тиеш. Аерма тик шунда гына: кыр яки бодай гади алтын булса, нефть — мәҗбүри рәвештә **кара** алтын. Әгәр җырда Чулпан калка башласа, аннан соң, һичшиксез, **алсу таң ата...**

«Туган ил, туган як, Татарстан» дигән бүлектә генә дә таң образы биш тапкыр кабатлана, **гүзәл, ямьле** кебек сүзләр һәр җырда диярлек очрый, ә инде **матур** сүзе унбер тапкыр кулланыла. Ягъни, Казан да **матур**, Идел дә, туган ил дә, иртә дә, кич тә... Өстәвенә, киләсе бүлек тә «Дөнья **матур**, дөнья киң» җырыннан башлана икән (Г. Афзал сүзләре, С. Садыйкова музыкасы).

Китерелгән эпитетлар хәзерге җырларда искиткеч киң таралган, бер үк формада, бер үк сүз тезмәсендә катып калган шаблон формасын алган. Алар күңелдә бернинди хис уята алмыйлар, күптән туйдырган гадәти бер нәрсә кебек эзсез үтәләр. Шуңа күрә күп кенә җырларның сүзләре тыңлаучы күңеленә үтеп керә алмый, бер колактан кереп, икенчесеннән чыгып китә. Алар җырга бернинди яңалык өстәмиләр, ә бәлки, киресенчә, еш кына примитивлыкка китерәләр...

Шулай да хәзерге җырларның «үзәгенә үткән» эпитет **ямьле** булса кирәк. Безнең җырларда Агыйдел, Мишә, Сөн, Чирмешән буйлары да, Минзәлә, тау буе, кырлар-болыннар да **ямьле...**

Гомумән, бездә ямьле нәрсәләр искиткеч күп икән. Ярый әле, бу турыда безгә җыр авторлары армый-талмый һәм берсеннән соң берсе уздырып, тырыша-тырыша язалар. Югыйсә, без җәй көннәренең дә, сабан туйларының да, хәтта яшьлекнең дә **ямен** сизмичә калган булыр идек...

Темалар, образлар, шигъри алымнардан тыш, кайбер җырларда хәтта конкрет юллар да сүзгә-сүз кабатлана кебек:

Диңгез кебек дулкынланып,
Кырда чайкала иген.—

дип язган иде Х. Вахит «Саба» җырында. Э. Шәрифуллина «Ямьле безнең Минзәләбез» җырында шул ук фикерне шундый ук сүзләр белән диярлек кабатлый:

Диңгез кебек дулкынлана
Киң басуларда иген.

Кайбер җырларда төрле характердагы стилистик төгәлсезлекләр дә очрый. «Граниттай нык итеп койгансың...» — дип башлый Г. Зәйнашева үзенең «Замандашыма» дигән җырын. Шуннан соң инде үзеннән-үзе эпик киңлек көтелә. Сүз дөнья күләм әһәмияткә ия булган тарихи вакыйгалар турында бара, күрәсең, дип уйлыйсың. Алга таба укысаң, нибары «Мин торган йортның нигез ташын...» гына икән. Менә бу юл җырның шактый югары ноктадан башланган аһәңен сүндерә, эпик киңлек юкка чыга. Киләсе юлларда автор никадәр тырышып караса да, ул әйләнеп кайтмый.

Р. Ишморатның «Мехчылар җыры» Казан мех комбинаты, аның уңган эшчеләре, кызлары һәм егетләре турында сөйли. Көтмәгәндә җырга түбәндәге строфа килеп керә:

Һаваларны ярып оча
Безнең ил бөркетләре;
Асыл затлы мех эшлиләр
Меховой егетләре.

Шушы строфаны укыгач, бу ил бөркетләренең меховой егетләренә нинди мөнәсәбәте бар икән? — дип уйлап куясың.

Кайбер җырларда образлар төгәлсезлеге, аларның чын шигърияттән ярыйсы ук ерак булуы күзгә ташлана. Мисалга «Әлмәт кичләре» җырын алыйк (Г. Зәйнашева сүзләре, З. Гыйбадуллин музыкасы).

Ай янында бер йолдыз бар,
Б р и л л и а н т шикелле якты...

Мондый колак шиңдерерлек, телеңне тешләрлек «образлар» белән язылган җырлар җыентыкның яңа басмасында урын алмаса да, китап берни югалтмаган булыр иде.

* * *

«Җырлар китабы» — киң катлау укучылар өчен чыгарыла торган популяр җыентык. Димәк, киләчәктә аның яңа басмалары кирәк булачак. Минемчә, җыентыкның дәрәҗәсен күтәрү, халкыбызның хәзер ярыйсы ук югары дәрәҗәдә торган эстетик таләпләренә җавап бирү өчен, аның алдагы басмасын әзерләгәндә кайбер принципиаль яңалыклар кертергә кирәк булачак...

Иң элек, җыентыктагы әерым әсәрләрнең сыйфаты күрсәтүенчә, китапка керү өчен җыр сайлаганда, аларның һәркайсы принципиаль тәнкыйть күзлеге аша үтәргә тиеш...

Алдарак җыентыкны хронологик принцип нигезендә төзергә омтылу сизелә дигән идек... Ләкин бу җитди фәнни принцип нигәдер ахырга кадәр сакланмаган. Башта хәзерге заман җырлары бирелеп, тик ахырда гына борынгы җырлар китерелгән. Монда төзүчене генә гаепләү бәтенләй ук хаклы булмас иде. Күрәсең, нәшрият шул катып калган традицион композицияне таләп итә. Бу таушалган принципның фәннилектән ярыйсы ук ерак торуын мин бер тапкыр язып чыккан идем инде. Анда сүз З. Хәйруллинаның «Халык җырлый» җыентыгы турында бара иде. («Казан утлары», 1971 ел, 6 сан.) Шулай да бу ялгыш принцип тагы бер тапкыр кабатланган. Популяр җыентык өчен фәннилек мәҗбүри түгел дип әйтүләре мөмкин. Ярый, шулай да булсын, ди. Тик борынгы җырларның иң ахырдан гына— «ярый инде, сезгә дә урын бирелсен» дигән шикелләрәк кенә кертү әлеге җырларның идея-тематик кыйммәтенә, искиткеч камил эстетик дәрәҗәсенә күләгә төшерергә тырышу кебегрәк тоела. Аннан соң, халык арасында әле бүген дә гаять киң таралган, кайда теләсәң шунда, кайчан теләсәң шунда яңгырый торган «Туган тел», «Сакмар», «Салкын чишмә» шикелле җырлар искерә алмый. Алар беркайчан да «борынгы җырлар» рәтендә генә кала алмас кебек. Мондый җырларның музыкаль-поэтик яңгырашы, идея эчтәлеге, эстетик мөмкинлекләре шул кадәр киң ки, алар гасырлар буе заманча, бүгенгечә яңгырап торачак.

Минемчә, җырлар китабының яңа басмасы бераз башкачарак төзелсә, яхшырак булыр иде шикелле. Иң элек зур булмаган кереш мәкалә. Аннан соң билгеле бер җитди принцип нигезендә урнаштырылган җырлар. Ахырда кыска һәм төгәл төзелгән аңлатмалар. Русча, мәсәлән, киң катлау укучылар өчен матур әдәбият редакциясе чыгара торган популяр җыр җыентыклары инде шул принциплар нигезендә чыга. Димәк, русча популяр җыр җыентыкларыннан үрнәк алып, китапны фәнни нигездә төзегәндә, ул тагы да матуррак булыр иде.

Ф. УРМАНЧИЕВ.

## Газиз Иделле

# БЕРЕНЧЕ ЗУР СӘЯХӘТ

## 10. Безне Әзербәйҗан каршы ала



Менә без Әзербәйҗанның башкаласы Бакуда.

Безне сәламләп каршы алулар юлда ук башланды. Туктаган станцияләрдә Баку газеталарын кулга алу белән, беренче битләрендә үк безне — Татарстан кунакларын — Әзербәйҗан һәм рус телләрендә «Хуш киләсез!» дип котлау-тәбрикләү сүзләрен дулкынланып укырга туры килде. Республиканың үзәк «Коммунист» газетасы безнең делегацияне каршы алуга алдан ук әзерләнә башлаган икән. «Казаннан алынган хәбәрләргә караганда, бу көннәрдә Татарстан язучыларының зур бер оешмасы, Әзербәйҗанда кунак булу өчен юлга чыккан», дип яза ул бер санында. Ә без килеп төшкән көнне (18 августта) ул безне үзенең беренче битендә: «Совет Әзербәйҗанының үзәге Бакуга кунак булып килгән татар пролетариат һәм совет язучыларына кардәшлек сәламнәре!» дигән аншлаг белән каршы алды.

Поезд килеп туктады. Без вагоннардан төшү белән әллә кайчангы дусларыбыз белән очрашкандай булдык. Станциядә безне партия, хөкүмәт вәкилләре, язучылар, артистлар, журналистлар бик җылы каршы алдылар. Башта вокзалның кабул итү бүлмәсенә алып керделәр, анда Әзербәйҗан пролетариат язучылары оешмасы рәисе Гали Мөхәммәдов иптәш Татарстан язучыларын Әзербәйҗан хезмәт ияләре исеменнән тәбрик итеп, дусларча речь сөйләде, илебезнең халыклары, әдәбият-сәнгатьләре арасында шушындый бәйләнешнең әһәмиятле чара икәнлеген әйтте. Безнең делегациянең җитәкчесе Галимҗан Нигъмәти дә, үз чиратында, Әзербәйҗан хезмәт ияләренә һәм язучыларына Татарстан язучыларының һәм барлык хезмәт ияләренең кайнар сәламен тапшырды, Әзербәйҗанга, Бакуга килүебезнең максаты турында да кыска гына сөйләп үтте.

Шуннан безне, автобуска утыртып, шәһәр үзәгенә алып киттеләр һәм бик яхшы «Яңа Европа» гостиницасына урнаштырдылар.

Без килгәннең икенче көнендә газеталарда һәркайсыбыз турында кыскача мәгълүматлар, фоторәсемнәр басылды. «Яңа юл» газетасы Ш. Зыяның «Кардәш Татарстан язучыларына» дигән менә шушы шигырен дә урнаштырган иде:

Шияк сыкыр... кәләп сыкыр сәвинечтән,
Сәвинечтән одлу, одлу сәламлар!

---

Дәвамы. Башы 3, 5 саннарда.

Сәламлар вар: вышкалардан, бензиндән,
Сәламнәр вар: заводлардан сәламлар!..
Дашгын хөрмәт, кызыл өлфәт сизләрә
Ачык йөзле кадыннардан, кызлардан,
Хуш гәлдиңиз, хуш гәлдиңиз, сизәләрә
Сәламлар вар эшчиләрдән, һырлардан.
Сәламлар вар: яшь шаер әдибдән,
Эшчи кәлди, шаер кәлди бир дилдән!..

Ихлас күңелдән язылган шундый сәлам-ихтирам сүзләрен укып ничек дулкынланмыйсың! Әйе, мондый каршылаулар дулкынландыра да, зур җаваплылык та йөкли безнең өскә.

Игътибарлы, кунакчыл хуҗаларыбыз бик тырышалар: безгә күбрәк нәрсәне күрсәтеп калу өчен, һәркөннең программасы бик киеренке төзелгән. Безгә унлап кеше һәм махсус автобус беркетелгән иде.

Әзербәйҗан Дагстан кебек күп милләтле ил түгел. Монда җирле халык — әзербәйҗанлылар күпчелек тәшкил итә (биштән өч өлеше). Әзербәйҗанның халкы 3 миллионнан артык. Территориясе 85,7 мең квадрат километр.

Территория дигәч тә, бу яктан бик үзенчәлекле, катлаулы ил ул. Бу аның Кавказ таулары белән Каспий диңгезе арасында урнашкан булуыннан килә торгандыр. Безнең Татарстанны, мәсәлән, аркылыга-буйга йөреп үт — аның пейзажында да, һава торышында да әллә ни үзгәреш сизмисең. Ә биредә пейзаж да, климат та төрле урында төрлечә. 500—1,500 метр биеклектәге, хәтта 4, 5 мең метр биеклектәге таулы районнар да, тип-тигез иңкү җирләр дә, хәтта диңгез тигезлегеннән түбән булган районнар да, бик куе урманнар һәм ком далалары да бар. Мәңгелек кар һәм боз белән капланган мәһабәт таулар да, ел әйләнәсе диярлек яшеллеккә күмелеп торган җирләр дә бар монда. Кыскасы, Әзербәйҗанда, әгәр аны аркылыга-буйга йөреп үтә алсаң, бер үк вакытта сигез төрле климатка тап буласың икән.

Баку.

Бу сүз борын-борыннан нефть сүзе белән янәшә йөри. Апшерон ярым атавында урнашкан Баку тирәсе — бөтен җир шарында беренче урыннарның берсен алып торган нефть районы. Кая карама анда — нефть вышкалары. Скважиналары бер-берсенә бик якын (100—150 метр, хәтта 20—30 метр чамасы гына) бораулانганнар һәм ерактан караганда урманга охшап тора.

Россиядә иң беренче нефть фонтаны 1873 елда нәкъ менә шул Баку янындагы Балаханы районында бәреп чыккан икән. Шуңа да игътибар итик: ул беренче скважинаның тирәнлеге нибары 15 метр булган! Бу — Баку нефть районының гомуми үзенчәлеге. Монда бик тирәндә булмаган нефть ятмалары күп. Шуңа күрә, һәм беренче чорда техника да түбән булу сәбәпле, скважиналар бер-беренә бик якын бораулаганнар. Аннары элекке хосуси нефть кампанияләрен, барыннан да бигрәк, нефтьне тизрәк, күбрәк алу кызыксындырган. Шуңа алар бер-берсе белән ярышып бораулаганнар, җир байлыгыннан кыргыйларча файдаланганнар, эшчеләрне хайван урынына эксплуатацияләгәннәр.

Ул чор тарихта гына калган инде. Ә бер карасаң, әллә ни ерак тарих та түгел икән үзе. Максим Горький, яшь чагында, ил гизеп йөргәндә, бу тирәләрдә булган һәм йөрәк тетрәткеч картиналарны үз күзе белән күргән. «Нефть промыселлары даһиларча эшләнгән караңгы җәһәннәм картинасы булып хәтеремдә калган,— дип яза ул.— Алар миңа шаккатырырлык, һуштан яздырырлык булып тәэсир иттеләр. Тәртипсез тезелеп киткән вышкалар арасында — көрән, соры төстәге һәм берничек тә эшкәртелмәгән формасыз ташлардан, озын һәм тәбәнәк итеп, ашык-пошык укмаштырылган эшче казармалары җиргә сеңеп китәргә дип торалар. Алар тарихкача булган кешеләр торагына охшый...»

Без инде монда хәзер капма-каршы күренешләр, капма-каршы тормыш-язмышлар белән танышып йөрибез.

Революциягә кадәр монда нефтьче эшчеләр арасында төп профессия — тартальщик булган. Нәрсә дигән сүз ул тартальщик? Әзербәйҗан сүзеннән алынган бу: дартмаг, ягъни тарту дигән сүздән килә. Элек буровой скважиналар кое кебегрәк киң

итеп бораулап казылганнар. Төбенә клапан ясалган озынча чиләкне корыч арканга бәйләп, шуны «коега» төшереп, нефтьне тутырып алалар да өскә тартып чыгара булганнар, трактор яки лебедка белән дә тарттырганнар, әмма күбрәк арзанлы кеше көчен файдаланганнар.

Хәзер исә аларның урынын машиналар алып тора. Механик-насос сыман техник корылма. Ул көне-төне туктаусыз эшли, башын бер күтәреп, бер иеп, нефтьне астан өскә кудыра. Эшчеләр аны «богомолка» дип йөртәләр. Татар эшчеләре дә безне алар белән «мәнә намазчы хатын» дип таныштырдылар.

Һәркайсыбыз дикъкать белән карап, аңлатмаларны тыңлап йөри. Кутуй блокнотын еш кына кулына ала, язгалый. Ул «Кызыл Татарстан» газетасына сәяхәтебез турында репортажлар җибәреп тора. Закир Гали дә шулай. Сәйдәш күбрәк төрле тавышларга колак сала, күрәсең, алардан музыкаль ритм эзлидер. Такташ, Фәтхи, әлбәттә, мондагы хезмәт поэзиясе турында уйланалар; күзләрен зур ачып, күбрәк нәрсәне күрергә-ишетергә тырышалар...

Шунда Демьян Фәтхи, шигырь өчен оригиналь образлар эзләп тә таба алмаган кыяфәттә, кая соң монда атып торган нефть фонтаннары, дип тә ычкындырып куйган иде. Галимҗан Нигъмәти аңа, гадәтенчә борынын тарткалап:

— Әй, син Рахман Ильяс хикәяләрен укыгансың икән, алайса. Рахман ул монда элегрәк елларда булган шул, хәзер, күрәсең, ул тасвир иткән фонтаннар да тезгенләнгән инде,— дип җавап бирде.

Нефть чыгаруда миңа тагын бер хикмәтле як. Баку районында, коры җирдә генә түгел, диңгез астында да нефть барлыгы ачылган икән. Мәнә Каспий диңгезенең шәһәргә якын гына ярлары. Җиде-сигез ел элек бу җирдә дулкыннар шаулап торган иде, диделәр безгә. Ә хәзер монда да вышкалар, монда да нефть чыгаралар. (Әйтергә кирәк, ул елларда хәзерге кебек диңгез эченә кереп бораулау ысулы юк иде әле. Ә башта болай эшләгәннәр икән алар: диңгезнең бер өлешен дамба белән чолгап-кисеп алганнар, суын кире диңгезгә кудырып, шул урынны тигезләгәннәр. Шуннан соң бораулап нефть чыгарырга керешкәннәр. Моның эше, мәшәкате күп булган, әлбәттә. Ләкин без булган ул еллар өчен бу да гаҗәеп зур җиңү — уңыш иде.)

Эшчеләрнең тормыш-көнкүреш шартлары да элеккә белән чагыштырмаслык дәрәҗәдә яхшыртылганын күрдек без. Алар әйбәт җиһазландырылган яңа йортларда яшиләр. Мәнә, мәсәлән, без «Яңа Баку» дип йөртелә торган Арменикенд районына килеп чыктык. Бу урын моннан өч-дүрт ел гына элек бушлык-дала булган. Ә хәзер монда йөзләрчә яңа зур-зур йортлар салынган. Бер эшченең яңа квартирына да кереп карадык. Бик пөхтә, чиста, уңай... Кухня, ванна, санузел. Инде төзелеп беткән бу кварталда хәзер меңнән артык кеше яши, диделәр. Ә төзелеш һаман дәвам итә, көндез кырык градуска җиткереп кыздыра торган кояш астында да, төнлә кояшны алмаштырган прожекторлар яктысында да көне-төне эш кайный.

Әзербәйҗан дусларыбыз безне туку фабрикасына алып бардылар. Ленин исемен йөртә торган бу фабрика — Баку шәһәрендәге зур предприятиеләрнең берсе. Анда өч меңнән артык кеше эшли. Күпчелеге, һәркайдагы кебек, хатын-кызлар. Шул уңган хатын-кызлар эшләтә торган машиналарда ап-ак мамык-җепнең гаҗәеп матур төсләргә бизәлгән тукымага әверелүен без үз күзләребез белән күреп тордык.

Гасырлар буе дин, шәригать, кыргый гореф-гадәт кебек чылбырларга бәйләнеп яшәгән төрек-татар хатын-кызларын революция әнә шулай якты юлга алып чыкты, социализм төзү эшенә актив катнашуга тартты.

Безне хатын-кызлар өчен махсус оештырылган производство клубына да алып бардылар. Бакуның Яңа шәһәр дип аталган районында урнашкан ул клуб 1920 елда ачылган. Башта аның нибары ун члены була. Ә хәзер анда биш йөз әзербәйҗанлы хатын-кыз эшли һәм укый! Клуб кынамы соң бу! «Менә диген фабрика ич!» — дип, бүлмәләрдән бүлмәләргә кереп йөрибез. Клуб мөдире — урта яшьләрдәге, житди-мөлаем чырайлы Гөлара ханым — безгә бу гаҗәеп оешманың дингле, предприятиенең димме, тарихы турында сөйли, аның бүгенгесе һәм киләчәге белән таныштыра.

Монда безне бөтенесе кызыксындыра. Бигрәк тә Сәрвәр апа Әдһәмованы. Күбрәк ул сораулар бирә. Җаваплар канәгатьләндермәсә, кат-кат сорый. Тегүче хатын-кызлар янына ук бара, алардан да нәрсәдер сораша, ни турындадыр, әле борчылып, әле

елмаеп-көлеп, үз кешеләрдәй, кардәш кешеләрдәй сөйләшәләр. Барыбыз да ир-ат, Сәрвәр апа арабызда бердәнбер хатын-кыз булгач, мондагы эшче хатын-кызлар да аңа аеруча игътибар белән карыйлар. Хәтта ничектер үзләренчә кызыксынып-көнләшеп карыйлар, дияр идем [1].

Шунда кинәт, бу хәлне күреп, үзең дә уйлана каласың. Уңае килгәндә бу турыда да берничә сүз әйтми булмый. Сәрвәр Әдһәмова — җитди, эшчән, тыйнак, югары белемле, акыллы, культуралы. Ул Кави агабызның тормыш иптәше генә түгел (гәрчә бу үзе генә дә күп нәрсә турында сөйли!), ә укытучы, тәрбияче, язучы да. Ул иҗат иткән пьесалар, хикәяләр, мәкаләләр безнең укучы балаларыбызга яхшы таныш. Аны Максим Горький иҗаты аеруча кызыксындыра. Һәм соңра аның әсәрләрен татарчага тәрҗемә итүче булып үсә, таныла ул. Бездән, аеруча миннән, тагын бер өстен, бәхетле ягы бар аның: ул Максим Горький белән узган ел ук Казанда очрашкан!..

Безнең делегация составында шул Сәрвәр апаның да булуы безнең үзебезгә дә яхшы тәэсир иткәнлекне искә төшерми үтә алмыйм. Болай дип әйтүемә укучы гаҗәпләнмәсен. Без тормышыбызда хатын-кызларның тоткан урыны турында кайвакыт җитәрлек уйлап та җиткермибез, ахры. Минә мин бик күп сынаганым бар: ир-атлар үзләре генә булганда, күп кенә очракта, үзләрен артык иркен тоталар, таркалып китәләр, үзара мөгамәләдә, сүздә-хәрәкәттә тупаслыкларга да юл куйгалыйлар. Шунда алар янына бер хатын-кыз килеп кердеме — кинәт җитдиләнеп, тәртипләнеп, җыйнакланып китәләр. Кыскасы, ирләр арасында хатын-кызлар булу аларны ничектер рухи күтәреп, сафландырып җибәрә. Гомуми күзәтүләрдән алган шундый тәэсир безнең бу очракта да, кай ягы беләндер, нинди күләмдәдер үзен сиздерми калмады, әлбәттә. Кабат әйтәм: бу озын, зур сәяхәтебезнең башыннан ахырына кадәр Сәрвәр апаның да безнең белән бергә булуына без бик канәгать һәм шат булып йөрдек. Безнең алдыбызда аның дәрәҗәсе гел югары булды. Без аны бердәнбер хатын-кыз буларак та, гомумән бердәнбер хатын-кыз язучыбыз буларак та хөрмәт иттек, ә ул исә моңа карап бер дә һаваланмады, үзен бик тыйнак һәм һәркайсыбыз белән бик гади тотты.

Минә хәзер дә шулай.

Сәяхәтебездә беренче тапкыр очраган бу зур хатын-кызлар коллективында ул үзен үз туган апалары-сеңелләре янындагыдай сизә, күптәнге танышлардай, әңгәмәгә җиңел катнашып китә.

Бүлмәдән бүлмәгә кереп йөрибез, танышабыз.

Мондагы хәзерге зур эшләр бик кечкенәдән башланып киткәннәр икән. Искелеккә каршы, яңа тормышка омтылучы ун-унбиш кенә кыю хатын-кыздан торган ательс сыман нәрсә оештырып җибәрәләр. Машинада тегү эшенә өйрәнүгә керешәләр. Әмма күпчелек укый-яза да белми. Нишләргә? Шунда наданлыкны бетерү курслары да ачыла. Бүлмәләрнең берсендә китапханә оештырыла. Шулай итеп, клубка йөрүчеләр бер үк вакытта хәреф танырга да, укырга-язарга да, машинада тегәргә дә өйрәнәләр.

Производствога, тегү эшендә осталыкны арттыруга зур игътибар бирелә. Хәзер инде бу — клуб дәрәҗәсеннән ашкан, махсус шартларга җайландырылып корылган тегү фабрикасына әйләнгән. Биш йөз кеше эшли бит монда, ә киләчәктә бу сан сигез йөзгә җиткерергә планлаштырылган булуын да әйттеләр.

— Башта безнең клуб эшләренә читтән генә, сагаеп кына караганнар иде,— дип дәвам итә Гөлара ханым.— Әмма безнең яңа, якты юлга чыгуыбызны бик тиз төшенеп алдылар. Безгә килүчеләр саны артканнан-арта барды. Аннары тормыш үзе алга яңадан-яңа бурычлар китереп куйды: безгә яшь кызлар гына түгел, балалы, семьялы хатыннар да килә башлады. Аларның үтенечен кире кагарга, үз арабызга кабул итмәскәме? Юк, килүчеләрдән беркемне дә кире какмадык без. Яшь кызларыбыз кияүгә чыгып, аларның туйларын да үткәрергә туры килде. Монысы күңелле вакыйга. Әмма яшь бала дөньяга килгәч, ул яшь ана нишләргә тиеш? Клубтан, яраткан эшеннән китәргә, кабат искелеккә кайтырга, дүрт стена эченә бикләнергә тиешме? Юк, мондый хәлләргә һич тә юл куярга ярамый иде. Безгә тагын яңа бер «цех» арттырырга туры килде: клуб каршында ясле дә ачып җибәрдек.

---

[1] Саубуллашканда, үзләренең тирән хисләрен белдереп, Сәрвәр апага истәлекле бүләк тапшырдылар.

Производство бүлмәләрендә эшләүче аналар үзләрен бик тыныч иркен тоталар, чөнки аларның нәни сабыйлары менә бу чиста, пөхтә бүлмәдә бик ышанычлы куллар карамагында иң. Монда аларны уңган тәрбиячеләр, махсус балалар врачлары тәрбияли. Клуб каршында акушеркалар курсы да эшли икән. Монысы инде клуб өчен генә түгел, бөтен республика өчен кадрлар хәзерли. Аның дүрт чыгарылышы булган инде һәм районнарга бик кирәкле йөзләрчә яңа яшь белгечләр җибәрелгән.



## II. Ике театр дуслыгы

Кәрим ага Тинчурин күбрәк театрлар тирәсендә, артистлар, драматурглар тирәсендә йөрсә дә, хатын-кыз язмышы проблемасы ничектер аны да бик кызыксындырды. Моның практик сәбәпләре бар. Ул күзгә күренеп үсеп барган драматург Җәгъфәр Җаббарлы белән бик дуслашып китте. Әзербайҗан драматургиясендә социалистик реализмга нигез салучы, күп драмалар авторы Җәгъфәр Җаббарлы кайнап торган энергияле, утыз яшьлек егет иде әле ул чакта. (Безнең Кәрим агадан уникә яшькә кече.) Уртача буйлы, куе кара чәчле, киң, зур маңгайлы, үткен күз карашлы, аз гына алга иелебрәк атлый, кызу-кызу сөйли торган бик хәрәкәтчән кеше һәм талантлы әдип булып минем истә калган ул. Үзенең беренче шигырьләрен, хикәяләрен, сатирик парчаларын һәм «Тугрылыклы Сәрия» исемле пьесасын язганда аңа нибары уналты яшь кенә була. Без Бакуда булган елны аның иң шаулаган әсәре— узган (1928) елда язылып сәхнәгә куелган «Севиль» исемле драмасы иде. Анда яңа тормыш һәм гаилә, революциядән соң хатын-кызлар азатлыгы проблемалары бик оста һәм үткен итеп куелган. Әйтүләренә караганда, әзербайҗан хатын-кызларын тулысынча азат итүгә чакыра торган бу пьесаның һәрбер постановкасы чын-чынлап иҗтимагый-социаль вакыйга булып әверелгән һәм спектакль барышында ук, аның көчле тәэсире астында, хатын-кызлар үзләренең чадраларын алып ташлый булганнар.

Без Бакуда чакта театрлар әле җәйге ялда булу сәбәпле, бу мәшһүр «Севиль» спектакле һәм гомумән әзербайҗан драма, опера сәнгате белән тиешенчә таныша алмадык, әлбәттә. Әмма Галимҗан Нигъмәти, Кәрим Тинчурин, Шәриф Камал, Кави Нәҗми, Гомәр Гали кебек олы агайларыбыз, алдан ук күпмедер хәзерлекле булулары сәбәпле, очрашу-әңгәмәләр вакытында бу мәсьәләләрдә үзләрен ярыйсы гына иркен тотуларын хәтерлим. Безнең Кәрим ага үзен бик кызыксындырган әлеге «Севиль» пьесасы белән дә яхшы танышып өлгергән һәм аның авторы белән үзара шундый практик килешүгә дә бик тиз ирешкәннәр: Җәгъфәр Җаббарлының «Севиль» драмасы Казанда Татар дәүләт академия театрында, ә Кәрим Тинчуринның «Зәңгәр шәл» драмасы Бакуда Әзербайҗан драма театрында куелырга тиеш, дип сүз куешканнар иде. Бу ике тугандаш халыкның театр сәнгате арасындагы күптән башланган дуслыкны дәвам иттерү юнәлешендә практик бер омтылыш иде бу булса кирәк. Мәсәлән, сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллин мәкаләсендә («Советская Татария», 22 май, 1969 ел) китерелгән түбәндәге тарихи фактлар бу һәр ике драматургка, әлбәттә, билгеле булгандыр: 1908 елда Казанда «Яшьләр» исемле һәвәскәр труппа тарафыннан Әзербайҗан драматургы Нәҗәфбек Вәзировның «Фәхретдин кайгысы» дигән драмасы сәхнәгә куела. Берничә елдан соң ук драманы мәшһүр «Сәйяр» труппасы да куя һәм ул зур уңыш белән бара. Шунысы характерлы: бу спектакльдә, Габдулла Кариев, Гыйззәтуллина-Волжскаялар белән бергә, әзербайҗан артисты Мирза-Ага Алиев та катнаша. Тугандаш ике халык артистлары хезмәттәшлегенең тагын да характерлырак шундый факты да булган икән тарихта: татар артистлары ул елларда бер урында гына эшләмәгәннәр. Моңа даими татар театры бинасы булмау да сәбәп булгандыр, әлбәттә. Шулай шәһәрдән шәһәргә йөреп, Уральскида һәм Кырымда булып үткәч, алар 1908 елда Тифлиска барып чыгалар, анда Г. Араблинский җитәкчелегендәге әзербайҗан труппасы белән очрашалар. Шунда ике труппа бергә кушыла, Әзербайҗанның атаклы сәхнә эшлеклесе Г. Араблинский җитәкче итеп билгеләнә һәм ул татар артистлары өчен беренче чын остаз һәм

акыллы киңәшче булып та таныла. «Казан-Кавказ артистлары җәмгыяте» дип исемләнгән бу труппа спектакльләрне ике телдә хәзерли һәм куя. 1908 елның язында труппа Әстерханга килеп, әзербәйҗан халкының атаклы большевик-революционеры һәм күренекле драматургы Нәриман Нәримановның «Надиршаһ» исемле драмасын сәхнәгә куя. Нәкъ менә шунда ул чактагы Әстерхан һәвәскәрләреннән Зәйни Солтанов, Сара Байкиналар да шундый квалификацияле труппа куйган бу спектакльдә беренче тапкыр катнашу бәхетенә ирешәләр һәм үз осталыкларын күтәрәләр. Берничә елдан соң, бу труппаның зур уңышлары белән бергә, спектакльләрне ике телдә хәзерләү һәм уйнау кыенлыклары да арта, һәр ике халыкның артистлары да сан һәм осталык ягыннан да гел үсә баргач, нәтиҗәдә алар икегә аерыла һәм һәркайсы мөстәкыйль яши-эшли башлый. 1913 елда Әстерхан артистлары тарафыннан татар телендә куелган «Надиршаһ» драмасында Надир ролен Зәйни Солтанов уңышлы башкаруга ирешә. Шул ук драманы «Сәйяр» труппасы да 1916 елда Казан тамашачыларына күрсәтә.

Әнә шундый кызыклы тарихи фактлар...

Әмма, мәгълүм булганча, кызганычка каршы, Бакуда без булган еллардагы Тинчурин һәм Җаббарлы планнары гамәлгә ашмый калды: бакулылар Тинчурин драмасын, казанлылар Җаббарлы драмасын күрү бәхетенә ирешә алмадылар. Моның сәбәбен эзләүне-аңлатуны мин үз өстемә ала алмыйм. Бүген исә шунысы әһәмиятле: бу әсәрем өстендә эшләп утырган көннәрдә мин үземне яңадан Әзербәйҗан җирләрендә, Бакуда, андагы дуслар янында кебек хис итеп шатландым. Совет халыклары, әдәбият-сәнгатьләре арасында бәйләнеш, дуслык, хезмәттәшлек хәзер елданел арта-көчәя бара. Рус, башкорт, кыргыз, украин, эстон һ. б. халыклар драматургиясе белән тамашачыларын әледән-әле таныштыра килүче Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә без шул ук Җәгъфәр Җаббарлының «Айдын» пьесасы буенча эшләнгән спектаклен карап куандык. Бакудагы дәүләт драма театрында исә Хәй Вахитның киң танылган «Күк капусы ачылса», Сумгаит шәһәр драма театрында Шәриф Хәсәеновның «Әни килде» спектакльләре куела. Ә 1969 елда безнең республикабызда әзербәйҗан әдәбияты һәм сәнгате декадасы үткәрелү исә аеруча зур бәйрәм булды! Без чын-чыннан онытылмаслык шатлык көннәре кичердек.

Кунак ашы кара-каршы дигәндәй, алдагы көннәрдә без дә үзебезнең шаулап үсеп киткән әдәбият һәм сәнгатебез вәкилләре белән Әзербәйҗанга барып чыгарбыз һәм аларда да шундый ук зур бәйрәм үткәрербез дип ышанам.

## 12. Революцион көрәш юллары

Әзербәйҗанның экономика, культура, әдәбият-сәнгать өлкәләрендә совет власте елларында ирешелгән уңышлары зур икәнлеген без ул елларда ук һәр кайда күреп йөрдек. Ләкин боларга ирешү җиңел булмаганлыкны да бик яхшы күреп-сизеп кайттык без. Анда патша самодержавиесенә һәм аларның ялчылары мосаватчыларга, дашнакларга каршы һәм совет властен урнаштыру өчен көрәштә героик та, романтик та, трагик та вакыйгалар аз булмаган. Болар турында махсус әдәбиятлар бар, хәзер монда аларның бөтенесе турында тәфсилләп сөйләү урыны түгел. Әмма аның искиткеч батырлыкны да, тетрәткеч фаҗигане дә эченә алган бер тарихи моменты турында кыскача гына булса да тукталмый үтеп булмый. Чөнки без әнә шул әллә ни ерак та булмаган тарих белән турыдан-туры очраштык: 26 Баку комиссары каберлегендә булдык без. Тирән уйларга чумып, баш иеп басып тордык. Безне озатып килгән шагыйрь Сөләйман Рөстәм шунда тетрәткеч нотык сөйләде. Аннары Гомәр Гали сүз алды һәм безнең уртак хисләребезне сөйләп бирде. Ул чакта әзербәйҗанлы дусларыбыздан ишеткәннәребезне, башыбыздан үткән уйкичерешләребезне укучыга бүген сөйләгәндә, бу героик эпопея турында инде беркадәр тулырак, тәфсиллерәк язып үтү кирәк дип саныйм. 26 Баку комиссары язмышы бер Әзербәйҗан тарихында гына түгел, ә бөтен илебез тарихында әһәмиятле, аның иң үткен бер чорындагы авыр сыналу үтүе турында сөйли.

Без монда күңелләребез тулы ихтирам һәм хөрмәт, кулларыбыз тулы чәчәкләр алып килдек...

...Ватаныбызда һәм бөтен дөньяда яңа эра ачып җибәргән «Аврора» залплары яңгыраган көннәр. Петроградтан еракта булган Бакуда Октябрь революциясенең алтынчы көнендә үк Совет власте игълан ителә. Әмма дошманнар, капиталистлар, аларның ялчылары сугышсыз бирелергә теләмиләр. Авыр, канлы-корбанлы көрәшләр алып бару нәтиҗәсендә, 1918 елның апрель аенда гына большевиклар партиясе, хезмәт халкы 26 кешедән торган Баку Халык Комиссарлары Советын төзүгә ирешә.

Яңа гына ирек яулап алган Ватаныбыз чит ил интервентларының һәм эчке контрреволюциянең атакаларын кире кагу сугышлары алып бара. Баку — экономик һәм стратегик яктан гаять әһәмиятле районнарның берсе. Шуңа аның өчен барган сугышлар аеруча кискен төс ала. Чөнки ул чорда Баку — илебезнең төп нефть байлыгын үзендә туплаган бердәнбер район иде диярлек, ә нефть яшь Совет республикасына һава белән судай кирәк иде. Чит ил шакаллары — интервентлар да аны үз кулларына төшерергә дип юкка гына азапланмаганнар икән шул. Алар үзләренең шул явыз максатларына ирешү өчен теләсә нинди ерткычлык эшләүдән дә баш тартмаганнар. Егерме алты Баку Комиссарлары нәкъ менә шул кабахәтләрнең корбаны булалар да: 1918 елның 20 сентябрендә тәнлә Англия интервентлары, эсерлар булышлыгы белән, Баку комиссарларын явызларча атып үтерәләр.

Ничек була бу героик фаҗига?

Англиядә чыга торган бер экономик журналда,— дип яза «Правда» газетасы,— бик образлы итеп әйтелгән шушындый сүзләр дә була: «Нефть — королева булса, Баку — аның тәхете ул». Һәм менә шул тәхеткә үрмәләү өчен Англия колонизаторлары төрле провокацияләр оештыралар, ә аларның сатлык җан ялчылары — меньшевиклар һәм эсерлар, мосаватчылар, дашнаклар, акгвардиячеләр халык арасында шовинистик коткы тараталар. Оешкан Баку пролетариаты, большевиклар партиясе, гайрәтле комиссарлар революция дошманнарына каршы аяусыз, фидакарь көрәш алып баралар. Алар хезмәт халыклары дуслыгын, интернационализмны үзләренең изге көрәш байрагы итеп күтәрәләр һәм барлык революцион көчләрне үз тирәләренә туплыйлар.

Баку совнаркомы ул елларда, асылда, бөтен Закавказьеда Совет властеның тулы хокуклы вәкаләте белән файдаланган оешма булды. Партиябезнең Үзәк Комитеты һәм Владимир Ильич үзе Баку пролетариатының героик көрәшен зур игътибар белән күзәтеп, бу тарихи көрәшнең конкрет юлларына кагылышлы конкрет киңәшләр һәм күрсәтмәләр биреп тордылар. Баку совнаркомы председателе С. Г. Шаумянга 1918 елның май аенда җибәргән хатында В. И. Ленин: «Сезнең ныклы һәм кискен политика алып баруыгыз безне сокландыра,— дип язды,— ул дөрес политиканы хәзерге бик кыен шартлар таләп итә торган бик сак дипломатия белән берләштереп алып барырга тырышыгыз, һәм шул чагында без җиңәчәкбез».

Баку совнаркомы партия Үзәк Комитетының, В. И. Ленинның күрсәтмәләрен көндәлек эшендә-көрәшендә кулланма итеп алды, совет Россиясенең бай тәҗрибәсенә, хезмәт ияләренең киң массасына таянып хәрәкәт итте. Совнарком председателе һәм тышкы эшләр комиссары С. Шаумян, губерна комиссары М. Азизбеков, совнархоз председателе И. Феолетов, җир эшләре комиссары М. Везиров, хезмәт комиссары Я. Зевин, эчке эшләр комиссары П. Джапаридзе, хәрби-диңгез эшләре комиссары Г. Корганов һ. б. Баку коммунасының рухы һәм намусы булалар, эшчеләр һәм крестьяннар белән очрашалар. Алар Ватаныбызның көнчыгышында Октябрьның беренче һәм гаять әһәмиятле крепостен дошманнардан саклау өчен завод һәм промысел эшчеләреннән дружиналар оештырдылар. Илебезнең башка шәһәрләреннән дә Бакуга төрле ярдәм килеп торды: Мәскәү һәм Ленинград, Әстерхан һәм Царицын һ. б. хәрби отрядлар җибәрделәр.

Баку совнаркомы бер үк вакытта гаять мөһим социаль чараларны тормышка ашырды: нефть промышленностен, Каспий сәүдә флотын, банкларны национализацияләде, бәкләрнең, ханнарның җирләрен конфискацияләү һәм аларны крестьяннарга бирү турында Декрет игълан итте, предприятиеләрдә 8 сәгатьлек эш көне билгеләде, мәктәпләр эшенә реформа кертте һ. б. Бу чараларның төп максаты —

пролетариат диктатурасын ныгыту, буржуазияне тар-мар итү һәм хуҗалыкны яңа социалистик нигезгә корып оештыру иде.

Баку пролетариаты, большевик комиссарлар җитәкчелегендә, үзенең совет Ватаны алдындагы интернациональ бурычын да батырларча үтәде. Бик катлаулы шартларда нефть чыгаруны һаман арттыра барып, кыска вакыт эчендә Бакудан Әстерханга сиксән миллион пот нефть озатты. Бу исә яшь Совет дәүләтенең хәрби-экономик куәтен үстереп җибәрде, көрәшне төп нефть районнарын дошманнан азат итүгә кадәр дәвам итәргә мөмкинлек бирде.

Бакуда һәм Әзербәйҗанда Совет властеның җиңүе Закавказье буржуазиясенең, контрреволюцион милләтчеләренең, Англия, Германия, Төркия интервентларының шашындырып ачуын китерде. Алар Бакуны, Әзербәйҗанны теләсә ничек басып алырга, Баку нефтенә хуҗа булырга һәм Әзербәйҗан җирләрен, бигрәк тә Каспий диңгезендә хакимлекне тәэмин итә торган һәм Советлар Россиясенә каршы көрәштә мөһим плацдарм була алган Бакуны үз кулларында тотарга дип бөтен көчләрен куйдылар.

1918 елның җәе Баку өчен авыруча кыен була. Аны чолгап алган дошман боҗрасы кысылганнан-кысыла бара. Төньяктан акгвардияче отрядлар, көньяктан Англия интервентлары кысрыклый. Баку пролетариатының чиксез батырлыгына, фидакарь көрәшенә карамастан, 31 июль көнне Бакудагы Совет власте җиңелүгә дучар була. Шунда Баку комиссарлары да кулга алына. Аларны Красноводскига алып китәләр һәм аннан 207 чакрым читтә, Ахча-Куйма белән Перевал станцияләре арасындагы ком сахрасына илтеп, төнлә атып үтерәләр. «Без коммунизм өчен үләбез. Яшәсен коммунизм!» дип батырларча һәлак булган легендар 26 Баку комиссарлары менә алар: С. Шаумян, М. Азизбеков, П. Джапаридзе, И. Феолетов, Я. Зевин, И. Малыгин, М. Везиров, Г. Корганов, А. Әмирян, С. Осепян, В. Полухин, Г. Петров, М. Басин, А. Костандян, И. Габышев, Б. Авакян, А. Берг, Т. Әмиров, А. Борян, Ф. Солнцев, М. Коганов, А. Богданов, С. Богданов, И. Мишне, И. Метакса, В. Николайшвили. Бу үлмәс исемнәр каберлек ташларында гына түгел, миллионнарча совет кешеләре йөрәгендә язылганнар. Ә Баку исә аларның йөрәк тибешен әле дә тоеп тора сыман...

**«Якты урамнар буйлап атлап барам һәм бик ачык ишетәм мин, эшче Баку, синең күкрәгеңдә егерме алты йөрәк тибүен...»**

Хәзер менә истәлекләремнең шушы кисәген язып утырганда, Сөләйман Рәстәм шигыреннән әнә шул юллар искә килеп төште. Халык тойгысын тәгәл чагылдырган көчле образлы юллар алар.

Бакуда без күп урыннарда булдык, күп кенә очрашуларда катнаштык. Һәм аларның һәрберсе бездә бик тирән эз калдырды. Берьюлы меңнән артык эшче ял итә торган, яңа салынган, бик уңай, бик пөхтә, чиста ял йортында булу, андагы көр күңелле эшчеләр белән очрашу-сөйләшү... Шәһәрнең Иске Баку дигән өлешендә «Хан сарае», «Кызлар манарасы» кебек бик борынгы корылмаларны тамаша кылу, алар турындагы төрле легендаларны тыңлау... Электр яктылыгы белән балкып торган төнге Бакуны күзәтеп соклану... Әзербәйҗан культурасын, сәнгатен, аның үткән зур юлын чагылдырган тарихи музейда булу...

Тарих дигәч тә... Иң башта бина үзе ук тарих турында сөйләп тора икән. Монда, революциягә кадәр, халыкны изүче, талаучы Тагеев дигән зур бер сәүдәгәр типтереп яшәгән. Хәзер ул сәүдәгәр юк, ә бинасы халыкка хезмәт итә... Бу музейдагы күп бүлекләрдән безне кызыксындырганы — әзербәйҗан театрларының тарихы турында сөйләгән бүлек булды. Монда театр тарихы гыйльми нигездә өйрәнелә, тикшерелә. Аның туу һәм үсү юлын күрсәткән күп төрле рәсемнәр, афишалар, кульязма әсәрләр, документлр — бары да шунда тупланган. Патша цензурасы тарафыннан тыелган дистәләрчә элекке пьесалар белән дә шунда танышырга мөмкин. Мәшһүр драматург Мирза Фәтехгали Ахундовның да күп кенә әсәрләре, кульязмалары шунда саклана.

Әзербәйҗан драма театрының зур тарихы бар. Аның беренче спектакльләре 1873 елда ук уйналган. Хәзер ул совет шартларында нык адымнар белән үсеп бара. Үзләренең классиклары һәм бүгенге драматурглары әсәрләрен кую белән бергә,

анда Шекспир, Мольер, Гоголь, Горький кебек бөтен дөньяга мәгълүм әдипләрнең дә пьесаларын уңышлы куя ала торган көчле коллектив булып әверелгән ул...

Без революциядән соң гына оешкан һәм уңышлы эш алып барган төрек эшче театрында да булдык. Аның үткән юлы, бүгенге эше, иҗат методлары турында театрның мөдире Әфәндиевнең әтрафлы әңгәмәсен тыңладык. Ә безнең Кәрим ага Тинчурин татар театр сәнгате турында сөйләде...

Әзербәйҗанлы дуслар башта хатын-кызлардан сәхнә көчләре җитәрлек булмау «авыруын» да кичергәннәр икән. Һәм шунда безнең татар хатын-кызларының ярдәмгә килүләрен ихтирам белән телгә алалар. Мәсәлән, аларда инде бүген бу мәсьәлә нигездә хәл кылынган булса да, Әзербәйҗан академия драма театрында татар артисткасы Марзыя ханымның, төрек эшче театрында Фатыйма ханымның әле һаман да күренекле урыннарның берсен алып торуларын, тамашачыларның ихтирамын һәм мәхәббәтен казанган булуларын әйттеләр...



## 13. Салих Сәйдәшев тантанасы

Бакуда онытылмаслык истәлек калдырган тагын зур бер вакыйга булды. Ул — коммунальниклар клубының зур бакчасында, ачык һавада үткәрелгән кичә. Кичәгә ике меңгә якын тамашачы җыелган иде. Күпчелеге — татар эшчеләре. Мондый кичәләрдә, очрашуларда кунакларның урыны сәхнәдә була инде. Тагын әзербәйҗан язучылары, культура, сәнгать кешеләре, партия, совет, эшче оешмаларыннан вәкилләр. Хәтта Кызыл Армия вәкилләре дә бар иде. Кыскасы, сәхнә шыгрым тулы булды. Һәркайда бер-береңә шулай якын булу, янәшә утыру, бер-береңнең сулышын тою туганлык хисләрен көчәйтеп тора иде. Ә тагын да әһәмиятлерәге, кыйммәтрәге — сәхнә белән залның бердәмлегендә! Халыклар дуслыгы тантанасы күренешенең бик ачык чагылышы иде бит бу. Хуҗаларның да, безнең дә дустанә эчтәлекле чыгышларыбыз... Партиянең Әзербәйҗан Үзәк Комитеты исеменнән, нефтьче эшчеләр, Кызыл Армия сугышчылары һәм командирлары исеменнән котлаулар... Аннары — шигырь укулар... Безнең Такташ, Кутуй, Демьян Фәтхи үзләренең ялкынлы да, лирик та шигырьләре белән бу кичәдә аеруча әйбәт чыгыш ясадылар. Бигрәк тә Такташ! Әзербәйҗан шагыйрьләреннән Сөләйман Рөстәм чыгышы истә калган. Ул елларда Әзербәйҗанда әле яңа туып килә торган яшь совет поэзиясенең иң актив һәм үсеп килә торган талантларыннан берсе иде ул. Алар Такташ белән нычектер бик тиз дуслашып киттеләр. Характерлары белән бер-беренә охшаганга күрәдер: икесе дә поэзиягә, кешеләргә, тормышка гашыйк, үзләре бик мөлаем һәм садә, кешеләр белән бик тиз танышучан һәм якыннан аралашучан иде алар.

Мин башта ук бу кичәне зур вакыйгага дип атаган идем. Чынлыкта ул нәкъ шулай булды да. Аның шулай булуына, бүтәннәрдән тыш, безнең Салих Сәйдәш тә сәбәпче булды.

Әйтергә онытканмын икән, Бакуга килеп төшү белән Салих үз стихиясенә чумып китте: музыка әһелләре белән аралашты. Бакуда, Әзербәйҗанда да аның исемен беләләр, лəкин нигездә ишетеп кенә беләләр, музыкасы-иҗаты белән тиешенчә таныш түгелләр икән. Ә татар совет музыкасы белән дә, Сәйдәш белән дә танышырга бик телиләр, бигрәк тә — шундый форсат чыгып торганда! Инициатива кай якта булгандыр, белмим, әмма Бакуга килүебезнең беренче көнендә үк Сәйдәш карамагына бер оркестр тапшырылуы мәгълүм булды. Ул көннәр буе шул оркестр белән репетицияләр үткәрде.

Җәй айлары бит, театр, концерт сезоннары әле башланмаган, барысы да җәйге ялда. Әнә шундый шартларда, әллә ни зур булмаса да, тулы бер симфоник оркестр составын җыйнап өлгерү — безнең кадерле хуҗаларыбызның гаҗәеп зур игътибарлылыгы, кунакчыллыгы билгесе иде.

Кичәнең әдәби өлеше тәмамлангач, без тамашачылар арасына күчеп утырдык. Сәхнә тулысынча оркестр белән Сәйдәшкә тапшырылды. Аның сәхнәгә килеп чыгып баш июе һәм, оркестрга борылып, дирижер таягын тоткан уң кулы күтәрелү белән залда дәррәү кул чабу башланды. Салихның күтәрелгән кулы тукталып калып, бераз

дәр вакыт шулай һавада хәрәкәтсез асылынып торды, концерт тиз генә башланып китә алмады. Шуннан Салих, кулын төшереп, тагын залга йөз белән борылды, катkaт баш иде һәм яңадан оркестрга таба борылып, тылсымлы чыбыгын күтәреп ишарә ясады, кул чабулар тына төшкәч, Салихның ике кулы да хәрәкәткә килде.

Башланды... «Зәңгәр шәл»дән, «Наемщиктан» арияләр, увертюралар, «Шарык балеты», «Кызыл Армия маршы». Әзербәйҗан композиторының (авторын хәтерләмим) «Яңалиф маршы» h. б.

Оркестрдагы төрле кораллардан чыккан сихри тавышлар һавада талпынып йөзә, әле бер урында туктап калгандай моң гына сузыла, скрипкалар, флейталар гына җырлыйлар, әле бөтен оркестр көче бергә кушылып, биекләргә, еракларга ашкынып куәтле яңгырый башлый, барабан скрипкалар тавышын күмеп китә... Әле музыка патшасы скрипкалар яңадан үзләренең сихерле көчләрен күрсәтәләр... Моңны яки куәтне, сагышны яки шатлыкны җырлаучы төрле музыкаль кораллар үз телләрендә әле бергә кушылып көйлиләр, сөйлиләр, әле алар үзара ызгышалар, тартышалар, көрәшәләр сыман...

Тамашачылар бик тиз әнә шундый музыкаль аһәңнәр ирегенә биреләләр: әле тып-тын булып утыралар, скрипка, флейта тавышлары белән катнаш алар бер-берсенең сулышларын да ишетәләр кебек, әле кинәт урыннарында тыныч кына утыра алмый башлыйлар, бер-беренә караналар, һавада агылып торган көчле музыка дулкыны арасыннан нәрсәнедер күрергә теләгәндәй, башларын күтәрәләр, әйе, музыканың көчле тәэсиренә бирелеп, һавада, үз тирәләрендә моңа кадәр күрелмәгән ниндидер гаҗәеп реаль бер нәрсәне эзләгәндәй итенәләр алар...

Кыскасы, ул кичәдә Салих Сәйдәш искиткеч зур уңышка иреште. Бу — безнең барыбызның да уртак шатлыгы иде. Икенче көнне газеталар бу кичә турында, аеруча Сәйдәш концерты турында бик күп мактау сүзләре язып чыктылар.

Ул елларда Салих Сәйдәшнең даны үзебездә киң тарала башлаган иде инде. Аның яңадан-яңа җырлары, маршлары, концертларда башкарыла, К. Тинчурин, Т. Гыйззәт пьесаларына язган музыкаль әсәрләре театр сәхнәләрендә яңгырый, халык аларны бик яратып тыңлый иде. Әмма ул елларда Татарстаннан тыш өлкә һәм республикаларда Сәйдәш исемен әле ишетеп кенә беләләр, ә аның музыкаль иҗаты белән таныш түгелләр иде дисәк тә ялгыш булмас. Чөнки, беренчедән, татар совет профессиональ музыкасының үзенең дә әле яңа гына туа башлаган чоры иде һәм безнең музыкаль күгебездә Салих Сәйдәш әлегә бердәнбер якты йолдыз булып яна иде. Икенчедән, ул чордагы тарихи объектив сәбәпләр аркасында, шушы якты йолдызыбызның иҗаты да киң тарала алмый иде, чөнки ул елларда әле безнең ил буйлап гастрольләрдә чыгып йөрерлек мөмкинлекләребез дә чикле иде. Радио техникасы да үзенең балалык чорын гына кичерә, аның да мөмкинлекләре бик чамалы иде. Ә телевидение турында әйтеп тә торасы юк, аның үзе түгел, исеме дә юк иде әле. Әнә шундый шартларда Сәйдәшнең Бакуда үткәргән бу симфоник концерты аның үзе өчен генә түгел, ә гомумән безнең татар совет профессиональ музыкасы тарихында күренекле бер вакыйга булып искә алынырга хаклы дип уйлыйм.

Кунак кадере өч көн диләр. Ә без Бакуда биш көн булдык. Әмма тагын шул кадәр булсак та, барыбер шундый ук кадерле кунак булып калыр идек — әзербәйҗанлы дусларыбыз белән шулай гаҗәеп тиз һәм бик якыннан танышып, үз кешеләр булып киттек без. Чөнки безнең дә сөйлисе сүзләребез күп булып чыкты, аларның да безгә сөйлиселәре, күрсәтәселәре иксез-чиксез иде. Ләкин, нишләмәк кирәк, аларның эчкерсез дуслыклары, кунакчыллыклары безне үзләренә нык бәйләп өлгергән булса да, безнең вакыт санаулы иде, безгә яңадан юлга чыгып китәргә кирәк иде һәм без 24 августта Грузиянең үзәк шәһәре Тифлиска юл тоттык [1].

Карт большевик Хәсән Ризван (1917 елдан партия члены) ул елларда партиянең Баку шәһәр Комитеты аппаратында эшли иде. Бакуда экскурсиябезнең уңышлы үтүендә аның да ярдәме зур булды.

---

[1] Безнең делегация составы тагын бер кешегә кимеде. Зариф Бәшири, сәяхәтен артык дәвам итә алмыйча, Бакуда бездән аерылып калды.

## 14. Грузин дуслар янында

Менә без — Тифлиста (хәзер ул Тбилиси дип йөртелә). Моңарчы беребезгә дә таныш булмаган бу шәһәргә без 25 августта иртәнге сәгать сигездә килеп төштек. Каршы алулар бик тантаналы булды. Газеталар безнең килүебез турында алдан ук хәбәр итеп куйганнар. Поездыбыз килеп туктауга көчле оркестр яңгырады. Каршы алучылар белән шыгрым тулы вокзал безне сәламләү транспарантлары белән бизәлгән иде. Безнең делегацияне Грузиянең әдипләре, матбугат һәм җәмәгатьчелек вәкилләре әнә шулай бик җылы каршы алдылар, ике арада якынлык, дуслык шулай бик тиз урнашты. Шунда ук, вокзалның кабул итү бүлмәсендә, митинг үткәрелгәннән соң безне шәһәрнең иң бай һәм атаклы «Ориант» гостиницасына китереп урнаштырдылар.

Тбилиси — Грузиянең башкаласы. Бу союздаш республика, география дәреслекләреннән белүебезчә, Кавказ тауларының урта һәм көнбатыш өлешендә, мең метрдан артык биеклектә урнашкан. Хәер, моны без үз күзебез белән дә күреп торабыз инде. Пароходтан коры җиргә төшкәч тә, таулар иле Дагстаннан башланды мондый күренешләр. Бу тирәләрдә йөргәндә безгә һәр вакыт төрле биеклектәге, төрле формадагы таулар очрап тора. Шуларга карыйм да, бигтарак сокланып искә алган Ослан һәм Жигули таулары кабат күз алдыма килеп басалар. Кызыклы хәл! Болар бит инде бер-берсе белән һич чагыштырмалы түгел. Түбәләре күккә тигән мәһабәт Кавказ таулары, мәңгелек карлы-бозлы таулар, үзләре турында гаҗәп әкиятләр һәм легендалар тудырган таулар бит болар... Кешеләргә зур игелек күрсәткән — тереклек уты алып биргән Прометей да, явыз аллалар тарафыннан җәзаланып, нәкъ менә шушы Кавказ тауларына кадаклап куелган, дип сөйли бик мәшһүр легенда! Аннары, безгә бик якын Пушкин һәм Лермонтовлар, Толстой һәм Горькийлар да сокланып-горурланып җырлаган таулар бит болар. Шулай ук хәзерге әдәбиятта да җырлану-тасвирланудан төшеп калмый торган таулар!

Әйе, шулай. Әмма... һәркайсы үз урынында матур бит, дип куанам мин. Без йөргән бу илләрне Кавказ таулары ничек бизәп торса, Идел буенда гомум ландшафтта бик ятышлы Жигули таулары да безнең якларны шулай гаҗәеп матур итеп бизәп торалар бит! Без монда Кавказлы, Эльбруслы, Казбеклы якларга сокланган кебек, биредән безнең тарафларга килгән кавказлылар да шулай ук Осланлы, Жигулилы Идел буйларының матурлыгына сокланып туя алмыйлар лабаса. Ә Иделнең әдәбиятта тоткан урыны Кавказга һич тә бирешмидер, мөгаен! Моңа дәлил итеп мин, әлбәттә, беренче чиратта Максим Горький иҗатын күз алдымда тотам.

Беркемгә дә сер түгел, тарихта билгеле: элек патша Россиясе халыклар арасында дуслыкны булдырмау, аларны бер-береннән аеру, алай гына да түгел, берберсе белән дошманлаштыру политикасын алып барды. Кавказ халыклары арасында шундый политика үзенең фаҗигале нәтиҗәләрен күрсәтә килүе дә мәгълүм. Мәсәлән, 1905 елның февралендә патша хөкүмәте Бакуда әзербәйҗанлылар белән әрмәннәр арасында кан коюлы суеш-кырылыш оештырды. Халыкларның алдынгы прогрессив вәкилләре бу хурлыклы хәл алдында дәшми кала алмадылар. Мәсәлән, «Баку» исемле газета работниклары Кавказ халыкларының якын дусты булып танылган Максим Горькийга мөрәҗәгать иттеләр һәм ул, бу турыда ишетүгә, «Кавказ вакыйгалары турында» дигән мәкаләсе белән бөтен дөньяга чаң какты, хезмәт халыклары арасында шундый канлы кырылыш оештыручыларны фаш итте, хурлык баганасына сөяде.

Бу мәкаләсендә ул башта Грузияне, аның мәһабәт, бай табигатен, аның кешеләрен бик тә яратуы турында яза, аннары болай ди: «Кавказда булган чагымда грузин белән татарның (әзербәйҗанлының — Г. И.) һәм әрмәннең ничек дусларча янәшә торып эшләгәннәрен, ничек балаларча күңелле һәм саф җырлауларын һәм көлүләрен мин һәркайда күрә идем һәм менә шул гади һәм гаҗәеп әйбәт кешеләрнең хәзер, явыз кара көчләрнең котыртуларына бирелеп, тупас һәм мәгънәсез рәвештә бер-берен кыйнауларына ышану миңа шулчаклы кыен...

...Якты акыллары булган барлык кешеләр, коллыкка бирелмәүче барлык ихтыярлы кешеләр, барыбызны да бердәй каты изүче явыз һәм мәгънәсез көчкә каршы көрәшү өчен бердәм семья булып берләшергә тиешләр.

Безнең барыбызның да дошманыбыз — бер.

Безнең бөтенебез арасында тигезлек һәм туганлык булсын. Безнең барыбызны да ачык акыл көче яктыртсын, барыбыз да бөек һәм җиңелмәс ихтыярлы көч булып берләшик һәм шул чагында — азатлык!»

Максим Горькийның тирән дулкынланып укыла торган, шартлагыч динамиттай көчле булган бу мәкаләсе үз заманында патша цензурасы тарафыннан тыелган булган. Тик аның кайбер кисәкләре генә шул елны «Баку» газетасында басылып чыга алган. Ә тулы килеш ул 1905 елда Швейцариядә, Женева шәһәрендә аерым брошюра булып басылып чыккан һәм бөтен дөньяга куәтле набат булып яңгыраган.

Октябрь революциясе барлык халыкларга, шул исәптән Кавказ халыкларына да, чын азатлык та, үзара туганнарча дуслык та китерде. Һәм менә 1922 елда, большевиклар партиясе инициативасы белән, Бакуда Грузия, Әзербәйҗан һәм Әрмәнстан Советларының берләштерелгән беренче съезды чакырыла. Шунда бер тавыштан Закавказье Федерациясе оештырыла һәм аның үзәге итеп Грузиянең башкаласы Тифлис билгеләнә. Бу федерация грузин, әзербәйҗан, әрмән халыкларының үзара дуслыгын, туганнарча хезмәттәшлеген тагын да ныгыту-үстерү юлында куәтле чара була, пролетариат диктатурасын ныгыту, ленинчыл милли политиканы уңышлы тормышка ашыруга хезмәт итә...

...Әйе, федерациягә берләшкән Кавказ арты халыклары, үз юлларындагы барлык киртәләрне җимереп, упкыннарны кичеп, үзара дуслыкны һаман ныгыта барып, Ленин партиясе җитәкчелегендә зур җиңүләргә ирештеләр.

Узган ул еллар гомумән барлык илебезнең экономика, культура өлкәләрендә яңа югары баскычларга күтәрелү еллары булды. 1936 нчы елны хәтерлик. Ул елны социалистик җәмгыятебезнең һәр яклап үсү-камилләшүен үзендә чагылдырган тарихи яңа Конституция кабул ителде. Нәкъ менә шул Конституция нигезендә Грузия, Әзербәйҗан, Әрмәнстан республикалары да, һәркайсы мөстәкыйль союздаш республика булып, СССР составына керделәр. Шулай итеп, үз алдына куелган төп бурычны, үзенең гаять зур тарихи ролен бик яхшы үтәп чыккан ЗСФСР да бетерелде. Әмма ул халыклар күңелендә, йөрәгендә яхшы, якты истәлек булып калды.

Ә без анда булган елларны ЗСФСР, үзендә гаҗәеп көч туплап, әле яши, эшли, төрле упкыннар аша җимерелмәс дуслык күперләре салып, ленинчыл милли политиканы практик рәвештә тормышка ашыру үрнәкләрен бөтен илебезгә, бөтен дөньяга күрсәтеп тора иде...

Тифлис. Монда без барыбыз да беренче тапкыр аяк басабыз бит. Күзләрне зур ачып, туймастай булып, тирә-якны күзәтәбез, өйрәнәбез. Өч яктан таулар белән чолганып алынган чокырлыкта утырган. Шәһәрне уртага ярып Кура елгасы ага. Халкы кебек үк, бик борынгы шәһәр. Аннары Горький исеме белән, аның әдәби биографиясе белән бик нык бәйле шәһәр булуы белән дә дан тота ул. 1891 елда үк, әле язучы Горький түгел, ә яшь егет Алеша Пешков чагында, Россия буйлап беренче зур сәяхәткә чыгып китә. Нижний Новгородтан башлап, Идел аша, Дон далаларын, Украина, Бессарабия, Кырым җирләрен җәяүләп үтеп, шушы Тифлиска килеп чыга. Тимер юл мастерскоена эшкә урнаша. Монда ул үзенә бик якын дуслар таба. Грузиянә, аның халкын, табигатен бик ярата ул. Тормышының Тифлистагы чоры, әйтергә кирәк, булачак язучының революцион карашларын формалаштыруга ярдәм итә. Грузия халкының алдынгы вәкилләре белән, монда булган рус революционерлары белән аралаша, якыннан таныша. Казанда, Красновидовода башлаган пропаганда эшен дәвам иттерә. Шунда ук әдәбият белән тирәнтен кызыксынып, үзенең дә каләм көчен сынап карарга була. Яза башлый, күн-төн эшли, күп яза... Шул язганнарыннан «Макар Чудра» исемле хикәясе шушы Тифлистагы «Кавказ» газетасында басылып чыга. Шулай итеп, Максим Горькийның иҗади биографиясе шул көннән — 1892 ел, 12 сентябрь көненнән һәм нәкъ менә шул урыннан — Тифлистан, Кавказдан башланып китә. Алексей Пешков, Максим Горькийга әверелеп, әдәбият мәйданында үзенең искиткеч данлы юлын шуннан башлап җибәрә.

...Гаҗәеп нык тәэсир итүчән бай табигатьле ил ул Грузия. Сулап туймаслык саф һава, кояшның явын алып, кояшта балкып торган төрле субтропик үсемлекләр, таулар һәм тарлавыклар, елгалар һәм бозлавыклар, гаҗәеп шифалы бик күп чишмәләр.

Без «Боржоми», «Цхалтубо» кебек бик популяр булган унлап кына чишмәләрен

беләбез бугай, ә алар Грузия җирендә меңнән артык санала икән! Аеруча аның Кара диңгез буе курортлар ягы буларак дан тота. Гагра, Сухуми, Гудаута, Пицунда, Яңа Афон... санап китсәң күп инде алар.

**Кипарислар исе аңкып бәргәч,**
**Әллә ничек булды күңелгә...**
**...Һава, су да бу Кавказда,**
**Кояшы да башка үзенең,**
**Шул кояшта**
**бу да безнеке дип**
**Рәхәтләнеп ятып кызындым.**

Бу шигъри юллар — Муса Җәлилнеке. «Кавказ» исемле шигыреннән аның астына ул «1929 ел, 17 июль, Яңа Афон» дип язып куйган. Димәк, ул бездән бер ай гына элек биредә — Грузиядә булган, Яңа Афон санаториенда ял иткән, дәвәләнгән һәм үзенең алган тәэсоратларын иҗатында да шушылай чагылдырып калдырган.

Бу сәяхәтебездән соң күп еллар үткәч (илленче елларда), Грузиядә шул ук Яңа Афон санаториенда Габдрахман Әпсәләмовлар белән бергә булып, аннан озакка җитәрлек ял, савыгу алып кайттык без. Кояшында кызындык, диңгезендә коендык. Тирә-як табигатен, тарихи урыннарын өйрәндек һәм алар безнең күңелләрдә, блокнотларда урын алып калдылар.

Кызганычка каршы, әлеге беренче сәяхәтебез вакытында Грузиядә без нибары өч көн генә булдык. Әлеге дә баягы, маршрут зур, вакыт аз иде. Әмма шул кыска вакыт эчендә дә Грузия җәмәгатьчелегенең, партия һәм хөкүмәт вәкилләренең, әдипләренең татар язучылары килүгә зур бәйрәм төсе биргәнлекләрен адым саен сизә тордык. Тантаналы утырышлар, дусларча әңгәмәләр, Грузиянең экономикасы, халкының тормышы, әдәбияты, сәнгате белән танышу, культура учакларында булу һәм тагын — төрле урыннарда котылгысыз банкетлар...

Менә без Орджоникидзе исемендәге клубта. Монда безне тимер юл эшчеләре бик җылы каршы алды. Үзара котлаулар, сәламнәр, әңгәмәләр, әдәби-музыкаль чыгышлар. Менә трибунага бер-бер артлы Тавтавидзе, Лордкипанидзе, Имрешвили, Вартанов иптәшләр күтәрелә. Алар язучылар җәмәгатьчелеге, завод һәм депо эшчеләре исеменнән Татарстан кунакларын котлыйлар. Җавап итеп Гомәр Гали, Гадел Кутуй чыгып сөйләделәр. Шунда ике арада бик җылы дуслык, туганлык урнашып китте. Безгә һәркайда уртак тел — бөек рус теле ярдәм итә. Югыйсә, без грузинча, алар татарча белмиләр бит. Хәер, без үз телләребездә дә аңлаша алдык бугай. Кутуй үз шигырьләрен татарча да, русча да укыды. Такташ шигырьләренең тәрҗемәсе юк иде — ул үз ана телендә укыды. Ә зал тып-тын булып тыңлады. Грузин шагыйрьләренең үз телләрендә ясаган чыгышларын шулай ук без дә аңладык дисәк, бик арттырып әйтү булыр инде. Ә менә грузин музыкасын һәм җырларын аңладык без, ләззәтләнеп тыңладык. Монысы бу кичәдә түгел, ә бүтән вакыт, бүтән урында булды. (Консерватория бинасында булды бугай — тәгаен хәтерләмим дә инде.) Гаҗәп концертта булдык без. Тагын нәрсә дип әйтергә? Сокланып, яратып тыңладык, бик канәгать булып калдык, чын күңелдән рәхмәт әйтеп, һәр номерны алкышлар белән озатып тордык. Хәзер ул концерттан алган әнә шундый гомуми тәэсир генә саклана. Башкаручыларның исемнәре дә, репертуарлары да инде хәтердә калмаган булуына карамастан, бүген дә әйтә алам: артист һәм артисткаларның гаҗәеп моңлы тавышлары, җырлау осталыклары безне тәмам әсир иткән, тыңлап туймаслык булган иде! Әле һаман радиодан грузин көйләрен ишетергә туры килгән саен шул концерт искә төшә, әледән-әле алкышлар дулкыны тулып китә торган матур зал күз алдына килеп баса һәм шундагы моң колакларда яңгырап тора сыман (хәтерем алдамаса, ул концерт безнең өчен махсус оештырылган иде бугай).

Язучыларның махсус үз йортларында да кунак булдык без. Сокландык та, көнләштек тә: эш-иҗат бүлмәләре, тамаша залы, бай китапханә — бары да бар. Язучыларның Мәскәүдәге Герцен йортыннан бер дә ким түгел.

Грузиянең үз кинофабрикасы да бар — «Госкинпрогрузия». Һәм ул кечкенә дә түгел икән. Безне шунда да алып бардылар. Аның производство базасы да, иҗади

көчләре дә мактанырлык. Нәфис һәм документаль фильмнарны бер-бер артлы чыгарып кына торалар.

Бик күп урыннар белән танышу, вакыт кыскалыктан, өстән-өстән генә булды, сөйләшүләр аша гына булды. Чал тарихлы Тифлис хәзер зур промышленность һәм бай культура үзәге. Анда яшәп-эшләп килә торган культура-мәгариф учаклары бик күп: дәүләт университеты, дәүләт консерваториясе, художество академиясе, опера һәм балет театры, театрлар музее, революция музее... Аларның һәркайсында да була алмадык, әлбәттә. Шулай да хуҗалар безне иң мөһим урыннар белән таныштырырга тырыштылар, йөрттеләр, сөйләделәр, аңлаттылар.

# 15. Грузин халкының корифейлары

Без кая гына бармыйк, кайда гына булмыйк, кайтканда гел Руставели проспектына килеп чыгабыз. Без урнашкан гостиница шунда, Тифлис үзәгендәге иң матур урамда. Шота Руставели! Бу исемгә тәмам күнегеп, аның белән үзләшеп беттек. Шуңа күрәдер инде, без көне буе ал-ялны белмичә күп йөрсәк тә, бу урамга килеп керү белән ару-талуны онытабыз, безне рухландыра торган поэзия кочагында тирбәлә башлыйбыз сыман.

Шота Руставели!

Грузин әдәбияты, аның тарихы, аның культурасы шушы бөек исемнән башка була алмый. Грузин дуслар да безне үзләренең әдәбияты, аның тарихы белән таныштырганда, беренче итеп шул исемне телгә алалар иде.

Руставели — грузин халкының 12 гасырда яшәгән һәм иҗат иткән мәшһүр шагыйре, «Юлбарыс тиресе ябынган баһадир» исемле атаклы поэма авторы ул. Бу поэма, мәгълүм булганча, грузин әдәбияты тарихында үзенә аерым бер урын алып тора. Башка халыклар әдипләренең урта гасырда иҗат иткән әсәрләреннән аермалы буларак, бу поэмада дини карашлар, схоластика дигән нәрсә бөтенләй юк. Поэма кешегә, мәхәббәткә, дуслыкка мәдхия җырлый. Гаделлекнең башбаштаклыкны җиңүе идеясе, яхшылыкның явызлыкны җиңүе идеясе, патриотизм хисләре идеясе — поэманың нигезен әнә шулар тәшкил итә. Үзара бик дус булган төрле милләт вәкилләре — Тариэл (индияле), Автандил (гарәп), Придон (мулгазарлы) исемле намуслы, турылыклы баһадирларның фидакарь көрәшләре, ниһаять, зур җиңү белән тәмамлана. Батырлыкны Руставели гаделсезлеккә каршы көрәштә генә күрә, шулай дип кенә аңлый һәм аңлата. Гаделлек белән гаделсезлек арасында, яхшылык белән явызлык арасында бара торган көрәштә, ахыр чиктә, җиңү гаделлек, яхшылык ягында була, дип күрсәтә ул үзенең поэмасында. Руставели фикеренчә, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләрендә төп мораль принциплар — дуслык һәм мәхәббәт. Мәхәббәтнең мистик мәгънәсен дә кире кага ул һәм аны җенси хисләр телэгенә генә кайтарып калдыручыларны да тәнкыйтьли. «Йөрәк, акыл, аң бердәмлеге» генә зирәклекнең иң югары күренеше була ала, ди ул.

Поэзия әсәре буларак бу поэма — осталыкның югары үрнәге булып санала. Ул грузин телендә кырык тапкырдан артык басылган, Советлар Союзындагы барлык халыклар телләренә диярлек тәрҗемә ителгән, Европа, Азия халыкларының күбесе теленә тәрҗемә ителеп кат-кат басылган, бөтен дөнья культура тарихында күренекле урын алып торган мәшһүр әсәр ул. Аерым кисәкләре безнең татар теленә дә тәрҗемә ителеп басылып чыкты.

Грузин әдәбияты турында сөйләүне бөек Руставелидән башлаганбыз икән, инде аңардан борынгыга таба да, аңардан соңгы чорларга һәм бүгенгегә таба да азрак сызык сызып үтәргә кирәктер бит.

Борынгысы хәтсез еракларга алып китә безне. Җыр, легенда, эпос, әкият һ. б. — грузин халкының бу төр әдәбияты безнең эрага кадәр үк булган икән. Бер генә мисал. Амирани дигән исем сезгә танышмы? Юк? Әйе, моңарчы безгә дә таныш түгел иде ул. Хәзер менә, әйдәгез, бергәләп танышыйк. Амирани — кояш улы дигән сүз икән ул. Бик борынгыдан килгән грузин халык эпосының герое. Ул изелгән халыкларны төрле дию-парилэр, аждаһалар кебек явыз көчләрдән азат итә, кеше-

ләрне ут булдырырга, металл эшкәртергә өйрәтә, күктәге «изгеләр» белән көрәшә. Бу эшләре өчен алла аны каты җәзалый һәм Кавказ таулары кыясына чылбырлап куя... Бу эпос безнең эрага кадәрге икенче гасыр урталарында иҗ.эт ителгән. Борынгы грек язучыларының әйтүләренә караганда, аллаларга каршы көрәшүче бу Амирани турындагы миф Грузиядә безнең эрага кадәрге 5—4 нче гасырлардан бирле яшәп килгән, Грузиядән Борынгы Грециягә дә күчкән һәм Прометей турындагы миф белән бергә кушылып киткән.

Бу эпосның басылып чыккан 120 варианты бар (аерым өзекләрен русчага Николай Тихонов тәрҗемә иткән)...

...Чал тарихлы, бай тарихлы әдәбият үзенең шундый традицияләрен, шундый дәрәҗәсен югалтмыйча, шуннан соң да, бүгенгә кадәр дә дәвам иттереп килә.

Грузиянең Руставели, Гурамишвили, Чавчавадзе, Пшавела, Церетели иле дип тә йөртелүе турында еш кына ишетергә дә, укырга да туры килә. Чөнки бу мәшһүр исемнәр үз иҗатларында грузин халкының тарихын, тормышын, азатлык өчен көрәшен, рухи дөньясын күрсәтеп-ачып бирүче буларак, халыкның даны һәм горурлыгы булып танылганнар...

Без булган елларда көчле әдәби төркемнәрдән саналган, академик дип аталган өлкән язучылар (девизлары — «сәнгать — сәнгать өчен!») белән дә, пролетариат язучылары белән дә, «Сул фронт» исеменә берләшкән яшь язучылар белән дә очрашырга, сөйләшергә, бәхәсләшергә туры килде безгә.

Без килүдән өч ел элек (1926 елда) грузин язучыларының I съезды булып үткән икән. Ул республикадагы әдәби көчләрне берләштерүдә зур роль уйнаган. Съездда барлык әдәби төркемнәр дә үзләренең социалистик төзелештә актив катнашырга теләкләрен белдергәннәр. Т. Табидзе, Г. Леонидзе, И. Абашидзе, К. Лордкипанидзе, Г. Дадиани, Б. Жгенти — ул елларда актив эшләүче яшь шагыйрьләр, прозаиклар, драматурглар, тәнкыйтьчеләр иде.

Мин, ничектер, барыннан да бигрәк Бесо Жгентины ачыграк хәтерлим. Озынчарак буйлы, туры, ябык гәүдәле, ап-ак йөзле, кыска, сыек аксыл чәчле, бик хәрәкәтчән сылу яшь егет иде ул. Гел безнең белән бергә була, сөйли, таныштыра, аңлата. Бигрәк тә Такташ белән дуслашып киткән иде алар. Еш кына, янәшә атлап, кәләшаяра сөйләшеп йөргәннәре әле дә күз алдыма килеп баса. (Берьюлы әйтеп китим: хәзер Бесо Жгенти — югары белемле күренекле тәнкыйтьче, әдәбият белгече, зур әсәрләр авторы, Язучылар союзы җитәкчеләреннән берсе.)

Грузиянең Главискусство башлыгы Алэвидзе, партия комитетының матбугат бүлеге мөдире Татулов, агитпропаганда бүлеге мөдире Бюль һәм, әлбәттә, Бесо Жгенти иптәшләр безне грузин халкының әдәбияты, сәнгате белән таныштыралар, без, аларга ияреп, музейларга, картина галереяларына барабыз, шәһәрне карап йөрибез.

Менә без Грузия революция музеенда. Узган гасырда чыккан революцион газета-журналлар, тарихи кызыл байраклар, атаклы революционерларның рәсемнәре... һәркайсы турында тулы, ачык аңлатмалар... Музей үзәгендә — бик җыйнак һәм энтәлекле итеп эшләнгән Ленин почмагы... 1905 ел революциясенә багышланган аерым бүлек бар. Анда — пуляләр белән тишкәләнгән кызыл байраклар. Алар утлы-ялкынлы көрәш елларын күз алдына китереп бастыралар... Грузиядә авыр һәм катлаулы шартларда Октябрь таңы ату... Көрәшчеләрнең батырлыгы һәм дошманнарның явызлыгы... Меньшевиклар тарафыннан вәхшиләрчә газаплап, яндырып үтерелгән Мардәнишвили һәм Иванов иптәшләрнең рәсемнәре... Героик көрәш картинасын һәм җиңү тантанасын күрсәткән бай экспонатлар... Күп алар һәм һәркайсы көчле, тирән тәэсир итә... Музейга килүчеләр өзелеп тормый һәм аның тәрбияви көче зур икәнлеге күренеп тора.

Вакыт аз, көн программасы бик тыгыз. Күп җирдә буласы, күпне күрәсе бар. Атаклы картиналар галереясында да булмый ярамый. Ул — грузия халкының мактанычларыннан берсенә әверелеп бара икән. Бай. Төрле. Сокландыргыч. Грузин халкының классик һәм бүгенге яшь художникларының картиналары белән янәшә бүлмәләрдә Франция, Италия, Голландия, Бельгия, Иран һ. б. илләр художникларының оригиналь картиналары да бар. 1920 елда гына оештырылган булуына карамастан, галереяның фонды бик бай һәм экспонатлар яхшы зәвык белән урнаштырылганнар.

*Дәвамы бар*

# Н. Э. БАУМАН

*Туусына 100 ел тулуга карата*

Большевиклар партиясен төзү, патша самодержавиесен бәреп төшерү һәм пролетар революциясенең җиңүе өчен көрәшкән данлы кешеләр арасында якташыбыз, атаклы революционер Николай Эрнестович Бауман күренекле урын тота.

Бауман кебек революционерларның эшчәнлегенә бәя биреп В. И. Ленин: «Шундый кешеләр булмаганда рус халкы мәңгегә кол халык, холоп халык булып калыр иде. Мондый кешеләр булганда, рус халкы үзенә һәртөрле эксплуатациядән тулы азатлык яулап алыр»[1],— дип яза.

Н. Э. Бауман 1873 елның маенда слесарьлык мастерское хуҗасы гаиләсендә туа. Казан гимназиясендә уку чорында Бауман бик күп китаплар укый. Унөч-ундүрт яшьтә Ф. Купер, А. Дюма әсәрләре белән мавыга. Унбиш яшьтә аның иң яраткан геройлары Спартак һәм «Кигәвен» романыннан Артур була.

Шул елларда Бауман рус язучыларының революцион әсәрләре белән дә таныша. Халык бәхете өчен көрәшкән рус язучылары аңа Россия халыкларының чын тарихы, аларның изүчеләр белән көрәше турында сөйли. Бауманны Н. Г. Чернышевскийның «Нәрсә эшләргә!» романыннан Рахметов образы әсәруча нык дулкынландыра.

Бауманда революцион карашлар тәрбияләнүдә сиксәненче еллардагы иҗтимагый көрәш зур роль уйный. Бауман тыелган китаплар укый, А. Желябов, С. Перовская, В. Фигнерның биографияләре белән таныша. Ул А. Ульяновның батырларча үлемен нык кичерә. Аңарда дөньяга революцион караш формалашуда Казан студентларының 1687 елдагы сходкасының йогынтысы да зур була. Студентлар хәрәкәте җитәкчесе булган Владимир Ульяновның исемен Бауманның беренче мәртәбә нәкъ менә шушы вакытны ишеткән булуы ихтимал. Казандагы 1889 елны тар-мар ителгән беренче марксистик түгәрәкләрне оештырган Н. Е. Федосеев турында да аның ишетми калуы мөмкин түгел.

Бауманның тыелган китаплар укуы, кулъязма журнал чыгаруда катнашуы гимназия директорына мәгълүм була: укудан чыгарылу куркынычы туа. Ләкин 7 нче класс укучысы Н. Бауман гимназияне үзе ташлап китә һәм Казан ветеринария институтына укырга керә.

Бу елларда Бауман студент тормышы белән кайнап яши. Ул мохтаҗ кешеләргә ярдәм оештыра, легаль булмаган китапханәнең эшен көйләп җибәрә, марксистик әдәбиятны өйрәнә. 1892 елны Бауман, А. Стопани белән бергә, Казан эшчеләре арасында түгәрәкләр оештыра. Бу түгәрәкләрдә К. Маркс һәм Ф. Энгельс әсәрләре өйрәнелә.

1895 елда Бауман институтны «бик яхшы» билгеләренә тәмамлый. Саратов губернасында бер ел чамасы врач булып эшләгәннән соң, Бауман ул вакытта революцион хәрәкәтнең үзәге булган Петербургка килә. Әмма ул Казан революционерлары белән элемтәне беркайчан да өзми.

---

[1] В. И. Ленин. Әсәрләр. Т. 16. 371 бит.

Петербургта Бауман Ленин тарафыннан оештырылган «Эшче сыйныфын азат итү өчен көрәш союзы»на керә, Ленин әсәрләрен өйрәнә һәм аларны эшчеләр түгәрәкләрендә пропагандалау белән шөгыльләнә. Киң күңелле һәм аралашучан булганга, эшчеләр Николай Эрнестовичны үз итәләр, ә аның тирән җаваплары эшчеләрдә пропагандистка карата зур хөрмәт уята.

1897 елның мартында Бауман кулга алына һәм Петропавловск крепостена ябыла. 1899 елның декабрендә ул Вятка губернасының Орлов шәһәренә сөргенгә җибәрелә. Тормышының бу чоры аның Ленин экономистларга каршы юнәлтеп язган «Россия социал-демократларының протесты»на кул куюы белән әһәмиятле.

Сөргендә 9 ай чамасы булганнан соң, Бауман кача. 1900 елның җәендә Швейцариядә ул В. И. Ленин белән очраша һәм шул көннән алып тормышының соңгы минутына кадәр Бауман бөек юлбашчыга турылыклы булып кала.

Бауман Владимир Ильичка «Искра» газетасын чыгаруда булыша һәм газетаның актив таратучыларның берсе була.

1901 ел. Бауман Мәскәүдә революцион эш алып бара. Ул яңадан эшчеләр түгәрәкләрендә Ленин әсәрләрен пропагандалый, «Искра» газетасын тарата, «экономистлар», зубатовчыларны фаш итә. Бу вакытта ул «Искра»ны Казанга да еш җибәрә торган була [1].

1902 елның февралендә провокатор доносы буенча Бауманны кулга алалар һәм ул Киев төрмәсенә ябыла. Шул ук елның августында ул иптәшләре ярдәмендә төрмәдән кача. Бауман шунда ук РСДРП съездын хәзерләү эшенә кушыла һәм соңыннан съезд эшендә актив катнаша.

1903 елның декабреннан Н. Э. Бауман тагын Мәскәүдә эшли башлый. Ул эшчеләргә съезд турында, Ленин турында сөйли, аларны революциягә әзерли. 1904 елның июлендә Бауманны тагын кулга алалар. Тагын иксез-чиксез сорау алулар башлана. 1905 ел революциясе килеп җитә. Мәскәү эшчеләр сыйныфы таләбе буенча патша хөкүмәте революционерны азат итәргә мәҗбүр була.

Иреккә чыгу белән Бауман эшчеләр арасында революцион эш алып баруын дәвам итә. Ул большевикларның Мәскәү комитеты составына сайлана. Революционер җыелышларда һәм митингларда эшчеләрне кулга корал алырга чакыра.

1905 елның 18 октябрендә Мәскәү эшчеләре революционерларны азат итү өчен Таганка төрмәсенә юнәләләр. Кызыл байрак күтәргән Бауман алгы сафта атлый. Кинәт капкадан кача-поса карагруһчы йөгереп чыга һәм труба кисәге белән Бауманның башына суга. Бауман егыла. Кызыл байрак аның канына буяла.

20 октябрьда Мәскәүнең йөз меңгә якын эшчесе Бауманны соңгы юлга озата. Бауманның үлемен В. И. Ленин бик авыр кичерә. Аның истәлегенә багышлап язган мәкаләсендә Ленин бөек революционер-большевикның образы гасырлар буе яшәячәген әйтә.

**В. СКВОРЦОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

---

[1] Х. Хәсәнов. «В. И. Ленин һәм Казан большевиклар оешмасы». «Татарстан коммунисты». 1969 ел. № 10.

Фаил Шәфигуллин

# КЫЧЫТКАН ЧЫПЧЫГЫ

Хикәя



Вәкил безнең цехта дежур слесарь булып эшли. Үзе болай күркәм егет. Киң җилкәле, табак битле, җәлпәк борынлы, кысыграк күзле. Өсте-башы да чиста гына. Хатыннарына баш биреп торган ирләрне яратмый инде үзе. Әгәр дә мәгәр берәү, хатынның туган көне, фәлән дигән сүз ычкындырса — бетте, җен ачулары чыга Вәкилнең. Кеше түгел сез, чүпрәк, ди. Сезгә яулык бәйләтәсе калган, ди, хатыншалар, ди. Хатынны аны менә болай учта гына кысып тотарга кирәк, күзеңә карап торсын хатының, ди. Ничу хатын кубызына биеп торырга, ди. Һәм, әлбәттә, хатыннарны ай саен бер тотып тукмамасаң, аларның эченә шайтан оялый икән дип, көлеп алырга да онытмый. Шуңа күрә арабызда Вәкил барында хәләл җефетләребезне искә төшермәскә тырышабыз.

Бер вакытны, ниндидер бәйрәм алдыннан бугай, Вәкилгә заводтан суыткыч бирделәр. Шуны илтешергә мин дә бардым.

Биш катлы йортның бишенче катына мендек. Вәкил звонокка басты — тавыш-тын юк. Вәкилнең җилкә тамырлары бүртенеп чыкты, йөзе күгелҗем төскә керде.

— Кычыткан чыпчыгы,— ди бу теш арасыннан гына.

— Кем? — мин әйтәм.

— Хатын, әлбәттә,— ди Вәкил, тешләрен шыгырдатып.— Син йорт бөтәйсен дип чабасың, ә ул кайдадыр трай тибеп йөри. Ну, кайтсын гына... иманын укытам мин аның, җиде бабасына җитәм.

Ишекне запас ачкыч белән ачып, бүлмәгә кердек. Суыткычны утка тоташтырып эшләтеп карадык та, чишенеп, юынып, өстәл янына утырыштык.

Хатынының өйдә юклыгы исенә төште, ахры, Вәкил ялт итеп урыныннан сикереп торды.

— Туктале, Хәйдәр малай, мин тиз генә йомырка тәбәсе салып алыйм. Теге кычыткан чыпчыгы өйдә булса, итле токмач пешерер иде дә бит...

— Мәшәкатьләнмә, зинһар,— дидем мин. Китәргә әзерләнә башладым.

— Юк, юк, ниткән мәшәкать,— дип, җиңемнән тартып урыныма утыртты мине Вәкил.— Суыткычны бик әйбәтләп юмыйча булмый инде... Карале, Хәйдәр, алай-болай теге кычыткан чыпчыгы кайтып килсә, син бер дә дәшмә. Бик каты җурить итәм мин аны.

Вәкил карават астыннан бер шешә «Вермут» тартып чыгарды. Йомырка кыздырып алды. Берәр рюмка эчтек. Йомырка ашап, бер чынаяк чәй эчкәч, мин урынымнан кузгалдым.

— Утыр әле, утыр,— дип кыстап, тагын урыныма утыртты мине Вәкил.— Теге кычыткан чыпчыгына бер тамчы ризык калдырмыйбыз. Йөрмәсен эштән соң да төтен санап.

Йомырканы ашап бетергәч, Вәкил авыз чите белән генә елмайды һәм:

— Болары хатынга кучтәнәч,— дип, юылмаган савыт-сабаны өстәл читенә өеп куйды. Аннары суыткыч алып кергәндә пычранган идәнгә карады:

— Ярты төнгә кадәр ат урынына эшләтәм мин аны бүген.

Кызыл гына булса да, эчми эчкәч башка китте, каһәр. Буыннар йомшады, телләр көрмәкләнде. Инде мин дә кузгалырга ашыкмадым. Бераз тегене-моны сөйләшеп утырдык. Ә тагын бераздан Вәкил сәгатькә күтәрелеп карады. Җилкәсен кашып, озаклады бу, диде. Җыелышлары-фәләннәре булгандыр инде, дип өстәде.

— Туктале,— диде ул аннары, җәһәт кенә аяк өстенә басып,— кайтмаган кешене көтеп ятканчы, үзем чайкаштыргалап куйыйымчы шул савыт-сабаларны. Тәртипсезлекне җенем сөйми.

Кухня ягында савыт-сабалар шылтыратканнан соң, Вәкил, бер кулына бүрек кадәр мунчала, икенче кулына иске чиләк тотып, түр якка чыкты. Бер уңайдан идәнне дә сөртеп алыйм әле, бигрәк күңелсез бүлмә дип, телевизор кабызды һәм җиң сызганып идән юарга керешге. Идән юып бетергәч, авыз эченнән генә нииндидер көй шыңшып, бүлмә буйлап әрле-бирле йөрде. Үзе әледән-әле сәгатькә, тәрәзәләргә карады. Идән уртасында тукталып нәрсәдер тыңлап торгандай булды, ашыгып телевизорның тавышын басып куйды. Аннары минем янга килде. Өченче бер кешегә эндәшкәндәй, ничектер уңайсызланып кына, кыенсынып кына әйтте:

— Алайса, малай, кайтам, дисең инде?!.

Телевизорда футбол уены бара иде.

— Шуны гына карап бетерәм дә,— дидем мин, күзләремне экраннан алмыйча.

Мин, тапшыруны карап бетереп, бүлмәдән чыкканда Вәкил кухняда бәрәңге әрчеп утыра иде. Мине күргәч, пычагын бәрәңгеләр арасына тыкты, көләсе килмичә генә көлде һәм:

— Тик торганчы тиген эш, бәрәңге әрчеп куйыйм әле. Пешерүен кайткач үзе пешерер,— диде. Минем плитәгә таба карап торуымны

күреп булса кирәк, комачтай кызарынды, плитәдә бик каты пар бөркеп, ит, суган исләре чыгарып утырган кастрюльгә ымлап алды:

— Әнә су да куйдым, кайный торсын.

Ул да түгел, ишектә кыска гына, кискен генә звонок шалтырады. Вәкил корт чаккандай сикереп китте, абына-сөртенә ишеккә ташланды. Ишекне ачкач, бусагада шоп-шома, кып-кызыл йөзле хатын күренде. Менә ул ишек яңакларына ышкылып әчкә үтте. Мамык шәлен бөркет канатларыдай ике якка җәеп җибәрде дә:

— Әле боларны селкеп кермәгәнсең икән,— диде.

— Кычыткан чыпчыгы,— дип пышылдады Вәкил.

— Кем?— диде хатын сабыр гына һәм фил чаклы гәүдәсе белән Вәкил өстенә килә башлады.

— Син нәрсә, Бибинур, чү инде, син нәрсә,— дип, миңа ышыкланды Вәкил.— Җә инде, Бибинур дим, үзем кычыткан чыпчыгы мин, оныткканмын бит, җир йотсын, җәймәләрне селкеп керергә онытканмын!..

Ул арада мин дә киенеп беткән идем инде. Идән җәймәләрен кочаклаган Вәкил Бибинурның бер култык астыннан, мин — икенчесеннән коридорга чыгып тайдык.

Урамга чыккач, мин, тәмәке кабызырга дип, Вәкил янына килдем. Ул, бар көченә идән җәймәләрен селки-селки:

— Килмә монда, килмә, күрәсең ич тузан,— дип кычкырды. Без саубуллашмыйча гына аерылыштык. Чатка җитәрәк мин артыма әйләнеп карадым: бер кулына чиләк, икенче кулына нииндидер әрҗә күтәргән Вәкил урам буенча каядыр йөгерә иде.

## Идрис Туктар

# Җөмләләр

Урынлы горурлану — нурлану, урынсыз горурлану — хурлану.

* * *

Кайгы-хәсрәтләрен җиңеп яшәгән кешеләр генә көрлек-шатлыкларының кадерен беләләр.

* * *

Авыру — чакырылмаган кадерсез кунак кебек: килсә китә белми, китсә эзен калдыра.

* * *

Күпләргә охшамавың күпләргә ошамый.

* * *

Ил бәрәкәте — ашлыкта, ил һәлакәте — ачлыкта.

* * *

Карт ир өчен иң зур бәхет — яшь хатыны аны ташлап китүе.

* * *

Үзен тәнкыйтьтән югары хис иткән — тәнкыйтьтән түбән төшкән.

* * *

Бәрәкәтле хәрәкәттә — бәрәкәт.

* * *

Күзләренә күзе төшсә, йөрәк серләрен аңлый; бакса зифа буйларына, гүя матур җыр тыңлый.

## Вәли Булатов

# ҖӨМЛӘЛӘР

Энә күзләргә дә көн кирәк.

* * *

Әртилендә әрле-бирле,
Үз өендә түгәр тирне.

* * *

Турылыкны яклап сөйләсәң, түбән җанның түбәсеннән төтен чыгар.

* * *

Эштә пешмәсенең түреннән түрә төшмәс.

* * *

Белгән йолкынмас,
Надан юл куймас.

* * *

Олы язар: «Сәлам сиңа, сәлам җибәр».
Улы язар: «Сәлам. Миңа сәмән җибәр».

## Хәкимҗан Халиков

### Конструктор мин

Бер минут тик тормыйм:
Конструктор мин.
«ИЛ» кирәкме, «ТУ»мы...
Ни кушсагыз, шуны
Хәзер төзеп ташлыйм.
Я, кайсыннан башлыйм?

Бусы менә — «Восток»,
Бусы булыр — «Восход»,
Ә монысы — «Ал таң»,
Үзем уйлап тапкан
Яңа космик кораб...
Шул корабка карап
Әйтеп куйды Марат:
— Ә гизгәндә галәм
Әйтерсеңме сәлам?
— Ялгыз кая барам —
Үзегезне алам!
Әй, очарбыз җырлап,
Чынлап.

### Аш пешердем

Ялкау, имеш. Юк инде,
Яратсам да уенны,
Андый малай түгел мин!
Әни эштән кайтышка,
Аш пешердем бүген мин.

Әти тора шаккатып,
Әни телен шартлатып:
«Күр,— ди,— нишләп куйган бит!..»
Нишләгәнне белгән юк —
Ашым тозсыз булган бит?!

Тукта, малай, сабыр ит.
Тоз җитәрлек, аны бит
Салуын, дим, салырсың,
Артык китсә, анысын
Аштан ничек алырсың?

### Эссе көндә

Су илтим дип абыйга
Чыккан идем басуга,
Әлсерәшеп уҗымнар
Йөгерәләр каршыма.

Бер чәйнек су нәрсә ул —
Сибәргә соң кайсына?
Абый чәчкән уҗымнар —
Кызганыч бит барсы да.

Үз абыем ничек тә
Кичерер дип бер юлга,
Чәйнектәге бар суны
Сиптем шунда уҗымга.

Мичкә белән илтермен
Суны инде моннан соң:
Абыем да, уҗым да
Үпкәләрлек булмасын.
Шулай бит?

## Иң шатлыклы көнем

Яңгыр яуса ява бирсен —
Күк чалт аяз миңа бүген.
Минем кебек көләч йөзле
Гүя бөтен дөнья бүген...
Чалт аяз күк миңа бүген.

Мәктәптән дә, «5» алгандай,
Чаба-чаба кайттым бүген.
Галстукны ничә салым,
Ничә тапкыр тактым бүген!..
Өйгә кадәр чаптым бүген.

Белмим кая басканымны,
Бии-бии йөрим бүген.
— Әнием,— дим,— беләсеңме,
Иң шатлыклы көнем бүген:
Пионерга кердем бүген!

## Ак тавык

Бездә бар бер зур ак тавык,
Күркәдән дә зуррак тавык,
Чыпчыктан да коты чыга,
Юктыр андый куркак тавык.

Аптырыйм мин, әни нигә
Аңа чеби чыгарткандыр.
Әнә ничек өзгәләнә:
Чебиләрен урлаткандыр?

Чабып чыксам, исем китте:
Ала карга килгән икән.
Мескен тавык шуны күреп,
«Ярдәмгә кил!» дигән икән.

Тавык очып кунмасынмы
Шунда чеби карагына!
«Менә сиңа!» дигән кебек,
Канат белән яра гына.

Мин көч бирәм: шулай кирәк!
Менә сиңа тавык йөрәк?!

## Кучтәнәч

Гөлсемнәргә барышлый,
Әни алды морожный.
— Берсе,— диде,— үзеңә,
Икенчесе Гөлсемгә.

Морожный ул бал кебек,
Бер карыйсың — бар кебек,
Икенче кат карасаң —
Җилләр исә аңардан.
Кабып карыйм бер, тукта.
Каптым микән ике, өч...
Морожныем бетте ич?!

Әни әйтә: — Үзең дә...
Ни диярсең Гөлсемгә?..
— Әнием,—дим,— карале,
Савыты бит бар әле.
Ком тутырып уйнарга
Шуны бирәм мин аңа.

## Кояш суккан

Әллә нинди шушы Борһан,
Кара инде килешен.
Әнине дә тыңламый бит,
Гел сукалый киресен.

Әни әйтә: кояш сугар,
Ник ялан баш йөрисең?
— Ничек суксын, кулы юк ич,
Нигә юкны сөйлисең!

Малайлар да көтәләрдер
Мине футбол уйнарга,
— Әни, сау бул,— диде дә ул
Чыгып чапты урамга.

Очты малай, пружинадан
Киттемени ычкынып.
— Башыңа ки, башыңа!..— дип,
Әни калды кычкырып.

Кояш көлде, Борһан көлде,
Комда җырлап ятты ул.
Башын тотып егылгачтын
Үзе дә шаккатты ул:

— Кояш ничек сукты икән,
Куллары да юк аның?
Әни генә күрә микән
Әллә аның сукканын?..

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## КОМПОЗИТОРЛАР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Март аенда Казанда Идел буе, Урал, Себер автономияле республикалары композиторларының һәм музыка белгечләренең өченче фәнни-иҗат конференциясе булып узды.

Конференциягә килүчеләр арасында Башкортстан АССРдан З. Исмәгыйлов, Х. Әхметов, Бурят АССРдан Б. Ямпилов, Мари АССРдан А. Искәндәров, В. Куприянов, Чувашия АССРдан Ф. Лукин, Ю. Илюхин кебек күренекле композиторлар, музыка белгечләре бар иде.

Мәскәүдән РСФСР композиторлар союзы идарәсе секретаре, «Советская музыка» журналы редакторы Ю. Корев, Мәскәү консерваториясе кафедрасы мөдире, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, композитор А. Леман, СССР Дәүләт премиясе лауреаты, РСФСР композиторлар союзы идарәсе секретаре Б. Чайковский, КПСС Үзәк Комитетының культура бүлеге инструкторы Ю. Уткин килгән иде.

Конференциягә шулай ук Монголия, Венгрия, Корея Халык Демократик Республикасыннан да музыка белгечләре катнашты.

Кереш сүз белән Ю. Корев чыкты. Ул Казанда инде өченче мәртәбә үткәрелә торган музыка форумының музыка сәнгате өлкәсендә эшләүчеләр өчен зур әһәмияткә ия булганлыгын әйтте.

Конференциянең беренче көн программасы — симфоник концерт — бурят композиторы, РСФСРның һәм Бурят АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Б. Ямпиловның «Бәйрәм увертюрасы» белән башланды. Аннан соң күп санлы җырлар, романслар, опералар һәм «Кодача» исемле музыкаль комедия авторы, РСФСРның халык артисты З. Исмәгыйловның «Шәүрә» операсыннан өзекләр, мари композиторы А. Лупповның халык көйләреннән файдаланып язылган кларнет өчен концерты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе А. Монасыйповның герой-шагыйребез үлемсезлегенә дан җырлаучы «Җәлил» симфония-поэмасы башкарылды.

Концертның икенче бүлегендә тамашачылар РСФСРның һәм Чувашия АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе Ф. Васильевның «Сарпиге» балеты сюитасы һәм ТАССРның дәүләт симфоник оркестры башкаруында СССРның халык артисты, композитор Н. Җиһановның «Сабан туй» симфониясе белән таныштылар.

Конференциянең икенче көнендә көндез Казан консерваториясенең актлар залында вокаль һәм инструменталь әсәрләрдән камера концерты булды. Яңа җырлар, тынлы уен кораллары өчен квинтетлар, фортепьяно өчен поэмалар, романслар, скрипка һәм фортепьяно өчен соналалар яңгырады. Кичен М. Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театрында опера һәм балетлардан өзекләр күрсәтелде.

Конференциянең өченче көнендә дә консерваториянең актлар залында тугандаш халыклар һәм татар композиторларының камера музыкасы әсәрләреннән концерт бирелде, кич музыка сөючеләр төрле хор коллективларының чыгышларын тыңладылар.

19 мартта конференциянең пленар утырышы башланды.

Партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев илебез һәм чит ил кунакларын республикабызның экономика һәм культура үсеше белән таныштырды. «Хәзерге этапта Идел буе, Урал һәм Себер автономияле республикаларының музыка культурасы» дигән темага доклад белән СССР һәм РСФСР композиторлар союзы идарәсе секретаре Н. Җиһанов чыгыш ясады. Сәнгать фәннәре кандидаты Я. Гиршман милли музыкаларның бер-берсенә тәэсире, үзара якынаюы һәм баюы турында сөйләде.

Башкортстан композиторлар союзы идарәсе председателе, сәнгать институты ректоры З. Исмәгыйлов башкорт халкының музыка культурасы ирешкән уңышларга, музыка белгече Ю. Илюхин чуваш халкының профессиональ музыкасындагы яңалыкларга, музыка белгече О. Егорова мари халык җырларына, музыка фольклоры белгече М. Нигъмәтҗанов татар музыкасындагы кайбер үзенчәлекләргә тукталды. Б. Чайковский чыгышы халык көйләре белән композиторлар иҗаты арасындагы бәйләнешне яктыртуга багышланган иде.

Венгрия кунагы фольклорчы галим Л. Викар 15 елдан бирле Идел буе халыклары музыкасын өйрәнә. Ул Идел буе республикаларында йөреп, ике меңнән артык җыр язып алган. Чыгыш ясаганда венгр галименең бигрәк тә татар музыкасы белән кызыксынуы мәгълүм булды.

Кич конференциядә катнашучылар Казан консерваториясенең А. Тихонов җитәкчелегендәге халык музыка кораллары оркестры чыгышын тыңладылар.

Конференциянең соңгы көнендә Монголия Халык Республикасы композиторлар союзы идарәсе секретаре Цэрэндорж, Баш-

кортстан композиторы Х. Әхмәтов, якут музыкасы белгече Э. Алексеев (Мәскәү), Чувашия АССР композиторлар союзы идарәсе председателе Ф. Лукин, РСФСР композиторлар союзы идарәсе секретаре А. Леман, РСФСР композиторлар союзының Ростов бүлеге идарәсе председателе А. Артамонов, музыка белгече З. Сәйдәшева, Б. Ямпилов (Бурят АССР), Т. Эррэ (Чувашия АССР), Г. Әхмәтова (Уфа), Ю. Корев (Мәскәү) һәм башкалар үзләренең чыгышларында конференциядән алган тәэсирләре белән уртаклаштылар, мондый очрашуларның тугандаш халыклар музыкасы үсешенә ярдәме зур булачагын әйттеләр.

СССР һәм РСФСР композиторлар союзлары идарәләре секретаре Н. Җиһанов йомгаклау сүзе белән чыкты.

Соңыннан музыка белгечләре Венгрия галиме Л. Викар һәм Будапешт университеты профессоры Г. Берецки белән очрашып, фольклорга кагылышлы әһәмиятле мәсьәләләр турында сөйләштеләр.

## КҮП МИЛЛӘТЛЕ СОВЕТ ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ

Бу тарих СССР Фәннәр академиясенең А. М. Горький исемендәге Дөнья әдәбияты институты тарафыннан чыгарыла. Ул алты томга планлаштырылган. Аның дүрт томы инде басылып та чыкты.

Тарихның беренче томы гражданнар сугышы һәм егерменче еллардагы әдәбиятлар турында сөйли. Шул чордагы татар әдәбиятына багышланган бүлекне Г. Халит, утызынчы елларга багышланган (II том) бүлекне Н. Гыйззәтуллин, Б. Гыйззәт һәм Р. Башкуров язганнар. Бөек Ватан сугышы чорындагы татар әдәбияты турындагы бүлек (III том) Р. Башкуров һәм В. Воздвиженский тарафыннан, Бөек Ватан сугышыннан соңгы әдәбиятыбыз турындагы бүлекләр (IV том) Н. Гыйззәтуллин, Н. Юзиев һәм Б. Гыйззәт тарафыннан язылган.

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ ТАРИХЫ

СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре татар әдәбияты тарихының биш томлыгын яза башладылар. Бу житди һәм җаваплы хезмәттә галимнәргә башка фәнни-тикшеренү институтлары һәм югары уку йортларында эшләүче әдәбият белгечләре дә булыша.

Тарихның һәр томында һәрбер чорның социаль-политик үзенчәлекләре, әдәби процессның, әдәбият үсешенең төп этаплары һәм күренекле язучыларның иҗаты турында аерым бүлекләр булачак.

«Татар әдәбияты тарихы»ның биш томлыгын 1977 елга кадәр язып бетерү күздә тотыла.

## БӨЕК АРТИСТНЫ ИСКӘ АЛУ

В. И. Качалов исемендәге рус драма театрында зур тантана булды. Аны, бөек артист В. И. Качаловның тууына 75 ел тулуга багышлап, ТАССР Культура министрлыгы, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге һәм Зур драма театры үткәрде.

Кереш сүз белән Казан шәһәр Советы башкарма комитетының культура бүлеге мөдире Ш. Шәмсетдинова чыкты. Аннары Казан Зур драма театры баш режиссеры Н. Орлов, Бөтенроссия театр җәмгыятенең Татарстан бүлеге председателе, Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры директоры Р. Җиһаншина, шул ук театрның баш режиссеры М. Сәлимҗанов, Чабаксардан театр белгече Ф. Романова бөек артистның сәхнәдәге эшчәнлеге һәм театр тарихындагы урыны турында сөйләделәр.

Соңыннан В. Качалов тормышын һәм иҗатын чагылдырган мемориаль бүлмә ачу тантанасы булды.

* * *

Казанның Актерлар йортында В. Качалов истәлегенә багышлап уздырылган кичәдә театр җәмәгатьчелеге, партия, совет оешмаларыннан вәкилләр һәм күп санлы театр сөючеләр катнашты.

Сәнгать фәннәре кандидаты И. Илялова Казан драма театрында В. Качалов традицияләре турында доклад ясады.

Кичәдә РСФСРның халык артисты В. Давыдов, РСФСРның атказанган артистлары В. Монюков, В. Шверубович, В. Качалов исемендәге Зур драма театры артисты, ТАССРның атказанган культура эшлеклесе И. Ингвар чыгышлары аеруча тәэсирле булды.

Соңыннан тамашачылар В. Качалов турында документаль фильм карадылар.

## «ВОЛГА» ЖУРНАЛЫНДА — ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ

Моннан берничә ел элек Саратов шәһәрендә «Волга» исемле әдәби журнал чыга башлаган иде. Бу журналда Идел буе республикалары һәм өлкәләре әдипләренең яңа әсәрләре басыла.

Узган ел Ә. Баянов «Волга»да «Яшьлегемне эзлим» повесте белән катнашкан иде. Быел бу журнал битләрендә Ә. Баяновның һәм И. Юзеевның яңа шигырьләре, М. Әмирнең «Балыкчыялганнары» дигән юмористик повесте, Мәҗит Рафиковның (автор тәрҗемәсендә) «Ишгилде» исемле лирик повесте дөнья күрде.

## ИҖАТ СЕКЦИЯЛӘРЕНДӘ

Татарстан язучылар союзының проза секциясе шагыйрьләр һәм драматурглар, әдәбият белгечләре һәм тәнкыйтьчеләр катнашында «Герой, стиль, осталык (татар совет әдәбиятының кайбер мәсьәләләре)» дигән җыентык турында зур сөйләшү үткәрде. Язучыларны да, галимнәрне дә, әдәбият сөючеләрне дә кызыксындырган китап хакында фикер алышуда филология фән-

нәре кандидаты А. Әхмәдуллин, язучылардан Г. Бәширов, Ә. Еники, Г. Шәрәфетдинов һәм башкалар катнашты. СССР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре, аспирантлары иҗат иткән бу хезмәт нигездә уңышлы дип табылды. Партия Үзәк Комитетының «Әдәбият-сәнгать турында»гы карарында билгеләнгән бурычларны тормышка ашыру юлында күркәм бер адым, дип бәяләнде.

* * *

Шагыйрьләр секциясе утырышларының берсе яшь шагыйрь К. Сибгатуллин иҗатын тикшерүгә багышланган иде. К. Сибгатуллинның шигырьләре хакында кереш сүз белән Ш. Маннур чыкты.

Фикер алышуларда Х. Туфан, Ш. Галиев, Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Ә. Баянов, Н. Дәүли, Р. Харис һәм башкалар катнашты.

Утырыш К. Сибгатуллинны Язучылар союзы каршындагы шагыйрьләр секциясе исеменнән СССР Язучылар союзы членлыгына тәкъдим итәргә карар чыгарды.

* * *

«Казан утлары» журналы редакциясе каршындагы яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәгенең чираттагы утырышы булды. Бу юлы утырышта Р. Абдуллина, Р. Сәлимҗанов, Ф. Хәкимова, Б. Антонов кебек яшь әдипләрнең яңа китапларга язылган рецензияләре тикшерелде.

* * *

Яшь шагыйрь Ф. Сафинның шигырьләре шагыйрьләр секциясе утырышында тикшерелеп, кимчелекләрен бетерү өчен авторга кире кайтарылган иде.

Биш-алты айдан Ф. Сафин шигырьләре секция утырышында кабат тикшерелде. Докладчы Ә. Баянов яшь шагыйрьнең өлкән әдипләр киңәшен тотканлыгын, үз иҗатына таләпчән килгәнлеген, шигырьләр өстендә бик нык эшләгәнлеген һәм кульязманы аерым җыентык итеп чыгару өчен Татарстан китап нәшриятына тәкъдим итәргә мөмкин икәнлеген әйтте. Бу фикерне утырышта катнашучы Х. Туфан, Ә. Исхак, Зөлфәт, Ф. Шәфигуллин һәм башкалар яклады.

## ОЧРАШУЛАР, ӘДӘБИ КИЧӘЛӘР

Казан пединститутының студентлар тулай торагында «Казан утлары» журналына багышланган әдәби кичә үткәрелде. Журналның баш редакторы Г. Ахунов һәм бүлек мөдире В. Нуруллин студентларны редакциянең эш планы белән таныштырдылар, журналның алдагы саннарында басылачак яңа әсәрләр турында сөйләделәр. Очрашуда редколлегия члены, шагыйрь С. Хәким, авторлар Ф. Хатипов һәм Р. Свиригин катнашты.

Чыгып сөйләүче студентлардан В. Галимова, С. Сафиуллина, З. Сәитовлар журнал турында фикерләрен әйттеләр. Ә. Гилялова Г. Мөхәммәтшинның «Пәрәккәге эзләр» романын беренче мәртәбә «Казан утлары» журналыннан укуын һәм ул романның булачак педагоглар өчен аеруча файдалы әсәр икәнлеген искәртеп китте.

* * *

Язучылар Р. Гәрәй, М. Хәмитов, Т. Камалиев һәм Татарстанның атказанган артисты Ә. Яһудин Арча районының «Октябрь», «8 Март», «Свердлов», «Киров», Камил Якуб исемендәге колхозларында әдәби кичәләр үткәрделәр, мәктәп укучылары белән очраштылар.

Арча педагогия училищесындагы очрашу аеруча җанлы һәм кызыклы узды.

* * *

Прозаиклар М. Хәсәнов, Ш. Бикчурин, шагыйрь М. Әгъләмов һәм артист М. Шиһапов КамАЗ төзүче яшьләр тулай торакларында кызыл почмакларда әдәби очрашулар үткәреп, әдәбият сөючеләрне бүгенге татар әдәбияты белән таныштырдылар.

Шундый ук очрашулар Чаллы районының кайбер колхозларында да булды.

## «ЧАЯН»ГА 50 ЯШЬ

«Чаян» журналының чыга башлавына 50 ел тулу уңае белән Ленин исемендәге республика үзәк китапханәсендә журнал хезмәткәрләре һәм авторлары белән очрашу үткәрелде. Журналның баш редакторы А. Яхин җыелган халыкны «Чаян»ның кыскача тарихы, бүгенге эш планнары белән таныштырды, сорауларга җаваплар бирде. Соңыннан «Чаян» журналының әдәби хезмәткәре Зөлфәт, даими авторлары Ә. Исхак, Ш. Галиев, Н. Мадьяров үзләренең сатирик һәм юмористик әсәрләрен укыдылар.

* * *

Актерлар йортында «Чаян» журналы чыга башлауга 50 ел тулуга багышланган тантаналы җыелыш булды. Җыелышны Казан шәһәре партия комитеты секретаре А. Кадыйрова ачты.

КПСС өлкә комитеты исеменнән «Чаян» журналы редакциясен, аның авторларын, күп санлы укучыларын КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев котлады.

Журналның ярты гасырда узган юлы турында доклад белән «Чаян»ның баш редакторы А. Яхин чыкты.

Юбилярны шулай ук эшчеләр, колхозчылар, язучылар, художниклар, артистлар кайнар котладылар.

Тантаналы җыелышта кунаклардан «Крокодил» журналының баш редакторы М. Семенов, Украина сатирик журналы «Перец»ның баш редакторы урынбасары В. Чепига, Үзбәкстан сатирик журналы

«Муштум»ның җаваплы секретаре М. Парпиходжаев, Мари АССР сатирик журналы «Пачемыш»ның баш редакторы В. Столяров, Чувашия АССР сатирик журналы «Капкан»ның җаваплы секретаре В. Григорьев һәм башкалар чыгыш ясап, «Чаян» адресына бик күп җылы сүзләр әйттеләр, аңа истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

Соңыннан зур концерт булды.

* * *

Түбән өлкәсендә татар теле укытучылары семинары булды. Семинар эшенә Татарстаннан язучы Х. Сарьян белән музыка белгече М. Нигъмәтҗанов катнашты. Алар бүгенге татар әдәбияты һәм музыкасы турында докладлар сөйләделәр. Укытучыларга мәктәпләрдә татар теле һәм әдәбиятын, татар музыкасын укытуга кагылышлы конкрет киңәшләр бирделәр.

## ЮБИЛЕЙ УҢАЕ БЕЛӘН

Республика курчак театрына кырык ел тулу уңае белән театрны ачуда, оештыруда башлап йөрүчеләргә багышланган иҗат кичәсе үткәрелде.

ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклесе С. Хәсни, ТАССРның атказанган артистлары М. Хисамова, В. Третьякова, Б. Рычков, В. Гафаров, артистлар С. Вәлиуллина, Н. Кирилловларны тамашачылар кайнар котладылар. ТАССР Культура министры урынбасары Ю. Әминов театрны оештыруда зур өлеш керткән артистларга яңа иҗат уңышлары теләде.

Залда курчак театры тарихына караган стендлар, күргәзмәләр оештырылган иде.

Кичәнең икенче бүлегендә спектакльләрдән өзекләр күрсәтелде, концерт бирелде.

## 8 МАРТКА БАГЫШЛАП

Республика Художниклары йортында Татарстанда яшәүче хатын-кыз художникларның әсәрләреннән яңа күргәзмә оештырылган иде. Республикабыз тормышын чагылдырган йөзләрчә әсәрләрдән торган бу күргәзмә бик тиз көндә халык ихтирамын казанып өлгерде. Күргәзмәгә шәһәребезнең йөзләрчә хезмәт ияләре яратып һәм теләп йөрделәр.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

* * *

Әлмәт язучылары гомуми җыелышта Р. Төхфәтуллинның иҗат отчетын тыңладылар. Э. Касыймов язучының соңгы елларда дөнья күргән «Кыңгырау чәчәк» исемле җыентыгына һәм «Бер коштабак катык», «Бөтнек исе» кебек хикәяләренә анализ ясап, аларга уңай бәя бирде. Докладчы Р. Төхфәтуллинның «Акбүз ат» исемле яңа повестендагы уңай һәм кимчелекле сыйфатлар хакында сөйләде. Чыгыш ясаучылардан С. Кальметов, Г. Афзал, Ә. Маликов, М. Хәсәнов, Ю. Әминов, яшь язучы А. Ганиев әһәмиятле темага язылган бу әсәрне камилләштерү кирәклеген әйттеләр.

* * *

Бүлек утырышында яшь язучы А. Хәсәновның «Алкалы малай» исемле яңа повесте тикшерелде. Әсәр интернат балалары тормышыннан алып язылган, кызыклы вакыйгаларга бай, әмма әдәби эшләнеше ягыннан әлегә йомшаграк, диделәр чыгыш ясаучылар. Повестьны тикшерүдә катнашкан Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, Ю. Әминов, М. Хәсәнов, К. Булатова, яшь шагыйрь Р. Башаров иптәшләр авторга үз әсәрләренә карата таләпчәнлекне үстерергә киңәш бирделәр.

* * *

Әлмәттәге әдәбият-иҗат түгәрәгенең чираттагы утырышында яшь һәм башлап язучы шагыйрьләрдән Ф. Галиева, Р. Аскаров шигырьләре укып тикшерелде. Шагыйрә С. Сөләйманова түгәрәк членнарының чыгышларын йомгаклап, шигъри осталык мәсьәләләренә тукталды, әдәбиятыбыз алдында торган бурычлар турында сөйләде.

### «Агыйдел дулкыннары»

Актаныш районы газетасы «Игенче даны» редакциясе каршында әдәби берләшмә оештырылды. «Агыйдел дулкыннары» дип аталган бу берләшмәнең беренче утырышында поэзия, проза һәм пропаганда секцияләре төзелде, аларның җитәкчеләре сайланды.

Берләшмә районадагы башлап язучыларның яңа әсәрләрен укып-тикшерү һәм газетага тәкъдим итү максатын күздә тота.

**ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫБЫЗ!**

Журналыбызның сигезенче санында Шәйхи Маннурның «Агымсуларга карап» дигән повесте басыла башлый. Әхияр Хәкимовның «Очар кошлар» повесте да сезнең игътибарны җәлеп итәр.

Поэзия бүлеге шагыйрь Илдар Юзеевның «Таш диварлар авазы» дигән поэмасын тәкъдим итә.

Очерклар бүлеге тулысы белән диярлек КамАЗга багышлана. Анда сез «КамАЗ елъязмасы» белән танышырсыз. Мәдинә Маликованың «Чәчәкләргә бай тормыш» дигән очеркын укырсыз.

Әдәби тәнкыйть мәсьәләләренә Нил Юзиевның «Хәрәкәттәге эстетика — хәрәкәттә», Тәлгат Галиуллинның «Матурлыкка бай ул безнең заман...» дигән мәкаләләре багышлана. Истәлекләр, китап күзәтү, мәдәният тарихына материаллар, әдәбият-сәнгать яңалыклары биреләчәк.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210